ISSN 0206-4189
Индекс 73210

12+

# КАЗАН УТЛАРЫ

2.2013





**Фатих Сәйфи–Казанлы**
**(1888—1937)**

# Казан утлары
# Qazan utlari

2013

2
(1084)

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

татмедиа

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Айрат Сибагатуллин**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир — 562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары — 562-10-38.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге — 562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге — 562-11-53.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге — 562-11-53.*
*Гамәли хезмәткәрләр — 562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80.*
**Факс** — (843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*


## Бу санда


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Рашат НИЗАМИ. Мәңгелеккә килеп тоташам. *Шигырьләр.* ....... 5
Хисам КАМАЛОВ. Сугыштан кайткан сөю. *Кыйсса.* ....... 10
Клара БУЛАТОВА. Яшәүгә омтылыш шундый нык. *Шигырьләр.* ....... 41
БАТУЛЛА. Туган ягым – Зәй төбәге. *Хатирәләр.* ....... 45
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Ил кадерен белер – илсез калган. *Шигырь.* ....... 109

**«ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН»**

Хәсән САРЬЯН. Зәңгәр күл сагышы. ....... 113

**ТАРИХ**

Рәмзи ВӘЛИ. Халкына багышланган гомер. ....... 137

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Рәдиф ГАТАШ. Тансык һәм бай бу кәрван... ....... 147

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ....... 150
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ....... 153

**СӘНГАТЬ**

Әзһәр ШАКИР. Артист язмалары. ....... 156

**ХӘТЕР**

Нәкыя ГЫЙЛӘҖЕВА. Кар башына кар җитә... ....... 162
Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ. «Без бит бәхетсез заман җимеше». ....... 166
Рәзинә МӨХИЯРОВА. Корымас гөл. ....... 169

**ФӘНИС ЯРУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ**

Рафикъ ЮНЫС. Кояшка үрелгән егет. ....... 171

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Әминә БИКЧӘНТӘЕВАның тууына 100 ел, Риза ШӘФИнең тууына 90 ел, Хәкимҗан ХАЛИКОВның тууына 80 ел ....... 183

«Казан утлары» архивыннан. ....... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....... 190

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: повесть Х.КАМАЛОВА «Любовь, пришедшая с войны»; воспоминания БАТУЛЛЫ «Мой Заинский край» (нач.); рассказ Х.САРЬЯНА; стихи Р.НИЗАМИ, К.БУЛАТОВОЙ, Г.БАЙРАМОВОЙ.
«История»: статья Р.ВАЛИ «Жизнь, посвященная народу».
«Литературная критика»: рецензия Р.ГАТАША на книгу Ф.Замалетдиновой «Караван времени».
«Наука»: Ф.ГАРИПОВА. «История наших деревень».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Искусство»: А.ШАКИР. «Записи актера».
«Память»: статья Н.ГИЛЯЗОВОЙ, посвященная писателю А.Гилязову;
А.ГИЛЯЗОВ. «Мы — плоды несчастного времени»;
статья Р.МУХИЯРОВОЙ, посвященная Ф.Сафиуллиной.
«75 лет со дня рождения Фаниса Яруллина»: статья Р.ЮНУСА «Знаете, каким он парнем был!»
«Наши юбиляры»: в номере отмечается 100-летие А.БИКЧАНТАЕВОЙ; 90-летие Р.ШАФИ; 80-летие Х.ХАЛИКОВА.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Чай вдвоем. Писатель Фанис Яруллин и его жена Нурсия ханум». Картина Зуфара Гимаева; поэтесса Гульзада Байрамова.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: story by H.KAMALOV «Love arrived from war»; memories by BATULLA «My Zainsk area» (beginning); story by H.SARYAN; poems by R.NIZAMI, K.BULATOVA, G.BAYRAMOVA.
«History»: article by R.VALI «Life dedicated to people».
«Literary criticism»: book review by R.GATASH on book by F.Zamaletdinova «Caravan of time».
«Science»: F.GARIPOVA. «History of our villages».
Page of «Tatar Encyclopedia».
«Art»: A.SHAKIR. «Actor's notes».
«Memory»: Article by N.GILYAZOVA dedicated to writer A.Gilyazov;
A.GILYAZOV «We are fruits of unfortunate time»;
article by R.MUHIYAROV dedicated to F.Safiullina.
«75th anniversary of Fanis Yarullin»: article by R.YUNUS «You know what guy he was!»
«Our jubileers»: in issue it is celebrated 100th anniversary of A.BIKCHANTAEVA; 90th anniversary of R.SHAFI, 80th aniversary of H.HALIKOV.
Diary of social and cultural life.
On our covers: «Tea for Two. Writer Fanis Yarullin and his wife Nursiya Khanum». Picture by Zufar Gimaev; poetess Gulzada Bayramova.

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция жавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә жыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 01.02.2013, график буенча 01.02.2013.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-282. Тираж 4001.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААЖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2013 ел.



Рашат
Низами

# МӘҢГЕЛЕККӘ КИЛЕП ТОТАШАМ

## Хөрмәтле Шамил ядкяре

**Кабанкүлдә ак болытлар йөзә,**
**Театрга баккан Кабанкүл.**
**Казан, Казан! Гел яшәргә бара...**
**Әмма тарихыбыз төпкелендә**
**Кайнар туфрак катыш һаман көл.**

**Табу, югалтулар...**
**Югалттык без**
**Театрның олуг Атасын.**
**Шушы мәлдә язмыш көзгеләрен**
**Йодрык белән килә ватасы!**

**Син халыкка әверелдең бугай —**
**Ярты Казан елап озатты.**
**Тукай заманнары килде гүя,**
**(Хәтеребез түгел йозаклы).**

**Күңелең диңгез иде, ә Син үзең —**
**Мәрхәмәт һәм шәфкать өлгесе.**
**Бер шәхестә шулай чагылыр икән**
**Татарлыкның асыл көзгесе!**

**Инкыйразга каршы күкрәк куеп,**
**Ярты дөнья белән дуслаштың.**
**Нигә, нигә шушы дөньяң белән**
**Бигрәкләр дә иртә хушлаштың?**

**Туган телне сөеп саклар өчен**
**Йөгәнләребез көмеш Пегасны.**
**Энҗеләрдәй саклый белсәк икән**
**Син калдырган изге мирасны...**

Рашат НИЗАМИ (1950) — *шагыйрь, прозаик; «Кызыл җәй», «Без яшибез», «Яшьлеккә хат», «Яшәүгә гимн» һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

## Минем җырым

*(триптих)*

*«Как гений чистой красоты».*
А. С. Пушкин

I

**Мин яшенгә гашыйк идем элек,
Коеп–коеп яңгыр яуганда.
Ничәмә кат, сөю ташын эзләп,
Сәфәр чыктым алсу таңнарда.**

**Күңел тырышлыгын багышладым
Гел кояшлы көннәр ягына.
Хыялларым, янар учак булып,
Җирдә–күктә канат кагына!**

**Яшьлегемнең ап–ак битләренә
Язмыш–каләмниләр язачак?
Айның аргы якларыннан хәтта
Күңелем сине эзләп табачак.**

**Ләйлә белән Мәҗнүн мәхәббәтен
Кабатларга телим мин, имеш...
Күрәсеңме, әйтер сүзем булып,
Калтырана кызыл гөлҗимеш.**

II

**Эчем–тышым яна... Барган шәпкә
Сикерәмен гүя ут аша.
Синең сурәт, синең нурың белән
Мәңгелеккә килеп тоташам.**

**Җиләк сыман посып тора әнә
Әйтеләсе сүзләр — ир(е)немдә.
Дәрман җитә: күкнең катламнарын
Мин күтәреп торам иңемдә.**

**Бәхетемне килми куркытасым,
Син — язмышым минем, син ярам.
Зинһар, тәкъдир! Биргән бәхетеңнән
Мәхрүм итә күрмә — ялварам...**

**Хыялымда сиңа, толым итеп,
Йолдызлардан гөлләр үрәмен.
Вулканнарга кереп баттым бугай, —
Мең терелеп, мең кат үләмен.**

III

**Ярый әле син бар янәшәмдә,
Безнең уйлар, күңел — янәшә.
«Яшәү – бәхет, тәмен белегез», — дип
Күкләр безгә хәтта эндәшә.**

Мәхәббәтне танып-белер өчен
Янып яшәү кирәк иң элек.
Таулар тикле таулар җимерелә,
Сөю генә җирдә — мәңгелек.

Күзләреңнән, керфек очларыңнан
Түгелә сыман гөлләр яңгыры...
Безне зурлап, зәңгәр офыкларда
Яшәү музыкасы яңгырый!

Кайсы йолдызлыктан төштең Җиргә,
Шуның серен миңа әйт әле.
Сихерләнеп багам: син бит, сеңел, —
Матурлыкның тере һәйкәле...

## Мин китәм...

Үз-үземнән качып барган чакта
Карурманның аргы ягына,
Ботакларын бәреп маңгаема
Яшь чыршылар миңа ялына:
«Китмә, абый, зинһар китә күрмә,
Яшик әле, яшик көч барда...»
Маңгаема канатларын куеп
Ялваралар хәтта кошлар да.

Кая китеп барам әле шулай,
Мәшрикъкамы, әллә котыпка?
Тирә-юньдә – сорау билгеләре,
Аяк эзләремдә — күп нокта...

Мәгыйшәтнең ватык күчәренә
Берекмәгән ләса кендегем, —
Усаллардан һәм ялганнан туйдым,
Күк катына китәм мин бүген!

Утлар-сулар кичеп, үз-үземне
Инде эзләп таптым дигәндә, —
Үз-үземнән качып барам менә...
Маңгай тирем тама үләнгә.

Күләгәләр, күксел томаннар да
Каплый алмый күзем карасын.
Атлам-атлам ерып барам шулай
Секунд белән гасыр арасын!

Дәррәү күтәрелеп кошлар оча,
Яфрак җиле чәчем аралый.
Үз кояшым көтә мине алда —
Юк, туктарга һич тә ярамый!

Ак болытлар тарафына таба
Этә-төртә вакыт сөңгесе.
Бурлак сыман Җирне тартып барам,
Әйтерсең, мин –
Планетаның соңгы кешесе...

## Афәт

*Россиядә туучыларга караганда үлүчеләр саны күбрәк.*
(Газеталардан)

**Рәсәй буйлап шәүлә йөри, —
Салкын үлем шәүләсе.
Туфрак белән тигезләнә
Адәмнәрнең гәүдәсе.**

**Илдә һаман эш күбәя
Кабер казучыларга.
Күрәк сабы һәм мускуллар —
Сез тиешсез чыдарга!**

**Чернобыльдә... уяттылар
Гигант дию пәриен.
Тып-тын гына шакып йөри
Моңсу илнең һәр өен.**

**Радиация явы
Килә мыштым үрмәләп.
Берни белми очып йөри
Көн яшәрдәй күбәләк.**

**Илдә үлем арта бара,
Кырылабыз шуңа без:
Җир-һавалар агулана,
Пычрана суларыбыз.**

**Мордар китү... Ирексездән
Бау астына керәләр, —
Гүя яшәешкә шулай
Протест белдерәләр.**

**Җан кыючы киллер-палач
Куаклыкка елыша...
Кеше гомерләрен җәлләп
Җир һәм күкләр елаша.**

**Үлем арта... Эш күбәя
Кабер казучыларга.
Тимер йөрәк кирәктер ул
Бу афәткә чыдарга...**

## Фаҗига

**Хәлил абый — фронтовик,
Сугышлар кичкән кеше.
Дөньяның ачы-төчесен
Чүмечләп эчкән кеше.**

**Чем-кара эте бар иде,
Исеме — Дүрткүз аның:
Бакчасын, йорт-каралтысын
Саклар иде хуҗаның.**

Көтмәгән–уйламаганда
Күрсәткән начар холкын, —
Шәһәрдән кайткан кунакның
Ботын тешләгән беркөн.

Хәлил абыйның карары
Кырыс һәм усал булган:
Дөньясы кителмәс әле
Дүрткүзне «югалту»дан.

Җилкәсендә — ау мылтыгы,
Тәкъдир шулай языла:
Малай-шалайны ияртеп,
Китте «Үләт базы»на.

Кырдагы яшь башакларның
Сөткә тулышкан чагы.
Гүя, капкын — этнең генә
Кысыла муенчагы.

Хәлил абый яшь каенга
Куйды этен арканлап.
Эре, кайнар кырмыскалар
Йөгерә күк аркамнан.

Дүрткүз шыңшый, сизенәдер —
Мөлдер-мөлдер күзләре.
Аптырагач җиргә чүгә
Ал аякка тезләнеп.

Кинәт мылтык көпшәсеннән
Утлар чыкты бөркелеп!
Якындагы куаклыктан
Кошлар купты өркенеп.

Хәлил абый, нигә безне
Чакырдың канлы туйга?
Иртәгә барасы идек
Югыйсә Сабантуйга.

Очты Сабантуй кайгысы,
Безнең күңел – яралы.
Дары исе тиз таралды,
Кояш кына... каралды.

Хисам Камалов

## СУГЫШТАН КАЙТКАН СӨЮ

***

Эштә тагын Нөркәев турында сүз чыкты. Тарик үз бүлмәсенә чакыртып алган иде. Лена да шунда утыра. Аның алдында редактор Мәгарифнең эшеннән канәгать түгеллеген белгертә башлады. Ленага сабак биргән шикелле иде. Эшебездәге чатаклыклар фабрика җитәкчелегендә уңай бәя ала алмый, диде. Канәгать түгелләр... Ник кадрларыңны идея ягыннан өйрәтмисең дип мине шелтәлиләр. Ни өчен эштә политик сизгерлек җитешми? Болай үзең башлы егет, каләмең дә бар, ә? Үз кимчелегеңне белү ансат түгел, билгеле. Үзең аңлап җитмисең икән, менә безнең, иптәшләреңнең әйткәннәренә әз генә колак салыр идең ди...

— Сезнең сүздән чыкканым юк бит, нигә алай әйтәсез?— дип сүз кыстырды Мәгариф.

— Син тыңла, тыңла,— диде Тарик ничектер карулашасы килмичә генә.

Ул аның үзе кебек, үзен көчләп, кызыл авыз булуын тели иде. Андый кешеләр тормыштагы һәр начардан үзләрен физически читләтеп куялар. Кимчелекне бер дә күрмиләр, теләмиләр. Карьера өчен генә шулай эшлиләр. Кимчелекләргә битараф, калын тиреле һәм дәшми торган кешене генә өниләр, үз итәләр. Шундый булсаң гына алар төркеменә керә аласың. Үзләрен идеяле итеп саныйлар, югары даирәгә нисбәтән күреп, эреләнәләр. Бик мөһим, эшлекле чырай белән йөриләр, зурдан сөйләшәләр. Күрсәң! Тарик Фәррахович та шундый кешеләр даирәсенә үрмәли иде. Сөйләшүендә, эшендә югарыдарак торганнардан отып алган чалымнар еш күренә. Бу кыланышлар, кызыл сүзле булып сөйләнүләр, фикер йөртүләр аның демократик характерына һич кенә дә ябышмый һәм кычкырып торалар. Матур пальтога ямаулык ябыштырып куйган шикелле тоела. Тарик ипле холыклы, үзе теләп алган рольгә кереп, килештерергә тырыша. Әмма мондый роль аныкы түгел икәнлеге сүз саен диярлек беленеп тора. Тешкә тия. Тарикны белмәгән кешеләргә бу нәрсә сизелми дә торгандыр. Ләкин Мәгариф аның ничек көчәнгәнен, булдыра алмыйча җәфаланганын, рольгә егылуын һәм оялмыйча тагын торып китүен күреп әрни. Мондый кешеләрдән залим тәрбияләү берни тормый.

— Үзеңне үзгәртергә кирәк, Мәгариф,— диде Тарик бераз тынып

*Ахыры. Башы узган санда.*

торганнан соң. Аның тавышы бик хәерхаһ һәм хәлгә керүчән, жәлләүчән сыман иде. Чынлап та, Мәгарифне чын күңелдән кайгыртып әйтә ул.

— Берне, ике, әзне күп дип әйтә алырлык булыргамы, Тарик Фәррахович?

— Тарихи максатыбыз хакына нигә әйтмәскә? Шулай кирәк диләр бит,— Тарик Ленага карап куйды. Ул да берәр сүз әйтсен дигән шикелле иде.

— Мәгариф абый, берне, ике, әзне күп дип әйтүнең ни авырлыгы бар соң? Бер кыенлыгы да юк,— диде Лена аны көйләгән, тәрбияләгән тавыш белән.

Мәгарифнең эчтән ачуы кузгала язды: шушы кәнтәй дә сине өйрәтеп утыра бит.

— Мин караны ак дип әйтә алмыйм шул! Караны кара дип, акны ак дип кенә күрә алам...

— Төсләрне аера белмәү синең шәхси кимчелегең, Мәгариф, аны ижтимагый эшкә кушарга ярамый,— диде Тарик бик йомшак кына итеп. — Төшенәсеңме?

— Юк, Тарик Фәррахович, барып житми әле бу миңа.

Тарикның йөзе караңгыланды, кашлары жыерылды, алсу тиреле каш, маңгаенда сырлар күбәеп китте.

— Ярар, тормыш төшендерер,— дип ул өстәлдәге бер папканы алды да актара башлады. — Тәк, менә болай,— дип дәвам итеп:

— Нөркәевне тәнкыйтьләп мәкалә яз. Завком ялгышны төзәтүне таләп итә....

— Нөркәев дошман түгел!

— Ярар, сине редакциягә эшкә алып ялгышканмын икән,— диде Тарик үкенечле тавыш белән. — Лена, мәкаләне син язарсың. Бетте!

Ул учы белән өстәл өстенә иплэп кенә сугып куйды. Аның кулы ниндидер зур бер кызгылт кысланы хәтерләтә иде. Лена тиз-тиз атлап чыгып китте.

Тарик торды да стенага таба борылды. Телефоннан чылтырата башлады. Аның кыяфәте, таза муены ачулы һәм читләшү төсмерләре белән тулган иде.

Мәгарифнең эченә салкын йөгергәндәй булды, баш өстендә болытлар куерганын бик яхшы сизде һәм шуңа урыныннан кузгала алмады. Бу килеш чыгып китсә жаны борчу белән телгәләнеп бетәр иде. Башын иеп, бик таушалган төстә һаман утыра бирде. Горурлыгы аңа чыгып кит, син хаклы, ник үзеңне ваклыйсың, ди, ә гамәл тота, утыр, башың и, үзеңне түбәнәйт, дип тукый.

Редактор телефонда сөйләшеп бетерде дә, чыгарга жыена башлады. Мәгарифкә йомшак кына сүз катты:

— И, туган, жайга ое, үзең өчен бит,— дип куйды. — Жалкы, каләмең бар. Миңа да бик авыр да соң, гамәл бездән көчле бит. Жаена ятмасаң, таптый да китә... Ну, монысы үзара гына, яме...

Ул, шкафын ачып, киемен ала башлады.

— Рәхмәт, Тарик Фәррахович,— диде Мәгариф аның соңгы ихлас сүзләреннән күңеле булып.

Саубуллашты да, чыгып китте.

Ни өчен Тарик соңыннан ачык күңелләнеп мине кайгырткан кебек итте, дигән уй килде Мәгарифкә. Ул эш бүлмәсенә кайтты, өстәл артына утырды, эшенә тотынган булды. Әмма уйлары һаман бая гына булып алган сөйләшүгә әйләнеп кайтты... Башта Тарик әйтте: сине эшкә алып ялгышканмын, диде. Аннары минем якта да хаклык барлыгын чамаладымы, әллә әчелешле буласы килмәдеме, «монысы үзара гына, барышка жайлы бул, туган» дип

ихлас сүзләр әйтеп ташлады. Тукта, нәрсәсе ихлас моның? Барышка каршы кеше түгел бит мин? Мин тормышның барча положениеләре белән риза, алар белән килешеп яшим. Тышкы яктан гына түгел, үземнең тиремне саклау өчен генә түгел, чын күнелдән шулай кирәктер дигән фикердә торам. Ләкин эшкә зыян китерә торган нәрсәләрне күрмичә, гаделсезлеккә каршы тормыйча булдыра алмыйм. Ул минем канымда. Безнең тормыш кагыйдәләре буенча да гаделсезлеккә каршы һәркем көрәшергә тиешле. Карасана, үзен тормышның төп таянычы итеп карый. Беренче сортлы кеше, ә мин барышка оемаучы безнең яклы түгел, янәсе. Менә Тарик ничек китереп чыгара. Ул югары затлы, ә мин түбән. Ул кимчелекләргә күз йомучы, гаделсезлекне юри күрмәүче, чиктән тыш җайлашучы тормышның ышанычлысы, терәге булсын, имеш. Мин гаделсезлекне күтәрә алмаучы, шуны әйтергә тырышучы — түбән дәрәҗәдә саналам. Һәрхәлдә, Тарик мине шулай хисаплый. Ул яраклаша алган өчен генә әйбәт, тормыш түрендә, ә шул сыйфат булмаганга күрә генә мин начар... Уйласан, шулай килеп чыга. Тарикның тел төбе шул мәгънәдә бит... Мин аңлыйм, яраклашырга кирәк, шунсыз гомер итеп булмый. Ләкин моның бер чиге бар бит. Рядовойлар өстәгеләргә йөз процент яраклашса, ул өстәгеләр үзләреннән өстәгеләргә ни боерасын дип күзенә карап кына торса, үзе янындагы кимчелекләрне күрмәсә, бер-берсеннән яшерсә — кая барып чыгар бу галәмәт?

Нөркәев эш процессын тизләтү өчен, димәк, производствоны арттыру өчен тырыша, чын күңелдән дип уйларга кирәк. Әмма шул кешене хәзер юк нәрсә өчен тәнкыйтьләргә кушалар. Димәк, җитәкчеләр эш интересы өчен, булсынга тырышмыйлар, ә политик нечкәртүгә бирелгән булып маташалар. Һәм бу нәрсә конкрет эштән, эшләп чыгарудан, ягъни байлыкны арттырудан мөһимрәк! Имеш, Нөркәев карашы белән безгә үзери түгел. Моннан да абсурдрак нәрсә булуы мөмкинме? Эш өчен тир түгә, булсын дип йөри, шул кешенең карашы хилаф булсын, ди. Сызыкка сызык туры да килмидер, бәлки. Әмма нигә шуны гаеп санарга? Кеше машина түгел бит. Үзенә кирәк якка бордың да куйдың...

***

Мәгариф тирене беренче эшкәртү цехында агитатор иде. Занятие уздырырга килсә, кеше бик аз калган. Гадәттә болай ук аз булмый торган иде. Ни сәбәп? Аның сөйләвен яратмыйлармы? Узганында дин турында әңгәмә уздырган иде. Бик җанлы гына булган иде шикелле. Күпләр кызыксынган сорауларын курыкмыйча әйттеләр. Ул ышандырырга тырышып, диннең ничек барлыкка килгәнен үзе аңлавынча бәян итте. Аны халык барлыкка китергән, иҗат иткән дип әйтергә була. Чөнки табигать каршында адәм баласы бик көчсез, яклаучысыз. Ә табигать кешеләргә һаман афәт, зыян китереп торган. Яшен сугулар, су басулар, янгыннар чыгарган, тауларны ишкән. Чәчкән игеннәрне боз сугу белән бетереп ташлаган. Кыскасы, табигать адәмнәрне дер калтыратып куркытып, җаннарын алып торган. Әнә шул куркудан, ниндидер бер гайре табигый көчле бар дип күрә башлаганнар. Шулай Алла җисеме барлыкка килгән. Алланың холык-фигыленә буйсыну, аңа табынып тору кирәклеге алга килеп баса. Чөнки табигатьтә, ягъни Алланың кануннарына буйсынмасаң, ул җиргә афәтләр, казалар китерәчәк. Ул бәла-каза китермәсен дисәң, табигать-Алланың җаена торырга, аңа табынырга кирәк, дип фикер йөрткәннәр. Тормыш иткәндә тәртип-низам зарури. Аллага ялварып тәртип-низам кагыйдәләре төзегәннәр. Шул кагыйдәләр буенча адәмнәрне Алла җәза бирер дип куркытып торганнар. Куркуны тәрбия чарасы итеп, кагыйдә нигезенә салганнар...

Мәгариф үзенең белем сайлыгын чамалап, дин турында тагын берничә

занятие уздырырга һәм тагын да ныграк хәзерләнергә дигән нәтиҗәгә килде... Шунын өчен ул Ленин китапханәсенә барып язылды һәм шул теманы яктырта торган берничә китап та алып кайтты. Бу эш анын педагогия институтында читтән торып укуына да ярдәм итә.

Бүген кеше әз, шуна күрә Мәгариф кыска гына политинформация ясап алды да, ничектер хәл-әхвәл турында сөйләшүгә кереп китте. Ике-өч кешенен күз төбендә «фонарь» бар иде. Мәгариф шулар белән кызыксынды. Башта ык-мык итеп, тартынып-тартынып тордылар... Кичә ипигә чират бик хәтәр булган, шунда яшь әтәчләр шикелле чукышып алганнар икән... Кайчан бетәр бу чират дигән нәрсә, дип зарланырга тотындылар. Өченче көн берәүнен кулын сындырганнар, ди.

Мәгариф үзе дә, очын-очка чак ялгап яшәсә дә, аларнын зарлануларын бик тиз басты: житәр, мондый сүзләр өчен беләсенме ни, диде ныклы гына итеп. Чират ул вакытлы күренеш, тиздән Яна бистәдә зур гына ипи кибете ачылырга тора диде. Ул кибет кечкенә булса да аны зур дип әйтергә мәжбүр булды. Чөнки обстановка өчен шулай кирәк иде...

Занятиедән чыккач та, бу хакта башында уйлар бөтерелде. Ни өчен һаман һәр нәрсәгә чират: сугыш беткәч тормыш әйбәт булыр дип өметләнгәннәр иде. Анысы өмет акланыр ул, шик юк. Немец-фашист бик нык бетереп, аяктан егып китте шул. Яраларны төзәтү бик авыр. Чиратка гына түзәрсен. Чират белән булса да икмәк алып була. Шунысы әһәмиятле. Хәзер бер кеше дә ач түгел. Анлаган кеше өчен бу бик зур казаныш. Шулай да кечкенәне зур, әзне күп дип әйтергә, ялганларга туры килә. «Положение обязывает» дигән нәрсә шулмы икән инде?

Тукай урамы чатында Кирәкмәсов очрады. Мин сине эзләп йөри идем ди. Мәгариф бераз аптырап китте. Нөркәев мәсьәләсе турында әйтергәме, юкмы дигән уй килде ана. Редакция серен сакларга кирәк иде. Ул дәшмәде. Кирәкмәсов бераз гына кызмача иде шикелле. Дәриягә кызыгып калганы турында сайрый да сайрый. Нәрсә сон бу ди, аптыраган төстә. Шул кыз күз алдыма килә дә баса, килә дә баса. Нидән шулай икән, ә, дип Мәгарифтән жавап көтеп күзенә карый... Дәрия синен күнеленә ошаган, менә шул, дип анлата Мәгариф. Юк, ди, егет, минем бит аны күнелемә кертергә теләгем дә булмады. Мин берни уйламадым да... Менә хикмәт, ә? Кирәкмәсов уйнап сөйләми иде, йөзендә үзенен бу халәтенә шаккату һәм жавап таба алмау иде... Матур, затлы кызлар теләмәсән дә күнелгә кереп кала, дип шәрекли Мәгариф. Ихтыярынны сындырып жанына оя коралар. Шунын өчен матур кыз диләр... Үзен тагын барып күрмәденме?

— Кичә барган идем, качып кайтып китте дип шыпырт кына колакка пышылдадылар. Матур булу өстенә батыр да икән...— диде Кирәкмәсов, сокланып сөйләүдән анын битенә нур төшкән, борын яфракларына чаклы елмаю яктысы белән тулы иде.

— Сон бит аны хәзер утыртачаклар, их, жилбаш кыз! — дип Мәгарифнен чырае кинәт карангыланды.

— Неужели шундый кояш кебек кызны хөкем итәрләр, ә? Юк, ышанмыйм,— диде Кирәкмәсов, һаман да үзенен хисләре тәэсирендә. Хисләр чынбарлыкка ышанып житми, хисләр тормыш кырыслыгын кабул итеп бетерми. Шуна еш адашалар.

— Үзен харап иткән, әй, юләр баш, юләр баш!— дип кайгырды Мәгариф чын күнелдән. Себергә китсәм харап булам дип бик курыккан иде, шул куркудан башсыз эш эшләп ташлаган. Тегеләй дә начар, болай да әйбәт түгел, дип уйлагандыр. Ә бит утыртачакларын яхшы анлый иде. Районда берәр жай табарына ышанды микән инде? Бәлки анда таянырдай кешеләре бардыр?

— Юк, Дәрия югалмас,— диде Кирәкмәсов.

Мәгариф бер сүз дә әйтмәде. Аны Дәрия турында уйлар биләп алган иде. Менә бит, Дәриягә берәр нәрсә булса, тагын аның өстенә гаеп төшә инде. Хәлләр чылбырының тәртибе башта бер бозылса, әллә ни вакыттан соң аны онытып бетергәннән соң да барыбер, бер хилафлыгы килеп тез астына сукмый калмый. Су баштан бер болганмасын инде, аннары буйдан-буйга пычрак китә... Дәрия тормышны мәктәп дәреслекләрендә язылганча итебрәк күз алдына китерә. Юк, дәреслекләрдә бер төрле, ә тормышта исә бөтенләй башкача! Нигә шулай кызыл төстә буяп язып яшьләрне адаштырырга? Әллә махсус рәвештә шулай эшләнәме бу? Мин күпме шул туры килмәү аркасында газапландым һәм һаман да җәфа чигәм. Кемдер әйткән, кеше яшәүдән бизмәсен өчен, тормыш җитәрлек кадәр кырыс һәм шәфкатьсез булырга тиеш, дигән. Уйлана торгач, үзеннең чаманы белгәч, бу кагыйдә белән тулысынча килешәсең, шайтан алгыры!

***

Мәгарифнең күн пинжәге бар иде. Шуны манный ярмасына алыштырып, бераз тернәкләнеп килделәр. Үлчәүле нәрсә бик тиз бетте. Нишләргә? Бала елавыннан да йөрәкне телә торганрак берәр нәрсә бармы? Артур үкси башласа, Мәгариф берәр сәбәп табып, урамга чыгып китә. Ләкин анда котылып булмый. Җәлләү хисе күнелен уеп-уеп ала башлый да, тизрәк өйгә атылып килеп керә.

Нөркәев белән фикерләре туры килә торган кешеләр булып бераз якынаеп киткәннәр иде. Дөресрәге, Мәгариф үзе ни өчендер аңа тартыла. Теге яки бу мәсьәләдә уйлар тәңгәл килеп тору бик зур нәрсә икән. Шундый кеше сиңа бер сәбәпсез якын булып тоела. Нөркәевнең тышкы мөлаемлыгы өстенә конкрет булуы, эшне булсынга гына эшләве, ничек тә яхшы булсын дигән нияттә йөрүе кешеләрчә үзенә тарта иде. Мәгариф моны байтактан аңлаган иде. Шуңа аны мактап мәкалә дә язды. Әйтелгәнчә, ул мәкалә кайбер җитәкчеләргә ошап җитмәде. Менә хәзер Мәгариф мәкаләсен бетереп ташлый торган әйбер әзерләнә. Ул моны Нөркәевкә әйтмәскә тиеш иде. Шулай да бер күңел ихласланып ачылган моментта тиште. Үзең генә бел, диде.

Нөркәев икенче көнне иртәнге эңгердә аңа өч кило чамасы ак төенчек кертеп бирде. Манный ярмасы. Хак алудан баш тартты. Монысы покага гына, диде. Һәм өйгә дә узып тормыйча, китеп барды. Мин аны якын иткәнне бәяләгән, үзе дә миңа хәерхаһ булып киткән, дип сөенде Мәгариф.

Тагын бер кичне соң гына Нөркәев ниндидер иптәше белән килде. Иптәшенең кулында чемодан иде. Бу чемоданлы Мәгарифкә таныш кеше булып чыкты. Таныш кына түгел, бу Сөнтиев дигән егет турында ул «Яшь сталинчы» газетасында фельетон бастырып чыгарган иде. Сөнтиев жулик кеше иде. Чи тиреләрне сортлау цехында эшләде. Мастерны хәйләләп, өченче сортларны беренче итеп җибәргән. Тагын шуныңише махинацияләр эшләп бетергән. Аның өстеннән материал күп иде. Үзе белән янәшә эшли торганнарны да күз ачып йомганчы хәйләли икән. Ут кебек елгыр, ди. Чынлап та аның күзләре хәзер дә йолт-йолт килеп тора... Мәгариф язган фельетон буенча аны эштән кудылар. Шул фельетон чыкмыйча эшеннән куа алмый йөдәгәннәр. Начальникларны үзара талаштырып бетергән. Көч-хәл белән Сөнтиевне фаш итәләр. Менә шул кеше тәкәллефле генә аның каршында басып тора. Мәгариф аның үзе белән икәүдән-икәү генә сөйләшкәне булды. Хәтта сыраханәгә кереп утырдылар. Мәгариф тыштан берни белгертмичә аның холык-фигылен белергә теләде. Сөнтиевтән һәркайда диярлек зарланалар иде. Башта үзебезнең газетада аны пешерергә кирәк таптылар. Мәгариф шуның өчен аның үзен якыннан белергә теләде.

Фельетон язу исәбендә дә юк иде. Сөнтиев эчендәген яшерә белми торган зат икән. Бер утыруда яхшы ук ачылгандай булды. Ул үз янындагыларны, эше төшкән начальникларны каралтып сөйли иде...

Нөркәев чемоданны урындыкка куеп ачты, анда сөттәй ак капчыкта бер пот манный ярмасы икән.

— Менә Сөнтиев синең өчен тырышты, иптәш Сайкин,— диде Нөркәев. — Бары синең хакка гына...

Мәгариф нәрсә әйтергә белми аптырап тора. Эчтән ниндидер тавыш: син бу жуликтан берни алырга тиеш түгел, ди. Ә алмыйча ни хәл итәрсең? Ач баланың елавыннан йөрәккә кан сава бит! Валлаһи, бу хәлгә үзе төшкән кеше генә аңлар моны... Икенче яктан, мин Сөнтиевне һәм аның ишеләрне дошманым кебек итеп күрәм. Менә шул дошман миңа игелекле кулын суза. Минем бәлагә таруымны көтеп, сагалап торганмы? Юк, Сөнтиевтә анысы булмас. Ул Нөркәевнең әшнәсе шикелле. Шулай ишеткән иде. Белмим, нинди дәрәҗәдәдер... Бу эшне Нөркәев үз инициативасы белән эшләгәне көн кебек ачык.

— Юк, мин куркам монардан,— дип Мәгариф башын як-якка чайкады. Әмма Сөнтиев йөзенә берни дә чыгармады, ул һаман елмаеп.

— Син монда берәр этлек бардыр дип шикләнәсең,— дип Нөркәев иптәшенә карап алды. — Юк, син Сөнтиевне белмәден, күрмәден. Шулай бит?

— Мин сиңа ачу тотмыйм, иптәш Сайкин,— диде Сөнтиев тыныч кына. — Ул әйбер миңа файдага гына булды диярга ярый. Әйбәтрәк эшкә урнаштым...

— Миңа да әйткәне бар: булган беткән, бер үчем юк дип...

Нөркәев ике араны җайламакчы, ышаныч тудырмакчы була иде. Мәгарифнең эчендә шик бетми, ул тиз генә чынга ала алмый иде. Киеренкелекне йомшатырга теләгәндәй һәм сүзләре каты бәрелмәсен өчен, ул елмаерга мәҗбүр булды.

— Сөнтиев әнә барыр да әйтер...

— Юк инде, иптәш Сайкин, син нәрсә?— диде Нөркәев кыдырып.

Аның шар күзләре тагын да зураеп киткән иде.

— Сөнтиев андый малай түгел. Кеше әлләниләр сөйләр ул, гайбәткә ышансаң...

— Ә теге кадрлар начальнигы Хөрмәтуллин белән булган хәл?

— Кая инде, сиңа бөтенләй ялгыш информация биргәннәр,— дип сүзгә кушылды Сөнтиев. Тавышы ничектер ышандырырлык иде. — Ул үзе Сталин турында начар сүз әйттең дип, миңа политика «текмәкче» булды. Карьера өчен. Шуның аркасында күпме йөрттеләр, күпме газапладылар. Сиңа киресенчә житкергәннәр икән...

— Сөнтиев хәзер төзәлде инде, иптәш Сайкин,— диде Нөркәев иптәшен чын күңелдән яклыйсы килеп. — Адәм баласы бер көе генә тормый, һаман үзгәрә...

Мәгариф чынлап та икеләнеп калды. Бер яктан Сөнтиев тә дөрес әйтә кебек, икенчедән, Хөрмәтуллин турында элек ишеткән хәлләр дә ышандырырлык иде. Сөнтиевнең эшләрен һәм үзен бераз белгәнгә күрә, ул сүзләр Мәгарифкә чын булып тоелганнар иде.

— Мин сиңа таш белән, ә син миңа аш белән,— диде Мәгариф дәшми торудан уңайсызлана башлагач.

— Күптән булган, кар астында калган,— дип Сөнтиев иптәшенә карады. Әйдә, үзең хәл ит инде дигән төсле...

Тагын бераз карашып торгач, Мәгариф күчтәнәчне алу ягына борылды.

***

Надия эшли торган госпиталь Горняк каршындагы иске бакча эчендә өч катлы зур бинада иде. Элек заманда анда кызлар гимназиясе булган.

Комлев урамына караган капкадан госпитальгә урта буйлы, какчарак гәүдәле бер хәрби килеп керде (Кулында посылка зурлыгындагы тартма иде). Погонында дүрт кечкенә йолдыз. Ул керү белән замполитны сорады. Аның кабинетына узды.

Алар бик тиз аңлаштылар. Керүче кечкенә кызыл книжкасын чыгарып замполитка сузды. Теге алып карады, укыды да: «Әһә, әһә, аңлашылды»,— диде. Ни боерасын, дигән кебек аңа түбәнчелек белән карап торды, күн диваннан урын тәкъдим итте. Капитан утырды, ә замполит һаман баскан килеш аның сүзен көтте. Капитан ни өчен килгәнен кыска гына итеп аңлатты. Мин биредә командировкада дип сестра Шамкина белән фронтта бергә эшләүләре турында сөйләп алды. Шәхси мәсьәлә буенча гына аны күрергә тели икән. Бүтәннәргә сиздермичә генә чакырыгыз, минем монда булуымны беркем дә шәйләргә, белергә тиеш түгел ди...

— Аңлашыла, — диде замполит каударланып һәм ишеккә атлады.

Берничә минуттан ишектә ак халатлы Надия күренде. Хәрби торып басты һәм аңа таба омтылды. Надия үзенең күзләренә ышанмыйча шаккатып калган иде.

— Надя, әллә танымыйсыңмы?

— Паша!— дип кычкырып җибәрә язды Надия. Ул бер учы белән йөрәк турын тотып, икенче учын маңгаена куйган килеш тигезсез атлап диванга килеп таянды. Аннары утырды.

Павел, эчке елмаю белән нурланып, Надияне җентекләп күзли иде. Надия бик нык үзгәргән, күкрәкләре шиңгән, битләре эчкә баткан, күз чокырлары тирәнәйгән һәм йөзен ямьләп торган борыны ябыгып озынаеп калган.

Берничә кило үлчәвен югалткан, дип уйлады Павел. Теге ире рәтле кеше булып чыкмадымы икәнни?

— Бик үзгәргәнсең, Надя,— дип бәрхет тавыш белән әйтергә мәҗбүр булды Павел. Йөрәгендә аны жәлләү кылы тибрәнеп куйды.

— Зато син әнә ничек чәчәк аткансың, ә?— диде Надия, ниһаять, һушы китү хәленнән көчкә чыгып. Ул елмайды да Павелның күз карашын тоеп, халат чабулары белән тезләрен япкалады. Үз-үзенә эчтән кыюлык өстәде. — Сиңа бит кырау төшкәне юк!

— Әйе, сезгә авыр туры килде,— диде Павел.

Ул сорау арты сорау яудырды: Надиянең хәле, эше, тормышы белән кызыксынды. Арага тулган, катлам-катлам өелгән читләшү тойгысын азайтырга тырышты. Читләшү, үзен аңардан аерып кую бигрәк тә Надиядә нык сизелә иде. Шулай булмый хәле юк, ул ир хатыны, иргә ярарга, аның төсле булып бетәргә кирәк. Ә Павелның әле һаман тормышын кора алганы юк. Баштагы хатыны белән тормышы барып чыкмады, Надя белән дә җимерелеп төште. Ул кыйпылчыклар белән ничек яңа тормыш кормак кирәк? Павел шул хакта әйткәч, Надиянең кызыксынуы арткан төсле булды. Әллә һаман миндә өмете яшәгәнме, дигән уй килде Павелга.

— Өйләнмәвеңә ни сәбәп?— диде Надия һәм ике кулын кушырып тез өстенә куйды.

— Сәбәпләр күп инде, сине дә онытып булмый...

— Анысын арттырма, кайнар канлы хатын булса, ата-анаңны оныттырыр.

— Әмма Артурны беркем дә оныттыра алмас, Надя! Юк!

— Аны да онытырсын, һи-и!— диде Надия, тавышы бик кинаяле иде.

— Гомергә дә! Мин Артурны яслегә барып күрдем,— диде Павел басынкы,

юаш тавыш белән. Әмма тавышы тигезсезләнде, калтыранып киткән кебек булды. — Шундый җәлләдем үзен. Минем җаным, минем валчыгым...

Ул сүзләрен әйтеп бетерә алмады, башы күкрәгенә салынып төште, күзләреннән ике тамчы яшь чыгып, тере шарчыклар кебек итек кунычына тәгәрәде. Надиянең дә күзләре яшьләнде, тизрәк кульяулыгын алып күз төпләрен сөрткәләргә тотынды. Павел авыр көрсенде, күзләрен угалады.

— Мине ничек таптың?— диде Надия сүзне икенчегә борып.

— Кайда эшләгәнемне беләсең бит, Надя!— Кирәкле информация безгә көне-сәгате белән бирелә,— дип кул селтәде Павел. Шунда ук бик житди тонга күчте.

— Без икебез дә ялгыштык, Надя. Мин шундый фикергә килдем. Без ул ялгышны төзәтергә тиеш. Хет Артур хакына, ә?

— Ни сөйлисең, Паша!— дип Надия аның йөзенә сынап, өйрәнеп карап торды. Тыштан берни сизелми. Эчтән танымаслык булып үзгәргән икән, дип уйлады ул. Кара, нинди сүзләр сөйли? Бу хәл бик яңа һәм бик сәер тоела. Бу шул элеккеге Павелмы соң, әллә бүтән кешеме? Уртак хисләр, авыртулар, кайгылар, уйлар беткән, алар урынына ялгыз җан сызлаулары гына калган. Алары да янып юкка чыккан, көлгә әйләнгән. Хәзер Павелның кичерешләре аңа барып житми, аңлашылмый. Читләшү тәмам ныгыган. Аларны бер-берсеннән бик нык ераклаштырган.

— Йөрәгем әрнегәнгә әйтәм,— дип куйды Павел. Аның йөзе күкселләнеп киткән иде.

Надиянең эчендә кинәт ачу нервысы кузгалды.

— Тагын ватарга, тагын җимерергә?— диде ул кырысланып.

— Мин дә кеше бит, Надя, йөрәгем таш түгел!

— Теге чакта нигә соң ул йөрәгең ташка әйләнде?!

— Ул вакытта тәҗрибәсез идем, ялгышканмын, Надя! Чын менә...

— Ялгышларың өчен бүтәннәрне җәзалыйсың, ә үзеңне хөкем итәргә кулыңнан килми.

— Теләсә ничек тиргә, Надя. Аның белән хәл жиңеләйми бит...

— Үзенә килеп бәрелгәч кенә кеше икәнең исеңә төшкән, ә мин? Мин дә кеше идем бит син миннән баш тартканда. Күпме кан-яшь түктем?

— Мин баш тартмадым, Надя, юк! Кызымны үлеп ярата идем, аны бик күрәсем килде. Азагын уйлап житмәгәнмен...

—Мин барысы да синең аркаңда булды дип әйтергә теләмим. Ир-ат җаваплылыкны үз өстенә алыр дигән ышаныч белән яшәгәнмен, шул адаштырган...

— Үз өстемә алырга дип килдем, Надя...

— Хәзер соң инде, Павел! Ничек син шулай әйтә аласың? Аптырыйм. Үзең хаклык хөкемчесе.

— Сайкинга шулай нык беректеңмени соң?!

— Ул мине түбәнлектән коткарды, син аткан пычрак чокырдан тартып чыгарды, беләсең ич, хәзер шул кешене адәм хуры итәргәме? Ул баланы үзенеке дип белә... Уйлап кара, ничек шуларны чәлпәрәмә китерергә? Беләсең, минем йөрәк сәламәт түгел, андый нагрузкага чыдый алмас... Павел, син бүтән кешеләр хакында бөтенләй уйлый белмисең.

— Мин малайны, сине жәллим, Надя, аңла! Тормышың да әйбәт түгел. Бу шартларда бала да нормаль булып үсмәс. Менә хикмәт нәрсәдә... Син хәзер мин белгән Надя түгел — бөтенләй икенче, — диде Павел бераз уйланып торгач.

— Син дә үзгәргәнсең, элек шактый кырыс идең. Бер якны гына тыңлый идең кебек. Хәзер икенче якны да исәпкә ала башлагансың. Күңелең йомшарган димме?

Павелның маңгаенда сырлар күбәйгән, битен сызгалап нечкә генә җыерчыклар сузылган. Яшәү аңа да җиңел генә бирелмәгән.

— Ирең ничек соң?— диде Павел Надияне ихласлыкка этәрерлек йомшак тавыш белән. Аның тавышында кайгырту, хәстәр бар иде.

— Бик әйбәт дисәм мактау булыр, начар дисәм — ялганлау,— дип елмайды Надия. Аның ялган горурлык саклап маташасы килмәде. Павел аны үтәли күрә кебек иде. — Син аны беләсең бит инде?

— Малай турында берәр нәрсә сизенмиме?— Бу Павелны иң нык кызыксындырган сорау иде. Йөзенә дә шундый төсмерләр чыкты.

— Юк шикелле,— диде Надия ничектер, икеләнебрәк. — Малайны үлеп ярата. Чөнки ул синеке түгел, аның малае...

— Ни сөйлисең, Надя, акылыңдамы син?— Павелның сулышы кысылды. Муен тирәсе нервланып әле аска, әле өскә бәргәләнде.

Надиянең исә бары үзе генә белгән нәрсәләрне бигүк белгертәсе килми. Теге вакытта врачлар, тикшереп-карап тормыйча гына, аны җәлләп, кәгазьләр язып бирделәр. Надия, бәлки, үзе ялгышкандыр? Хәзер ул баланың кемнән икәнен үзе дә төгәл генә өзеп әйтә алмый. Бала исә әзрәк Каймакчига, әзрәк Мәгарифкә дә охшаган сыман тоела...

Беркатлыланып бу хәлләрне Каймакчига ычкындырса, Надия аны алдаган булып күренер иде. Юк, беркатлыланырга һич ярамый. Бары хатын-кыз гына белә торган серләрне читкә чәчү абруйны төшерә. Шул ук вакытта, эчке сиземе әйтә: горурлык өчен генә Каймакчины бу четерекле хәлдән азат итеп ахмакланма; материаль хәлең авыр, алда ни буласын белгән юк, ди. Шуның өчен кырт кисеп ташлама, Каймакчига өметләнергә урын калдыр. Күперләрне яндырма... Әнә ул һаман сине онытмаган, ярата ул. Үзеңне бер яратса, малай өчен исә ике яратыр. Ул югары баскычка күтәрелгән кеше, җитеш тормыш белән гомер итәчәк. Ә синең сәламәтлегең дә шәптән түгел. Шайтан ни белән шаяртмас, Каймакчи, бәлки, тормышын синең белән бәйләргә тәвәккәлләр? Син бит аны йөрәгең белән яраттың, нииндидер ярсу, үч белән сөйгән идең. Сугыш вакытында ир-атның түбәнсетүләреннән үч кайтару зәһәре аша аны йөрәгеңә алган идең. Каймакчи ташлап киткәч, тагын алдандым дип паникага төштең. Шул ук җанны кая куярга белмәгәнгә, Мәгариф кочагына кердең, шунда гына азрак тынычлану таптың. Элеккеге халәтеңә — аек акыл кималына кайттың. Акланып, горурлык җәрәхәтен дәваладың: Каймакчи бөтенләй башка склад кешесе, дидең.

Тынлык озакка сузыла башлагач, Надия Каймакчига күз чылгыен төшереп алды һәм бөтенләй ул көтмәгәнчә сөйләп китте:

— Сайкин бик әйбәт кеше, теге чагында аны бәладән коткаруыңа һаман рәхмәт укый...

— Бала аныкы дидең, үзе берни сизмиме?

— Ни әйтим, чынын мин үзем дә белмим,— диде Надия һәм бит очларына каушау кызыллыгы типте.

— Ничек белмисең?— Каймакчиның гаҗәпләнүдән күзләре маңгаена менде, кашлары җыерылып бергә тоташты. — Шулай буламыни?

— Була икән шул...

— Менә табышмак — әкәмәт димәсәң...

— Ышанмасаң — мәйлең.

— Безнең эштә бер-ике шундый «дело» булды. Мин анда үзләренә файдалы булганга шулай сөйлиләр дип уйлый идем. Чынын исбат итү авыр инде. Мөмкин дә түгел... Һәркем үз интересын гына кайгырта...

— Мине ташлап киткәндә син дә үз интересыңны гына кайгырттың бит, Павел?— Надия каушавын җиңде, шуңа тавышы да каты чыкты.

— Анда минем дә өмет акланмады...

— Хатынын икенче кешегә чыккан булганмыни?

— Әйтеп тормыйм,— дип Каймакчи кулын селтәде. Ул хакта телгә аласы килмәгән шикелле. — Малайнын мина охшаган жирен күрдем мин...

Ул погонлы кителенең бер жинен салды да эчке күлмәген өскә сыерып менгерде. Беләгенен терсәктән түбән эчке ягында йөзек зурлыгында көрән мине бар икән... Малайның беләгендә дә шушы тамга...

— Сайкин беләгенен дә нәкъ шул жирендә нәкъ шундый тамга,— диде Надия Каймакчига туры карап. Надиянең керфекләре дә селкенмәде. Ышансаң ышан, ышанмасаң юк...

Каймакчи жинен киеп кителен рәтләде. Ул Надия сүзләренә ышанмады, ләкин аны белгертмәде, торды да куен кесәсеннән бер төргәк акча чыгарып Надия алдына салды...

— Теләсә ничек уйла, Надия, мин сине хөрмәт итәм һәм гомердә дә онытмам! — Ул үзенен купшы сүзләреннән унайсызлангандай тиз генә фуражкасын киде дә ишеккә таба ыргылды... Коридорда замполит тавышы ишетелеп алды. Надия акчаларны тиз-тиз күкрәк уемына яшерде.

Надия эштән кайтканда өйдә карт ягында күрше кызы елап утыра иде. Таныш күренеш. Күрше бер аяксыз инвалид, эчеп кайта да өйдәгеләрне куып чыгара. Табак-савытларны ватып бетерә. Надия врачлар белән сөйләшеп, культясы авырта дигән булып, аны госпитальгә салып карады. Эчүеннән бераз бизмәсме дип өметләнгән иде. Гаиләсе дә бераз хәл алсын дигән иде. Өч айлап яткызды ул аны. Әле госпитальдән чыкканына бары 15 көн булып, үзенең элекке гадәтен куарга тотынган. Нигә эчә бу адәм баласы? Нәрсәсе тарта шул ачы суның? Ул тылсымлы бер эчемлек кебек. Кеше шуңа бер бәйләнсә, ычкына алмый һәм тәмам харап була. Ярый әле Мәгариф андый түгел. Нишләр идең, юләр. Чынлап та ул аракының әллә бер-бер тылсымы бармы икән? Дингездә һәлак булганнарга караганда стаканга батып үлүләр күбрәк бит.

Кыз тырыш бала иде, үзенең дәрес әсбапларын онытмаган. Надия аны мич артындагы кечкенә якка алып кереп өстәл янына утыртты. Дәресләрен карарга кушты. Кыз үзе атлыгып тора иде. Шунда ук белмәгән, аңламаган нәрсәләрен сорарга тотынды. Унайсызланып тормады. Анын сорауларына Надия бик теләп җавап бирә. Чөнки ана хәзер Павел белән очрашу калдырган халәттән тизрәк арынырга, шуны оныттыра торган нәрсәләр эшләргә кирәк. Менә бу кызның керүе кулай гына булды. Мәгариф кайтып күренгәндә дә Надия ана булышып утырачак. Йөзендәге үзгәрешләр шул шөгыльгә күмелеп, сизелмәячәк. Кәефе күтәренкелегән инвалидның эчүе өчен борчылу төсмерләре белән күмәчәк. Аннары бүген Мәгариф янына ятмаска сәбәп бар. Кыз үзе генә йокларга курка иде. Надия анын белән шушы якта гына калачак. Баланың рәшәткәле караваты да шушында... Павелдан йогып калган тузан бөртеге дә булмаска тиеш. Бәхеткә каршы, бала һаман Надиягә охшыйрак бара төсле. Павел чалымнары бер дә беленми. Әллә күрергә теләмимме? Яхшыга гына була күрсен инде. Мәгарифне генә яратам дип Павелның өметен өзсәм ни булган иде?! Ахмакны чәчеп үстермиләр шул. Чынын әйтәм, имеш, ялганламыйм. Үзен ялганга батып беткәнсен! Чын белән яшәп буламыни? Мәгариф бит әйбәт кеше! Юк, ул ясалма әйбәт була алмый, табигатьтән яхшы башлангыч белән туган. Мин шул кешене алдаладым. Ник? Ник башта ук барысын булганча аңа әйтмәдем? Чит кешеләр, әти-әни каршында әхлаклы, инсафлы булып күренер өчен генә шулай эшләдем. Тышкы тәүфыйклылык яуладым, ә эчтән алдау оятсызлыгына баттым. Һаман батуымны дәвам итәргә кирәк. Менә бит яши-яши күп нәрсәләр белә барасың. Элек белмәгән, житешмәгән нәрсәләр. Күпләрнең яшәү юлы беркем аяк басмаган сукмактан, тормыш

чирәмен ача-ача бара. Минем өчен Мәгариф тә ачылмаган чирәм әле. Мин дә аның өчен шулайдыр дип беләм. Мәгарифне мин аңым белән яраттым, хисләрем белән түгел. Аң белән ярату көчлерәк һәм тотрыклы, ныклы, ышанычлырак. Хис белән ярату тигез генә була алмый, ул көн кебек гел алмашынып тора. Бүген бар андый ярату, иртәгә бетә дә китә. Кранда су беткән кебек. Ул ышанычлы түгел. Кайберәүләр әнә шул ышанычсыз, таянычсыз хискә бирелеп, алданалар. Үз-үзләрен алдалап, әллә нинди ялгышлар ясап ташлыйлар. Хис белән яраткан кешеләр бер-берсенә тигез-тыныч була алмый. Аларда бер-берсенә карата көнләшү туа. Шул көнчелек кимерә башлый аларны. Ә аң белән ятратканда андый буталчыклар булмый. Парлар бер-берсенә тигез-тыныч мөнәсәбәттә була. Йолдызларга очу да, түбән чоңгылга тәгәрәү дә булмый. Нервлар саклана, организм үзенең көчен тигез тота, озакка житкерә...

Мәгариф, әйбәт кеше син. Синең әйбәтлегең минем начарлыгымны бетерә, юкка чыгара. Бер кешенең яхшылыгы әллә ничә адәмнең начарлыгын капларга житә икән. Син әйбәт булмасаң, минем начарлыгым беленер, фаш ителер иде. Шуның өчен генә дә мин сине мең тапкыр хөрмәт итәм, яратам. Яратуым-хөрмәтем торган саен тирәнәя генә бара...

Менә ул Артурны күтәреп кайтып керде. Ишек тупсасында Надия баланы үз кочагына алды. Үз ягына алып чыгып чишендерде. Рәшәткәле караватына утыртты. Теге кыз тизрәк аның янына килде, иркәли-сөя, уйната башлады. Улының тавышын ишетеп, үз киемнәрен кияргә өлгергән Мәгариф бүлмәгә кереп чыкты. Аның кәефе кырылып кайтканын Надия шунда ук сизде, ләкин үземнең серем беленә күрмәсен, үземне сатмагаем дип сагайды, күзен түбән төшеребрәк йөрде. Балага манный боткасы пешерү белән мәшгуль булды, шул эшне озаккарак сузарга тырышты. Мәгариф әтисе ягына чыгып киткәч ул иркен сулап куйды...

Иртән иртүк Надия кызны ашатып-эчертеп мәктәпкә озатты. Ул китүгә Мәгариф чыкты. Ул күңелсез, канәгатьсез иде.

— Нәрсә булды тагын?— диде Надия йомшак тавыш белән һәм чәй ясап аның алдына куйды.

— Әти белән чәкәләшеп алдык,— дип Мәгариф кул гына селтәде. Пычак алып зур кисәк патоканы бүлгәли башлады. Шикәр урынына шул бәрәңге балын саталар иде.

— Син бабайны чукып кына торасың, житәр инде,— диде Надия. Ул картны «әти» дип әйтергә кыймады, син иреннең әтисен әти дияргә тиеш дисәләр дә, үзен жинә алмады. Ул кечкенәдән рус мәктәбендә укыган, шулар белән аралашып үскән, татарның гореф-гадәтләренә өйрәнмәгән. Әти-әнисе дә иске йолаларны тота торган кешеләр түгел иде.

— Һаман шул динен ташлый алмый бит,— дип акланды Мәгариф. Бер кисәк патка кабып чәен уртлады.

— Аның мулла булып йөрүе синең хезмәт дәрәжәңә зыян итә дип юкка уйлыйсың, Мәгариф. Юкка!— дип Надия ире алдына өлеш тәлинкәсе белән бәрәңге боламыгы куйды.

— Гел төртеп күрсәтәләр, синең әтиең мулла икән, диләр. Ни әйтергә, оятымнан кая керергә белмим. Шул булдымы эш? Үз баласына бәла китереп торсын әле ата кеше! Үзе үк аңларга тиеш. Юк, һаман элеккегене куа...

Мәгарифнең бик каты ачуы купкан иде, ул хәтта ризыгын ашый алмады, бер якка этәрде дә чәй генә эчте.

— Атасы өчен улы җавап бирми дип әйтәләр бит.

— Сүздә ул шулай, ә гамәлдә башкача... Атасы кем? Мулла! Андый кешегә кем ышансын, кем аны җаваплы урынга куйсын? Беркемнең дә башы ике түгел. Һәркем як-ягына каранып кына эш итә.

— Аның муллалыгы хезмәт карьерасына суга микәнни соң? Кем белсен?— дип куйды Надия ире ягына авыша башлап.

— Мин карьерага омтылмыйм бит. Мина ышанмыйчарак карыйлар, минә нәрсә бик авыр! Аннан авыр нәрсә бармы икән?!

— Ышанмасалар, жанга бик авыр шул.

— Сина ышаналардыр анысы?

— Бер яралыга инфильтрация булды, энә стерилизацияләнмәгән, диделәр. Хәзер шул яралы укол ясаттырмый — мина ышанмый,— диде Надия гаеп үзендә икәнен яшермичә.

— Андый аерым кешеләр була ул, ә менә житәкчелек ышанмыйча караса, бик яман. Жанны бик нык изә. Бу бит сине кеше буларак инкарь итү. Менә нәрсәгә түзеп булмый...

***

Тире юу цехына барган иде Мәгариф, шунда теге Дәриянен туган тиешле апасы аны туктатты. Дәрия турында бик начар хәбәр әйтте. Үзе белгертмәскә кушкан булса да, барыбер беленер диде, андый хәлне яшереп калып буламыни: Дәрияне төрмәгә утыртканнар... Әй, бала, бала, хараплар гына булган инде... Апасының ике бите буйлап күз яшьләре эз салып төште. Мәгариф шаккатты да калды, теле тотлыкты. Мондый хәлне уена да китерә алмаган иде. Аның бу хәлгә ышанасы да килмәде хәтта. Апа да, шуны чамалап алып, тәфсилләргә керешге: шәһәрдән 60 чакрымдагы Кабаны дигән бер авылда икән. Башларым бетте инде, апа жаным, дип елый-елый язган. Сон япь-яшь кыз нишли алсын, шул күз яше түгәргә генә кала инде...

Мәгариф, кайтып, мәкалә язарга утыргач та, Дәрия турында уйлаудан туктый алмады. Язмышы нинди борылыш ясаган? Ай-һай! Ул бит мона үзе генә гаепле. Торфка жибәрсәләр, ни була иде? Ичмаса, ФЗӨдә һөнәргә өйрәнер иде. Ахыры ни яман булса да, төрмә түгел иде инде. Ни өчен вербовкадан качып авылына кайтып киткән, югыйсә кулга алуларын яхшы белә, анлый иде бит. Нәрсәдән килеп чыккан бу хәл? Әйе, колхозның завхозы, хәлле кеше, авылда авторитетлы кеше. Районнан килгән нәчәлникләр аларга гына төшә. Алар өчен өенә кушып салынган аерым ике бүлмә тота... Бәлки Дәрия һәм әти-әнисе шуларга исәп тоткан булганнардыр. Дәрияне чакырып кайтарганнардыр. Әмма тормыш һәм кешеләр бик тиз үзгәрә — бүген болай булса, иртәгә тегеләй. Эшне баштарак йөртмәгәннәр күрәсең. Район нәчәлникләре йолып кала алырлар иде. Әллә ни зур эш түгел бит. Эш шәһәр кулына килеп кергәч, авырая шул. Биредә хәзер район берни майтара алмый инде. Әй, бичара, бичара!

***

Мәгариф өчен янә урак өсте башлана — вузларда сессия якынлаша. Укыйсы материал тау кадәр. Ул укыган бер әйберсе хакында конспект язып бара. Кайберләрен Надиягә дә сөйли... Менә Ломоносов, нинди бөек кеше, энциклопедист булган. Докторлык диссертациясен шигырь белән язган. Патшаларга ода язудан да кыенсынмаган. Павел I гә бик шәп мактау одасы ижат иткән. Аны үтергәч, Екатерина II гә зур ода язып жибәргән. Оданы алгач, Екатерина II әйткән: Михаил Васильевич әле яна гына Павелга ода язган иде, инде озак та үтми, мине мактап шигырь чыгарган. Моны ничек анларга?..

Тарихчылар шәрехлиләр: Ломоносов моны монархларга ярау өчен дә эшләгән, диләр. Әнә нинди даһи кешеләр дә барышка жайлашу өчен тырышканнар. Ә без гади гүр ияләренә ни кала?

Надия йөрәк авыруын Мәгарифтән яшереп килә иде. Дөресрәге, үз-үзенә дә бу хакта таныргa базмый иде. Бер-ике мәртәбә йөрәк тотуыннан соң аны машина белән өйгә китереп куйдылар. Больничный да алгалады. Ләкин йөрәк әллә ни рәтләнмәде. Гидувка да салдылар. Госпитальгә аннан берничә врач килеп эшләп йөри иде. Танышлар. Шулар хәлен аңладылар һәм ярдәм иттеләр. Юкса, хәзерге вакытта, гидувка эләгү ансат түгел.

Китап укып ята-ята күзләр арыгач, Надия уйларга бирелә. Үләрмен микәнни дигән уй аның башына да килми. Тик нәрсәдәндер һаман малае хакында борчыла. Малае исенә төшә, күз алдына килә дә йөрәген лезвие белән сызып җибәргән кебек итеп китә. Ул тизрәк учы белән күкрәгенә ябыша. Авырту озак бармый, ләкин хәлен алып өлгерә. Бала бәгырьдән өзелеп төшкән шул, дип уйлый ул. Ә ник әле мин шөбһәләнәм? Әллә аннан тыш кына йөрәгем ни дә булса сизенәме? Соңгы вакытларда нәрсәдер эчем поша һәм Артур гел күз алдымда басып тора. Әллә үзен сагындыммы? Алай дисәң, әле кичә генә Мәгариф белән килеп киттеләр. Малай кинәт кенә үскән кебек булып, тереләнгән, сизелерлек әйбәтләнгән. Тагын да сөясе килеп тора үзен. Мәгариф тырыша, шул бала өчен үлә инде... Әмма моның соңы ничек булыр? Артурның Павелга охшаган чалымнары таныш. Тора-бара ул нык сизелеп торса? Мәгариф Павелны бик шәп хәтерли, аның һәр төсмере, йөзендәге һәр сызыгы миенә уелып калгандыр. Алдавым ачылса, нишләрмен? Мәгариф мине ташлап китәрме? Ничектер ышандырмый. Юк, ул горур, гарьләнүчән кеше. Бу ялганны күтәреп яши алмас. Димәк, китә. Аннары нәрсә? Павел белән нишләргә? Ул хәзер өйләнгәндер, үз гаиләсе бардыр. Гаилә камытын кигәч, ир-ат үзгәрә, бөтенләй икенче кешегә әйләнә, вакчыллана, тиеннәр саный башлый. Чөнки хатыны кысанлыкка өйрәтә. Хатын-кыз гуж, аңа берни дә житми, ул төпсез тоба. Мин – Надия дә шулаймы икән? Юк, Мәгариф үзе бик сакчыл, экономный кеше. Гаилә тәртәсенә җигелгәч Павел да үзгәргәндер. Малайны онытмыйм, книжкага салып барам, диде дә, кая инде. Сүзләре гамәлгә туры килсә, һәркем патша булыр иде. Павелның хатыны гаилә кучерында утыра, кулында чыбыркы. Читтәге әллә нинди малаеңны түгел, туган анаңны онытырсың. Теләмәсәң, чыбыркылап оныттырыр.

Мин дөреслектән, ялгызлык газабыннан курыктым. Без электән үк чын дөресен әйтергә, ачарга ярамый дигән кагыйдәне ишетеп үсәбез. Дөреслекне әйткәнгә җәза бирелә. Бала чактан ук шулай. Җәзадан куркып, чынны яшерәбез, ялган артына посабыз. Менә ни өчен балалар күп ялганлый. Дөресен әйтергә ярамау һавага сеңгән. Җәзага эләкмәү өчен адәм баласы әллә ниләргә бара. Әллә нинди ялганнар уйлап чыгара. Башта ялганласаң, аннары гел шуны дәвам итәргә туры килә. Юкка тотылуың һәм бар корган нәрсәң җимерелеп төшүе мөмкин. Дөреслекне ачарга шүрләп ялганга тирәнрәк бата барасың. Бервакыт карыйсың, ялганнан инде чыгып булырлык түгел. Ялган капкынына бик каты эләккәнсең. Менә мин хәзер шул капкында. Нишләргә, ничек котылырга?

Ул Павел йөри тагын. Безнең материаль яктан житкелекле яшәмәвебезне белеп килгән инде ул. Ник аңа минем яннан эзенне суыт, бүтән күренеп йөрмә дип әйтмәдем.Ул акыллы кеше, үзе дә аңларга тиеш иде. Сер ачылса корбан булуы ихтимал. Мәгарифкә ишетелүе бар. Ул биреп киткән әйберләрне мин гомерен саклап алып калган өчен бер полковник бүләк итеп китерде дип әйттем. Андый бүләкләр булгалый. Билгеле, комсоставлардан. Ялганларга тормыш фактын файдаландым. Юк, Павел белән бернинди бәйләнеш булырга тиеш түгел. Өзелгән, беткән. Бүтән ялганмый инде ул. Мин көч-хәл белән корган тормышны бетерергә йөрмәсен! Кабат күренсә, минем хакта бөтенләй оныт, исеңә дә төшермә дип аңлатырга кирәк.

Малайны да бар дип белмәсен, хәтеренә дә алмасын. Андый ир-атлар күп бит. Ирләр элеккегеләрне онытырга ярата. Павелга якты йөз күрсәтеп начар эшләдем. Горурлыгым бөтенләй юк икән. Мин горурлыгымны саклар өчен дөреслекне яшердем бит. Якын кешеләр алдында әйбәт, итагатьле булып күренү өчен.

Ничек башланды бу хикмәт? Павелдан ышанычым алдангач, ниндидер үчегү, үҗәтләнү белән үзем дә яхшы-яманны шәйләп тормадым. Рас мине алдаганнар икән, нигә мин барын да үз өстемә алып торырга тиеш? Әллә мин корбанмы? Юк, минем корбан буласым килмәде. Мине төп башына утырткannар икән, нигә мина кәнфитләнеп торырга дигән кайнар үчле фикер юл ярды. Шул үчем белән мин Мәгарифкә барып ябыштым. Аны кулдан ычкындырмас өчен шул ялганнан тайпылмадым. Баламны законлы аталы итү минем өчен иң мөһим максат булды. Күпме яралының гомерен саклап калдым мин. Күпме алар мина рәхмәт укыдылар һәм укыйлар! Мин хурлыкка лаек түгел идем. Үземне хөрмәткә хаклы санадым. Бу нәрсә мина көч бирде. Дәрәҗәмне төшерергә теләмәдем. Үч кайтарырга үземне хокуклы итеп сиздем. Сина ташланалар икән, яки кеше буларак түбән төшерәләр икән, син үзенне яклый белергә тиешсең. Саклану өчен эшләнгән әмәл судта да аклана...

Үч дәртенә бирелеп мин Мәгарифне яратып киттем. Әйе, аны яратуыма үч тә булышты. Рәнҗетелгән хисләрем әле терелеп җитмәгән иде, мин аң белән, акыл белән яраттым. Хисләр белән ярату озак чыдамый, ныксыз, ә акыл белән кешегә нык берегәсең. Моны тегенди-мондый чит җилләр какшата да, бора да алмый...

***

Надия, күптән больничныйдан чыгып, эшкә йөри башлады. Бер кичне сменага барырга әзерләнеп йөргәндә, абыйсының хатыны маржа җингәсе килеп керде дә өстәлгә башын куеп үксергә тотынды. Надия ни булды, ни, дип янына килеп басты. Теге һаман үкси, йөзен учлары белән каплаган. Анын берәр нәрсә булса, әйтми-нитми, үксеп интектерә торган гадәте бар иде. Шуна Надия анын янында бары әдәплелек өчен генә торды. Елап, эчен бушатып бетергәнен көтте. Берәр юк-бар өчендер әле. Шулай күз яше чыгарган булып, абыйнын теңкәсенә тиеп, нервысын бетерде инде. Абый үзе бик иркәләп хатынын бозды, узындырды. Үзе, райкомда күренекле урын били торган кеше.

— Абыеңны эштән чыгарганнар,— диде чибәр йөзле килен, анын битләре коры иде. Күзләре әз генә кызарган сыман.

— Ни өчен? Булмаганны!— диде Надия киленнең сүзләренә ышанып җитмәде, шулай да эчке уйлары кан тамырларында ут кебек йөгерешә башлады.

— Шул акчаларын аркасында,— диде килен кинәт нормаль төскә кереп. — Мина әйтмичә, астан эшләдегез. Һәм менә җәзасы! Минем кинәштән башка берәр нәрсә кылса, көт тә тор, берәр бәлагә юлыкмый калмый. Хәзер үзе дә аңлаган, ләкин терсәк ерак...

Киленнең сүзләре Надиянең башына китереп суккандай итте. Ул сул күкрәгенә учын куйган килеш өстәлнең икенче ягына килеп утырды. Бик зур бәхетсезлек булганлыгы миенә зарбы ясады. Шуларданмы йөрәге тагын энә белән чәнчегән кебек булып авыртып китте. Ул шкафтан үрелеп кенә дару алды, иң элек киленгә бер микструра алып бирде, аннан үзе эчеп куйды. Каһәр суккан акчалар! Павел ана 12 мең сум биреп киткән иде. Һаман яшереп тотты. Акча алышынуы турында ишеткәч, абыйсынын эшенә йөгереп барды. Кассага салган акчаларның бәясе төшми икән, дип ана кемдер

килеп пышылдаган иде. Ә болай 10 сум бер сумга кала иде. Аерма бик зур. Надиянең коты чыкты һәм абыйсына ярдәмгә чапты. Күрәчәген булса, күзең күрмәс була, диләр. Надия белән дә нәкъ шулай килеп чыкты. Житмәсә, иртәгә алышына дигән көн. Райком кешесенең үтенечен үтәгәннәр. Акчалар кассага алынган... Надия акчалар сакланды дип күнеленнән сөенеп йөргән иде. Менә бервакытта да иртә сөенмә! Иртә сөенү көенүгә генә була.

Маржа килен бигрәк тә үзен читләтеп үткән өчен үртәлә иде шикелле. Ирен райкомнан чыгарганга түгел. Абый аның сүзе белән генә йөри иде. Сугыштан кайтуга аны райкомга алганнар иде. Килен бу хәлне, мин тиешле жиргә барып әйттем дә, шул жаваплы эшкә куйдылар, дип сөйләнде. Моны үз хезмәте итеп куйды. Абый нәрсә генә эшләсә дә, минем киңәш белән эшләде ул аны, ди. Һәр ирешкәнне үзенеке итеп күрсәтеп өлгерә. Бер дә унайсызланып тормый. Абый тир түгә, борчыла, төн йокламый, ә маржа килен исә, миннән башка Надим бер адым да атлый алмый, дип барысын үзенә кайтарып калдыра. Шул чакта абыйның бик күнеле була. Килен дә үзен бик акыллы хатын, аннан башка тормыш бара алмый кебек төстә тоя. Бик куана, канатлана. Абый аны сөендерер, очындырыр өчен шулай үзенең эшен аныкы итеп күрсәтеп киләме? Юк, абый үз хатынына ялагайлана иде шикелле. Әллә бу үзенчә хөрмәт, ярату булды микән? Һәрхәлдә, абый бар хезмәтен хатыныныкы итеп күрсәтүчән булып китте. Менә апагыз нинди эшләр башкарып йөри әле, дип хатыны белән горурлана иде. Аны үзенә патша итеп куйды. Апагыз, шулай дип әйтте, болай дип әйтте дип, хатыны сүзен зур итеп санау аның гадәтенә керде. Апагыздан башка безнең тормыш бармас иде дип тәкърарлаганда Надиянең ачуы куба иде. Ләкин ул хисен абыйсына белгертмәде. Чөнки килен күнеле белән әйбәт кеше, абыйсына бик бирелгән, тугрылыклы. Сансызланмый, әмма холкын күрсәтеп алгалый.

Берничә көннән соң Надия абыйсы янына сөйләшергә барды. Шул акчалар аркасында фажига килеп чыктымы, әллә алар гөнаһ савытын тутыручы соңгы тамчылар гына булдымы? Гаепләү исемлегенә керсәң, әмәлләр табыла инде ул. Ләкин абыйлары тапсыз, югары бәяләнә торган кадр иде. Артын-алдын карап эшләүче, тотнаклы, анардан бер артык сүз дә ала алмыйсың. Көн-төн үз өстендә эшли. Ике еллык партия мәктәбен тәмамлады... Неужели шул тикле жәза бирерләр икән? Килен бик күпертергә ярата...

Ишекне һәрвакыттагыча килен ачты. Чәчләрендә бигуди көпшәләре, карбыз чаклы биек күкрәкләре чуар халатыннан яртылаш күренеп тора. Надияне күргәч, аның күзләре зур булып ачылды, борын тишекләре киерелде, өске тешләре алгарак чыкты, ул ачудан муенын кабартып корбанына ташланырга әзер жәнлек кебек. Унга таба тайпылып, үрелеп нидер алды да, Надия алдына томырды.

— Мә, акчаларыңны!— дип ысылдады һәм борын төбендә ишекне шап итеп ябып куйды.

Надия төргәкне сумкасына салды һәм баскычтан төшәргә борылды.

Надия ачулана алмады. Килен гадел эшләде. Аның урынында һәркем шулай итәр иде. Ирен бәлагә төшерүгә сәбәпче булган кешегә бүтәнчә нинди мөнәсәбәт булуы мөмкин. Надия абыйсын зур дәрәжәдән төшерүен бик авыр кичергән иде. Бу көннәрдә үзен-үзе эчтән жәзалап яшәде. Үзен генә гаепләде. Нишләргә, кая керергә белмәде. Бу кайгысын Мәгариф белән дә бүлешә алмый иде. Шунда тагын үзен-үзе каргады. Менә бит абыйны да бәхетсез иттем. Бу акча дигән нәрсәдә иблис утыра, ахрысы, шул иблис котыртты мине. Акча белән бергә иблис йөри дигәнне ишеткәне бар иде. Бакча аша узасың да, акча аша уза алмыйсың икән. Акчага кызыкмый да булмый шул, бар нәрсә акчага бит.

Маржа килен хәзер абыйның жилеген суыра инде. Менә синең

туганнарын нинди, дип күзен дә ачырмый торгандыр. Мин сина әйтә килдем, син колагына элмәден. Тагын әллә ниләр. Ул телгә оста, чәт-чәт килеп тора.

Тукта, бу хәл Мәгарифкә ишетелсә, нишләрмен? Килен аны житкерми калмас. Ул хәзер авызлыгын тешләп чапкан дуамал ат кебек. Әнине әзерләп куярга кирәк: минем заемга откан акчам иде, дисен. Надия хараплар итте дип мине тиргәсен. Барысы да мине тиргәсеннәр, мина шулай жинелрәк булыр. Чөнки нинди дер дәрәжәдә мине каргап ачулары кайта, гаебем дә түләнеп, бераз гына йолынган кебек тоелыр. Өстемә алган каргыш түләвем булып чыга. Гаепкә жәза табигый нәрсә. Артык авыр булмый.

Ул акчаны мин балам өчен булыр дип саклый идем. Анын өлешенә тигән көмешенен ун мәртәбә төшүе белән күнел ничектер килешмәде. Һаман да шул нәфсе. Кеше картаер, нәфсе картаймас, дип юкка гына әйтмәгәннәр. Балама яхшылык эшлим дип, күпме кешене бәхетсез итеп ташладым. Һич ярамый иде. Бигрәк тә маржа килен алдында оят. Элек тә безнен турыда фикере шәптән түгел иде. Менә шул фикерләренә зур дәлил табылды. Болай да абыйны үзенен үкчәсе астында тота иде. Хәзер нишләрләр инде. Юк, ул акыллы, башлы хатын. Барыш пружинасын яхшы белә. Фикер йөртергә батырлыгы да бар. Абыйны бу көе калдырмас...

Шушы жанга йөк булып төшә торган хәлләрдән сон Надиягә тагын больницага керергә туры килде. Аны Домрачев шифаханәсенә салдылар. Биредә нигездә язвинниклар иде, әмма йөрәк белән авыручыларнын да бер палатасы бар икән. Язваларга операция ясыйлар, ә йөрәкне төрле уколлар, дарулар белән дәвалыйлар.

Һәр кич саен диярлек күрше ишегалдыннан музыка ишетелә. Яшьләр бер агач ботагына лампочка сузганнар, шунда урындыкка радиола чыгарып куйганнар. Пар-пар булып танцада әйләнәләр. «Сирень куагы», «Арыган кояш» дигән гажәп монлы танголар. Бу көйләр Надиянен уйларын әллә кайларга, үткәннәргә алып китәләр... Госпиталь урнашкан зур казармалар янында тәрәзәләре түшәм янына ук куелган тагын бер жыйнак кына бина бар иде. Немецларнын казиносы булган ул. Шунда танца залын күреп алганнар. Движоктан мона ут уздырып, октябрь бәйрәмен билгеләү өчен шәп урын әзерләгәннәр. Рәсми бүлекне тиз тоттылар. Беренче вальсны Надия үзенен бүлмәдәш кызы белән биеде. Әй, рәхәт! Жанга канат чыккан диярсен. Икенче вальска пластинка алыштырдылар. Шулчак анын каршына калын кашлы, кин мангайлы, көрәнсуырак йөзле гажәп сөйкемле бер лейтенант килеп басты. Кызлар урындыкларда тезелеп утыралар иде. Ә ул килде дә ничәмә-ничә кыз арасыннан бер Надиягә кулын сузды. Гажәп иде бу. Надия як-ягына каранды. Әллә берәр шаяртумы? Надиянен тез буыннары бушап калган кебек булды. Сер бирмәде, житез генә егетнен кулларына тотынып, музыка ритмына кереп китте. Бераз биегәннән сон, егет үзенен исемен Павел, диде. Надия дә әйтте. Ул егетнен йомшак куллары аша үзенә нинди дер дулкын сыман нәрсә агылганын сизгәндәй булды. Нәрсә икән бу, дип эчтән генә аны гажәпләнде. Жавап таба алмады. Егетнен күзләре дә очкынлы, ничектер төнлә күбәләкләрне үзенә тарта торган ут кебек иде. Күбәләкләр утка киләләр дә янып һәлак булалар. Утны бары яктылык итеп кенә беләләр, анын яндыруын исәпләмиләр... Мин дә шул күбәләк кебек булдым инде... Бер мин генәме? Кызлар барысы да күбәләкләр...

Менә ишегалдында пластинканы алыштырдылар. Татар тангосын куйдылар. Бу көйне бар жирдә жырлыйлар хәзер.

> Кайтырсын дип мин өмет итәм,
> Мин сине көтәм, көтәм, көтәм....

Аналар, хатын-кызлар һаман кемне дә булса көтәләр. Бу елларда әсирлектә булганнарны күпләп кайтара башладылар. Аларны Германияне азат иткәннән соң туры Себергә озаткан булганнар икән. Күбесенең әле дә язмышы билгесез, хәбәрсез югалганнар дип әйтәләр...

Кызлар, егетләр бәхетле, чыр-чу килеп бииләр. Тагын нинди кызлар-күбәләкләрнең кемнәр утында янасы бар икән? Кызлар-күбәләкләр һаман утка таба омтыла. Утка, утка! Бары утка гына! Бүтән әмәл юк. Янсаң янып калырга, көйсәң, көеп калырга! Утка! Утка! Ул да шундый утка ташланып янды...

***

Мәгариф әтисен дәһри итәргә ныклап кереште. Моңа ныклы сәбәпләр бар иде. Тарик Фәррахович Татиздатка эшкә күчте. Үз урынына Лена Идалованы калдырды. Мәгариф шуңа үлеп гарьләнде. Тарик озак кына эштә күренмәде, аннары гына күчкәне турында әйттеләр. Күзгә-күз очрашудан, ихлас сөйләшүдән качыбрак йөрүеннән Мәгариф нидер сизенгән иде. Бу ник болай итә икән дип уйлаган иде ул чакта. Менә хәзер ник икәне анлашылды... Шулай булмый ни, мине үз урынына калдырам дип әйткәне бар иде. Ул аны онытмаган бит. Үз урынына лаек икәнемне дә эчтән танымый хәле юк. Газетада языла торган барча яңа материалны мин эшләгәнне дә яхшы белә. Әмма кинәт кенә һава үзгәреп киткән, җилләр миңа каршы искән. Тарик аз гына җаваплылыкны да үз өстенә ала торганнардан түгел. Агымга кушылып сайлаучы. Очрашса, эчендәге шул уйлары беленер дип тә шүрләгәндер. Үзенең сүзендә тора алмавына да уңайсызлангандыр. Мин аны гына аңларлык — биредә Тарикның гаебе юк. Әмма күпме дус булып йөреп, берни әйтмичә китүе шиккә төшерә. Мине редактор итү-итмәү хакында сүз булгандыр, Тарик шунда якламагандыр. Бер-ике төпле, кире какмаслык сүз әйтсә, партком аңа каршы килмәс иде. Тарикның анда сүзе үтә. Юк, ул хәлиткеч сүзләрне әйтмәгән. Алар белән бозылышасы килмәгән. Аның иң яраткан тактикасы — өстәгеләр белән берничек тә каршылыкка кермәү. Бер үк вакытта начальникларга һәм үз кул астындагыларга ярау мөмкин түгел ул. Билгеле, һәркем диярлек начальникларга баш июне сайлый, шулай файдалы. Бу инде язылмаган закон...

Минем нинди хилаф ягым бар икән соң? Хикмәт минем биографиямдә, әтинең мулла булуында...

Әмма әтисе һаман үзенекен тукыды, диненнән китәргә теләмәде. Бик каты торды.

— Ничек инде мин имансыз калыйм?— диде. — Адәм баласына бер иман кирәк ул!

— Безнең тәгълимат та иман бит, яңа иман!— дип каршы төште Мәгариф. —Алласы да бар — Ленин! Ул Алла, реаль! Ә син әллә нинди әкият аллаларына ышанып алданып йөрисең. Барысы да уйлап чыгарылган, Ленин — чын. Уйлап чыгарылмаган. Син үз акылыңда ләбаса, төрле юк-бар нәрсәләргә ышанасың. Ленинга ойыйсың килми...

— Ленин пәйгамбәр кебек, дисең, ә алайса могҗизасы кайда?— диде карт улын төп башына утыртырга теләгәндәй.

— Менә ирекле, яңа тормыш төзеде, шул могҗиза түгелме?— дип Мәгариф кызып китте. — Бу тормыш өчен коллар мең еллар буе көрәшеп килгәннәр. Спартакны укыганың бар бит. Шушы азатлык өчен канын койган. Аның кебек тагын миллионнар...

— Мин Ленинны яратам анысы, чын күңелдән. Ләкин аның үзен пәйгамбәр, тәгълиматын дин кебек итеп күңелемә сеңдерә алмыйм.

— Теләсәң, сеңдерә аласың, сөйләмә!

— Менә син чит тел өйрәнә аласыңмы хәзер? — Юк. Дин дә шуның кебек, кечкенәдән иман итеп кеше күңеленә салына. Олыгайгач, икенче дингә күчеп булмый.

— Дөрес әйтәсең, әти...— Мәгариф әтисен хуплаган булып, үз ягына аудармакчы итә иде. Әмма картның үз кырыгы кырык. Катырак бәрелсәң, отыры карыша. Шуның өчен йон унаена сыпырырга кирәк.

Алар хәзер һәр көн бәхәсләшәләр. Баланы әбигә тапшыргач, вакыт күп кала. Әштәге әбәд чорында Надия янына кереп чыга. Ара ерак түгел.

Кич белән сүз көрәштерә-көрәштерә әтисен тәмам аркасы белән сала ул. Карт аның дәлилләре белән килешә. Дөньяны, аның чыгырларын аңлаган кебек була. Башлы ул үзе, искелеккә чеpәшеп катмаган. Чөнки тормыш аны нык кына каккан-суккан, үзенең сабагына өйрәткән. Тормыш бит ул акыллы укытучы кебек дип әйтергә ярата ул. Зиһене эшли әле. Гомер буе аракы эчмәгән, тәмәке тартмаган. Эшләмичә бер көн дә яшәмәгән. Хәзер дә тик тормый. Парфюмерия кибетендә төнге каравылда. Ишекләрне яхшылап бикли дә йоклап ала. Җылы, әйбәт. Көндезләрен өйгә өстәп тагын бер бүлмә эшләргә тотына. Артурга булыр, укый башласа, үз почмагы кирәгер ди...

Мәгариф кич белән (бүген картның сменасы түгел иде) әтисен үгетләде дә үгетләде. Башта гозерләнеп карады, аннан каты-каты сүзләр әйтеп ташлады. Тәмам нервысы чыкты. Ике күзеннән яшь агарга тотынды. Карт шуннна соң гына йомшады, сынды.

Шушы момент күптән көтелгән иде. Мәгарифнең барысы да әзер. Ул алдан хәстәрен күрде. «Белем» җәмгыятендә Әхмәтов Тәлгат дигән кеше мөселманнарны дин сөременнән коткара, баш тарттыру буенча эшли икән. Үзе Коръәнне бик яхшы белә, аңлата, исбатлый. Һәр сүрәне шәрехләп тәрҗемә итә. Диненнән ваз кичүчеләргә кыска гына текст язып бирә. Ваз кичүче шуны йә гәзиттә бастырып чыгара, йә радиодан укый.

Карт үзенең тәүбәсен эфир аша белгертсә әйбәтрәк булыр дип уйланылды. Әхмәтов динне фаш итеп сала торган лекция белән чыгачак икән. Менә шуның артыннан ул сөйләгәннәргә дәлил рәвешендә картка сүз бирелер.

Яналифчә син бит яхшы укыйсың, диде Мәгариф бер битле текстны аңа сузып. Әтисе ятып тора иде. Теге «сынган», риза булган көннән соң кәефем юк дип еш әйтә башлады. Эндәшмәскә әйләнде. Ул кәгазь битен бармаклары арасына кысты, әмма кулы калтырарга тотынды. Уң кулын сулы белән эләктереп торырга мәҗбүр булды. Текстны эчтән генә укыды. Кайбер тәгъбирләрне аңлап җитмәде. Шуна тагын бер мәртәбә күз йөртеп чыкты. Бер кулын баш астына куеп уйга чумды. Күзләре йомылды. Аның чырае нигә мине газаплыйлар, минем динле булуым кемгә комачау итә, кемгә шуның зарары тия соң, дигән төстә иде.

Иртән торып бер сүз сөйләшми генә чәй эчтеләр, бер сүз алышмый гына киенделәр.

Бина эченә кереп, тар гына тимер баскычтан өске катка менделәр. Анда шулай ук тар гына биек түшәмле коридор иде. Тар биек ишекләр тезелеп киткән. Урындыкларга утырдылар. Кайсыдыр ишектән чыгып, алар алдына озын гына берәү килеп басты. Кулына кәгазь битләре тоткан. Ул Әхмәтовны белә иде, үз кешеләр кебек сөйләшеп киттеләр. Тапшыру турында кыска аңлашып, тәгаенләп алдылар. Аннары теге картка таба борылып, аңа инструктаж бирде, кат-кат аңлатты. Микрофон алдында тамак кырырга ярамый, дип тукыды. Берние юк, каушама гына, үзеңне нык тот, диде ул.

Шулчак каршыдагы биек ишектән карасу озынча йөзле, мөлаем бер хатын-кыз чыкты да: «Сез әзерме, башлыйбыз!,— дип теге озынга дәште. Тавышы гаҗәп ягымлы иде. «Без әзер!»— диде озын. «Әйдәгез!»— дип хатын

Әхмәтов белән картка карады. Ул инде барысын да белә иде. Әхмәтов, торып, картның беләгеннән тотты. Хатын бүлмә ишеген ачкан иде. Әхмәтов картны шунда алып кереп китте. Зур гына ярым караңгы бүлмә иде, өстәл янына килеп утырдылар. Әхмәтов үзе укыйсы кәгазь битләрен алдына куйды, карт алдына да бер бит чыгарып салды. Һәм ым белән шушыны укырсың дип искәртте. Бүлмәнең кай төшендәдер микрофон шытырдавы һәм теге озынның: «Башла»,— дигән тавышы ишетелде. Хатын Әхмәтовка ым какты. Һәм Әхмәтов өстәл өстендә яткан бер битне кулына тотып укый башлады. Аның бу эштә бик шомарганлыгы сизелеп тора. Бик аңлаешлы, көчле мәкам белән сиптерә генә. Ул диннең уйлап чыгарылган булуын, өстен сыйныфларның гади халыкны изү өчен кулланыла торган өскормә әмәл икәнен күп мисаллар китереп исбатларга тотынды. Дәлилләре бик көчле, ышандырырлык иде. Ул сүзен: хәзер сезнең алда дин сөременнән үзен арындырган, күп еллар мулла булып йөргән Сайкин иптәш чыгыш ясый, дип тәмамлады.

Каршыда утыручы хатын картка ым белән «башла» дигәнне белгертте. Карт әз генә каушап калды, кәгазь битен тоткан кулы калтырый иде. Ул укырга тотынды, тавышы да калтыраулы. Икенче җөмләсендә төртелде. Ыкы-мыкы килеп торды, аннан укып китте. Тавыш калтыравы бетмәде. Азагына чаклы шундый тавыш булды. Борын очыннан тир бөртекләре тамды.

Укып бетергәч, бүлмәдә тагын бер лампочка кабынды. Ишек ачылды. Әхмәтов каушап, хәлсезләнебрәк киткән картны култыгыннан тотып ишеккә алып барды. Мәгариф әтисен күзәтте — бераз төсе киткән, әмма үз көчендә кебек. Бит очларына әз генә алсулык йөгергән.

— Бүген кичке сигездә эфирга чыгарабыз,— диде хатын аларны озатканда.

Әхмәтов, картның беләгеннән тоткан килеш, аңа авыша төшебрәк һаман сөйләде. Үзе гел елмаеп кына тора иде. Коръәннән бер дога әйтә дә, шуны татарчалаштыра. Һәр сүзне тәрҗемә итә, төрле мәгънәләрен төрле тәгъбирләрдә китерә. Мөхәммәд пәйгамбәрнең шәхси тормышында булган хәлләрне сөйли.

Ул аларны Ленин бакчасына хәтле озата төште. Бер сөйләшеп утырырга килермен әле, диде елмая-елмая.

Өйгә кайтып чәй эчәргә утырдылар. «Ну, әти, ничек», —диде Мәгариф чынаякларга бүлә-бүлә. Сорау мәгънәсезрәк килеп чыкты. «Менә котыңны алып торган динеңнән ваз кичтең, күңелеңдә берәр төрле үзгәреш бармы?»

Карт ачуланып кулын селтәде дә үз ягына кереп китте. Мәгарифнең сүзне зурга җибәрәсе, үзенекен исбат итәсе килмәде. Бүген болай да карт өчен бик киеренке көн булды. Әйдә, ул аны ныграк ачулансын, эчендәге бар ачуын минем өскә түксен дигән уйда торды.

Радио кухняда иде. Кичке чәй вакытында Әхмәтов белән әтисенең сөйләгәннәрен тыңладылар. Карт йөзен чытып утырды. Эчен нидер кимерә иде аның. Мәгариф эндәшмәде, картның баягы кебек кабынып китүеннән шүрләде. Ярасына кагылмаска кирәк.

Эштә аны теге кырыс партком күреп алды. Бик җылы елмаеп кул бирде. Эшләр барамы, дип хәл-әхвәл белеште. Теге радиодан сөйләгән Сайкин синең әтиең мәллә, дип сорап куйды. Аның Мәгарифнең әтисе икәнен белгәнлеге сизелеп тора иде. Сынау өчен телен тартып карыйсы килгәндер, мөгаен. Мәгариф баш кагып кына җавап бирде. Партком картны мактады: нинди зиһенле, акыллы, диде, ничек, үзе шундый фикергә килдеме, синең дә йогынтың булдымы?

— Үзе, үзе,— диде Мәгариф горурланып.

— Молодец, карт, ә?— дип, тагын бер-ике хуплау сүзе әйтте дә, газета турында сораша башлады. — Карале, бу Идалова редактор булгач, газета бераз сүрәнләнә төште шикелле әле бит?! Син ничек уйлыйсын?

— Белмим шул, алай микәнни?— дигән булды Мәгариф туры фикерен әйтергә теләмичә. Идалова турында кире сүз әйтүдән тыелды. Дөрес анламаулары мөмкин. Үзен белән бергә эшләп, бер бүлмәдә утыра торган кешенең артында сөйләү әхлаксызлык ич.

...Ә бит артымда мине сөйлиләр, гел яманлап кына — мулла малае диләр, ана иске караш йоккан булырга тиеш дип тел озайталар. Нигә соң әле мина да үз нәүбәтемдә бүтәннәрне сөйләмәскә? Юкса мин юләр булып калам бит... Башкалар ни эшләсә, син дә шуны эшләргә тиеш. Моннан соң ушлырак булырга кирәк.

...Әнә әтинең радиодан сөйләве парткомга ошаган. Фикере унайга борыла башлаган күренә, бөтенләй икенче төрле карый. Мине күтәрергә чамалый түгелме? Ничектер өметләндергеч итеп сөйләште...

Эш арасында Надия янына барып килде. Анын хәлендә әллә ни алга китеш сизелми иде. Мәгариф партком белән сөйләшүдән туган шатлыгын белгертмәскә тырышты. Әтисенең радиодан сөйләве хакында да әйтмәде. Ярый әле, Надия берни дә ишетмәгән. Хәле чит нәрсәләр белән кызыксынырлык түгел шул. Менә яна дару биргәннәр, шул бераз арулатып җибәрде ди. Надия һаман Артур хакында гына сорашты. Зиһенендә бары шул гына, ахрысы, шуны гына уйлап ята булыр. Бүтән берни белән дә кызыксынуын белгертми. Артурга ни булсын, ул чаба да чаба, анда-монда эше юк.

Өйгә кайткач, Мәгариф эчендәге сөенечен әтисенә сөйләмәкче булды. Тик әтисе башын мендәргә күмеп, ике беләге белән кочаклап яткан. Башым бик авырта, утны яндырма, диде. Ул ынгырашып-ынгырашып куйды. Мәгариф «тройчатка» дигән дару алып килеп эчерде. Картнын төсе әйбәт түгел иде. Мангай тамырлары юанаеп киткән шикелле тоелды. Ярар, үтәр, анын болай да вакыт-вакыт авыртуы янарып тора... Үтә торган иде әле...

Мәгариф эштән туры фабрикага китте. Кешеләрне күреп материал аласы бар иде.

Цехта Дәриянең апасы очрады. Мәгарифне бер почмаккарак алып китте дә, еларга тотынды. Дәрияне җәлләп елый. Алар яныннан бер хатын-кыз срогын тутырып кайткан һәм ана килеп Дәриянең хәлен сөйләгән. Кызыбыз беткән, кызыбыз беткән, дия-дия яшен тыя алмады апасы. Бик әшәке бандитлар кулына эләккән. Йә малын, йә жанын дип пычак кына күрсәтәләр дә, теләсә нишләтәләр икән. Нинди генә каргышларга юлыгып бәхетсез булды бу бала? Чибәр булганга шулай бәла ябырылды ана, матурлар бәхетсез булалар диләр иде аны... Инде ни хәлләр итәргә? Әти-әнисе анын кайгысыннан үләр чиккә житкән. Моны ишетсәләр, бөтенләй ычкыныр-лар... Ичмаса син, Мәгариф, бер-бер әмәл эшли алмыйсынмы?

Мәгариф үзенең көчсезлеген танығандай күзләрен аска төбәде. Йөзендәге кайгы төсмерләре битләрен сорыландырып, ияк, борынын зәңгәрсуландырып җибәргән иде. Нишли генә алсын инде ул? Нәчәлникләр тирәсендәрәк чуалганга әйтә торгандыр, мөгаен. Апа, ул эштә беркем беркемгә ярдәм итә алмый, диде Мәгариф кайгылы тостә. Менә авыл советыннан ходатайство алып, әти-әнисе йөреп караса гына берәр эш чыгаруы мөмкин. Ә болай юк... Апа шул киңәшкә дә бик сөенде. Үзләре дә шул исәп белән Казанга килгәннәр икән, әйтим әле алайса, нәтиҗәсе булмый калмас диде...

Апа миннән әллә ни өмет итмәгән шикелле дип үзен юата-юата атлады Мәгариф. Ул ярдәм итәргә бик теләсә дә, берни чыгара алмас иде.

Һәркем үз тиресе, өне-көне өчен калтырап тора бит. Мин дә үз тиремне кайгыртам, ник яшереп маташырга? Һәркемнен үзенеке үзенә житкән. Без һаман китапча үлчәүләр белән уй йөртәбез. Өметләр дә китапча канатлана. Тормыш ул канатларны сындыра, имгәтә... Бәлки бу процесс шулай кирәктер. Кешеләр рәхәтлеккә өйрәнеп, сорсеп бозылмасыннар өчен. Адәм баласы үзен-үзе белештерми, ак белән караны аермый, бик тиз бозыла, юкка чыга. Дөресрәге, үзен-үзе юкка чыгара ул. Әйе, үзен-үзе! Бер иблис тә кешегә анын үзеннән күбрәк зарар китерми. Билгеле, кешене чолгап алган тормыш шартларынын да роле зур. Кай очракта, бәлки, хәлиткеч рольдер. Тормышта шундый шартлар булмаган булса, Дәрия һич тә андый бәлагә төшмәс иде. Әйе, тормыш факторлары бик көчле, саллы — теләсә нинди характерны да үз ихтыярына бөгә. Кемнәрне генә бетереп салмаганнар да кемнәрне генә тәгәрмәч булып таптап үтмәгәннәр!.

Ял көне иде. Иртүк торып Надиягә илтергә һәм төнге дежурдан кайтачак әтисенә йомыркалар пешерде. Үзе, тиз-тиз капкалап алды да, Надиягә әйберләр төйнәде. Ниләр кирәген ул өченче көн язып чыгарган иде. Әле больницага иртәрәк булыр, әти кайтканны көтәргә кирәк, дип уйлады Мәгариф. Олы якка чыгып өстәленә барып утырды. Контроль эшләр буенча чит ил әдәбияты дәреслеген укырга тотынды.

Шулчак ишек шакыдылар. Мәгариф тәрәзәдән капка төбендә торган парфюмер магазины атын күреп алды. Әти тагын ватык әрҗәләр төяп алып кайтты микәнни, ди-ди ишеккә атылды. Чыкса, олаучы башын иеп капкага таба китеп бара. Мәгариф тә шунда атлады. Арбада әрҗәләр юк иде. Ул капкадан тышкы якка атлауга, олаучы брезентны ачып җибәрде. Анда ни күрсен: әтисенен гәүдәсе ята. Үлгән диган уй башына килми әле, авырган икән дип уйлап өлгерде. Тик якынрак килеп, анын кара янган йөзенә карагач һәм олаучынын кыяфәтен күргәч кенә миенә нәрсәдер китереп органдай тоелды. Буыннарынын кинәт көче бетеп, ул тизрәк арба үрәчәсенә тотынып калды.

Аннары, брезентка төргән килеш, картны кертеп, караватына салдылар. Менә шул мәлдә генә Мәгариф әтисенен үлгәненә ышана башлады.

Ни кылырга, нишләргә белми торганда, комбинаттан кешеләр килеп житте. Олаучы конторага кереп әйткәнме, үзләре белгәннәрме. Нөркәев, Кирәкмәсов һәм тагын берничә таныш егет килгән иде. Алар, эшләрне бүлешеп, һәрберсе ни дә булса башкарырга киттеләр.

Кич белән, күз бәйләнгәч, шәһәрнен указлы мулласы, мәетләрне җеназа укып озатучы мулла, һәм тагын бер карт килде. Шөкер, алар әле Фатыйх картны һаман да намуслы кеше дип таныган килеш иде. Фатыйх картны белүчеләр бик күп анысы, әмма радио аша Алланы юк дип диннән ваз кичүен тынлаганнан сон, бик каты ачулары купканга, анардан йөз чөергәннәр, иманын саткан кяфер дип бик нык каргаганнар, ди.

— Нишлисен,— диде мулла сакалын күкрәгенә терәгән килеш аскарак карап. — Язмышы шулай кушкандыр инде. Улым, әтиенне ничек озатасын? Җеназа укып, кәфенгә төрепме, әллә яначамы?

Мулла Мәгарифкә таба башын бормыйча, күзен төбәмичә генә шулай сорады.

— Иманын сатты бит, ничек ана җеназа укымак кирәк, мулла абзый?— дип каты гына әйтеп куйды бер карт.

Анын сакал баскан озынча йөзе, кәкре борыны бик каты дәһшәт белән тулган иде.

— Алай димә, кем, жанына гөнаһ алма,— диде мулла бик ышанычлы төпле рәвештә. — Алла үзе аны иманнан мәхрүм иткән. Әйе, язмышын җинеләйтү өчен! Аллаһы Тәгаләнен кодрәте иксез-чиксез, бәлки, син карт

үзен дә бу сәгатьтә имансыз калып утырасыңдыр. Алла иманнан мәхрүм итсә, ниләр кылмак кирәк. Тәүбә, Тәүбә!

— Тәүбә, тәүбә, хәзрәткәем, — диде карт каушап. — Инша алла, иманым бар шикелле әле! Тәүбә, тәүбә!

— Иманнан мәхрүм кылырмын, әмма адәм баласы моны үзе белмәс дигән Аллаһы Тәгалә! Шуның өчен вафат булган кеше хакында иманын саткан дип аваз салырга ярамый. Аның язмышына шулай язылгандыр, нишләтәсең бит... Адәм балалары ниләр генә кичерми,—диде мулла һәм гәүдәсе белән Мәгарифкә табарак борылды.

— Йә, улым, ничек?

— Без аны янача озатырбыз инде,— диде Мәгариф.

— Ярый, ярый, хужа эше, хужа эше,— дип мулла урыныннан кузгалды. Аның артыннан куркынган, күзләре түгәрәкләнгән теге карт та иярде.

Заман мулласы, ахрысы. Тиешле җиргә алып барып үзен өшкергәннәр булса кирәк. Югыйсә, ул Мәгарифнең әтисен аклап маташмас иде. Теге картның да ничек телен тешләтте. Бу Алла дигән зат бигрәк уңайлы нәрсә инде. Ни генә булса да шуңа сылтыйлар да куялар. Бәхет ишелеп төшсә дә Алла кушты гына дисең дә котыласың. Бәхетсезлеккә төшкән кеше өчен дә тынычландыра торган сәбәп. — Ходайның ихтыяры шулай булган. Бер гаепле кеше юк. Гаеплене эзләп җәфаланасы, көч түгәсе түгел.

Врачлар картның миенә кан йөгергән дигән диагноз язып бирделәр... Әмма гаилә эчендәге хәлләрне күзәтеп, исәпләп торучылар бар.

— Син карьераң өчен, әтиеңне харап иттең,— диделәр ана, нindидер явыз тантана белән. — Син аны диннән ваз кичәргә мәҗбүр итмәсәң, шундый зур мулла кыек адымга бара алмас иде?

Юк, ул моны үз ихтыяры белән эшләде дип акланса да «карьераң өчен әтиеңне үтердең», дигән сүзләре утлы энә булып Мәгарифнең йөрәгенә барып кадалды. Ул күкрәгенә учын куеп, тынып утырды, сулышы тукталгандай булды. Тамагына ачы төер тыгылды. Менә ул көч-хәл белән әлеге төерне йотты да, әтисенең бу көфер эшне үз ирегe белән эшләгәнен кабат-кабат исбатларга, дәлилләргә керештe.

Шунысы күңеленә тынычлык бирә: әтисе аңа бервакытта да рәнҗемәде. Ул барышны аңлый иде. Кайчак ихлас ачыласы, күңелен бушатасы килгән чакларда әйтә иде: тормышның тегермән ташыннан бер зат та читкә тайпыла алмый. Ул таш һәр затны он итеп тарта һәм хәзерге тормышка яраклы хәлгә китерә. Бу яшәеш өчен зарури! Кешеләрне җәмгыять итеп оештырып эшләтү һәм нормаль яшәтү өчен бүтән бернинди дә чара юк.

Надиянең авыруы әтисен юксынуны тиз оныттырды. Больницадан чыкканда ук кыяфәте шик тудырырлык иде. Бик нык үзгәргән ул. Күзләре тирәли күксел кыршау яткан, борыны очлаеп, маңгае алга чыгыбрак киткән шикелле. Үзе кай төше авыртканын да әйтми, тик хәле юклыгыннан гына зарлана. Малайны бик нык сагынган, кочагыннан бер дә чыгармый. Гаепле елмайган килеш аның белән сөйләшә дә сөйләшә. Малай, ниһаять, арыды, алдында йоклап китте.

Баланы үз ягына кертеп яткыргач Надия ире янына килеп ятты. Аны муеныннан ике куллап кысып үзенә таба китерде.

— Чит хатыннар янына бардыңмы, ә?— диде шаярткан кебегрәк итеп, үзе һаман яратып кысты да кысты.

— Нәрсә сөйлисең, Надия, әллә...— дип үпкәли башлады Мәгариф хатынын шулай ук биленнән кочып.

— Ә син бар, Мәгариф, югалып калма,— диде Надия кулларын бушайта төшеп. — Гөнаһ кыл, тик миңа ишетелмәсен.

— Йә инде, Надия, мине сынама...

— Мин чынлап әйтәм, Мәгариф. Чөнки бүгеннән соң мин сине кочагыма ала алмыйм. Хәлем юк, кәефем начар — күреп торасың. Син гөнаһ кыл, әмма күнелең нык булсын, күнелең белән миңа хыянәт итмә. Болай тыштан гына кыл гөнаһны. Ир-атка кирәк ул...

— Нәрсә син, Надия, валлаһи...

— Ант итмә. Тыштан гына булса, берни юк. Ләкин хатыннардан үзеңне бетертмә. Кешегә нәселдән төп энергия салынган, шуны чыгарып бетерсә кеше бик тиз шәлперәя. Ә син үзеңне сакла! Хатын-кыз белән тиешеннән артык булма. Чамасын белеп кенә. Йөрәгеңне бирмә хатын-кызга, йөрәгеңне сакла.

Надия сөйләгәндә Мәгариф көлде дә көлде, барысын да шаяруга борырга теләде. Әмма Надиянең житдилеге ихластан иде. Нигә кирәк әле аңа мондый сүзләр?

— Нигә син тузга ялмаганны сөйлисең?! — диде Мәгариф.

— Мин кирәген сөйлим, сине ятратканга күрә...

—Син тыныч бул, Надия...

— Ант итмә, дидем. Ул мәсьәләдә сүзеңдә тора алмый кеше, нигә эчтән кыйналып яшәргә? Искитәрлек берни юк, ир-ат белән хатын-кыз арасында барысы да булуы мөмкин. Нигә яшерергә, нигә шуннан фажига ясарга? Янәсе, хыянәт...

— Юк, Надия, син авыруыңнан чыгып уй йөртәсең, ахрысы,—диде Мәгариф ятратып. —Чирең шул чаклы ныкмыни?

— Ир хыянәт итте, хатын тугры түгел, дип аерылышучылар бар бит... Исен киткән, бер көн ире ниндидер хатын белән йоклап чыккан икән! Харап, ну, шуннан ни була?

— Юк, минем хатыным берәрсенең кочагында ята калса, мин бүтән аның янына бара алмыйм, аның тәненә кагыла алмыйм,— диде Мәгариф.

— Яратсаң дамы?

— Чит ир кочагында булсын да, ничек мин аны тагын ятратыйм, ди.

— Димәк, синең әле ятратканың юк...

— Мәзәк тә син, Надия, ә сине?

— Мине бары аңың белән генә ятраткансың, ахрысы?..

— Ни сөйлисең, Надия, валлаһи... Аң белән дә, хис белән дә! Юк, син әллә ничек булып кайткансың әле.

— Хис белән ятратсаң, аның вак-төяк гөнаһларына әһәмият итмисең.

— Ничек инде, хатының сиңа мөгез куеп йөрсен, син шуңа битараф кына кал, имеш! Булмый торган хәл, ниндидер идиотизм.

— Ирләр хатыннарына гел мөгез куеп йөриләр, монысы ничек? Ике баласы бар, ничек ул мондый ирен ташлый алсын, ә? Ирләрнеке чутка алынмый, ә хатын әз генә күзен ялтыратса да, ире тавыш кубара. Электән килә, ирләр хатыннарына хосусый милек итеп карый...

— Мин... әйе, мин... хосусый милек кебек күрәм алайса, чөнки хисләрем саф һәм көчле... Яшермим, гаеп итсәң, итәрсең...

— Ничек гаеп итә алыйм? Юк! Уф! Арыдым инде мин...— дип Надия ирен үз янныннан читкәрәк этәрә башлады. Мәгариф хатынының хәлен аңлады, торды да аны яхшылап яткырды, юрганына төрде. — Хәлемне аңлавың өчен рәхмәт сиңа, Мәгариф!— диде Надия йөрәге белән.

Мәгариф диванга чыгып яткач та, озак йокыга китә алмады. Надия белән сөйләшү аңа тәэсир итте һәм башына төрле уйлар китерде. Нигә шулай күнелен әйләндереп салырга ашыга ул. Аларның моңа охшаш сөйләшүләре элек бер дә булганы юк иде. Күрәсең, больницада бик нык уйланып яткандыр, күрше хатын-кызлары да күп сөйләшә торганнары туры килгәндер. Тукта, Надия сүзләрендә ниндидер моңарчы сизелмәгән төсмер

дә чагыла шикелле. Нәрсәгә дип әллә нинди китапча сүзләр сөйли? Хисен беләм яратмагансың, имеш. Ярату хакында сүз сөйләп буламыни? Кеше ярату турында сөйли икән, димәк, ул нәрсә юк дигән сүз. Шуңа сөйли ул аны. Надиянең мина карата хисләре бетте микәнни? Яратуы балага күчкән, ахрысы. Шулай булырга тиештер инде.

Авыруы бик җитди шикелле. Надия нәрсәнедер әйтеп бетерми. Нужәли терелергә бер өмет юк? Надия сизенә, ләкин белгертәсе килмиме?

Бу сизенүләр дөрескә чыкса, дигән уйдан Мәгариф эсселе-суыклы булып китте. Бу хакта башка китерү белән җанын коточкыч куркыныч биләп алды. Мондый гаделсезлек аны читләтеп үтә күрсен. Юкса, нишләр ул? Кара, ничек ул барча тамырлары белән Надиягә берегеп киткән икән. Тамырлар өзелсә, беттен дигән сүз. Ярату-яратмау хакында сөйләнгән булалар. Ир белән хатынның бер-берсенә берегүендә ярату бик кечкенә нәрсә ул. Бер күнегелгән гадәт кебек. Ул гадәтне үтәмәсән дә яшәп була, дус булып та. Арада бар хисләрдән, гадәтләрдән өстене бала бар. Менә нәрсә ир белән хатынны бер-берсенә беркетә.

Ул баланы мин бар нәрсәдән өстен саныйм. Аны бар нәрсәдән ныграк яратам. Мин анын өчен үләргә әзермен сыман. Сүзләр генәме бу? Сөяксез тел ни сөйләмәс? Әгәр шундый ситуация килеп чыкса, мин баламны саклар өчен үлемне сайлармын шикелле. Андый хәлнең булмаслыгын белеп, шулай кыю уйлыйммы? Юк, барыбер ул җан валчыгым өчен үземне корбан итәрмен... Баланы шулай яратасың икән. Адәм заты өчен бу иң көчле һәм риясыз рәхәт тойгы. Кеше теләсә нинди очракта рияланса да, бала мәсьәләсендә икейөзләнә алмыйдыр, мөгаен. Монардан да эчкерсезрәк тойгы юк.

Надия баланы аеруча нык ярата. Бер мәлне Мәгариф аның Артур белән сөйләнгәнен шыпырт кына тынлап торды. Надия Мәгарифне өйдә юк дип белә иде бугай.

— И, бәхетсез балам, үскәч, син мине ачуланмассың, яме? Әнине ачуланырга ярамый, гөнаһ була, улым.

— Әни, нәрсә ул гөнаһ?— дип сорап куя Артур. Анын бик матур итеп сөйләшә башлаган чагы. Сүзләрне белергә тырышуында зиһенле булуы сизелә. Һәр сүз белән кызыксына, колак артыннан уздырып җибәрми.

— Әнине ачулану, яратмау гөнаһ була, улым, аңлыйсыңмы? Әйе, син миңа үпкәләмә, рәнҗемә. Сиңа бик авыр хәлләргә калырга туры килер. Тик син чәүчәләнмә, сабыр гына чыда, сабыр гына көт. Барысы да бер үтә ул. Начар да, яхшы да үтә. Бик бәхетсез чакларында мине каһәрләмә. Язмыш шулай булгандыр инде диген. Минем тормышым четерекле булды. Менә мин үзем генә гаепле. Тик мин бер дә бәхетсез булмадым. Миңа гел җай килеп кенә торды. Мөшкел хәлләрдә инде беттем, дип уйлаган чакларымда һич көтмәгән җирдән җай чыга иде дә, котылып кала идем. Сугышта да шулай булды. Безнең госпитальне берничә мәртәбә бомбага тоттылар. Врачлар, сестралар һәлак булды, мин ничектер, исән калдым. Гомер буе мине Ходай саклады.

— Ә-ә, йоклап киттеңме, балам, йокла, йокла... Йокы ул йөрәккә файдалы... Син, улым, мине онытма. Мин үлгәч, минем каберемә кил, яме. Килми калма. Мин сине гел сагынып көтеп ятармын. Син кил дә, әкрен генә: «Әни!» дип дәш, мин шунда ук ишетермен, сине танырмын. Менә тәүфыйклы бала, әнисен онытмаган диярмен. Миңа бик-бик рәхәт булып китәр. Нинди генә авыр булса да син мине ташлама, улым. Мин сине юксынырмын. Бу бала нишләп килми икән дип борчылырмын. Син килсәң, минем рухым шатланыр, салкын җир астында ятуы миңа җинелрәк булыр... Минем сөякләрем дә синең өчен кайгырып ятар. Балама яшәү авыр микән, бәхете бармы икән, дип кайгырыр.

Минем синнән дә кадерлерәк беркемем дә булмады. Мин сине бу кырыс, шәфкатьне белми торган дөньяга китереп ялгышмадыммы икән? Их, беләсе иде шуны? Мин белмичә генә китәм. Шул белмәү мине газаплар. Шулай да син бирешмә, улым, әрсез бул. Әрсезлек ярты бәхет дип юкка гына әйтмиләр. Дөньяда яхшы кешеләр күп, шуна күрә тормыш яхшырганнан-яхшыра барыр. Кешеләр дөреслекне әйтергә дер калтырап тормаслар. Дөреслек булса, гаделлек тә булыр. Беркем дә бер гаепсезгә кимсетелмәс. Сезнең буын әйбәт, кешеләрчә булган тормышны күрер. Тормышны кешеләрчә күрү өчен күп көч түгәргә, тир түгәргә туры килер әле.

... Берничә көннән Надия әниләренә күчте, шунда үзенең элеккеге кечкенә бүлмәсенә урнашты. Күбрәк караватында ятып кына тора башлады. Әнисе шулай кушты. Чөнки үзе аптекада эшли. Дефицит даруларны алып кайта ала иде.

Мәгариф аның янына көн дә бара. Электәгечә зарплатасын Надиягә бирә иде. Әби кеше киявенең өтәләнеп йөрүен ошатмый, һаман төрттереп кенә тора. Надиянең йөрәге эштән чыгуын анардан гына күрә ул. Бу хакта кызы аңа Мәгариф алдында аңлатып-аңлатып карады: аның бер гаебе дә юк, әни, ник син шул элементарь нәрсәне аңламыйсың, ди-ди өзгәләнде. Бала чактан ук булган миндә йөрәк авыруы, балалык, яшьлек белән беленмәгән, менә хәзер килеп чыкты... Медик булып үзең дә чамаламагансың, әни.

Әнисе ишетәсе дә килми, башын гына селки һәм Мәгарифкә кырын күз белән карый, тизрәк чыгып китүен тели ахрысы.

Мәгарифнең русчасы бик үк әйбәт булмавын чыгарыр өчен русча гына сөйләшә. Кызына да русча гына эндәшә. Ә Надия белән Мәгариф шыпырт кына татарча сөйләшәләр. Надиянең сүзләрендә терелергә өмет юк икәне бик нык беленә иде.

— Бала өчен кайгырма, әни үзем тәрбияләрмен ди, — дип куйды Надия пышылдап.

— Ни сөйлисең?— Мәгариф аның кулларына ябышты, каты итеп кысканын сизми калды. — Ничек итеп мин үз баламны аңа бирим? Надия, тукта, бу хакта ачык сөйләшик. Әниеңне чакыр. Аңлашылмау калмасын!..

— Өйләнмичә тормассың бит?

— Нигә жиргә китәргә ашыгасың?

— Мин ашыкмыйм. Ул хакта кирәкмәс. Өйләнгәч, Артурның чит кулда калуын теләмим. Син каршы килмә. Хәзерге хисләрең үзгәрер, реаль аң килер. Әллә белмимме, кеше ничек үзгәргәнен. Йөз сиксәнгә генә түгел, өч йөз алтмыш градуска үзгәрерсең.

— Юк, син мине белмисең икән, Надия! Әй егетләр! Артур хакында мин үзгәрмәячәкмен. Шуны бел, әниеңә дә аңлат! Конкрет итеп!

Шулчак Надиянең әнисе кереп, Мәгарифнең китүен үтенде. Яхшы гына, итагатьле итеп, син үзең дә аның хәлен аңлыйсың, диде. Чынлап та, Надиянең хәле беткән иде. Аның үтә күренмәле булып калганын ак куллары яшел юрганы өстендә тәмам көчсезләнеп, нindидер җәнлек ботарлаган кошның кызганыч канатларын хәтерләтеп ята иде.

Мәгарифнең йөрәге сулкылдый-сулкылдый авырта, ул ни уйларга, ни кылырга белми. Тимер читлектәге җәнлек шикелле өендә әрле-бирле килеп йөренә. Авыр уйларын башыннан, күңеленнән куып җибәрә алмый. Ул чәнечкеле уйлар аны ерткыч кебек җәллаусез кимерә, җанын каната. Мондый хәл килеп туасы исенә дә килеп караганы булмады. Надия авырсын, имеш, һәм Мәгарифне ялгыз калдырып китсен, имеш... Нәрсә генә булды икән соң? Надия нинди таза, тутырган туп кебек тыгыз тәнле иде. Бүтәннәр үпкә чиреннән шулай тиз шиңәләр.

Монын бар жире таза, бары йөрәк начарлыктан кеше шулай тиз бетәшә микәнни?

Шушы көннәрдә Надияләрнең бертуган тиешлесе Ашхабадтан кайтып төште. Аны Мәгарифләр квартирына куйдылар. Абзый сугыш башында ук уң кулының ике бармагын өздергән булган. Бүтән алмаганнар. Ашхабадның бер поселогында үз йорты белән яшәгән. Мәктәп завхозы булып эшләгән. Гаиләсе булган: хатыны, ике баласы. Бу бәрәкәтсез эштән туеп, яңа салынып ята торган Газлы шәһәренә эш белешергә барган. Сварщиклар курсында укып йөри икән, кинәт бер көнне Ашхабадта жир тетрәве хакында сөйли башлаганнар. Газлыны да әзрәк селкетеп алган ул. Күп зыяны тимәгән, көче әз булган. Ашхабадта бик көчле булган, диләр. Рәсми игълан юк, халык шулай сөйли. Абзый бик пошынгач торган жиренә кайтып китә. Кайтса, ни күрсен, шәһәр тәмам жимерелеп беткән, көлгә әйләнгән. Алар яшәгән поселок бөтенләй әллә кая киткән, жир йоткан, ул төштә күл барлыкка килгән. Гаилә, хатын, балалар шул упкынга киткән дә беткән.... Менә ничек була икән... Берәүләрне сугыш афәте кыеп ташлады, безне менә тыныч вакыт хәвефе бетерде. Ни әйтә аласың, ни кыла аласың?

Абзыйны Мәгариф эшкә урнаштырып йөрде. Ул аз сүзле, боек иде. Йөрәгенә чыдый алмаганнан гына сөйли иде кебек... Анда бит жир тетрәү бик күп баллы булган, тугыз-ун диме. Ә бит дүрт-биш балл дип кенә яздылар. Әгәр тугыз-ун балл дисәләр, коткарышырга халыкара оешмалар киләсе икән. Аларны илгә кертергә ярыймы соң? Тоташ шпионнар жибәрәләр бит алар ярдәм итүчеләр ролендә (!). Шуңа күрә кертмиләр. Халык та нык кына кырылган. Анысын да йомачаклар. Нигә безгә шулай яшеренеп, качып-посып яшәргә соң, һич аңламыйм. Барча нәрсәне сер итү бик кирәк микәнни? Кирәктер шул, диде Мәгариф, кирәкмәсә эшләмәсләр иде. Капиталистлар бит безне бетерергә генә тора. Бүген үк юк итәрләр иде. Барлык ниятләре шул. Мондый кискен шартларда безгә үзебезне саклап калырга кирәк. Шуның өчен секрет чаралары кулланмыйча булмыйдыр.

Абзый кызыклы хәлне исенә төшерде. Бер таҗик шәһәрдән ерак авылга ишәк сатып алырга киткән. Жир тетрәү алдыннан гына. Ишәкне алган, мөгәрич эчкәннәр. Мөгәрич пары белән ишәккә атланып өенә кайткан бу. Ни күрсен, өенең эзе дә калмаган. Чокыр якасындагы өе төпкә упкан да, чокырның ике як ярлары бергә килеп тоташкан. Хатыны, апасы жир астында калганнар. Шуннан аягына нидер килеп сарылганга иелсә, мәчеләре икән. Менә тамаша! Нинди гаҗәп бу? Соңрак белгән, мәче жир тетрәвен бер көн алдан сизеп, балаларын таучык башына ташып куйган икән. Менә сиңа ахмак мәче! Мәчеләр, җәнлекләр сизә дип ишеткән бар иде, әмма менә үзем шаһит булдым. Бер-ике көн алдан кешеләр юлларда еланнар күреп, шиккә төшкән булганнар. Ләкин әллә ни әһәмият итмәгәннәр. Еланнарның юкка кузгалмаганын кайберәүләр шәйләгәндер, саклану чарасына да керешкәннәрдер. Ләкин беркем дә шундый көчле афәт булыр дип һич көтмәгән... Ул төштән кешеләр кача хәзер. Безнең яктан барып урнашканнар бигрәк тә. Исән калганнары бик тиз тәртәләрен борды. Китәргә рөхсәт юк, беркемне дә жибәрмиләр. Минем Газлыда булуым ярдәм итте...

Абзый ике учына башын салып утыра да дога укыган кебек: ничекләр генә монда яшәрмен, ничекләр генә. Бигрәк авыр икән монда. Ул якта тормыш җиңел, көн итү ансат. Бередәге кебек кысанлык юк. Халыгы да мәрхәмәтле, ярдәмчел, дини. Диннән курка, шуңа күрә кешегә начарлык эшләргә шүрли. Олыны олы, кечене кече дип белә. Ата хакын, ана хакын, туган хакын хаклый. Анда бөтенләй башка тормыш. Кыш булмый. Ел тәүлеге җимештән өзелмисең... Юк, юк, ул якка бүтән аяк атлый алмыйм инде. Нишләргә соң, нишләргә дип сөйләнә дә сөйләнә...

***

...Менә ничә көн инде Мәгариф ангы-минге исенә килә алмый йөри. Әйтерсең лә зиһенен жуярлык итеп башына китереп суктылар. Башта уйлар чуалган, бер төенгә, һич тә жыярлык түгел. Житмәсә, маңгайга кыршау кигергән сыман, бик нык басып авырта. Күзләрне кан сарган, яктылык томанлы булып тоела. Бар нәрсә ничектер куе томанга төренгән сыман. Әйберләрнең, кеше йөзләренең төсе сорыланды. Ак чырайлы кешеләр соры йөзле булып күренә. Бу Ашхабад зилзиләсеннән исән калган Фидай абзыйның кыяфәте дә үзгәргән кебек. Ул ничектер бөкшәебрәк калган. Мәгариф үзенең дә кечерәеп, бушап киткәнен сизә. Эчемлек эчеп карый, һич алмый, башына китеп тә карамый. Абзый көн дә эчемлек алып кайта, Мәгарифнең кайгысын уртаклашмакчы була. Эчемлек кабул итсәң, кайгың жинеләя, имеш. Ул үзенең ачы кайгысын шушы әче су белән юа, шуңардан жинеллек таба. Бер стаканны салып куйгач, ул йомшый, язмышка булган ачуы кими төшә. Әйбәтләнә, бар нәрсәне яхшы яктан гына күрә башлый. Кешеләр барысы да яхшы, яхшылык эшләп кенә торалар. Һәм ул үзе дә әүлиягә әйләнә. Мәгарифне мактарга тотына: син, энем, әйбәт кеше. Шуңа күрә бар нәрсәне йөрәгең белән кичерәсең, йөрәгең аша уздырасың. Син йөрәк кешесе. Син бер хәлдә дә начарлык кыла алмыйсың. Чөнки син намус тозагында. Син хатыныңа бер тапкыр да хыянәт итеп карамагансыңдыр. Юк. Ә минем андый гөнаһым әз-мәз булды. Ул як минем тегеләй. Мин аны Аллага япсардым, Алла үзе кушкандыр, үзе хәерле кылсын, дидем. Гаиләмнең бу фажигасен дә Аллага япсардым, Алла шулай теләгәндер дидем. Шуңардан беразкүңел тынычлык тапты. Аннары менә бу шайтан суыннан йөрәккә әз-мәз ял алгалыйм. Ә синең сыенырга бер Аллаң да юк, ичмаса! Эчемлек тә тәэсир итми, ахрысы. Эчемлек эчкәч, тагын да агарып, зәңгәрләнеп китәсең. Нинди дә булса бер Алла кирәк ул, энем, сыенырга, сылтау итәргә, гаепне аңа аударырга. Мин бар гаепләрне Аллага аударып яшим. Шулай жиңелрәк яшәргә. Юкса, барысын да кеше йөрәге ничек күтәрсен? Кеше башы барысын да ничек уйлап бетерсен? Ничек очына чыксын? Бу дөньяның очы-кырые юк. Ә кеше дөньяда бик аз яши, ул мосафир гына бу дөнья дип атала торган йортта. Кешенең бар нәрсәсе дә чикле, бар нәрсәсе дә нечкә кыл өстендә. Аңа бу катлаулы дөньяда көн итүе бик авыр. Барысы да үз өстендә, үз башында. Ничек чыдамак кирәк?

Минем абый авылда укытучы иде, малаена Урал дип исем кушкан өчен теге елны алдылар, шунда һәлак булды. Моны ничек аңламак кирәк, ничек жанга кабул итмәк кирәк? Ни гаебе булсын аның? Әгәр тормышта мең сорауга жавап табылмый икән, монда Алласыз мөмкин түгел инде. Ә хәзер бик күп сорауларга жавап табып булмый әле... Әйдә, тагын әз генә салып кара, жинел булып китмәсме, ә, Мәгариф?

Мәгариф уянып киткән кебек башын күтәрде, болганчык күзләре белән абзыйга карады. Абзый стаканын чәкешергә сузган. Мәгариф аңышып бетми тора. Шул аңламаган көе ул стаканын кулына тотты, белешми генә чәкәште һәм эчеп жибәрде. Ачы су бик жирәнгеч булып тоелды, ничек эчәләр моны дигән уй килде башына. Абзый тагын сөйләнергә тотынды:

— Хатынның үлүе ул кадәр үк түгел, менә балалар бәгырь ите, аларның үлеме синең дә ярты үлемең. Мин балаларым өчен ярты үлгән кеше. Ә син хатының үлгәнгә шул чаклы интегәсең! Балаң бар бит, менә сиңа юаныч, менә сиңа таяныч! Минем әнә ничек булды, барыбер яшим, ярым үлгән көе яшим. Йөрәгем телгәләнеп беткән. Син алай үлмисең, малаең өчен яшисең. Артык хафаланма. Хатын үлеме авыр булса да, йөрәкне яраламый, менә бала үлеме йөрәккә мәңге яра калдыра. Ул гомер буе төзәлми. Кеше нишләргә тиеш? Менә тагын шуңа Алланың кирәклеге килеп чыга. Хатын

табыла, ә бала табылмый, юк. Бала ул үзен кебек үк, үз тәнен кебек үк! Тәнне әз генә кис, авырта, бала белән дә шулай, үз әгъзаң шул, үз жаның... Син артык туры күңелле кеше. Мин дә башта шулай идем. Минем абый да шундый иде. Тугрылыгы өчен харап булды. Абый язмышы мине күп нәрсәгә өйрәтте. Тугры булу ярап бетми икән дидем мин һәм бүтән кешеләр шикелле икейөзләнә башладым. Битлек кию кайбер бәлаләрдән коткарып кала. Теләмәсәң дә йөзгә битлек бәйләмичә булмый. Шыр дурак булып калмас өчен. Ә синең дурак булып калган чакларың күп булгандыр. Синең битлегең дә юк, Аллаң да юк. Сиңа бик авыр. Ничек чыдый торгансыңдыр. Адәмгә бер ышык, посу урыны кирәк. Юкса, озак тереклек итә алмавың мөмкин. Мин хәзер хәйләкәр, язмышка жайлаштым инде. Сиңа да жайлашырга киңәш итәм. Үзеңә дә, синең яныңдагы кешеләргә дә әйбәт булып китәр. Жайлашмыйча барыбер булмый... Намус та хәзер казнаныкы.

— Юк, минем үземнеке!— дип өстәлдән башын күтәрде Мәгариф. Аның авызы кыегайган, чырае гарипләнгән кебек иде.

— «Тем хуже для вас» дияр иде рус булса, ярый, мин әйтмим инде,— диде Фидай абзый.

Кыш бик авырлык белән үтте. Мәгариф эшенә барды, эшеннән кайтты. Фидай абзый бүтәннәргә йөк булмыйча, жинеллек китерергә тырыша торган булып чыкты. Утын артыннан үзе йөрде. Усиягә әллә ничә мәртәбә барды. Ләкин яшәгән саен бирешәдәге тормыш аның гайрәтен чигерә иде. Ул тагын үзе торган якка карый һәм тагын икеләнеп кала, нишләргә белми. Мәгарифкә әйдә икәү китик, дип әйткән чаклары да булды. Анда яшәүнең жинел булуын сөйләп кызыктыра иде. Ул якка абзыйны ниндидер тамыры тарта иде шикелле. Шулай да үз-үзе белән күп тартыша торгач, абзый Ашхабадка барып кайтырга теләде. Кичке сменада эшләп шактый гына отгуллар жыйды. Шул исәпкә китеп тә барды.

Ял көне иде. Мәгариф иртүк торып чәй кайнатып эчте дә, китапларына тотынды. Укуга бирелеп, ялгызлыктан качарга тели иде. Яхшы китап та яхшы дус кебек бит ул — киңәшкә ярый, ярдәме тия.

Кинәт тышкы ишекне шакыдылар. Надиянең абыйсы микән?— дип уйлады Мәгариф бикне ачканда. Тик каршында хәрби кеше басып тора иде. Майор погонлы, бик пөхтә киенгән. Итекләре көзге кебек елык-елык килә.

— Танымыйсынмы?— диде хәрби кыю һәм үзенә ышанган тостә.

— Күргән кебек булам булуын....— дип Мәгариф сүзен әйтеп бетермәде, келт итеп хәтеренә төште. — Ә-ә, сез теге трибуналдагы ни түгелме, Каймакчимы әллә?

— Тиз оныткансың, Сайкин,— дип ул властьлы төстә бусагадан атлады. Мәгарифнең эченә кинәт салкын йөгерде, йөзе агарып китте. Тәнендәге ниндидер эчке калтырау канын башына, миенә куды. Бар гаепләре һәм гаеп түгел нәрсәләре минут эчендә электрон машинасындагы кебек күз алдыннан уза башлады. Теге чагында эш ябылмый калды микәнни? Тагын нәрсә булды икән? Лейтенант бар гаепне үз өстенә алган иде, әллә чигенчәкләндеме? Ул эш өчен хәзер хөкем итә алалармы? Дүрт еллап вакыт узган икән инде. Надия аңа һаман әйтте: сине Павел гына коткарды дип. Шуны исбат итте. Хәтта Мәгарифне поездан арестовать итеп алып калуларын, яңадан тикшерү уздыруларын ышанычлы булсын өчен эшләнгән эш, диде. Чөнки Павел сине шунда котылдырып жибәрсә, соңыннан берәр нәрсә чыгуы ихтимал булган. Шик уятырлык бер пункт калган икән. Ә болай эшне яңадан тикшергәндә Павел катнашмагандыр. Эш ике инстанциядә каралгач, раслана һәм бүтән кузгатмаслык итеп ябыла. Павел бу тактик эшне якын танышлары, фикердәшләре кулы белән эшләгән булырга тиеш

дип аңлатты Надия. Бу мәсьәләгә ул кабат-кабат кайта иде һәм Павелның хезмәтен зур итеп күрсәтергә ашыга иде... Тагын нәрсә булды икән, юкка йөрми торгандыр бу кеше...

— Казанга килгән идем, иске танышларга сугылыйм дидем. Ул сөйләнә-сөйләнә бүлмәгә узды. Мәгариф өстәлендә өелеп торган китапларны күрде дә, ымлап:

— Әллә галим булырга җыенасыңмы?— диде һәм баягы өстән каравы бетеп киткән кебек булды. Ул елмайды, ничектер әйбәтләнде, йомшады сыман. Сайкинның бүтәнчәрәк булуын көткән. Ә ул әнә нинди, ак күлмәктән, гастуктан, китапларга күмелеп утыра, белем гранитын кимерә...

Каймакчи ике пряжкәле зур портфелен ачып, өстәлгә бер коньяк һәм кызыл икра, олы кусәм осетр балыгы чыгарып куйды. Мәгариф китапларын янәшәдәге этажеркага күчерде. Коридорга чыгып керосинкага чәйнек утыртты. Өстәл тартмасыннан ипи алып телемләде. Рюмкалар чыгарды. Иртәнгедән калган кабыклы бәрәңгене китерде, ул әле суынып җитмәгән иде.

Каймакчи, шинелен салып, ишек катындагы элгечкә элде.

— Надяның үлеме бик нык аптырашта калдырды,— диде ул өстәл янына утырып. — Ышанырга да, ышанмаска да белмәдем...

Ул Мәгарифкә сынаулы карашын юнәлтте һәм төбәлеп торды. Һәр нәрсәдән шик табарга өйрәнгән гадәте үзенекен итә иде кебек.

— Каян белдем дисеңме?— дип сүзен дәвам итте ул Мәгарифнең сораулы карашыннан аңлап. — Мин үзем Куйбышевта гына, биредәге иптәшләр белән телефон аша сөйләшеп торабыз. Һаман шул эштә... Ул кызга ни булды?

Каймакчи шешәне ачып, рюмкаларга бүлде. Мәгариф Надиянең авыруы турында җентекләп сөйләде. Бәбәй тапканнан соң өзлегеп калган шикелле, диде. Шул вакыттан башлап йөрәгеннән зарланды. Больницаларга ятып дәваланып карады, алга китеш булмады...

Мәгарифнең тавышы калтыранды, кинәт өзелеп китте, ул, башын аска иеп, кулын өметсез селтәп алды.

Берничә рюмка эчкәч, арадагы читләшү һәм шик бетә төшкән кебек булды. Ачылыбрак китеп сөйләшә башладылар. Каймакчига ышанып булмый иде. Мәгариф аның тел төбеннән үзенә дәгъва юклыгын, теге эшнең койрыгы калмаганлыгын әзрәк чамалаган кебек булды. Әмма һаман сагайды, майорның дипломатлык сәләте булуын теге вакыттан исендә калган иде. Ул һаман Мәгарифне ныграк исертмәкче булган шикелле чалым сизелеп китте. Ул, билгеле, үзен өстен итеп саный иде. Бу хәлне Мәгариф тә дөрес аңлады һәм бик чишелеп китмәде. Алар үткәннәрне искә төшерделәр. Шундагы кайбер кешеләрнең соңгы язмышлары ничек булуы турында кызганып һәм кызыгып та сөйләнеп алдылар. Каймакчи нәрсәгәдер һаман сүзне Надяга бора, аның хакында кайбер штрихлар әйтеп куя. Ләкин ничектер азагына чаклы ачып бетермәгән кебек тоела. Ихласланудан үзен тыйган да сыман була. Шулай да ул шактый кызмачаланды. Мәгарифнең тәнендә кан дулкыны үзенең хәрәкәтен тизләткән иде. Шешә төбен рюмкаларга бүлгәндә, Каймакчиның кул тамырлары бүртеп зәңгәрләнеп тора иде. Йөзе дә кирпеч кебек кызыл, шул фонда калын, аксылрак чәчләре җитен сүсен хәтерләтеп алалар иде.

— Без Надя белән өч еллап гел янәшә булдык,— диде ул урындык артынарак тарая төшеп. — Безнең кечкенә часть гел алар госпитале белән бергә урнаша иде. Безнең өчен әйбәт, бер төркем өчен ашханә, кер юу урыннары корып мәшәкатьләнәсе булмый. Бәйрәмнәрне билгеләп үткән чакларыбыз да бергә була иде. Госпиталь персоналында кызлар, хатын-кызлар шактый күп иде. Без ничектер беренче күрү белән бер-беребезгә тартылдык. Әллә нинди кодрәт безне бер-беребезгә кадаклады. Мин Надяга өйләнгән булуымны, кызым үсеп килүен әйттем. Ләкин бу факт безне

суындырмады. Минем тәмам башым әйләнде. Үземнең шундый хәлгә төшәремне уема да китергәнем юк иде. Мин хисләрнең башына сугып, аларны тәмам үземдә корытып бетергән кеше. Эшем шулай таләп итә иде. Законнан һәм уставтан башка нәрсәне белми идем. Белергә дә теләми идем. Ә монда гайре табигый хәл килеп туды: мин Надяны күрми тора алмыйм, ул мине күрми тора алмый. Нишләргә белмим, мин каты бәгырьле кеше рәхәт томан эчендә йөзәм. Кызык бер хәл: карангы төн ничектер тоныкына якты булып тора. Ак төннәрне күргәнең бармы — шуның кебек. Бүлмәдә утны сүндереп ятам, күз алдым якты, якты. Йөрәгем рәхәт булып тибә, миңа гомумән бик рәхәт. Анадан яңа туган кебек, диләр бит әле, яисә яңа гына мунчадан тазарынып кайтып яткандагы шикелле. Шундый рәхәттә йөзәм, барча эшләремне оныттым. Эшләремне механик рәвештә генә башкарам. Эчемдә нииндидер туеп булмый торган, үзенә йота торган рәхәтлек. Бу халәт миндә беренче һәм соңгы мәртәбә булды. Билгеле, ул чакта мин моны аңларлык түгел идем. Аңлау һәм бәяләү соңыннан гына килде. Күрәм, Надя да башын җуйган кебек йөри. Миңа килә дә:

— Нәрсә бу, нишләттең син мине, һич аңламыйм, гомердә болай булганым юк иде,— ди. Зарлана, яшь агызган чаклары да була. Без икебез дә шушы пожар кебек безне чолгап алган хисләр тозагында идек... Хәер, нигә сөйләп торырга, иске яралар кутырын кубарырга?..

Каймакчи урыныннан торды да, идән буенча адымнарга тотынды. Мәгариф ана аптырап карый, аның башына киткән эчемлек пары юкка чыккан кебек булды.

— Нигә сез моны миңа сөйлисез?— диде ул калкынып.

Каймакчиның йөзе киеренке, бар дикъкате ниндидер эчке фикеренә тартылган, шуңа гына йотылган кебек иде.

— Белмим, белмим,— диде ул сәер гасабиланып. Аннан ниндидер карарга килгән төстә урынына килеп утырды һәм тыныч тонда сөйләп китте:

— Шулчак мине командировкага җибәрделәр. Айдан артык йөрелде. Надя миңа записка язып калдырып киткән. Анда язылган: «Павел, я, кажется, понесла...» Мине бер-ике көннән кайтыр дип уйлагандыр. Мин озакладым, мин кайткач, ул сине үзенә якын итүен, безнең араның өзелүен килеп әйтте. Чөнки минем аны ала алмавымны белә иде. Шуннан соң көн дә килеп, елап, минем сине ничек тә булса коткарырга кирәк дия башлады. Бик нык үтенде. Начальнигына барысын да әйтәм дип куркыта иде. Мин, билгеле, начальниклардан дер калтырап тора идем. Начальник безнең Надя белән чуалышканны белсә, шунда ук миңа каты гына күңелсез эшләр эләгәчәк иде. Безнең полковник бик кырыс иде. Надя каршында үземнең гаебемне аңлый идем. Аның сүзен аяк астына саласым килми. Гаебемне йолар өчен сине котылдыру чарасына керештем. Бик четерекле эш...

— Нәрсә, әллә бала синекеме?— диде Мәгариф уянып киткәндәй, бая әйткән фикернең мәгънәсе ана әле яңа гына барып җиткән иде.

— Надяның язуына караганда, шулай,— диде Каймакчи бик гади нәрсә турында сүз барган төстә. Моны ул үзен үзе ышандырыр өчен эшләде. Күкрәк кесәсеннән дүрткә бөкләгән кәгазь бите алып Мәгарифкә сузды. Мәгариф карау белән Надиянең язуын таныды. Зәңгәр трофей карандаш белән язган. Андый карандашлар аларда хәзер дә бар.

— Юк, бу дөрес түгел, булуы мөмкин түгел!!!— диде Мәгариф сискәнеп. — Сез акылыгыздамы? Ай-һай ла!— Ул торып басканын сизми калды. Каймакчи аның капылт хәрәкәтеннән бераз сагаеп куйды. Ана икенче төрле уйлар ябырыла башлады. Бирегә килгәнче ул башкачарак фикер йөрткән иде. Ә күзгә-күз калгач — «очная ставкада» хәзер башына бөтенләй башкача фикерләр тулды. Ничектер зиһене таркауланып китте. Чынлап та,

үз акылындамы ул? Шушындый ике бер-берсен яраткан йөрәкләр арасында гына була торган нәрсәне өченче кешегә әйтергә, чыгарырга ярыймы соң? Нәрсә уйлап, нәрсәгә исәпләп килдем мин бирегә. Ахмак, ахмак! Хәзер бу чоңгылдан чыгу, арыну юлын табарга кирәк. Үзем өчен генә түгел, аның өчен дә чокырдан үрмәләп булса да котылу әмәлен табу бик зарури.

— Надя, мөгаен, ялгышкандыр,— диде Каймакчи акыллыланып.

— Юк, ул ялгышмаган, просто мондый хәлнең булуы мөмкин түгел! Юк! Юк! Надя өчен мине коткаруыгызга да ышанмыйм хәзер. Моңа чаклы ышана идем...— диде Мәгариф бик нык дулкынланган төстә.

Каймакчи бер сүз әйтми тынып кына утырды. Тынлык урнашты һәм шактый дәвам итте. Бераздан Каймакчи тәрәзәгә һәм сәгатенә карап алды да урыныннан торды. Йөзендә, күзләрендә караңгы уй иде. Әмма ул аны әйтергә җыенмый шикелле. Сайкинга хәзер ышанмау кирәген, шул аңа файдалы булуын аңлап алды. Һәм үзенең аны трибуналдан аралап газаплануларын исбат итеп торасы килмәде. Бала анык булган очракта да, аны үзенә ала алмаячак. Димәк, бала Сайкин белән үсәчәк. Аның бала үзенеке булуына әз генә, тамчы кадәр да шиге булырга тиеш түгел... Тамчы кадәр генә башка төрле уй баланың тормышын, киләчәген фаҗигале итәчәк. Моны Каймакчи һич теләми, юк, теләми! Баланың язмышын менә ничек итеп җимереп ташлаулары мөмкин икән. Нигә миңа мондый фикерләр алданрак килмәде, бирегә килгәнчерәк? «Очная ставка» хәлне бөтенләй икенчегә бора да ташлый шул. Бу хакыйкатькә ул күп мәртәбә шаһит булды бит.

Каймакчи шинелен киде. Алар коры гына кул кысыштылар. Мәгариф тәмам югалып калган, ни әйтергә белмәгән төстә иде...

Җанга ничек кенә авыр булмасын, вакыт үтә, су кебек ага тора. Үткәнен сизми дә каласың. Нииндидер өмет белән ымсынып яшисең. Кинәт бер мәл ул өмет тустаганын кулыннан бәреп төшерәләр. Башларың әйләнеп китә, аягыңда көчкә басып каласың. Ләкин тормыш алай ук мәрхәмәтсез түгел, синең кулыңа тагын бер өмет тустаганы бирә. Шуның белән тагын бераз гомереңне сузасың. Аннан тагын нииндидер борылышта абайламый каласың, сине яшәткән өмет савыты кулыңнан тагын очкан, челпәрәмә килгән. Син аның ватыкларын алдыңа җыясың, күз яшең белән һәм тозлы тирең белән кыйпылчыкларны бергә ябыштырасың. Менә тагын синдә өметнең тулы тустаганы... Шулай бер өметтән икенче өметкә хәрәкәт итә гомер, бер дә туктап тормый.

Көз көне теге апа Дәриянең кайтканын әйтте. Мәгарифнең ни өчендер аның белән очрашасы килми иде. Теләмичә генә барды, чөнки күңелендә һаман яра барлыгын сизеп йөри ул. Шулай итагать өчен генә күрешергә кирәк дип уйлады.

Дәрия бик нык үзгәргән, танырлык та түгел. Элеккеге кояш кебек кыздан берни дә калмаган сыман иде. Нурлары беткән, сүнгән. Ул Мәгариф белән сөйләшергә теләмәде бугай. Чакырганга апасын ачуланып алды. Дәриянең эчендә, тышында кешеләргә рәнҗү, нәфрәт тулы. Мәгарифкә дошманын күреп үртәлгәндәй ачу белән бүре кебек карады. Сөйләшү берничек тә ябышмады. Апасы аларны ялгыз калдырып чыгып китеп карады, әмма сүзләр ялганмады. Дәрия кешеләрдән бизгән, ышанмыйча карый. Ышаныч тиз генә кайтмас әле аңа дигән фикергә килде Мәгариф.



Клара
Булатова

# ЯШӘҮГӘ ОМТЫЛЫШ ШУНДЫЙ НЫК

* * *

**Миңа бер мирас калдырды атам,**
**Миңа бер киңәш калдырды атам,**
**Миңа бер акыл калдырды атам:**
**— Гадел кермәгән керемнән саклан!**

**Байлык–мөлкәтне кем ничек тапкан?**
**Кемгә кем аны түләүсез аткан?**
**Бәясез саткан? Кем кайтарткан да,**
**Ул кемгә болай гел бушка кайткан?**

**Бераүгә дә ул күктән төшмәгән,**
**Беркадәр җыйган күптән эшләгән.**
**Беркадәр мөлкәт токымнан күчкән,**
**Саклый белгәндә маяда үскән.**

**Тик бүген андый гадел байлык юк,**
**Булганын дәүләт алды башта ук.**
**Калганын йотты талап мур кырган,**
**Калганын упты реформа корган.**

**Ачык авызлы бер катлы халык,**
**Ваучерлар алып алданып калдык.**
**Түрдә түрәләр төпле уйлыйлар**
**Акцияләрне йөкләп җыйдылар.**

**Менә аларда, әйе, бар байлык,**
**Милек иттеләр законын табып.**
**Балаларына, оныкларына**
**Зур сарайларны куйдылар салып.**

Клара БУЛАТОВА — *шагыйрә; «Шушы яктан, шушы туфрактан без», «Әрну», «Каурый канат — җил атым» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Әлмәттә яши.*

**Уйламыйлармы түбән тарафтан,**
**Дәҗҗал хәрәкәт купса кабаттан –**
**(Дөрес, диварлар җидешәр каттан)**
**Алай да афәт төрсә як–яктан?**

**Акыллы киңәш калдырган атам:**
**— Гадел кермәгән керемнән саклан,**
**Байлыктан саклан!**
**Хәрамнан саклан!**

* * *

**Син бит минем сорауларга**
**Туры җавап бирмәдең...**
**Күзгә карап буладыр ул**
**Чиста булса гына йөрәгең.**

**Ә шулай да сине аkладым мин,**
**Аклар өчен нигез мин таптым!**
**Күзгә карап алдамыйсың икән**
**Югалмаган әле оятың.**

**Ә оятың югалмаган кеше**
**(Күрәсеңме, барын күрәмен,**
**Ак өметкә нигез бирәмен мин!..)**
**Бер чистартыр керле йөрәген.**

* * *

**Кануннарга баш игән дип уйлама!**
**Гел үземчә яшәдем мин дөньяда.**
**Күңелемдә ачу тотып йөрмәдем,**
**Күңелдә ни — телдә шуны сөйләдем.**

**Күзем төшкән үргә мендем — биләдем,**
**Кемнәрнеңдер сихерләдем йөрәген.**
**Үземнекен саклап тота белмәдем –**
**Әмма кеше өлешенә кермәдем!**

**Җирдә яшим — булды гөнаһ кылганым,**
**Җир хатыны — юк, фәрештә булмадым!**
**Ил алдында изгеләрдән була алмам,**
**Өметләнәм,кичерер дип бер Аллам!..**

* * *

**Кала — урман, мал югала торган**
**Кара сазлык белән аралаш.**
**Итәгемә бәйләп тотып тормам,**
**Җаның тели икән — чык та кач!**

**Куа бармам, мин сунарчы түгел,**
**Капкын куймам киткән юлыңа.**
**Дүрт ягың кыйбла, бар, тыелма!**
**Сыен барып яңа урынга.**

**Сазлыккамы,чытырманлыккамы**
**Язмышыңны ялгыш батырсаң –**
**Бүре кебек айга карап ула –**
**Коткарырмын килеп ...чакырсаң**

* * *

**Сөенечем булса, әйтмәсәм дә,**
**Әллә кайдан ишетеп киләсең.**
**Көенечем булса юатасың,**
**Авырып китсәм хәлем беләсең.**

**Бәйрәм булса,бүләк китерәсең,**
**Сизеп яшим: якын күрәсең.**
**Әллә болай гына дус күрәсең,**
**Әллә инде чынлап сөясең.**

**(И, хатын–кыз! Әле бу яшьтә дә**
**Алданудан армый, күрәсең).**

* * *

**Тәрәзә артында тын тышта**
**Яшеллек, яшеллек, яшеллек.**
**Бу йөрәк һаман да тырыша**
**Яшим дип, яшим дип, яшим дип.**

**Иртәдән баш түбәң өстендә**
**Зәңгәр күк, зәңгәр күк, зәңгәр күк.**
**Яшәргә дәрт һаман көчендә**
**Җиде кат күкләргә әйдәр күк.**

**Яктылык, яктылык, яктылык,**
**Һичнәрсә каралтмый яктыны.**
**Яшәүгә омтылыш шундый нык –**
**Якынлый тик гомер ахыры.**

## Хәтерлим

**Беренче кышны хәтерлим,**
**Буранлап килгән кышны.**
**Икәүләп шул бураннарда**
**Адашып йөргән кышны.**

**Беренче кышыбыз иде**
**Таныштырган кышыбыз.**
**Вакытлыча дип гомергә**
**Кавыштырган кышыбыз.**

**Беренче аңлашуыбыз,**
**Хыялый куышыбыз.**
**Уйныйбыз диеп, чын–чынлап**
**Кушылган тормышыбыз.**

**Беренче кышны хәтерлим,**
**Бик салкын үткән кышны!**
**Җиде ятны — син солдатны**
**Бик якын иткән кышны.**

**Утыз ел элгәре килеп**
**Кырпак кар койган кышны.**
**Язмышның асларын-өскә**
**Китереп куйган кышны.**

* * *

**Су агымын учта саклап булмый,**
**Җил тотырып булмый куенга.**
**Шуның кебек синең сөюне дә**
**Саклап булмый гомер буена.**

**Учта кибә суның юешлеге,**
**Берни калмый җилдән куенда.**
**Шулар кебек сөюең юкка чыкты,**
**Булмагандай гомер юлында.**

**Юкка чыкты синдә, синең якта —**
**Әмма миндә калды эзләре.**
**Эзләрнең дә мәңге җуелмастай,**
**Берни капламастай тирәне.**

* * *

**Мин үләргә җыенмыйм да әле,**
**Уйламыйм да әле үләргә!**
**Мин ул кадәр акылсыз ук түгел,**
**Саналсам да кайчак юләргә.**

**Уйламыйм да әле үләргә мин,**
**Бу яшәргән яшел көннәрдә —**
**Арттырасы бар бит җирнең ямен,**
**Бакчаларга орлык сибәргә.**

**Мин ул кадәр акылсыз ук түгел,**
**Буш калдырып язгы түтәлне**
**Озатырга кара җир астына,**
**Якты сөйгән ап-ак бу тәнне.**

**Саналсам да кайчак гел юләргә,**
**Яшәү яклы акыл бар әле.**
**Җир яшәргән ямьле бу көннәрдә**
**Җирдә яшәр хакым бар әле.**



Батулла

# ТУГАН ЯГЫМ – ЗӘЙ ТӨБӘГЕ

ХАТИРӘЛӘР

## Тарих баскычлары

*Ямьле Зәйнең буйлары,*
*Ямьле, тәмле шул Зәйнең сулары.*
Татар халык жыры.

«Зәй» — «елга, инеш, ермак» дигән сүз. Зәй елгасы Писмән, Әлмәт якларыннан агып, Чулманга (Камага) килеп кушыла. Зәйнең ин олы кушылдыгы — Зичә. Шыкмай авылы әнә шул Зичә инешенең ике як ярына урнашкан. Батуллаларның борынгы токым тамыры Зичә буендагы Шыкмай авылында булыр.

«Зичә» — «Зәйчә», ягъни «Кече Зәй» мәгънәсендә булуы ихтимал.

Бүгенге Иске Зәй бистәсе урынында әүвәл зур кальга, ягъни кала-шәһәр булган. Бер яктан текә яры белән Зәй суы, икенче яктан калын урманнары белән чорналган бу кальга-шәһәр кайчан салынгандыр, мәгълүм түгел. Әмма Зәй исеме тарихта ундүртенче гасырдан билгеле.

Тарих төпкелләренә төшәр өчен, без якташыбыз, 1838 елда вафат булып, Зәй төбәгенең Имәнлебаш авылында жирләнгән Тажетдин Ялчыгол исемле олуг галим калдырган тарих китапларына тотынырга тиешбез. Тажетдин Ялчыгол шәхесе документаль кинолар, нәфис фильмнар төшереп, аның турында китаплар язып кына тулы гәүдәләнә алмый. Гажәеп серле язмыш, серле һәм мажаралар тулы бер тормыш кичерә Тажетдин исемле галим, әдип, тарихчы, музыкант, табиб, мулла кеше. Ул калдырган фәнни әсәрләр арасында исемнәре иң алда йөри торган «Рисалә—и Газизә» белән «Тәварихы Болгария» китаплары бәһаләп бетергесез кыйммәтле әсәрләрдән санала. Шушындый да олуг шәхес белән Зәй төбәге генә түгел, бөтен татар халкы, әйтергә кирәк, бөтен кардәш халыклар да горурланырга хаклы. Аның язганнары бер татар халкына гына кагылмый.

БАТУЛЛА (Роберт Мөхлис улы Батуллин) (1938) — *прозаик, драматург; иллегә якын китап авторы, Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Дөрес, Зәй (Эзәй, Сәй) исеме, нәкъ безнең туган якларыбыз буларак, борынгы кулъязмаларда очрый. Зәй бәклеге Бөек Болгар дәүләтенең бер илчәсе булган.

Зәй тамагында бик күп халык яшәгән. Бараж исемле котчыккыч аждаһадан куркып, бу халыклар ватаннарын ташлап, читкә качканнар. Яңа урында алар тагын да матуррак шәһәр корып, аңа Биләр дип исем кушканнар, үзләрен бараж халкы дип атый башлаганнар. Ләкин Аксак Тимер явы килеп Биләрне җимерә, халкын кыра. Бу сугышта Биләрнең хакиме Жадыш бәк батырларча һәлак була. Әсир төшкән халык кырыла. Аксак Тимер бары тик Жадыш бәкнең тол хатынын гына ике углы белән исән калдыра. Беренче углы Инсан исемле бәк Зөя суы буйларына китеп урнаша, икенче углы Ихсан бәк:

— Мин иске ватаным Зәй буена китәм һәм шунда яңа тормыш корып яши башлаячакмын, — дип Зәйгә әйләнеп кайта.

«Дәфтәри Чыңгызнамә»дә шулай язылган. Галимнәр фаразынча, бу әсәр унҗиденче гасырда Ихсан бәкнең оныклары тарафыннан язылган.

Димәк ки, атаклы «Дәфтәри Чыңгыз намә» Зәй каласында язылган булып чыга?

«Кымыз, бүзә, көфек эчеп туйганнар;
Зивә жаны Сәй буенда күргәннәр.»

Иске төрки язмалардагы җырның шушы сүзләре Һади Атласиның «Казан ханлыгы» исемле китабында язылган. (1993, 187 бит.) Атаклы галимебез Атласи шул ук биттә дәвам итә.

*«Аксак Тимер Болгарны Габдулла хан заманында харап кыйлды, Габдулла ханны үтерде. Аннан ике угыл калды. Берсе Галимбәк вә берсе Алтынбәк. Галимбәк горбәтлектә (ятим, чит илдә) үсте, галим булды, Болгар илендә Касан дигән кечек шәһәрдә имам вә мөдәррис булды. Алтмыш өченче баба, аннан Әмир хан туды. Ул Касанда утыз ел торып, Зәй катында үлде.»*

Фараз кылсак, димәк, Галимбәк белән Алтынбәк Болгардан 1395 елда качып китә. Аларның берсенә тугыз, икенчесенә жиде яшь була. Бәгъзебер галимнәр әйтүенчә, бу вакыйга 1361 елда булган. Димәк, Бөек Болгарның соңгы ханы Абдулланың оныгы, Казан ханы Галимбәкнең углы Әмир хан изге Зәй туфрагына жирләнгән. Гасырлар, афәтләр генә аның кай урынга жирләнгәнен яшереп тора. Килер заман, иншалла, анысы да ачыкланыр. Ачыкланыр һәм татар халкы аның туфрагы өстенә мәһабәт төрбә салып куяр.

Әмир ханның Зәйгә килү тарихы, ни өчен Казан тикле Казанны, тәхетне ташлап, Зәй кебек провинциягә китүе турында болай фикерләргә була. Ни өчен ханзадә Әмир атасы урынына Казан падишасы булып каласы урында кинәт кенә Зәйгә китә, шунда вафат була? Читләтеп булса да, бу сорауга җавап табып була кебек һәм Әмир ханзадәнең Зәйгә күчү тарихын төгәлрәк әйтергә була. 1445 елда Олуг Мөхәммәд хан Казан ханы Галибәйне үтереп, үзе тәхеткә менә, үтерелгән ханның углы Әмир ханзадә яки үзе качып киткән яки Олуг Мөхәммәд тарафыннан читкә сөрелгән. Шулай булганда Әмир ханзадә чама белән 1415 елда туган булып чыга. Утыз яшендә, ягъни 1445 елда Зәйгә килә.

Шулай итеп, без борынгы Зәйне эзләп, тарих коесына бер баскыч төштек. Һәм Зәйнең тарихы 560 елга озыная да 1445 елга барып тоташа.

Шул заманнарны саран тасвирлаган документларда («Дәфтәри

Чыңгызнамә»дә) Зәй сүзе тагын телгә алына. Ул вакытта Зәйнең олуг бәге Колый углы Байраш хан була. Имеш, шушы Байраш хан бүгенге Баграж янындагы Шәрәтау башына Аксак Тимер өчен йорт, яхшы сарай салып куя һәм, имеш, Тимер әмир Болгарны җимергәннән соң шунда кыш чыга (1395). Галимнәр бу вакыйгага төрлечә карый. Кемдер моны булган хәл, ди, кемдер аның дөреслегенә шик белдерә. Моны бары тик Баграж тавы башында җитди казылмалар үзгарганда гына исбат итеп яки инкарь итеп була торгандыр. Ни генә булмасын, бу — тарихка язылып куелган бер вакыйга бит инде.

Менә, без Зәйне эзләп, тарих коесына тагын бер баскыч төштек һәм Зәй тарихы озынаеп, 1395 елга барып терәлде.

Өченче баскыч безне тагын да түбәнрәк, 1212 елларга алып төшә. Ул безне монгол яулары, Батый хан, Кол Гали заманнарына чаклы китерә. Ялчыгол язуынча да, бүгенге кайбер галимнәрнең фикеренчә дә Кол Гали безнең якташыбыз булып чыга.

*«... Болгарда асыл шаһзадәләрдән олуг дүрт бәкнең берсе—Габдулла ханның оныгы Мирхаҗи углы Кол Гали... Кол Гали кыргыз даласына качып, аннан атасының йорты Зәй тамагына килә.»*

Габдулла XII гасырда яшәгән, дип уйларга нигез бар.

*(Татар әдәбияты тарихы, 1984, 1 т. 126 бит.)*

— Нишләп соң без тарихи вакыйгаларны бары тик менә шушы, бүгенге Зәй шәһәре урынына бәйләргә тырышабыз? Бу Зәй кешеләренең артык ватанпәрвәрлегеннән килмиме? Бәлки Зәй елгасы буенда тагын берәр шәһәр булгандыр? Документларда бит «Зәй шәһәре» дип төгәл язылмаган,— дип әйтүчеләр дә бар.

Зәй тамагында, ягъни Зәйнең Чулманга кушылган тарафында тагын нинди шәһәр булды икән? Зәй каласының урнашу шәкеле: ул тау башында, елга буенда, артында урман, стратегик яктан бик унай урын. «Зәй тамагы, Зәй ягы» дигән тарихи язмаларны без «Зәй кальгасы, Зәй шәһәре» дип фаразларга гына түгел, ныклы ышаныч белән әйтә алабыз. Зәй бәклегенең башкаласы нәкъ бүгенге Зәй шәһәре урынында гына була ала. Бәс, татар милләтенең әдәбияты, мәдәнияте башында торган атаклы «Йосыф—Зөләйха» кыйссасы безнең туфракта, Зәй төбәгендә яралтылган, дип хаклы рәвештә горурлана алабыз.

Өченче баскыч Зәй тарихын тагын да озайтты һәм без 1212 елларга барып чыктык.

Дүртенче баскычта без «Зәй» сүзен, Зәй елгасының түбән тарафында кулкулыкка салынган шәһәр атамасы буларак, 1180 еллар тирәсендә очратабыз. Хәтта борынгы харитада[1] без ул шәһәрнең нәкъ бүгенге урында утырганын да күрәбез. «Җәгъфәр тарихы» китабындагы харитада Чулманга коя торган елгага «Тамта Зәй» диеп язылган һәм нәкъ бүгенге Иске Зәй шәһәре утыра торган урында шәһәрне аңлата торган нокта куелган. Китапның 136 битендә укыйбыз:

*«Чәлбир аның белән тыныша алмады һәм 1179 елда ул Кол Даут углы Мирхуҗаны сәед итеп куйды. Мирхуҗа исә Ислам динен тарату эшендә ару-талуны белмәс кеше иде, ул гомере буе төрле төбәкләрдә Ислам динен таратып йөрде-йөрде дә, ниһаять, Тамта тамагы белән Җәлмәт кушылган җирдә урнашып калды.» (Иман Бахшы. Җагфар тарихы, 1993, 136 бит.)*

[1] харита – географик карта

Зәй тарихы тагын өлкәнәйде һәм без 1147 елга барып җиттек.

Шул ук «Җәгъфәр тарихы»нда (60 биттә) Җолыт би углы Тартуның Тамта төбәгенә олугбәк (губернатор) итеп тәгаенләнгәне турында языла. Бу төбәк, ягъни Тамта төбәге, дип яза автор, Чишмә белән Уралтау арасындагы җирләрне били. Бу төбәкне урталай бүлеп, Тамтазәй елгасы ага, ди.

— Җолыт углы Тарту кем тарафыннан Тамтазәй өлкәсенең олы бәге итеп куелган соң? — дигән сорауга:

— Алмыш падиша!— дип әйтәбез.

922 елда Ислам динен рәсми кабул иткән атаклы Болгар ханы Алмыш (Алмас) падиша, Зәйгә Тартуны олуг бәк итеп тәгаенли. Тартуның Зәй башлыгы итеп билгеләнгән елын чамалап буламы? Тырышып карыйк.

«Җәгъфәр тарихы»нда (56 бит.) бу вакыйгадан алдарак болай язылган: *918 елда Алмыш ханның сәяси хәле мөшкелләнә (ул хәзәрләр белән сугыш хәлендә яши. Р.Б.). Менә шул вакытта Җолыт би Болгар артындагы Барынҗар (Барын җире. Р.Б.) бистәсенә килеп урнаша. Аның углы Тарту шул Барынҗар бистәсенең бәге Барынның кызына өйләнә.*

921-22 елларны Алмыш падиша Багдадтан илчеләр көтеп узгара. Шуңа күрә, Тартуның Зәйгә хаким итеп җибәрелүе, кайдадыр, 918 ел белән 920 еллар арасында булырга тиеш, дигән нәтиҗәгә килеп чыгабыз.

Димәк ки, 918-22 еллар арасында инде Зәй каласы Тамта өлкәсенең баш шәһәре булып торган. Һәм аның олугбәге булып Җолыт углы Тарту исемле шәхес торган. Байраш ханга чаклы булган Зәй падишаларының исемнәрен тарих хәтерләми, ә менә Тарту бәк исеме тарихта калган.

Шулай итеп, без тарих төпкеленең дүрт баскычына төшеп җиттек тә тукталдык. Бу урында без сорау билгесе куябыз: Тарту вакытында ук олы бер төбәкнең, бәклекнең башкаласы булган Зәй шул көнне генә корылмагандыр бит? Аннан алда да бу стратегик унай урында кешеләр яшәгән, идарә иткәннәр. Кемнәр анда хаким булган? Анысы инде безгә караңгы, әмма Зәй шәһәренә нигез салыну вакытын бүгенгечә хисапласак, 2010 — 918 = 1092 килеп чыга.

Зәй каласы Казаннан да, Мәскәүдән дә алда корылган!

Димәк ки, Зәй каласына кимендә 1092 яшь!

Зәй ягы әле бүген дә иң гүзәл төбәкләрнең берсе; урманнар, инеш-чишмә-елгалар, биек булмаган таулары, болыннары, тугайлары, әрәмәлекләре җанны, күңелне иркәли. Моннан биш йөз-җиде йөз ел элек бу табигать ничек булгандыр? Егерме-утыз өйлек кечкенә-матур авыллар белән рәттән икешәр йөз хуҗалыклы зур салалар[2] арасы нибары ике-өч-биш чакрым гына. Алыш-биреш, кыз бирү, кыз алу йолалары, базарлар шау-гөр килгән; болыннарда җылкы, сыер, сарык, елгаларда балык; урманнарда сунарчылык белән көн күрүче аучыларның кайнап торган тормышын күз алдына китерү кыен түгел. Халык көр-таза булган, кан уйнаган. Авыллар бик куе утыру сәбәпле, халыкка җир җитмәгән, җирле булыр өчен урманнарны төпләргә туры килгән, җир өчен гаугалар еш чыга торган, канлы бәрелешләр турындагы риваятьләрне Зәй тарихы күпләп саклый.

1552 елгы җимерелүдән соң бу якларда авыллар тагын да күбәя, ешая, булганнары зурая, халык саны арта барган. Мәскәү золымыннан качып, татар халкы Зәй якларына күпләп күченгән. Унҗиденче гасырда бу тирәләргә тагын урыс хакимиятенең кулы килеп җитә. Тыгыз утырган татар-мөселман авыллары арасына урыслар, керәшеннәр килеп урнаша.

[2] сала – зур авыл; село

## Керәшен мәсьәләсе

*Аралар да безнен, һай, җырак түгел,*
*Нигә килгәләмисең?*

Керәшен халык җыруы.

Бу мәсьәләнең асылына төшмичә генә кайберәүләр:

— Керәшеннәр алар Исламны саткан, нигә керәшеннәр янадан Исламга кайтмый икән? — дигән кебегрәк сорау ташлыйлар.

— Алар беркайчан да Исламга кермәячәкләр, керәшеннәр беркайчан да Исламны сатмаган, алар мөселманнар алдында хаин түгел! Алар күз карасыдай Ана телен саклаган халык. Ассимиляциягә жаны-тәне белән каршы торып, Ана телебезне саклап калган халыкка «сатлык-хаин» дип әйтү — олы гөнаһ! Кайсы милләткә караганлыкнын асылын дин билгеләми! Рухи якынлык, тел берлеге, халык авыз ижатының уртаклыгы, уртак жырулар хәзинәсе билгели. Без — мөселман-татарлар — керәшен-татарлар белән бер милләт вәкилләре. Керәшеннәр Исламга кире кайтмас, чөнки алар беркайчан да мөселман булмаган. Ирексезләп чукындырылган мөселманнар тиздән үз диненә — Исламга кайта. Яки алар чит динне кабул итәргә теләмичә, ватаннарыннан качып китәләр. Ә керәшеннәрне мөселманлыкка кайтырга өндәү — ул ин кимендә, әдәпсезлек. Урысларның югары даирәләрендәге татар нәселле шәхесләр катламы исә бик жинел генә һәм үз ирекләре белән христианлыкны кабул иткән, мөселманлыкта озак тормаган татар гаиләләреннән хасил, аларның күбесе даладагы татар телле мәжүсиләр. Мөселманлыгы какшау булганнар тиз генә христиан булып киткән. Ирексезләп чукындырылган татарлар (яна керәшеннәр) хәзер юк, диярлек, чөнки алар бик тиз урыслашып киткән. Алар керәшен түгел. Яки алар янадан Исламга кайткан. Алар да керәшен түгел. Алар «кире дүнгәннәр» санын арттырган. Чын керәшен кыстаганнан гына Исламга күчмәячәк. Шулай булулары белән алар татар милләтенең оригиналь катлавын тәшкил итә. Алар безнең байлыгыбыз.

Илле-алтмыш еллар әүвәл керәшен жырулары радиодан янгырамый, сәхнәдән дә жырланмый иде. Әллә ничек шунда, керәшен халкының бай ижаты тар даирәдә генә, керәшеннәрнен үз араларында гына кала килә иде. Сүзләре дә матур, көйләре дә матур. Ул жырулар керәшен туйларында, аулак өйләрдә генә ишетелә торган иде. Мин үзем дүрт яшьтән алып, сигезгәчә Зичәбаш исемле керәшен авылында яшәдем, атам-анам укытучы булып эшләгәндә аларны Зичәбашка жибәргәннәр иде. Гомерем буе колагымда керәшен көйләре чынлады. Керәшен жыруын ишетсәм, хәзер дә жирси башлыйм. Кырык эшемне кырылай ташлап, жыру тынлыйм.

Илһам Шакирнын туган авылы Яна Булэк кешеләре арыш-бодай тарттырырга урман аша Зичәбаш тегерменәнә йөри иде. Илһам да бала чактан ук Зичәбашка килеп йөргән. Ул керәшен жыруларын үз итеп, яратып, үз моңына сендереп үскән кеше. 1959 елда булса кирәк, сүз иярә сүз чыккач, мин ана:

— Илһам, шул жыруларны сәхнәгә алып чыгарга иде, жырларга иде, — дидем.

Илһам керәшен жыруы «Бишмәтемдә биш төймә» не беренче булып башкарды шикелле. Рәйсә Темәпи (Тимофеева), Гүри Ибуш, Лена Бичарина, Әнфисә Василова, Галина Казанцевалар кебек талант ияләре бу матур башлангычны күтәреп алды һәм дәвам итте.

Монарчы тарлыкта, кысанлыкта яткан керәшен моннары бөтен татар халкына кайтты, таралды, алар сөеп-яратып жырлана. Репертуарында керәшен жыры булмаган бер генә жырчы да юк шикелле. Бу жыруларны бөтен жырчылар белән бергә бөтен татар милләте жырлый.

Керәшен халык авыз иҗатының алмаздай байлыгы Зәй ягында мулрак тупланган кебек тоела миңа. Үзем шулар арасында үскәнгәдер инде. Аны сакларга, йолаларын дәвам итәргә кирәк. Бу мәсьәләдә мин Зәйнең хакимият башлыгы Сәет углы Рәшит Хәмәдинең исемен бик рәхәтләнеп язып узам. Ул үзе дә керәшен халык җыруларын гаҗәеп оста башкаручыларның берсе иде. Ул хәтта профессиональ җырчылар да белмәгән борынгы җырларны күнелендә саклый, җырлый торган куәгә ия шәхес. Рәшит әфәнденең ярдәме белән Сәвәләй авылында керәшен ансамбле оешты, ул ансамбльнең җыруларын чит илдән, Швециядән килеп язып алып киттеләр. Һәм бөтен Ауропага, бөтен дөньяга керәшен татарларының җыруларын күп сәгатьләр буе яңгыраттылар. Их, дип уйлап куям, керәшен ансамбльләре бер Зәйдә генә түгел. Алар Мамадыш, Бондюг-Чучунский, Алабуга якларында да байтак, аларны Швеция генә түгел, үзебезнең киностудиядән, телестудиядән дә килеп тасмага, кинога язып-төшереп алып китсеннәр иде, гасырларга сакласыннар иде, дим.

Шулай. Зәй халкы турында фильмнар дә төшерелер, китаплар да язылыр, альбомнар да чыгарылыр, иншалла. Зәй мәшһүрләренең бу кечкенә язмама кермәгәннәре турында яна материаллар тупланып, Зәй энциклопедиясе тагын да тулыланыр, шәт.

Дөресен генә әйткәндә, шушы борынгы якның, данлы якның төп халкы мөселман-татарлар, керәшен-татарлар үз ватаннарында—Зәйдә ятим булып, килмешәк сыман булып күренә килде. Вакыты-вакыты белән Зәйдә керәшен-татар, мөселман-татар төсмерләре югалып тора. Бу, әлбәттә, җитәкчеләрдән дә, сәяси мохиттән дә тора торгандыр. Әмма соңгы елларда, төбәкнең хакиме итеп Рәшит Хәмәдине куйгач, эш уңай якка үзгәрде. Татарлар иркенрәк сулап куйды. Зәй халкы талантлы җитәкче Рәшит Хәмәди әфәндене мәңге онытмасын иде.

Чистай шәһәрен Мишәрстанның башкаласы, Зәй — ул Керәшенстанның мәркәзе, диеп уены-чыны белән сөйләүчеләр бар. (Керәшеннәр «Эзәй» дип сөйләшә). Чыннан да, керәшеннәрнең иң тыгыз урнашкан төбәге Эзәй буйларыдыр, мөгаен. Безнең якта зур-зур керәшен авыллары бар: Борды, Җәйләү, Зичәбаш, Кабан, Сәвәләй, Туңылҗа, Ләке. Шулар белән бер рәттән ярымкерәшен, ярыммөселман авыллары да еш очрый: Бишавылы, Бистебашы, Дүртмунча, Әхмәт, Кадер авыллары катнаш халыклы.

Мондагы керәшен авыллары, керәшен халкы электән үк шушында яшәгәнме, әллә болар мөселманнарның тыгыз утырган төбәкләрен чукындырыр өчен күчереп китерелгәннәрме? Әллә соң болар монда күчеп утырган урыслар булып, христиан динендә калып та, соңра үзләре татар теленә күчеп, керәшен хисабында йөрүчеләрме? Әлбәттә, бу сорауларга тарихчылар, тел белгечләре, этнографлар бергәләшеп җавап бирергә тиеш. Ләкин шулай да күзәтүләрем нәтиҗәсендә тупланган фикеремне өстән-өстән генә булса да язып китмәк буламын. Ялгышларым булса, белгечләр төзәтер. Мин аларга рәхмәтле булырмын.

Бу фикер сөрешендә алда саналган өч компонентның да катнашы булырга мөмкин. Керәшен хисабында йөрүче татар телле урыслар күрше-тирә авылларда байтак. Мәсәлән, кайбер авылларда керәшеннәр дә, урыслар да яшәгән. Соңра урыслар татар теленә күчеп, керәшен хисабына кергәннәр. Заманында мин Кадер авылында укытучы булып эшләп алган идем (1955-1956), Туңылҗа исемле керәшен авылыннан Кадер мәктәбенә татар телле урыс балалары да йөри иде. Халык сөйләвенә күрә, Туңылҗа авылына калмыклар нигез салган. Тунгыл исемле калмык җитәкчесенең исеме авыл исеме булып киткән. Сәвәләй авылында элек чуашлар утырган да, имеш, алар христианлашып, татар

теленә күчеп, керәшен санын арттырганнар. Болар турында «Зәй энциклопедиясе»ндә дә язылган.

Татарлашу (мөселманлашу) сөреше урта гасырларда бик тә куәтле булган; хәтта Казан ханлыгы егылгач та, чукыну белән бер рәттән, әле бу гадәт, татарлашу гадәте озак еллар дәвам иткән.

— Алтын Урда, Болгар, Казан дәүләтләре эчендә яшәгән кайсы халыклар татарлашкан? — дигән сорауга:

— Мари, чуаш, удмурт һәм башка халыкларның күпмеседер Исламны кабул иткән яки үз динендә калып, татар теленә күчкән. Татар телен бу халыклар Исламга кадәр күп еллар элек үзләштергән, әлбәттә. Бу гадәтнең калдыклары шушы көннәргә чаклы килеп житкән. Татарча белмәгән чуаш, мари, удмурт сирәк иде әле утыз-кырык еллар элек кенә. Бүгенге Татарстанның Чуашстан, Мари, Удмуртстан, Мордвага чиктәш төбәкләрендәге татарлар кайчандыр татар телен һәм Ислам динен кабул иткән чуашлар, удмуртлар, мариларның торыннары.

1552 елдан соң ирексезләп чукындыру гасырлары дәвамында элек чуаш, мари вә башка халык булып, әле күптән түгел генә Ислам кабул иткән кешеләр икенче бер дин — Христианлыкка күчәргә мәжбүр булганнар. Тел кала — дин үзгәрә. Шулай итеп, татар телле христиан кавеме барлыкка килә. Бу христаннарның бер өлеше яна гына Исламга күчеп, шундук чукынган татар телле чуашлар, удмуртлар, марилар. Бу христианнарның икенче бер өлеше Исламны кабул итмәгән татар телле мәжүсиләр, потпәрәстләрдән тора. Исламны әйләнеп узып, алар мәжүсилектән турыдан-туры христианлыкка күчкән халык. Ул керәшеннәр беркайчан да мөселман булмаган. Ягъни Исламны «сатмаган». Мәскәү контроле йомшаруга ук бу христианнарның кайсылары Библияне жиргә күмеп, янә Коръән укый башлый. Жәза әтрәтләре килүгә алар Коръәнне күмеп, Библияне яшергән урыннан алып укырга мәжбүр булалар. Бәгъзеләре гомерлеккә христиан булып китә, кайберләре мөселманлыгын югалтырга теләмичә, ераккарак күченә. Янә Исламга кайта. Шулай итеп, борынгы авылларда берничә зират барлыкка килә. Шушы ук халыкның бабалары мәжүсилек зиратына да, мөселманнар зиратына да, христианнар каберлегенә дә жирләнгән. Әлбәттә, мәжбүри чукындырган чорларда чын мөселман-татарлар арасында да христиан динен кабул итүчеләр булган, бигрәк тә нугай татарлары Мәскәүгә китеп, чукынып, кенәз кызларына өйләнеп, хәрби дәрәжә, жир, бүләкләр алган, Йосыпов, Шереметьев, Мусин, Карамзин, Державин, Аксаков, Кутузов, Давыдов, Куприн, Куратов, Рахманинов һәм башка бихисап урыс кенәзләре татар токымыннан. Боларның борынгы бабалары үз теләкләре белән чукынган һәм урыслашкан халык. Ләкин Казан, Болгар, Алтын Урда жирендәге борынгыдан килгән мөселман халкы арасында чукыну бөтенләй булмаган, дип әйтергә була. Һәрхәлдә бик сирәк булган. 1552 елдан соң кайбер татарлар чукынып, малын саклап калган, ләкин тора-бара алар урыска әйләнгән.

Татар халкының төп өлеше, затлы нәселләре сугышларда кырылып, әсирлектә үтерелеп, бер өлеше чукындырудан качып, Урал, Агыйдел, Зәй якларына күченә. Зәй төбәгенә якын урыннарда чуашлар, мари халкы күпләп утырмаган. Димәк, бу якларга керәшеннәр кайчандыр (XVIII йөздә) Ак патша, Әби патша заманнарында күчерелгән кавем түгелме икән, дигән уйга этәрә. Чөнки гасырлар буена Ислам динен тоткан нәсел чукынуга караганда үлемне яки күчеп китүне яхшырак санаган. Чын мөселман-татар христиан динен кабул иткән очракта да, аның гадәте тиз генә үзгәрмәс иде: кием, ихата, йолалар, гадәтләр, төскә мөнәсәбәт шул килеш сакланган булыр иде. Керәшеннәрнең алача, кызыл, карангырак төсләргә тартылуы урыс,

чуаш, мари, башкортларныкына бик якын. Башкортлар Исламны Казан татарларына караганда соң кабул итә. Мөселман-татарның сөйгән төсләре: ак, яшел, зәңгәр, бирүзә. Кызыл төс тастымалларда, ашъяулыкларда гына хакимлек итә. Мөселман-татар хатыннарының киемендә кызыл төп төс түгел, бары тик башка төсләр аралашында гына була. Көйләрдә дә шул ук уртаклык нык сизелә. Керәшеннәрнең борынгы көйләре күрше-тирә татар булмаган халыкларның көйләре белән дә аваздаш.

Димәк ки, Зәй керәшеннәре патша гозере белән бу якларга китерелгән халык, дип әйтергә җирлек бармы? Әллә алар шушы урында утырган мөселман татарлар булып та, христиан динен кабул иткән керәшеннәрме? Алайса, ни өчен бер үк авылда яшәүче мөселман-татар каралты курасы белән керәшен-татарының каралты-курасы нык аерыла. Киемнәре белән дә нык аерыла иде.

Әгәр дә керәшеннәр күчерелгән халык булса, ни өчен китерелгән соң алар?

Монда фаразлар байтак, мин бәлки сәпит уйлап табарга тырышамдыр, әмма фаразларымның берсен генә булса да әйтергә кирәктер.

Патша Русиясе керәшеннәрне мөселман-татар өстеннән күзәтче буларак кулланырга тырыша. Чыннан да, тимер эшләрен мөселман-татарлардан алып, урыска, керәшенгә биргәннәр, чөнки мөселман-татар тимерчесе баш күтәрү өчен корал кояр, дип курыкканнар. Без үскәндә генә дә әле Зәй якларында бары тик урыс белән керәшен кешесе генә тимерче булып эшли иде. *Тәмәкече, бөкече, тимер сандал чүкүче*, дип такмаклый торганнар иде. Шушы кечкенә генә такмак белән дә социаль мохитнең бер почмагын аңлатып була. Тимерчеләр бары тик урыс яки керәшен булган, дидек. Урыс белән керәшен өзлексез тәмәке тарткан. Тәмәке тарту гадәте татарга бик соң керә. Тимерче икән — ул кяфер, кяфер икән ул —тәмәкече. Тимер сандал чүкүче.

Христианнарга икенче бер вазифа да йөкләнә. Мөселман-татарлар күпләп урнашкан төбәкләрдә җәза оешмаларында бары тик урыслар яки керәшеннәр генә эшләгән: становойлар, урәтникләрнең барысы да христиан кешесе булган. Бу гадәт бүген дә дәвам итә, Зәй ягындагы бөтен милиционерлар да дип әйтерлек, керәшеннәр яки урыслар иде. Урманчылык та шулар кулында иде. Чөнки урман ул — байлык. Байлык бары тик христианнар кулында гына булырга тиеш. Зимләмирләр заманасыннан алып, бүген дә урманчылар, абияшшикларның барысы да христианнар була килде. Абияшшик − объездщик, урман күзәтчесе.

Шушындый каршылыклы вазифалар йөкләтелсә дә, татар-мөселманнар белән керәшен-татарлар дустанә яши алдылар. Без үскәндә инде ике арада канлы бәрелешләр юк иде. Шулай да керәшен белән катнаш никах хупланмый иде.

Йомгаклап шуны әйтергә була, Зәй якларына керәшеннәр унҗиденче йөздә күпләп килә башлый, бигрәк тә 1620 елларда Зәй каласын, аның тирә-якларын ныгытырга, сакларга китерелгән гаскәр составында.

Керәшеннәрнең теле вә җырулары, йолаларын өйрәнүдә галимнәр аз эшләми, ләкин бу чиксез байлыкны мәңгеләштерү тиешле югарылыкка куелмаган кебек. Керәшен җыруларын әле күптән түгел генә сәхнәгә менгездек түгелме?

Тел мәсьәләсендә мин шуны әйтер идем, керәшен татарларының теле Ислам йогынтысыннан еракта камилләшкән тел. Димәк, бу тел бик тә борынгы тамырлы. Монда тагын бер мәсьәлә калка: дин алыштырдым, дип кенә тел үзгәрмәс иде. Бәс, керәшеннәр элек Ислам динле булган очракта да, ул диндә озак тормаган халык. Шуна күрә, аларга әле үз булып

бетмәгән Исламны ташлап, христиан булу әллә ни хәтәр нәрсә булмаган. Әле яна гына Исламны кабул иткән нәсел һичкаршылыксыз христиан динен кабул иткән. Хәсән Туфан авылында Кармәт кешеләрен дә чукындыралар, поплар китүгә үк кармәтләр тәреләрен, хачларын яшереп, Коръән укый башлыйлар. Поплар килә башлауга ук алар Коръәнне яшереп, тәреләрен чыгарып почмакка эләләр икән.

*«Татар акылы төштән сон. Керәшеннен акылы, керәле дә чыгалы», дигән сүзләрне күрше авыл кешеләре безгә карата әйткәндер кебек. Бер чукынып, бер Исламга кайтучылар турында түгелме ул әйтем?*

Хәсән Туфан сүзе.

Тел белән мәшгуль кешеләр өчен Евангелиенен урыс хәрефләре белән керәшен өчен татар телендә басылып чыккан нөсхәсен, 1883 елда чыккан гарәп хәрефле татарча Инжил Мокаддәсне чагыштырып өйрәнү бик тә кызык булыр иде. Керәшеннәр өчен чыкканында гарәптән кергән сүзләр бик аз. «Инжил Мокаддәс» дип аталган татарча Евангелиедә гарәп-дин сүзләре шыгрым тулы. Юкса, икесе дә татарча. Әйтик, урысча «Святой Дух» керәшенчәсендә «Ару тын» диеп, икенчесендә «Изге Рух» буларак тәржемә ителгән. Керәшенчә —«Кодай», «Инжил Мокаддәс»тә — «Аллаһ».

Борынгы татар телендә «ф» авазы булмаган, диләр. Ана Телебезгә ул бары тик Ислам әдәбияты белән кергән, янәсе. Хактыр да. Зәй татарлары (керәшене, мөселманы) бүгенге көндә дә Патыйма, Пәхри, Нәпис, дип сөйләшә. Керәшеннәр, гомумән, «ф» авазын кулланмый: «пикер—фикер, Пидут—Федот». Керәшеннәр «х» авазын да кулланмый: какъ—хак, Кодай—Ходай, казер—хәзер.

Керәшеннен телендә «н» авазы да сирәк кулланыла: безнен, синен.

Тагын бер кызык күренеш: керәшен «мина—сина» дими, «миа—сиа» дип, «н» авазын бөтенләй төшереп калдыра. Ни гажәп, Татарстан Балтачы, Биектау ягындагы мөселман-татарлар да нәкъ шулай: безнен, сезнен, миа—сиа, дип сөйләшә. Бу күренеш аларнын тамырда бер халык булганлыгын сөйләмиме? Булган бит андый хәлләр, әйтик, Лаеш төбәгенен Ташкирмән исемле керәшен авылы белән Мәрәт Хужа исемле мөселман-татар авылы халкы кайчандыр бертуган булган. Шулай итеп, тагын бер жавапсыз сорау:

— Балтачтагы, Биектаудагы халык башта мәҗүси яки керәшен булып мөселманлыкка кайтканмы? Әллә безнен керәшеннәребез башта Балтач мөселманнары булганмы?

Минзәлә, Актаныш, Мөслим, Зәй, Түбән Кама, Чаллы, Сарман төбәкләрендәге мөселман-татарлар янгырау «з» авазы урынына сакау «з» («д») куллана. Бер туфракта, бер авылда яшәүче керәшеннәребез телендә сакау «з» («д») юк. Бу хәл дә керәшеннәрнен бу якларга сонрак күчеп килгәннәре турында сөйләмиме? Юкса, дин үзгәрткәч кенә ни өчен хәреф-аваз үзгәрергә тиеш? Кыскасы, бу мәсьәләләр үзенең өйрәнүчеләрен көтә.

Зәй шәһәре (керәшеннәр «Эзәй»дип сөйләшә) биек яр башына урнашкан, дидек; бер Эзәй каласы гына түгел, борынгы шәһәрләребезнен күбесе яр башында, су буена корылган. Бу — яу-сугыш вакытларында шәһәрне саклау өчен кулай булган. Казан да, Алабуга, Чаллы, Болгар, Сарытау, Самара, Сарай, Кызыльяр да— барысы да татар шәһәрләре, барысы да су буенда, яр башында, калкулыкта.

Менә мин, Батулла бабагыз, шушы Эзәй якларында туып-үскән кеше.

## Түбән Олыжы

Ие, мин Зәй төбәгенең Олыжы авылында туганмын. Шыкмай кешесе атам Мөхлисулла белән анам Мәкәррәмә ул авылга укытучы буларак тәгаенләнә. Икесе дә балалар укыта. Шунда 1934 елда аларның беренче сабыйлары: минем апам Әнисә дөньяга килә.

Мин Олыжыда 1938 елдан 1942 елгача яшәгәнмен.

Олыжы авылында яшәгәндә чана шуганда җылкы көтүе астында калып, Әнисә апаның күкрәгенә зыян килә. Шуннан соң Әнисә апамның ике яктан да бөкресе чыга башлый. Мин үземне белә башлаганда Әнисә апа бик еш чирли иде, бөкресе зурайганнан-зурая барып, арка сөяге тишелеп ага башлады, анда сөяк туберкулезы азган иде. Әнисә апам гариплегенә бик хурлана иде. Шуңа күрә, ул мәктәпкә йөрми. Өйдә укый. Аның укымаган китабы юк. Өебездә бик бай китапханә бар иде. Әнисә апам 14 яшендә вафат булды. Әбием әйткәндәй, котылды, бичара!

Әнисә апамнан соң, 1936 елда Әнәс абый дөньяга килә. Әнәс абый озын гомерле булмый, кычыну авыруыннан сабый чакта ук үлеп китә.

Әнәс абыйдан соң, 1938 елда дөньяга мин аваз салам. Мин дә кычына башлыйм. Миннән дә өмет өзелә. Ләкин яшәп китәм. Алланың рәхмәте, дүрт яшемдә кычынуларым бетә.

Олыжы мәчетендә балалар ясләсе оештырган булганнар. Мине дә әни шул ясләгә биргән. Ике катлы иде ул мәчет. Асты таш, өсте агач, икенче катында яслә. Мин-чытлык үрмәләп тәрәзә төбенә менгәнмен дә икенче каттан егылып төшкәнмен. Караучы апалар аһ-вах килеп, аска йөгереп төшкәннәр, мин бераз гына елаганмын да, яңадан уйный башлаганмын. Шулай итеп, караучыларга берни дә булмаган. Ләкин умыртка сөягенең астагы икесе имгәнгән булып, гомерем буе шул төшем сызлады. Имгәнгән сөякләрне 1996 елда Һабургтагы хастаханәдә рентген күреп, шаккаттылар, интеккәнсең икән гомер буе, диделәр.

Шул мәчеттә беркөнне кино күрсәттеләр, әни мине дә киногa алып барды. Йонлы күкрәкле, йонлы беләкле бер дию кешеләрне тотып, кайнап торган казанга сала башлагач, мин куркып эскәмия астын төшеп киттем, кино беткәнче шунда яттым. Ята-ята йокыга киткәнмен, әни мине кинодан күтәреп алып кайткан.

Олыжы авылыннан мине дүрт яшемдә алып китәләр. Ләкин Олыжы белән бәйле берничә вакыйга, төштә күргән кебек кенә булып, истә калган.

Миңа бер яшь чагында 1939 елда әтине солдатка алганнар. Без өчәү: әни, мин, Әнисә апа кеше өстендә тора идек. Бу кешеләрнең Хәйдәр исемле бер малайлары бар иде. Ул миннән олырак, миңа өч-дүрт булса, аңа алты-җиде булгандыр. Шушы Хәйдәрне мин гомерем буе онытмыйм.

Сабыр, салмак, басынкы иде ул. Хәйдәр көн саен ындыр артына чыгып, ашлык суктыра торган атларны әйдәкли иде. Шуның өчен аңа бер телем ипи бирәләр. Бу — кырык икенче еллар. Сугышта да, тылда да авыр чаклар булган. Балалар ачыккан чаклар. Хәйдәрләр өендә дә ипи сирәк була торган иде. Хәйдәр шул бер телем икмәген үзе тешләп тә карамый, сындырып, миңа бирә, калганын алып кайтып, әнисенә тапшыра.

Ипи кисәге әләгәсен белеп, мин гел Хәйдәр абыйга ияреп, ындыр табагына барам. Әнисе, әбисе, апалары өйдә ач утырганда, шул бердәнбер телем ипине сындырып миңа бирүнең никадәр авыр эш икәнен мин хәзер аңлыйм. Үзе дә сабый гына Хәйдәр тилмереп, ипи өмет итеп, басып торучы сабый күзләрен күргәч, үз өлешен сындырып миңа биргән.

Хәйдәр абыйларның өе инеш яры ягына, тыкрык буена, эчкәрәк кертеп салынган иде. Тыкрык буйлый апалар аска, ындыр табагына эшкә йөриләр. Анда киндер сугалар, киндер талкыйлар. Шушы апалар яшертен-пошыртын

гына әнигә киндер орлыгы алып кайтып бирәләр иде. Бер уч орлык белән тотылган хатынны ун елга өтермәнгә алып китәләр иде. Әнием шул киндер орлыгын кыздырып, төеп, кыстыбый яки дурычмак пешерә иде. Житмешне узып китүемә карамастан, минем әле дә булса шундый тәмле ризык ашаганым булмады.

Икенче дустым минем Мөнәвир исемле иде. Мөнәвир Йөзлебикә апаның бердәнбер улы. Мөнәвирнең әтисе дә сугышта. Беркөнне Мөнәвир кош тоткан шикелле шатланып, кабынып безгә килеп керде:

— Бүген төшемдә мин Ысталинны күрдем! Исәнме, Мөнәвир, диде. Мин аның кулын чеметтем. Нигә минем кулны чеметәсен? диде Ысталин бабай. Минем әтине кайтар, дидем. Ярар, кайтарырмын, диде Ысталин.

Ләкин Ысталин бабасы Мөнәвирнең атасын сугыштан кайтармады. Йөзлебикә апа яшьли тол калды, Мөнәвир гомере буе ятим булды.

Мәңге юылмаслык булып, бер бабай хәтергә уелып калган. Матур бабай иде ул. Аның карчыгы да бик матур иде. Кыш көне чанага, жәй көне арбасына утырып безнең турдан узганын күтеп, сагалап тора идем.

Аны күреп алуга мин, дөньямны онытып кычкырам:

— Алла баба-ай, Алла баба-ай!— дип аның каршысына йөгерәм. Ул да минем капка төбенә чыкканымны бик тели иде, ахрысы. Алла бабай мине үз янына утырта. Мина дилбегәсен тоттыра. Мин шат.

— Улым, — ди бабай.— Син миңа Алла бабай димә. Алла бирәүгенә була ул. Кабат миңа алай әйтмә, — ди.

Ишегалдына кайтып житкәч, бабай атын тугара, матур әби аның кулына комганнан су салып тора.

— Һи—и, безнең улыбыз кунакка килгән икән, — дип матур әби мине өйгә чакыра.

Әби белән бабай мине бал белән сыйлый. Ул гел мине бал белән сыйлый иде. Шуннан соң мин аны «Балбабай» дип йөртә башладым. Күп еллар узгач, мин Олыжыга кайтып килдем. Шунда миңа сөйләделәр. Гыймазетдин исемле булган икән ул бабай. Халык арасында «Имай баба», дип йөрткәннәр, ул умартачы булган, карчыгы белән икәвесе генә гомер кичергәннәр, балалары булмаган. Бәлки бала тансыклаганга күрә, алар мине шулай яраткандыр!

Урыннары жәннәттә булсын!

## Хасталыклар

*Спорт сәламәтлекне арттыра дигән сүз дөрес түгел, юкса, спортсменнар озын гомерле булыр иде. Йөргән саен машина яңармый бит, туза гына.*

Разил Вәлиев.

Аллаһы Тәгалә миңа озын гомер биргән, шөкер; «озын гомер» дигәч, бәгъзеләре: алтмыш яшь күпмени ул, дип тә куяр (мин инде 74 не тутырып килем), ие, кайберәүләр өчен аның сиксәне дә озын түгел, ә минем өчен, минем холкым, минем какшау сәламәтлегемә күрә, алтмыш яшькә кадәр яшәүне дә «озын гомер» дип санарга була.

Әни сөйләгәннәрдән мин шуны хәтерлим. Дүрт яшькә чаклы миндә төче авыруы була, бүгенгечә әйтсәк—аллергия. Абыем Әнәс тә ике яшькә чаклы да яши алмаган, кычынуларга түзә алмыйча, жан биргән. Мине дә шулай кашынып, кычыту йөрәгенә төшеп, үләр, дип уйлаганнар. Ходаның рәхмәте, дүрт яшемдә бу чир миннән киткән. Хәтерлим әле, кашып чиләнгән урыннарга күкертле май сылыйлар иде. Күкерт сылауга ук жәрәхәтләр үтереп

әчетә башлый, астына җибәрәсең. Шул ук мизгелдә рәхәтлек тә сине били бара. Үзең җылыйсың, үзең рәхәтләнәсең.

Авыруым китте, әмма шул әрнү катыш ләззәт икесе гомерем буе миннән калмады. Шул авыруымның тере шаһитләре булып, сабый чакта тырнакларым белән умырып кашыган урыннардагы җөйләр хәзер дә колак артларында, саңакларда саклана. Ул урыннарга төк чыкмый: тамырлары тырнак белән йолкынган.

Үземне белә-белгәннән алып минем саруым кайный. Калган бәрәңге, борчак ашы, тары боткасы, балан, арыш ипие кебек ризыклар ашасам, хәзер дә бугазыма әче су менә.

Әнием Мәкәррәмәне Зичәбаш исемле керәшен авылындагы мәктәпкә күчерделәр. Миңа дүрт-биш яшь чамасы. Әбием Мәгъсүмә өйрәтүе буенча, мин керәшен өендә ашамаска тиеш идем, чөнки керәшеннәр дуңгыз ите ашый. Керәшеннәрнең чишмә-кое яннарындагы, авыл башларындагы чачауникларына акча салмаска тиеш идем. Чачауник – часовня, юл чатларына, авыл башларына, чишмә башларына куелган кечкенә куыш, оя. Шул куышка үткән-сүткән хәер-садака салырга тиеш. Акчасы булмаса, кульяулык, сәгать, балдак, һәм башка әйберләр. Җыелган малны поп җыеп ала да, чиркәү файдасына тота яки мохтаҗларга өләшә.

Ярый, салырга акча булмаса, алырга ярый торгандыр дип, мин тау чишмәсе янындагы чачауникны таладым. Андагы патша акчаларын, совет акчаларын, сәгать тәгәрмәчләрен, үземә ни ошаса, шуны кеше күрмәгәндә генә, төнлә барып урладым. Шуннан соң икенче көнне үк мин каты авырып, урынга яттым. Борыннан кан китә, тамактан аш узмый, тәнем ут яна. Бу кызамык чире иде булса кирәк. Әнинең котчыккыч курыкканын гына хәтерлим. Шулай үлем белән тарткалашып ятканда, күрше Сашук дәдәйнең анасы Начтук җинги кереп, яныма утырды да:

— Улым, әллә сун син Кодайга каршы берәр җазык эшләдеңме? Син әллә берәрсенең бакчасына кердеңме, әллә сун берәр нәмәстә урладыңмы? Урлаган булсаң, син алган нәстәләреңне кире илтеп куй, аннары сун терелерсең, — диде дә чыгып китте.

Мин бу турыда беркемгә дә әйтмәдем, караңгы төшүгә үк көч-хәл белән торып, алган акчаларымны, сәгать шөрефләрен чишмә буендагы чачауникка илтеп куйдым. Керәшен әйтмешли, Кодайның рәкъмәте, чыннан да, шуннан соң мин савыга башладым.

Минем кечкенәдән йөрәк авырулы икәнемне атам-анам да, әби-бабам да, күршеләрем дә, гомер буе бергә аралашып, кайнашып яшәгән дусларым да белмәде. Сабантуе узышларында сабый чактан ук мин һәрвакыт икенче урында килә идем. Беренче урында Нурзаһид Мәүләви була торган иде. Аның озын буе, озын ботлары, озын тыны сирәк спортсменнарга гына эләгә торган бер байлык иде. Ләкин сугыштан соңгы татар авылында аны зур спортка кем кыстасын? Юкса, ул йөгерү буенча дан казанган булыр иде. Боз өстендә тәтке белән шуып узышканда да беренче Мәүләви Нурзаһиды, икенче мин килә идем. Тәтке – агач табанчага яссы тимер беркетеп, итеккә, чабатага бәйләнә, бозда шуа торган җайланма: коньки. Чаңгы ярышларында да шушы ук хәл гелән кабатлана торды. Суга чумганда да мин су астында иң озак торучыларның берсе идем. Чаңгы буенча— разряд, мылтыктан, автоматтан ату буенча разрядлы спортсмен, кылыч сугышы—фехтованиедә мин ВУЗыбызның беренче рапирасы идем. Ир-җегет булып өлгергәч тә мин Кара диңгездә давыл вакытларында да өчәр сәгать диңгездә йөзеп йөри ала идем. Кырымда, Күктүбәдә иҗат йортында ял иткән чакта Мәхмүт Хөсәен, Нил Юзи белән бәхәсләшеп, мин иртә таңнан, сәгать биштән диңгезгә кереп китеп, сәгать сигез тулганда гына

әйләнеп, йөзеп кайта идем. Шушы чарышлыгым аркасындадыр, ахрысы, мине җен кебек таза, аю кебек сәламәт, бүре кебек чыдам, дип уйлый торганнардыр. Чыннан да илле яшемә чаклы минем авырып ятканым бик сирәк булды. Чыннан да, көннәр буе, атналар буе уза торган мәҗлесләрдә кешеләр егылышып беткән чакларда да мин аякта, алар махмырлап, өчәр көн тора алмый яткан чакларда мин икенче көнне иртән иртүк торган, кырынган, юынган, саф чырайлы кеше булып, «авырулар»ны тәрбияләп йөрүче кеше була торган идем. Кешеләр тулай торакта толып киеп утырганда, мин бил тинентен ялангач йөрим, кышкы салкыннарда, бураннарда кешеләр икешәр кат юрган өстеннән тун бөркәнеп ятканда, мин тәрәзәмне шар ачып йоклыйм.

— Батуллага кырау тими ана, ул җен кебек таза бит! — ди иде шагыйрь Рәдиф дустым.

Шулар өстенә мин әле биюче дә идем, Микулай Дунай белән без профессиональ сәхнәдә, Усман Әлми концертлары составында Мәскәвендә, Питербурында, авылларда гастрольләрдә биегән кешеләр. Мин биеп туймас дәрәҗәдә хәрәкәтчән булдым. Печән чабу, утын яру бүген дә минем бик яратып башкара торган эшләрем. Вышний Волочокта кыска вакытлы солдат хезмәтендә безне төнлә уятып, кырык чакрымлык «марш бросок»ка алып киттеләр. Солдатның тулы кирәк-яракларын күтәреп, без кырык чакрым җәяү барырга тиеш идек. Җәйге чиллә вакытында барабыз әлсерәп, рота сузыла, җәелә бара, артта калалар, урыс җегетләре күз яшьләре белән җылый, татарлар «эһ» тә итми бара да бара. Урыс курсында укучы Сережкин—алып гәүдәле, таза җегеттә кул пулеметы, миндә автомат, Сережкин утырып артта кала, командирлар куа, кычкыра, Сережкинның барырга хәле юк, әллә хәле юк, әллә сансызлана, безнен курсның хәрби житәкчесе полковник Рябовол акыра:

— Не отставать, иначе мы проиграем другому полку!— ди.

Шуннан соң мин Сережкинның кул пулеметын, үземнең автоматны, төрелгән шинельны, көрәк, противогаз һәм башка кирәк-яракны өстерәп калган егерме чакрымны уздым. Безнен полк алга чыкты. Итеге Сережкинның үкчәсен кырган. Ул бичара итек кигәндә аяк чолгавын бәйли белми иде, лазаретка кереп ятты.

Ләкин мин чыдам, мин эшчән, дип никадәр генә мактансам да авылда сабый-үсмер чакта мин ялкаулар рәтеннән чыкмадым. Бакча чүбе утасам да, тәпке (матик) белән күксагыз төбе өйгәндә дә мин Раифлар, Хәнифләрдән артта кала идем. Алар женнәре белән эшли, әйтерсең лә алар ару-талуны белми. Минем бил сызлый. Иелеп эшли башладыммы, үтерә — билем сызлый. Каткан балчыкка шул авырткан, сызлаган төшем белән ятып ауныйм, йодрыкларым белән шул авырткан урынны төям, бераз беткән кебек була да, тагын тотына. Әби дә, Зәкия тутам да мине ачулана:

— Ата ялкау! Эшләмәскә хәйлә табасың, әнә Әминә малайлары жирнең теге башында, син ятасың аунап, — диләр.

Юк, алар минем сул яктагы умыртка сөягемнең үтереп сызлавына шулай ышанмаган килеш үлеп тә киттеләр.

Аягүрә озак басып торганда яки бала күтәреп, яки бер-ике кило сумка күтәреп барганда да билем гомер буе сызлады. Һаман да сызлый. Юк, мин ялкау түгел идем. Мин хәйләләми дә идем, мин чыннан да авыру идем. Һәм илле сигез яшемдә Һамбургка йөрәк операциясенә баргач, мине табиблар жентекләп тикшерделәр. Йөзтүбән яткызып, умырткамны да рентгенга төшерделәр. Рентгенда эшләүче фрау:

— Гомерегез буе сезнең менә шушы төшегез сызладымы?— дип сорады. Үземне белә-белгәннән бирле җәфаланганымны сөйләп бирдем. Шуннан

соң табибә болай диде: — Анда сезнең астан бер умыртка сөягегез дөрес утырмый, кайчан да булса сез каты әйбергә бәрелгәнсез.

Менә шунда гына кылт итеп исемә төште. Ие, шулай һәм шулай булырга тиеш иде. Өч яшьлек вакытымда мине әни Түбән Олыжы авылының балалар бакчасына бирә. Балалар бакчасы элеккеге мәчеттә урнашкан була. Мин—чытлыкны апалар карап өлгерә алмагандыр, күрәсең, асты таш, өсте агач мәчетнең икенче катыннан мин аска, өеп куелган такталар өстенә егылып төшкәнмен. Төшүем җайлы булгандыр, ахрысы, мин озак җыламаганмын, шулай итеп, баланың сынган, канаган җире булмаганын күреп, сөенешеп, бу вакыйганы онытканнар. Әнисә апам гына бу турыда онытмаган иде. Миннән дүрт яшькә олы Әнисә апам бу вакыйганы үз күзләре белән күреп торганлыктан онытмаган, җае чыккан саен ул аны гел-гел миңа сөйли иде.

Менә, Батулланың үсмер, җегет чактагы «ялкаулыгы» кайлардан килә икән. Мин хәзер дә иелеп эшләүдән качарга тырышам. Суык тигәннәрдә, язын-көзен шул кимерчәге каткан умыртка сөяге һаман үтереп сызлый. Ул сөяк ул кадәр дә каты сызламаган да булыр иде. Нәкь шул урыныма тагын өч тапкыр көч килде.

Беренчесе, унбиш-уналты яшьтә чакта Хәсән абыйга без — үсмерләр йөк төяүче булып йөрдек, машина белән Чаллы элеваторына икмәк ташый идек. Йөкне бушатып, кайтырга чыктык, Нурзаһит атасы янына кабинага утырды, мин ашлыктан бушаган чыбылдыкларга төренеп машина тартмасына яттым. Шулчак ни булганын да абайламый калдым, нидер шартлады, сынды, мин һавада очканымны чамаладым, аста тартмасы чыгып очкан машина, ул туктарга тырышып әкренли, мин туп-туры бензин багы белән арткы тәгәрмәч арасына егылачакмын. Ходаның рәхмәте киң, Хәсән абый тормозга вакытында басып өлгерә, мин таш юлга нәкь бая әйткән урынга, арткы тәгәрмәч алдына умырткам белән барып төшәм, сытылып калмас өчен тиз генә үрмәләп кырга чыгам. Йөк төягән машина безнекенә бәрелеп, кузовны кыеп алып киткән икән. Шуннан соң билем бик озак авыртып йөрде: яшь вакыт, аны табибларга күрсәтеп тормадым, әти-әни моңа игътибар итмәде.

Икенче тапкыр мин авыр йөк күтәреп, тагын шул билемне кузгаттым. Унынчыны тәмамлагач, мин Алабугадагы милиция мәктәбенә укырга кергән идем. Укулар башланыр алдыннан безне — курсантларны авылга урып-җыю эшенә җибәрделәр. Милиционер булып эшләп, белемнәрен күтәрергә дип, документ алырга килгән егерме биш-утыз яшьтәге абзыйлар, дыңгычлап тутырылган арыш капчыкларын бик җиңел күтәрәләр, мин — буыны ныгып җитмәгән унҗиде яшьлек үсмер — алардан калышмыйм, дип шундый ук капчыкларны амбардан машинага ташыйм. Чәндер, ябык идем мин ул чакта. Аяклар көчкә басып тора, юк, барыбер миңа капчык күтәртәләр, барыбер мин авыр капчык ташыйм. Шунда, икенче көнне булса кирәк, мин егылып, капчык астында калдым. Шуннан соң гына олы агайлар, моңа капчык ташытырга иртәрәк икән, дигән нәтиҗәгә килеп, бу эштән алып, җиңелрәк эшкә куйдылар.

Өченчесендә, 1969 елда мине дүрт-биш җегет, һич сәбәпсезгә, кыйнадылар. Саз көн иде, алар кирза итекләр белән бөерләремә, умырткама каты тибә-тибә озак кыйнадылар. Бер кулым белән ике бот арасын, икенчесе белән колагымны тотып, ана карынындагы яралгы бала кебек бөгәрләнеп җирдә, пычракта ятам. Аркам, умырткам аларга ачык мишень иде. Менә шуннан соң элеккеге сызлаулар ешрак һәм катырак кабатлана башлады.

Чыннан да, мин сабый чакта чәндер, чәүчәләк, чебен тимәс, чер итәр, тукмак тисә, тик торырдай идем. Мине бик еш кына яшьтәшләрем

кыерсыта иде. Ләкин көчем житәме, юкмы, тырнашып булса да сугыша идем. Ниндидер үҗәтлек, ярыш рухы бар иде миндә. Әйтик, мин онытылып уйный идем. «Клүкле», «үдриле», «чокыр—туплы», «кәшәкәле—шаралы» уеннарын бик бирелеп уйный торган идем. Үсмер чакта чаңгы ярышларында мин барысын да узарга тырышам. Үзем тәбәнәк кенә булсам да озын-озын яшьтәшләремне узып, өч-биш чакрымда мәктәп чемпионы булдым, аннан соң район күләмендәге ярышларда да алга чыккаладым, 1955 елда без Писмәнгә республика күләмендәге чаңгы ярышларына киттек. Шунда ул вакыттагы спорт, ДОСААФ эшләре белән житәкчелек итүче Филиппов мине ун чакрымлы арага профессиональ спортсменнар белән узышырга жибәрде. Өч-биш чакрым араны ничек йөгереп узасын мин яхшы беләм, кайда көчне сакларга, кайчан соңгы көчең белән чабарга кирәклеген чамалыйм, әмма ун чакрым арада мин нинди хәйлә кулланасын белмим, бер генә хәйлә кала: йөгер, женен өзелгәнче чап, барысын да узарга тырыш. Бичара сабый диген, нигә кирәк булган узу, сабыр гына, акыллы гына йөреп кил шул ун чакрымыңны, командадан кеше катнаштымы, катнашты. Юк, узарга кирәк, дан казанырга кирәк, мин янганчы чаптым. Чыннан да, ин беренче кеше булып, финишка якынлашканда, өч йөз метр ара калгач, мин чаңгы эзенә егылдым. Янып егылдым. Мин әле ул чакта бу гамәлнен нинди нәтижәләргә алып чыгасын, башыма да китерә алмый идем. Авылыма кайтып, аттестатка имтиханнарга әзерләнә башладым, өстәл янында утырганда чыдап булмый, күкрәк кыса, сулыш алуы кыен, бигрәк тә ун як чәнчи, сул якта тупас бер сыкрау барлыкка килде. Бик еш киерелергә, аягүрә басып йөрергә туры килә, бер урында озак бөкрәеп утырып булмый. Әти, кызыш кеше:

— Син нәрсә, чыгымчы ат шикелле, таптанасын, — дип ачулана башлады.

Мин үпкәмә салкын тигән, дигән нәтижәгә килдем. Узар әле янәсе. Юк, күкрәк кысулар узмады, көчәйгәннән-көчәя барды.

Ул вакытта сугыш-хәрби романтика иде без — үсмерләрдә. Барыбызның да офицер буласы килә. Ә мин очучы булырга хыяллана идем. Районга хәрби комиссариатка каралырга киттек. Очучы булу хыялы беренче каралуда ук чәлпәрәмә килде, минем ике күзем дә начар күрә икән. Башкалар астагы чебен хәтле хәрефләрне дә укый, мин өстәге беренче рәтне укыйм, икенчесен дә чамалыйм, өченче рәтне инде укый алмыйм булып чыкты. Мин близорукий, күрә караулы икәнмен. Шуннан сон мине пехотага язып куйдылар. Әйләндерә-әйләндерә тыңласалар да, рентгеннан баксалар да, комиссариат табиблары минем башка чиремне тапмадылар. Ләкин күкрәк кысуы артыкка киткәч, мин авыл хастаханәсенә киттем. Ул вакытта укытучы Галимжан абыйның хатыны Сәйдә апа шәфкать туташы булып эшли иде. Табиблар булмадымы икән, берәр яры киткәннәр идеме икән, белмим, мине Сәйдә апа агач кашык—стетоскоп белән тыңлый башлады. Озак тыңлады, шикләнде. Тагын тыңлады да әйтте:

— Үскәнем, синең йөрәгең дөрес типми, сул якка бик каты кинәйгән булырга тиеш,— диде.

Һәй, авыл медсестрасы ни белә соң ул, дигән шикелле, мин анын бу сүзләрен ишеттем дә, оныттым да. Янә хәрби комиссариатта комиссиядә врачларга күрендем, ләкин берке ı дә йөрәк авыруы турында берни дә әйтмәде. Авыл хастаханәсендәге гап-гади шәфкать туташы агач кашык белән тыңлап, нинди диагноз куя алсын, дип мин тынычландым. Ләкин без Сәйдә апаның никадәр хаклы, никадәр сәләтле табибә икәнен алга таба күрербез.

Беренче тапкыр мин 1951 елда хастаханәгә кереп яттым. Шуклыгым, чытлыклыгым аркасында булды ул хәл. Мин тиктормас бала идем. Чәндер,

ябык, арык булсам да, тере, хәрәкәтчән булдым. Биек агачларга аркан бәйләп, Тарзан булып атыну дисеңме, чаңгы белән тауларыбызның иң текә урыннарыннан шуып төшү дисеңме, сәпитнең утыргычына аягүрә басып, «цирковой номер»лар эшләү дисеңме, ике кул арбасын машина итеп тау түбәсеннән коточкыч тизлек белән аска төшү дисеңме, суга чумып озак тору дисеңме — барысы да минем эш иде. Бервакыт өй кыегыннан коймага, коймадан аягүрә басып, албакча рәшәткәсенә таба барырга булдым. Аягым ычкынып, очып киттем, уң култыгым белән очлы рәшәткәгә эленеп калдым. Аягым җиргә җитми, казыкка элеп куйган карга үләксәсе кебек асылынып торам. Мин акырганга өйдән Исхак абый йөгереп чыкты да, күтәреп алды. Уң култык астымнан шаулап кан ага, сөякләр үтереп сызлый, куркуы аларыннан да артыграк, Исхак абый тиз генә мине сәпитнең алгы рамына утыртты да Бишавылына, хастаханәгә алып очты. Биш-ун минутта мин инде табиблар каршысында идем. Мине шундук хастаханәгә салдылар. Операция ясадылар. Сөякләргә ул-бу юк, ләкин иңбашы белән кулбашын тоташтыра торган мускул тегәрҗеп нечкәлегендә генә калган. Авыл табиблары мине кулсыз калудан—чулаклыктан коткарып калды. Унөч сантиметр озынлыгындагы биш чатлы яра бик озак төзәлде.

Җегет булып өлгергәндә дә чытлыклыгым бетмәгән иде, арта гына бара иде. 1955 елда аттестат алып, гармун күтәреп җегет сыныгы булып йөргән чаклар иде. Мине ул елның җәе дә сагалап торган икән. Әтинең ул чагында бик тә абруйлы «Иж» матае бар иде. Әтидән рөхсәт алып, мин урман хуҗалыгында әрдәнә тураган өчен, акча алырга дип шул матайга атланып чыгып киттем. Кантурдан акча алып, кайтырга чыктым. Иртәгә Сабантуе, акча бар, сөйгән кызым Мөзәянә дә кунакка кайткан. Әти матаена Мөзәянәне утыртып, өр-яңа җиз телле гармунымны асып, Сабантуена чыгачакмын. Кәеф шәп. Йөрәк талпына. Карурмандагы юлда кем булсын, дигәндәй, зур тизлек белән кайтып килгәндә, борылмада җигүле ат башын күреп, матайны кинәт сулга бордым, чытырманлыкларны ерып, янәшәдә генә үсеп утыра торган агачка бәреләсемне күрдем... аңыма килгәндә ике агай мине торгызырга азаплана, янда гына матай ята. Сул аякны тоймыйм. Үзе бар, үзе юк, кул белән капшап та, чеметеп тә карыйм, аяк берни сизми, бил чәнчеп авырта. Агайлар матайны юлга куеп, атландырып кайтарып җибәрделәр. Бормач (руль) кәкрәйгән, тизлек тәбәлдереге (педале) крендил шикелле бөгәрләнгән, икенче тизлектән өченчегә күчереп булмый, шуның өстенә аяк та тыңламый. Ун чакрым араны кайтканчы сул аяк гөбе кебек шеште, балтырдан шаулап кан ага. Матайны ишегалдына кертеп куй да, бакча артлатып, күрше авылга, бүлнискә ычкын. Олы юлга чаклы аксаклап, тыйтаклап бардым, бер агай йөк машинасы белән бүлнискә илтеп куйды, табибларыбыз баскалап, мине акыртып карадылар да:

— Шеше кайтмыйчан сынганмы, тайганмы икәнен әйтә алмыйбыз, — диделәр. Акырып ятам, төнлә чыдар әмәл юк. Бил сызлый, аяк сызлый, матай өчен әти ачуланыр дип җан сызлый. Иртәгә Сабантуе, Алабугадан мин йөргән кыз кунакка кайткан. Мин бүлнистә аягым түшәмгә асылган килеш, үкереп ятам. Өч көн узды, йокы юк, күршеләргә дә йокы юк, сызланам. Шуннан соң Микайла җизни ат арбасына түшәк салып, мине утыртып, Бистебашы авылына алып китте. Анда тайган-сынганнарны дәвалаучы атаклы Гариф абый яши. Ул Казанга киткән булып чыкты, тагын кире кайтып киттек, мин ике кулым белән шешкән аягымны зенитка тубы шикелле күккә төзәп үкереп кайтам. Җизни мине үзләренә алып кереп яткызды. Әти килеп җиткән, ул минем ни хәлдә икәнне күргәч, кырыс кына:

— Матайны төзәттем, кайгырып ятма, — диде дә чыгып та китте.

Ике көннән соң гына Гариф абый кайтты, жизни аның үзен барып алды, мине кымшатыр җай калмаган иде инде. Гариф абыйның шифалы кулы, кешенең рухын анлавы мине шаккатырды.

— Әрҗүдә килен, — диде ул тутама аягымны сыпырып караганнан соң. — Бер таска җылымса су әзерлә, сабын белән тастымал бир.

Шешкән аягымны җылы суга бастырып, Гариф абый салмак кына, тияр-тимәс кенә аякка су сибә, чылата, кулын сабынлап, шешкән аягымны сыпыра башлады, үзе жизнигә карап кызык мәзәк сөйли. Әйтерсең, мин монда юк. Үзе мәзәк сөйли, үзе аягымны сыпыра.

— Менә, дустым, Микайла, — дип башлады ул сүзен. — Сугышта чакта мәетләрне җирләргә куштылар. Мин немец мәетләрен кабер якасына өстерим, икенче бер солдат үзебезнекеләрне икенче чокырга ташый. Карыйм, малай, бер немец әфисәренең кулында алагаем олы алмаз ташлы ике йөзек. Кыйбат инде бу, мәйтәм. Алырга кирәк. Кеше күрмәгәндә генә бер алмазын суырып чыгардым мин моның. Икенчесе чыкмый, каһәрен, алай тарттым, болай эттем — чыкмый. Шуннан мин моның бармагын пычак белән кистем дә, алмазын алып, бармагын кабергә ташладым. Ике алмазлы булдым. Төнлә шул үлгән немец төшемә керде, ул якамнан тотып:

— Китер бармак белән алмазларны! —дип кычкырды.

Мәзәкнең иң кызык җиренә җиткәч кенә, ул сул кулы белән балтырымны тотып, уң кулының баш бармагы белән шайтан сөягенә каты итеп басты, мин акырырга дип авызымны ачтым, ләкин тамагымнан тавыш чыкмады, чөнки шул мәлне үк үзәкләрне телгәли торган сыкрау юкка чыкты. Рәхәт булып китте.

— Бас!— диде Гариф абый.— Аягыңа бас!

Кая басу, куркыта.

— Бас, бас...

Бастым, кая киткән авырту? Дөнья рәхәте.

Аксавым озакка барды. Ләкин Гариф абыйның шушы гамәлен мин гомер буе онытмадым. Рәхмәт йөзеннән күчтәнәчләр алып кайтып, аның хәлен белешеп тора идем. Минем килүем аның күңеленә бик тә хуш килә иде, ахрысы, сөйләшеп сүз бетми торган иде. Мунчасын ягар, карчыгына бәлешен салдырыр иде. Юкса, мин аны сыйларга дип Бистәбашына килдем. Юк, ул мине олылап кунак итә торган иде. Аның яхшылыгын онытмаганыма күрә ул сөенә иде булса кирәк.

— Сызланган кешегә җиңеллек, рәхәтлек бирүдән дә олы бәхет бармы икән?— диде ул тыныч кына. — Мин синең аягыңны утыртканымны хәтерләмим, —ди Гариф абый.— Тик Кәлимулла Мөхлисулласының олы улы икәнеңне генә беләм.

Гариф абый үз гомерендә бик күп кешеләрне аякка бастырган кеше. Шуңа күрә, ул вак-төяк тайганнарны утыртканын хәтерләми дә. Ләкин дөньяны шаккатырган бер вакыйганы тирә-як халкы әле һаман да онытмый, Гариф абый үзе дә аны хәтерли. Еллар буе урыныннан тора алмый яткан унсигез яшьлек кызны арбага салып, Гариф абыйга күрсәтергә, әллә кайлардан алып килгәннәр иде. Гариф абый шуның билен төзәтергә алына. Кыз анасы белән боларда яшәп кала. Гариф абый көн саен мунча ягып, карчыгы, кызның анасы белән авыруның аркасын, умырткасын уалар, сыпыралар. Берничә көннән соң кыз аякка баса һәм үз аягы белән өенә кайтып китә.

Гариф абый турында үзе исән чакта ук риваятьләр йөри иде.

Имеш, бер яшь хатын бик каты кырылышка эләгеп, куркудан ике кулы күтәрелеп, катып калган икән дә, еллар буе шулай яшәргә дучар икән. Алар Зәй төбәгенең Бистәбашында яшәүче халык табибы Гариф абый турында

ишетеп, ерак аралар узып килгәннәр. Гариф абый аны да дәваларга алына. Берничә көн ул аның ин өстен, аркасын уа, сылый, һәм бер көнне Гариф абый яшь жегетләрне, ирләрне үз өенә ашка алдыра. Мәжлес вакытында авыру кызны сәкегә бастырып, кунакларга күрсәтә. Жегетләрнең күзе гажәеп чибәр, әмма гарипләнгән кызга карап ката. Сөйләнә-сөйләнә Гариф абый кызга якынлаша да, кинәт кенә кызның күлмәк итәген кендегенә чаклы ача, кыз:

— Аһ, — дип кычкырып, ике кулы белән ачылган жирен каплый.

Шуннан соң кызның куллары хәрәкәтләнә башлый.

Мин бу вакыйга турында да сораштырган идем.

— Арттыралар, — диде карт.— Алай ук түгел инде, — дип ул дөресен сөйләп бирде.

Кулы катып калган яшь хатынның кулын дәвалап жибәрү вакыйгасы чыннан да булган икән. Гариф абыйның:

— Үзем белгәнне мин малайларыма өйрәтергә тырышып карадым, булмады, берсе дә кызыксынмады, — дигәне хәтердә калган.

*Кешеләрне интектерүдән ләззәт алуга караганда кешеләргә жинелек бирү күпкә ләззәтлерәк.*

Гариф абый сүзе.

Минем аякта матай белән бәрелгәннән жәрәхәт жөе калган. Анысы сызламый. Әмма агачка бәрелгән билем онытылырга ирек бирми. Шул ук умырткамның дүртенче тапкыр бәрелүе иде.

Һәм шулай итеп, мин Мәскәүләргә киттем, анда тагын чаңгы ярышларында женем өзелгәнче чаптым, фехтование буенча да разряд алып, ВУЗыбызда бию дәресләре, сәхнә хәрәкәте, физкультураларда жан тиргә төшеп шөгыльләнә башладым. Һәм Мәскәү ВУЗлары арасында фехтование буенча олы ярышлар алдыннан сәламәтлегебезне жентекләп тикшерә башладылар. Ике яшь кенә табиб, чибәр генә жегетләр, мин ишектән килеп керүгә үк чыраема карый-карый латинча сөйләшә башладылар, минем йөздәге табигый булмаган алсулыкка ишарә итеп, ни турындадыр гәп кордылар. Мин шиккә калдым. Аннан соң алар мине озак тикшерделәр, рентгеннан да карадылар һәм минем тренерны чакыртып нәтижәне әйттеләр:

— Бу жегет ярышларда катнаша алмый, аның йөрәге авыру,— диделәр.

Тренер:

— Это же надежда училище, он—первая рапира в нашей команде, — дигән иде, табиб жегетләрнең берсе:

— Без аны ярышка кертә алмыйбыз, келәмдә егылып үлсә, кем жавап бирер. Ярыш кына түгел, сез аны физкультура, сәхнә хәрәкәте, бию кебек дәресләрдән дә азат итәргә тиешсез, менә справка, — диде.

Шулай итеп, мин хәрәкәт дәресләренә йөрми башладым. Ләкин «Келәмдә егылып үлсә» дигән сүз эшнең житди икәнлеге турында сөйли иде.

Агач кашык белән тикшереп, йөрәгең дөрес типми, сул якка ныклап кинәйгән, дип әйтә алган Сәйдә апа искә төште. Яхшы табиблардан да яхшы шәфкать туташы булган икән ул. Шуннан соң инде мин йөрәк авырулы икәнемне гомерем буе белеп яшәдем.

Табиблар мина тозлы, майлы, кыздырган ризыклар ашамаска, йөрәккә артык көч китермәскә, борчылмаска кушты. Ләкин мин гомерем буе тозлы, майлы, кыздырган, әче-борычлы ризыклар гына ашадым. Сигезәр килолы герләр алып кайттым, һәр көн шулар белән уйный башладым. Табиблар әйткәннәрнең киресен эшли идем.

Шуннан соң егерме биш яшемдә ГИДУВта эшләүче якташым Марс Михайлов (ул академик булды) ашказанымда җәрәкәт барлыгын ачты. Ул да мина ни ашамаска, ни ашарга кирәген әйтеп, физик эш эшләмәскә кушты. Мин аны да тыңламадым. Үземчә актив яшәдем, ни теләсәм, шуны ашаудан ваз кичә алмадым. Елга бер тапкыр гына булса да, утын яру, печән чабу кебек эшләрне бик теләп башкара килдем. Әйтерсен лә, мин барлык авыруларым турында онытпым. Җәмәгать эшләренең уртасында кайныйм, үз иҗатым белән әвәрә киләм. «Ядкәр» исемле иҗат берләшмәсенең рәйсе, ШТМ исемле театраль миниатюралар театрының җитәкчесе, шигъри-музыкаль кичәләрнең уртасында бөтереләм. Сценариесын үзем язам, актерлар белән үзем эшлим, кичәләрне үзем алып барам. Телевидениедә өзлексез тапшырулар эшлим. Өемдә ит ризыклары әзерләп, мәҗлес җыям, дастархан уртасында да мин. Шулай итеп, мин «аю кебек сәламәт, җен кебек таза» булып илле яшемә чаклы яшәдем.

*Яшең җитсә кырыкка,эшләр китә шырыкка*, дигән мәкальне мин, чыннан да, кырык яшемдә генә аңладым. Кырык яшемне мин Мәскәүдә, әдәбиятчыларнын Югары сыйныфларында укыганда уздырган идем. Табын мул, кунаклар күп, хатын-кызларга кытлык юк. Бер атна күтит иткәннән соң мин авырдым. Бавыр ягында элек тә чәнчүләр булгалый иде, бу юлы бавыр ягы каты тотты, өянәге белән тотты. Киттем табибка: унике уймак эчәктә кан саркып торучы җәрәхәт барлыгын һәм үт куыгына шыплап таш тулганын әйттеләр. Табиблар мине бик каты куркытты. Мин Казанга кайтып китәргә тиеш идем. Казанга кайтуга хастаханәгә кереп ятарга куштылар. Ләкин мин хастаханәгә кереп ятмадым. Ике ай буе Казандагы фатирымда кунак җыеп, бәйрәм итеп яттым, уймак эчәктәге җәрәхәт тә онытылды.

*Анын комы коела башлаган инде*, дигән мәкальнең дә никадәр дөрес икәнен мин илле ике яшемә җиткәч аңладым. Чыннан да, туры мәгънәсендә ком килә башлады. Шыгырдап торган кызыл кайрак комташы шикелле ком килә. Атна-ун көнгә сузыла ком килү.

— Бәхетең, —диде табиб.— Ташка әйләнгәнче, бөереңдәге ком агып бетә, сөен син бу эшкә.

Әмма илле җиде яшемдә кинәт кенә таш килеп, интектерә башлады. Чыдап булмый. Бер-ике тапкыр «ашыгыч ярдәм»дә алып китеп энә кадаштыргалап кайтарып җибәргәләделәр. Ләкин берсендә мин өч көн кәкрәеп-бөкрәеп йөрдем, «ашыгыч ярдәм» килә дә:

— Сине хастаханәгә алмыйбыз, синең ташың килә бөереңнән,— дип энә кадап китәләр.

Дүртенче көнне кич буе тырмашып, диварга менә-менә авырып, таң алдыннан эшем бик мөшкелләнгәч үземә әйттем:

— «Ашыгыч ярдәм» мине алмаячак, бу чир мине алып китә икән, —дидем дә өйдәгеләрне уятмаска тырышып кына хастаханәгә үзем барырга булдым.

Хатыным Рузия уянды. Ул шундук эшне аңлап алды. Сәгать иртәнге биш иде.

— Хатын, иң якын хастаханәгә илт, юкса, эш мөшкел, —дидем.

Ярый әле, дежур троллейбус килеп, унсигезенче хастаханә капкасы төбендә төшереп калдырды. Мине каридурдагы кәнәфигә кертеп салдылар. Дустым Радик булмаса, мин шунда сузылып үлә идем. Радик шул хастаханәдә теш табибы булып эшли иде. Ул мине күреп алып, табибларны ду китереп, мине шундук гамәлият[1] өстәленә салдылар. Җирле наркоз биреп, ярдылар. Ләкин уң аяк күтәрелә-китә, күтәрелә-китә. Табибларга эшләргә

[1] гамәлият – операция.

ирек куймый. Табиб пычагын ташлап, каядыр чыгып йөгерде, яндагысы урындыкка утырды, мин:

— Утырам-тартам, кирпеч юкмыни? —дидем.

Янәшәдәге шәфкать туташлары:

— Әле шаярып ята үзе, — дип пышылдый, миңа ачык ишетелеп тора.

Ул арада бер туташ дөбердәтеп, система алып керде, кан тамырына наркоз бирделәр.

Кояшның уң тәрәзә почмагына кереп барышы иде.

Уянып китсәм, Кояш һаман шул почмакта тора. Бик тиз булган бу, дидем. Мин кыймылдаганны күреп, баш очымда уникеләп баш, игезәкләр кебек бер-берсенә охшаган, барысының да авызы ерык. Наркоздан уянганда бер кеше ике булып күренә икән. Мин артык наркоздан ике тәүлек буе айнымаганмын, алар минем авыру йөрәкле икәнемне белмичә, каушаудан наркозны артык биреп ташлаганнар, ахрысы, сукыр эчәгедән коткарып, наркоз белән үтерә язганнар. Эш катлаулы булган. Минем сукыр эчәге шартлаган булган, ләкин ул арка якта булган, җирле наркоз гына алмагач, эшнең катлаулы икәнен күргәч, табиб тагын каты наркоз бирдергән. Болар мин уянган шатлыктан елмая икән. Табиб:

— Авыртмыймы?— дип сукыр эчәк тирәсенә ымлый.

— Юк, —дим, — анысы авыртмый, әмма башым авырта, —дим.

Башыма баксалар, табиблар авып китә язды, табиб кемгәдер кычкырды, тегесе спирт алып килеп, баш түбәмне уа башлыды, әчетә, мин кычкырам:

— Спиртны әрәм итмәгез, миңа да калдырыгыз, —дим.

Шәфкать туташларының берсе тагын иптәшенә пышылдый:

— Әле һаман шаярта бу бабай, — ди. — Теге дөньядан кайтканын белми.

Баксаң, эш болай булган икән, мин тәүлекләр буе ятып, наркоздан чыга башлаганда, сакта торучы шәфкать туташы «барыбер бу уянмас инде», дип каядыр киткәнме, йоклаганмы, коры сәкедәге башымны бора-бора, баш түбәмне суеп, канатып бетергәнмен, чиләнеп беткән баш очым.

Хатын да, ике бала да ике тәүлек йокламаган, утырып чыккан, табиб ана:

— Сез бераз сонга калгансыз, ахры, — дигәч, хатын авып киткән. Бу бит инде: сез үлемтекләр әзерләгез, дигән сүз. — Без барысын да эшләдек. Ләкин ул уянмый, хәле мөшкел. Барысына да әзер булыгыз.

Хатын ни үле-ни тере булып ике баласын житәкләп кайтып китә. Һәм, ниһаять, мин айныйм. Башымны марля белән урап, ап-ак түмәр ясадылар. Берничә көннән соң мин аякка баскач, хатыным белән улларым килде, мин каридурга чыктым, каршымда ике улым белән Рузия. Аларның карашы куркулы, сәер иде, кече малай мине күргәч, анасының итәге артына кереп качты:

— Әнисе, улларым, —дип мин аларга таба атладым, ләкин әниләре дә сәерсенеп артка чикте.

Мин тагын:

— Улларым, әнисе, — дидем.

Шунда гына хатын мине тавышымнан танып, ураулы башыма ишарә итеп:

— Карале, әтисе, синең сукыр эчәгең башыңда идемени соң? — диде.

Шунда гына мин үземнең машина кырылышында исән калган яралы кеше сыман күренгәнемне аңлап алдым. Хатыныма аңлатып бирдем.

— Синеке кешенеке төсле булмас инде, — дип куйды хатын.

Шулай итеп, үлле-мәлле булып, мин тагын аякка бастым, савыктым.

Ләкин алты айдан соң тагын икеләтә наркоз алып, тагын ике тапкыр үлеп тереләсе булачак әле.

Хастаханәдән чыкканда Радик дустым:

— Мондый хәлдә исән калган кеше булмый!— диде.

Ярый, шулай итеп, мин әҗәлдән котылдым. Ләкин баш түбәмдәге яра кутырлап катты. Бер айдан соң башым үтереп кычытырга тотынды. Сак кына кашысам да, түбәмдәге кутыр, каткан кан, чәч кубып төшә башлады. Умырылып куба. Шулай итеп, ике ай булды дигәндә мин чат пеләш калдым. Көзгедән карап, шаккаттым, каршымда Ленин башлы Батулла басып тора. Ярый, минәйтәм, пеләш баш белән дә яшәрбез, кабат кызлар кызыктырасы юк, дип тынычландым.

Шулай пеләш баш белән кеше арасына чыктым. Радио редакциясенә барып кердем. Анда Равил Фәйзуллин, Рәшит Әхмәтҗан, Мөдәррис Әгъләм утыра. Барысы да пеләшбаш. Минем шәп-шәрә башымны күргәч, Равил шатлыгын яшерә алмыйча:

— Әттәч! Безнен полкта да берәү артты! — диде.

Шуннан соң мин авылга кайтып киттем. Анда өч ай чамасы тордым. Баксам, баш түбәмә тагын да куерак булып чәч чыгып килә. Тора-бара пеләш капланды. Башым элеккеге хәленә кайтты. Куп-куе чәч белән мин тагын кеше арасына чыктым. Тагын редакциягә киттем, анда тагын шәрәбашлар гына утыра иде. Минем куе чәчне күргәч, пеләшләрнең берсе кәефсезлеген яшерә алмыйча тамак кырды, аннан соң сорады:

— Карале, чәченне ничек үстерден? — ди бу.

— Өч ай буе сыерлы ялгыз әбидә тордым. Һәр кичне әби сыерының койрыгы астыннан чыккан җып-җылы нәстәне пеләшемә каплап яулык белән бәйләп йокладым. Өч ай булды дигәндә куп-куе чәч калыкты! — дидем.

1989 елның егерме өченче гыйнварында мин йөрәгем тотып беренче тапкыр урамда егылдым. Һәм мин янә ГИДУВта табиблар кул астына барып эләктем. Монда берничә диагноз чекерәеп тора иде инде: ишимия—стенокардия—грудная жаба, уникe эчәктә олы җәрәхәт, зурайган бавыр, ике бөердә шыплап тутырылган ком-таш, острый холецистит, какшаган нерв системасы...

Моннан соң да әле мин табиблар сүзен тыңламыйча яшәдем. Әмма хәлләр әйбәт түгел иде инде, иртә-кич инфаркт алды халәте еш кабатлана иде. Ашыгып йөреп булмый, бераз гына борчылсаң да кан басымы сикерә, сулыш кысыла. Тора-бара мин туктап ял итмичә, тел астына нитроглицерин салмыйча, йөз метр да йөри алмый башладым. Мәрхүм Рәшит Әхмәтҗанның ватанына кайтып, мин халык алдында ярты сәгать чамасы нотык сөйләргә тиеш идем, сәхнәгә чыгып, шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан турында сүз башладым. Биш-ун минут та узмады, йөрәк тотты. Тагын бер-ике сүз әйтсәм, мин сәхнә уртасында йөрәгем ярылып үлә идем. Шулай итеп, мин әзер нотыгымны да сөйли алмадым, сәхнәдән алып чыктылар. Шуннан соң мин тантаналарда сөйли алмас булдым.

Азатлык мәйданында, 1992 елда булса кирәк, бер-ике тапкыр йөрәк өянәгеннән егылдым. Шуннан соң мин ГИДУВта, Унсигезенче хастаханәдә, Кардиология хастаханәләрендә еш ята башладым.

Израильдән килгән табиб белән кардиолог Рөстәм Фәүзетдин улы мине җентекләп тикшергәннән соң катгый нәтиҗәгә килделәр:

— Һич кичекмәстән синең йөрәккә операция ясарга кирәк!— диделәр.

Минтимер Шәймиев, Зәй җитәкчесе Рәшит Хәмәди, Туфан Миңнуллин, Чаллы җегетләре: Рафаэль Сөләйман, Зөфәр Абдуллиннарның актив ярдәме белән йөрәккә операция ясатырга дип, мин Алманиягә, Һамбург каласына киттем.

Һамбургта йөрәгемә гамәлият (операция) ясаганнары турында «Үлем җәрәхәте алган йөрәкнең тибеше» дигән намәдә тәфсиллерәк язылган. Анысы өч томлыкның икенче томында «Сәяхәтнамәләр» бүлегендә булыр.

Шушы гамәлият аркасында миңа «Икенче дәрәҗә гарип» дигән кәгазь биреп, яшьтәшләремнән ике ел алдан мине пенсионер иттеләр. Пенсиягә чыккач, хөкүмәт эшенә ике аягымның берсен дә атламам, дигән сүзем бар иде, шулай эшләдем дә. Пенсиягә хәтле яшәп, ин гайрәтле чагында кеше баеп кала алмаса, пенсия яшендә эшләп кенә байый алмас, дидем. Пенсионер булуның да үзенә күрә бер рәхәте бар икән анын. Акчаң гына житсен. Акча житә, шөкер, уч тутырып өч йөз сум пенсия алабыз. Бер айга өч йөз сумлык бензин яна. Төп-төгәл, бензинлык пенсия. Шулай да, акчага мул яшәмәсәм дә, дусларым аркасында мин кытлык та кичермәдем, шөкер. Шамил Закир минем хәлләрне аңлап, һәрвакыт, җае чыккан саен, миңа ярдәм итә килә. Махсус заказлар биреп, миңа акча эшләтә. Разил Вәли дә мине ыштатка урнаштырып, ел ярым чамасы гаиләмне ашатып тотты, аның өчен мин Төркиядә яшәүче галимебез Надир Дәүләтнең «Русия төркиләренең милли көрәш тарихы» исемле китабын төрекчәдән тәрҗемә иттем. Зәй башлыгы Рәшит Хәмәди дә, калхузыбызның рәисе Камил Ногман да гел-гел ит белән, шикәр-он белән ярдәм итә тордылар. Рөстәм Яхин исемле инженер миңа яхшы хезмәт хакы түләп, Коръәнне тәрҗемә иттерде. Аларның барчасына да чиксез рәхмәтләрем, Аллаһ аларга озын, сәламәт, бәхетле гомер бирсен. Амин!

«Хасталыклар» бүлеген тәмамлаганда тагын шуны әйтәсем килә, миндә барлык авырулар да бар. Баштан-аяк авырудан гына торам мин. Минем кушаматым да «Батулла» түгел, «Бацилла» бит. Көз життеме, ел саен Татарстан гәзитләрендә «Сак булыгыз, Батулизм» дип яза башлыйлар. Батулизм эләктергән кеше сәламәт калалмый. Сул кашым астында башым чәнчеп-чәнчеп авырткалый, салкын тигәннәрдә, озаграк пирәшләгән чакларда була бу хәл. Шуннан башыма кан савар кебек.

Йөрәктә тимер капкач, дүрт тамыры алыштырылган, ашказанында, унике уймак эчәктә җәрәхәт, бавырым шешкән, шәһвәт бизе бүсер белән каплана бара, аякта оян (рожа) һәм ревматизм, шулар өстенә нерв системам какшау.

*Акмулланың олуг бәйрәмен уздырырга Мәскәүгә Башкортстаннан да, Татарстаннан да күп язучылар килә. Барысы да «Россия» кунахканәсенә урнаша. Шунда Муса Гали белән Илдар Юзи очраша.*

*— Нихәлләрен, Муса агай, — ди Илдар.*

*Жае чыгуга зарланырга күнеккән Муса агай ух-вах килә башлый.*

*— Баш авырта, Илдар, чыдап булмый! —ди.*

*— Баш чүп кенә ул! — ди Илдар.*

*— Бавырым да чәнчи! — ди Муса.*

*— Бавыр чүп кенә ул!*

*— Ашказаным да...*

*— Чүп кенә!*

*— Йөрәк начар!*

*— Йөрәк тә чүп кенә, Муса ага!*

*— Алайса нәрсә чүп түгел соң? — дип ачулана Муса.*

*— Ин мөһиме, — ди Илдар. — Ин мөһиме — сәламәтлек!*

Миндә булмаган авырулар: бөеклек чире, мескенлек (кимсенү) хасталыгы, ЙАКТАМ— йогышлы авыруларга каршы тора алуга мохтажлык (СПИД), әшәке көнчеллек, хөсетлек кебек чирләрнең берсе дә миндә юк, Аллага шөкер.

## Сәке

Татар тарихында сәке сөйләп бетергесез мөһим урын били. Татар йолаларының барысы да дип әйтерлек сәкегә бәйле. Сәке юкка чыкты, ана бәйле йолалар да бетте.

Сәке ул тезелешеп йоклау урыны. Сәкең булмаса, балаларыңны, килгән кунакларыңны кая яткызырсың? Иң беренче сәкедән баш тарткан кешеләр коммунистлар, укытучылар булды. Сәкене сүтеп, алар өйләренә ике кеше сыярлык караватт куйдылар. Кунак килсә, карават — кунакка, хуҗалар үзләре идәнгә ята башлады.

Сәке ул йокы урыны гына түгел, сәкегә утырып тәгам җыялар. Сәкегә утырып Коръән, шигъри кыйссалар, никах укыйлар. Сәкедә хатыннар бала таба, сәкедә тәгәрәшеп балалар үсә. Шул сәкедә әкиятчеләр әкият сөйли, бәет әйтә, яңалыклар игълан ителә. Сәке ул университет, сәке ул телевизор-радио хезмәтен үти иде. Сәке өстендә затлы сандыклар, түшәк, ястык, мендәрләр өелгән. Сәкегә утырып, бабаларыбыз изге китаплар язганнар. Сәке астында бәрәңге, икмәк саклана.

Сугыштан соңгы елларда, без—Шыкмай малайлары аулагөйгә йөри идек. Аулагөй ул җитди йолаларның бер тармагы. Аулагөй, радио-телевидение, газета вазифаларын үти торган иде. Аулагөйдә яңалыклар, гайбәт ишетәсең. Аулагөй ул клуб, культура йорты, театр вазифаларын үти. Монда җыр, бию, табышмак әйтешү гөрли, театр уеннары уйнау аулагөйнең җаны иде. Мәрхүм Кайнар Гыйлаҗи абзый өч ир баласы белән хатыны Хәлиләне калдырып, үзе гүр иясе булган. Таһир абый—олысы, Мөнип уртанчысы, Сәет — төпчеге. Аларның өе шау килеп тора. Сәкене сәхнә итеп, без Гафурлар, Гакифләр, Ясирләр, Мөнипләр, Раифлар, Галимҗаннар «театр уйныйбыз». Пьесалар юк. Өйрәтүчебез юк. Әмма спектакль куябыз. Гадәттә, без импровизация белән уйный идек. Әйтик, Гафур аю була, мин аучы, кемдер куян була. Очрашабыз, сөйләшәбез, атабыз, качабыз. «Залда»—идәндә утыручы тамашачылар тәгәри-тәгәри көлә. Гафур бу мәсьәләдә төрле кызык сүзләр уйлап табып, эчне катыра иде. Гафур Йосыпов үзенә күрә актер-импровизатор иде. Балачакның матур хатирәләренә кереп калган бу замандашларымның күбесе юк инде.

Ни кызык, татар халкы пьеса китапларын роман кебек укый, китапханәләрдәге пьесалар җыентыгына чират. Хәтерлим әле, 1952 елда Таҗи Гыйззәтнең төйгән шомырт төсендәге тышлык белән пьесалар китабы чыккан иде. Мин шундагы пьесаларны аулагөйләргә йөреп, җылы мунчаларда ике тапкыр укып чыккан идем. Фатих Кәримнең «Язгы төндә»сен, Марк Твенның «Том Сойер мажаралары»н авыл малайлары кат-кат укыттылар.

Мәгъсүмә әби сәке түренә менеп, озын-озын әкиятләр сөйли. Әкият сөйләгәндә ул курай тарта, кубыз чиртә, аннан үзе көйләп-җырлап, әкиятне дәвам итә торган иде. Әбиемнең сөйләве бер кешелек театр булган икән.

1950 ел. Авылга театр килү—олы вакыйгага әйләнә иде. Чикачи Минлеголы югары очтан, түбән очка чаклы машина сыман тавыш биреп:

— Төйт! Театр килгән! Төйт! Театр килгән!— дип хәбәр сала.

Элеккеге мәчет шыгрым тулы була. Минзәлә театры «Өйләнү» спектакле белән килгән иде. Татар тамашачысы ул тәрҗемә әсәрләрне карамый, дигән фикер яши. Әмма Гогольнең «Өйләнү» спектаклен без—малайлар үзебезнең авылда карагач, Бура-Киртәсенә, Ашытына барып кат-кат карадык. Минем яшьтәшләрем әле дә булса, Әтәч Аяк, Подколесиннар—Әнвәр Фәсхетдиновларны, Кочкарев—Бари Әшрәповларны яхшы хәтерли.

Бари абый, Әнвәр абыйлар белән киләчәктә, егерме ел узгач, сәхнәдәш,

табындаш булырмын, дип кем уйлаган? Бари абый минем «Өчәү юлга чыктык» спектаклендә Әхмәт ролен бик оста башкарган иде. Әнвәр абый «Сөйгән ярым ятка кала» комедиямдә Харамшаны яндырып уйнаган иде.

Урамда Минлегол тавышы ишетелә:

— Төй-йт! Курчак театры килгән! Төй-йт! Курчак театры килгән!

«Дутан батыр» спектаклен карап, минем ушым киткән иде. Могҗиза иде ул тамаша. Әйе, ун ел узгач, шушы спектакльдә катнашучы Фоат Таһиров, Сара Вәлиуллиналар белән, «Дутан батыр»ны язган һәм куйган драматург, режиссер Сәлах абый Хөснияләр белән бергә эшләрмен, дип кем уйлаган? Шушы театрда минем дүрт пьесам уйналыр, дип кем уйлаган? Шушы театрда мин режиссер буларак, унбер спектакль куярмын, дип кем уйлаган? Ул пьесаларда Сара апа Вәлиуллина, Фоат абый Таһиров катнашкан иде.

Чикачи Минлеголы хәбәр сала:

— Төй-йт! Кансирт килгән! Төй-йт! Кансирт килгән!

Фәйзи Йосыпов белән баянчы Мостафа Сәләхетдинов концерты иде ул. Хәтерлим әле, Фәйзи абый, кара-бөдрә чәчләрен селкетә-селкетә шигырь сөйли, Мостафа абый кызыл аккордеонында, вак гармуннарда уйный.

Язмыш шулай хәл итте, мин Фәйзи абый белән дә, Мостафа абый белән дә күп мәртәбәләр сәхнәгә чыктым, гастрольләрдә йөрдем.

Мостафа абый күптән вафат инде. Фәйзи абый исән. Мин аны ике тапкыр видеога, бер тапкыр магнитофонга тавышы, кыяфәте тарихта калсын дип, яздырып алдым.

Урта мәктәпкә йөри башлагач, мин гел-гел спектакльләрдә катнаша башладым. Укытучы булып Кадердә эшләгәндә дә сәхнә минеке иде.

«Социалистик Татарстан» гәзитендә «Мәскәүдәге театр училищесенә артистлар хәзерләү өчен жегетләр-кызлар алына», дигән игъланны күргә үк хәл иттем: мин артистлыкка каралырга барачакмын. Әти:

— Син мал врачлыгына укы! — диде. — Әнә, мал врачы Тикан ничек рәхәт яши. Кулында аты бар. Малны, курмыны үзенә китереп бирәләр.

Мин мал духтырлыгына укырга керергә вәгъдә бирмичә генә, Казанга киттем. Без өчәү идек бер мәктәптән: Микулай Дунай, Хәмзә Арслан, мин. Йөз кырык кешедән егерме ике кеше алдылар, шулар арасында без—якташлар өчәү идек. Бер мәктәптән өчәү кердек, өчәү бетереп чыктык. Ләкин өчебезнең беребезгә генә театр актеры булырга язган икән. Хәмзә Арсланов конкурс белән театрдан китте, мин ике ел эшләгәч, телевидениегә күчтем. Дунай калды. Ул гомере буе сәхнәгә тугрылыкты булды. Бүләкләрен дә, исемнәрен дә яулады. Дөресен генә әйткәндә, мин дә сәхнәдән бөтенләйгә китмәдем. Язучы буларак та, актер буларак та, режиссер буларак та, әкиятче буларак та мин һәрвакыт сәхнәдә, һәрвакыт экранда була килдем. Димәк, сайланган юл дөрес, файдалы булып чыкты.

Икенче сыйныфның кышкы татилында (каникул) мин авылга кайттым. Бу 1959 ел иде. Авыл жегетләрен, кызларын жыеп, программа әзерләдем. Программаның беренче бүлеге «Зәңгәр шәл»дән качкыннар пәрдәсе, икенче өлеше жыр-биюләрдән тора иде. Яшь чак, жүләр чак, дигәндәй, калхуз эше арасында көненә икешәр репетициягә жыелабыз. Куырам мин жегетләрне-кызларны, вакыт тар. «Артистлар» сүзләрен яттан белә, суфлер юк. Биш бию куйдым. Казанда, театрда ни күргән булсам, барысы да сәхнәгә менде. Шушы «труппа» белән без күрше авылларга гастрольгә чыгып киттек. Алты авылда булдык. Бура-Киртә, Кадер, Ашыт, Бишавылы, Бордыбаш, Шыкмай кешеләре әле дә булса ул концертны исләренә төшереп сөйли икән. Гажәеп кызык, матур вакытлар булган икән ул. Грим, париклар алып кайткан идем. Билет сатып уйныйбыз. Тамашачы шаша. Шулай итеп, мин авыл халкына тикмәгә генә артистлыкка укырга китмәгәнлегемне күрсәттем.

## Бабай
## (1875 – 1945)

1913 ел.

Кәлимулла Батуллин (минем бабам) толып киеп, яхшы айгыр жигелгән түрле чанага утырып, янына карчыгы Мәгъсүмәне алып, Пидут исемле урыс авылы урамыннан узып бара икән. Авылга кергәч, кырый йорт капкасы төбендә бер малай маңкасын агызып басып тора икән. Кәлимулла атын туктата да әлеге малайның маңгаена чиртеп, янә чанага утырып китеп бара. Малай акырып жылап кала. Бераз баргач, Мәгъсүмә иренә әйтә:

— Нигә рәнжеттең инде шул сабыйны? – ди.

— Үскәч, олы урыс була ул! – дигән, имеш, Кәлимулла.

Бабам Кәлимулла озын, какча буйлы иде. Тешләре ат теше кебек озынча эре, сирәк. Кул тырнаклары каты, озынча; бармаклары озын, йонлач. Исхак агамның, әтиемнең, энеләремнең бармаклары, тырнаклары—бабамныкы. Мин әби ягына тартканмын. Миндә әбием тешләре, әбием тырнаклары.

Бабам бераз гына «төшергәли» торган була. Мин анысын хәтерләмим. Әби сөйләве буенча гына. Бабам сабыр холыклы иде. Ул яшьрәк чакта толып киеп, жигүле атка чыгып утырганда мактаныбрак гелән:

— Мин бояр Батуллин нәселеннән! — дип әйтә торган булган, диләр.

Имеш, Батуллиннарның бер тармагы бояр булып киткән дә, урыслашкан, икенче тармагында урта хәлле Батуллиннар, ягъни без торып калганбыз.

Бабакаемның ике күзе дә тома сукыр иде. Аның әнисе Хәбибжамал да сукыр булган. Юк, нәселдән булмаган бабамның сукырлыгы. Аның бер күзе элеккеге Ярман сугышында, ядрә тиеп сукырайган. Икенчесе тимерлектә кайнар кыйпылчык тиеп, күрмәс булган. Әбием Мәгъсүмә карчык минсабыйга гел башкача сөйли иде. Имеш, бабай урман кырында Кояшта кызынып ятучы жыланга сыек тал чыбыгы белән суккан да, жылан һавага сикергән, һавадагы жылан бабайның күзенә сигән: бабай шуннан сукыр булып калган. Йоклап ята торган жыланга да, шуышып бара торганына да, сугарга ярамый икән шул.

Сукыр булса да, бабай көн саен үзенә эш таба. Капшана-капшана итеккә олтан сала, утын яра, пычкы теши. Мин аның пычкы тешәгәнен карап утыргалыйм. Пычкы үткерләргә өйрәнүдән битәр, эш азагында бабамның пычкыдан көй чыгарганын тыңлыйсым килә. Пычкының бер сабы ике тезе арасында, икенче сабы сул кулында: сул кул пычкыны ия-бөгә, пычкы: уй-юуй-юуй, диеп тавыш чыгара, уң кулындагы игәү белән бабай пычкыга тиеп-тиеп ала — гажәеп матур көй чыга. Электронный музыкаң бер кырда торсын!

— Бабаң балтада да уйный белә әле ул, — диде әбием.

Мин ышанмадым.

— Ничек уйныйсың инде ул балтада? – дидем.

Бабай мина келәттәге бөтен балталарны да алып керергә кушты. Дүрт балта алып кердем. Бабай балталарны чиертеп-чиертеп тыңлап карады да икесен әбигә, икесен мина тоттырды. Аннан соң игәү белән балталарга жиңелчә генә суккалый башлады. Зең-чең, зең-чең, чә-ча-чә, чә-чә, ча-чә ча-чә ча-чә-чә...

— Әпипә көе бит бу! – дип кычкырдым.

Шуннан соң әби тустаганнар тезеп, бераз су салып чыкты, кайсысына күбрәк, кайсына азрак салды да, балкашык белән сугып тагын «Әпипә» көен уйный башлады.

Әби жәмкинең бер ботына жеп тагып аса, икенче ботын авызына кабып, жәмки арасына чыра пычагы белән сугып көй чыгара иде.

Бабай тешәлгән пычкыны, балталарны келәткә чыгарып куярга кушты.

Эше беткәч, бабай алачыкка, Югарочтагы тимерче агайлар янына бара. Агайларның сукыр тимерче Кәлимулла белән озаклап сөйләшергә вакыты юк, алар сука ясый, урак теши, дага яки арба күчәре ясый, амбар ишегенә күгән коя. Бабай сүзсез генә чүкеч тавышларын тыңлый.

Озак кына шулай утырганнан соң ул:

— Һәйдәле, улым,— ди. — Түбәноч алачыгыннан да бер әйләник.

Таякның бер башын бабайга биреп, үзем икенче башыннан тотам, чакрым ярым араны шулай таяк житәге белән узабыз.

Мин ялан тәпи. Аяк йөзләре чебиләгән. Яңа гына юл уртасына сыер җылы, йомшак «кузикмәк» салып киткән, чебиле аяклар җылы тизәктә рәхәтләнә, мин тизәк ярып барам. Бабай кычкыра:

— Улы—ым, карап бар әле, тизәккә батырдын бит, — ди.

Түбәноч алачыгында да без икәү чүкеч чаңкылдаганын тыңлап утырабыз. Баш тимерче керәшен Кузнецов бәләкәй чүкеч белән кызган тимернең кай төшенә сугасын күрсәтә — чең, Чикачи зур чүкеч белән шул урынга суга — чаң. Оста тоткан бәләкәй чүкеч, «чен-чен» диеп суга. Сугыштан аяксыз кайткан Чикачи Миннәхмәте ут кызган тимерне таптый: чаң-чең, чаң-чең...

Бабай монда да сүзсез генә «чаң-чең» тыңлый, күрек өрдергән кайнар тимернең салкын суга тигәч, җылан кебек чыжылдаганы, олы чүкеч белән бәләкәй чүкечнең сандалга тиюе бабайның яшь-куәтле чакларын хәтерләтәдер.

— Һәйдә, улым, өйгә кайтыйк булмаса, — ди бабай.

Дүрт яшьлек сабый-мин алдан, сукырлыктан бөкрәя төшкән озын буйлы бабам арттарак, уртада—таяк — без өйгә кайтып барабыз.

Капкадан керүгә үк болдырга басып безне әби каршы ала.

— Кайда йөрисез? Мунча шартлап өлгерде, — ди.

Бабай белән мунчаның беренче эссесенә китәбез. Мунча оялдында чишенәбез. Бабай кушучлап үзенең «шәҗәрәсен» каплый.

— Алъяпкычны бир, улым! – ди бабай.

Мин почмактагы агач чөйдә эленгән бабай алъяпкычын кулына тоттырам.

— Син дә алъяпкыч бәйлә, — ди бабай.

Мин дә чүпрәк белән «шәҗәрә»мне каплыйм.

— Бабай, нигә алай итәбез ул? – дим.

— Кешеләр оят җирләрен бер-берсенә күрсәтергә тиеш түгел, олан! Һәр кешенең үзенең сере бардыр.

— Бабай, син күрмисең бит, нигә миңа бәйләтәсең? – дим.

— Мин күрмәсәм, мунча иясе күрер, — ди бабай.

Ул ах-вах килеп, чабына. Мунча эссе, аягүрә бассаң колак пешә. Кат-кат эссе салып, бабай озак чабына, үзе һаман ләззәтләнеп: «ә-әх, әттә-т -тәтә» дип кычкыра. Аннан соң мине ләүкәгә сузып сала да ике себерке белән алны-артны чабарга тотына. Берничә кат чабынгач, без чайканып, киеп килгән керле киемнәребезне киеп өйгә кайтабыз.

— Рәхмәт мунча хөрмәтенә! – дибез өйдәгеләргә.

Бездән соң әби, әни, Әнисә апа мунчага китә. Бөтенесе дә юынып чыккач, бабай белән без янә мунчага керәбез. Бу юлы чабыну юк, юынабыз гына. Мин бабайның аркасын ышкыйм.

— Зур үскән минем улым, ярдәме тия башлады! – дип бабай мине мактый-мактый сыртын ышкыта.

Аннан соң чиста киемнәребезне киеп, янә өйгә кайтабыз.

— Рәхмәт мунча хөрмәтенә! – дибез.

Кабак-чәй эчәбез. Тәмсез булса да, бабай чәйне мактый-мактый, шопыра-шопыра тәмләп эчә. Кабак-чәйдән соң бабай кулына гармун ала. Әби такмаклый-такмаклый бии.

Кыштыр-кыштыр тунынный,
Кыштырдатып киярсең.
Бәхетеңә туры килгәч,
Күрмәсә дә сөярсең.

Бабай җавап әйтә:

Киндер ыштан билдә тормый,
Былафкый кадамасаң,
Шул ыштанны бүләк итәм,
Ятларга карамасаң.

Гармуннан соң бабай чүкеч, кадак, юка такталар алып, ишегалдына чыга. Бисмилла әйтеп, бабай нидер ясарга тотына, мин ана кирәк-ярак биреп торам.

— Бабакай, син ни ясыйсын ул?— дип сорыйм.

— Очкыч ясыймын, олан, яраплан,— ди бабам.

— Ул очкыч нигә ул, бабай, ә?

— Атаңны эзләргә! Ничә ел бит инде, хәбәре юк, атаннын...

— Әтине эзләшергә мине да аласынмы соң, бабай?

— Алмыйчан! Синнән башка мин ни күрәм? Икәү очарбыз, Алла теләсә...

Әти сугышка китеп, хәбәрсез югалган шул. Шушы такта очкычка утырып, бабай белән әтине эзләп табып, ишегалдына кайтып төшкәннәремне мин әллә ничә тапкыр төшемдә күрдем. Ләкин өн башка, төн башка булган икән шул, очкычыбыз очмады. Бабай яз көнне, 1945 елда май аенда үлеп китте. Очкыч дигән нәмәрсәгә, ягъни зур гына фанер тартмага әбием бабайның мич башындагы иске бүрегендәге сап-сары чебиләрне чыгарып салды.

Күп тә узмастан, чебиләр әтәч булып кычкырырга хыялланганда Сукыр Кәлимулланың олы улы Мөхлисулла, ягъни минем әтием исән-сау кайтып төште.

Бабай гына күрә алмады улынын әсирлектән исән кайтканын. Мин әтине бабамның каберенә алып бардым.

Сукыр бабам ясаган «очкыч» еллар буена чеби-бәпкә оясы булып хезмәт итте.

Бераз ашыктым бугай, алгарак китеп сөйли башладым. Әле әти кайтмаган, бабам үлмәгән чаклар турында сөйлисе калган бит әле.

Бабамны мин үлеп яратам. Җәйге каникулларда мин гел Шыкмайда, бабам янында, йоклаганда да анын җонлы куенында булам.

Бабамны мин карурман аша алып чыгып, Зичәбашка китереп житкездем. Әни аны тәмле дурычмак белән сыйлады. Ничә көн кунак булгандыр сукыр бабам, анысын хәтерләмим, мин аны тагын карурман аша Шыкмайга илтеп куйдым да, тагын берүзем генә төлкеле, куянлы, жыланлы, пошыйлы сукмаклар буйлап Зичәбашка йөгердем.

Урманда йөрергә ярата идем мин. Урман кырында, юл буена Кояшта кызынырга чыгып бөгәрләнеп яткан кара жыланнарга озаклап карап торам. Жыланның кабыгын салган вакытын да качып, күзәтеп торганым бар. Жылан ике тар агач арасына кереп кысыла да, әкрен генә кыймылдый, шуыша башлый, шулай итеп, ул иске кабыгыннан чыга, кабык ике агач арасында кала. Шундый жылан кабыгын таяк башына элеп өйгә дә алып кайткалаганым булды. Әби алып кайтырга куша иде ул жылан кабыкларын. Ул алардан ниндидер дару ясый иде шикелле.

Шәйхетдин улы Кәлимулла Батуллин сарыдан 1945 елда дөньядан китте. Урыны оҗмахта булсын!

## Әби
## (1889 – 1959)

*Кеше күрми дип, ямьсез кыланма, барыбер сине кем дә булса күреп тора: кош-корт, киек-җәнлек, Аллаһ!*

Мәгъсүмә карчык сүзе.

1953 елда мин сигезенче сыйныфта укый идем. Сталинның үлгән көнендә бик күп укытучылар җылады. Хәтерлим әле Агъмал Камалы Шыкмай югары очтан түбән очка хәтле акырып, илаулап җылап төшә:

— Атабыз Иосиф Виссарионович Сталин үлгән, нишләрбез инде Сталиннан башка—а...

Шулай илаулап безнең турдан узып барганда әбием Мәгъсүмә:

— Катты тагын бер кяфер! – диде. – Гүре җәһәннәм булгыры!

Шыкмай халкының сөргенгә, сугышка, шахтага киткән чагында җырлый торган җырлары. Әбием Мәгъсүмә карчыктан ишеткәннәр:

Сикереп Айга менә диләр
Арысланның азганы,
Ормыйк башны, түкмик яшьне,
Күрик Хода язганын.

Без китәрбез, ахрысы,
Бөгелмәләр аркылы,
Өстемдәге ак күлмәгем
Кәфен булыр, ахыры.

Шыкмай таулары биектер,
Менә алмабыз инде,
Бәлки рәхәт көннәр булыр,
Күрә алмабыз инде.

Колыманың кырларында
Зәңгәр чәчәк үсмәгән,
Исән булсак, бер кайтырбыз,
Монда туып-үсмәгән.

Урак урган җирләрем лә,
Печән чапкан җирләрем,
Күк чәчәктәй күкрәп калды
Туып-үскән җирләрем.

Безнең илләр кай якта дип
Кыр казыннан сорадым,
Кыр казлары очып узгач,
Бер утырып җыладым.

Мендем тауга, бастым ташка,
Ташның киртләчләренә;
Бер кычкырам, бер сызгырам,
Калдым иптәшләремнән.

Сабый чагымда әбиемнең әйткәннәре хәзер дә колагымда:

— Без — Асыл Хужа балалары, — ди торган иде, мәрхүмә.

Нинди Асыл Хужа ул? Кайчан яшәгән? Ул чагында сораштырырга башка килмәгән. Әбиемнең атасы Ашыт авылының Шәйхетдин исемле кешесе, алар тармагында да Асыл Хужа исеме очрамый. Бабай ягындагы шәҗәрәдә дә Асыл Хужа юк. Кемне күз алдында тотып әйтте икән әби ул исемне? Белгән юк. Гомумән, безнең әби гаҗәеп серле карчык иде ул. Дин, тел, әдәбият, риваять, тарих, музыка мәсьәләләрендә ул кайбер галимнәреннән күп белгән, дигән нәтиҗәгә килдем мин еллар узгач. Шуңа күрә, мин Батулла нәселенең шәҗәрәсен әнә шул серле Асыл Хуҗадан башларга уйладым.

Әбием Мәгъсүмә килен булып Ашыттан төшкән. Ашытның бөтен талантын, матур гадәтләрен Шыкмайга бирнә итеп алып килгәндер ул. Әбинең бер үзендә әллә никадәр сәләт бар иде. Аның зифа буе, яшь кызлар көнләшерлек төз иде. Өчәр-бишәр сырлы бәбәй итәкле күлмәк кияр, толымнарына таллир тәнкәләр асар, матур читекләр кияр, күз явын алырлык итеп чигелгән алъяпкыч бәйләр, көянтә-чиләк асып, тау чишмәсеннән саф су алып кайтып килер. Бик эшчән, житез, пөхтә. Елмайса, күк йөзе

яктыра: утыз ике теше дә исән, энже кебек тигез, хәтта алгы ике көрәк теше дә аның башкалары белән тигез иде: энже диме, ни диярсен. Аның беркайчан да бер генә теше дә сызламады, төшмәде, ул энже тешләрен үзе белән каберенә алып китте. Үлеменә кадәр ул урман чикләвеген үз тешләре белән ватып ашый иде.

Минем тешләрне әбиемнекенә охшаталар.

Мәгъсүмә әби әкият остасы, курайчы, бәет әйтүче, кубызчы, биюче иде. Кич утырганнарда, мәҗлесләрдә ул игътибар уртасында. Әкият-җырдан тыш, ул изгеләр, пәйгамбәрләр турында сөйли башлый. Ул гыйлем кеше, китап укый торган әби иде. «Йосыф—Зөләйха», «Сак-Сок», Сөембикә бәетләре, үзе чыгарган бәетләр дә аның репертуарында байтак иде.

*Сонра мин шушы риваятьләр, бәетләр нигезендә «Сөембикә»(1989) һәм «Сак белән Сок» (2003) әсәрләрен яздым. «Сөембикә» дүрт тапкыр кабатлап басылды. Сак-Сокның ике пьесасы, бер кыйссасы дөнья күрде. Кыйсса «Ялкын» журналында һәм әкиятләр томында, ә «Сак-Сок» (2003) Татар яшьләр театрында, «Ана каргышы» Чаллы драма театрында куелды (2004).*

*Иртә картайган кеше очратсагыз, белегез: ул әкият сөйми торган адәм булыр. Өлкән булса да, күнеле белән япь-яшь, жор телле, дәртле, шаян кеше очратсагыз, белегез: ул — әкиятче!*

Әбием Мәгъсүмә карчык сүзе:

Бервакыт мин Исхак агамның йөз данәлек папирус тартмасыннан жидесен алдым. Тәмәке тартырга өйрәнеп йөргән чак. Мина жиде яшь. Сизгән бит әбием минем бу эшемне.

— Чыгарып сал әле тәмәкеләренне!— диде әби.

Алты папирусны өстәлгә куйдым.

— Берсен тарттыңмыни? — диде әби, мин дәшмим.— Ярар тартсаң. Менә калган бу алтысын да тартып бетер. Ләкин шуннан соң тәмәкегә йогынасы булма.

Әби папиросларны кире бирде. Чыннан да, мин бу папиросларны иптәшләремә таратып, берсен үзем тартып бетердем. Ләкин шуннан соң гомерем буе мин тәмәке тартмадым.

Тавыклар кытаклаудан туктауга әби мине лапаска яна салынган йомыркаларны алып төшәргә менгезеп җибәрә. Маймыл житезлеге белән сәндерәгә менәм, жып-жылы йомыркаларны алам, өч йомырка булса берсен эчәм, эчәм дә жинаятем тотылмасын дип, салам түбәне тишеп, шул тишектән йомырка кабыгын абзар арына ташлыйм. Биш йомырка булса икесен эчәм. Йомыраларны әбигә тапшырганда, ул һәрвакыт ризасызлык илә:

— Һе, кая сала икән бу коңгырт тавык йомыркасын! Монда өч йомырка булырга тиеш иде. Саескан аламы, сасы көзәнме иялгәнгән лапаска? – дип сукрана.

Җәй урталары узып бара торган чакта әбием мине чакырып:

— Улым, бар абзар артында котырып үскән кычытканнарны, әпертиләрне[4] чап! – диде.

Мин чалгы белән кычытканнарны, әрекмәннәрне чаба башладым, әбием читтәрәк карап тора:

— Әйбәт чабасын улым, машалла! – ди.

[4] әперти — әрекмән, тигәнәк. «Әпертмән» дә диләр.

Берзаман минем чалгы әвен кебек өелгән күкәй кабыкларын ачып ташламасынмы!

Әбемнең ике күзе шар булды:

— Әһә, менә кем икән ул саескан! Син чөмереп ташлагансың бу күкәйләрне!

Шуннан соң миңа Саескан кушаматы тагылып калды, ярый әле әбием мине Сасы Көзән димәгән!

Мин гомерем буе чи йомырка эчү гадәтемне ташламадым. Хәзер дә эчәм.

Мәгъсүмә карчыкны сихерли белә, дип сөйлиләр иде. Дөрестерме ул сүз, юкмы, белмим. Урманда йөргән чакларда ул ниндидер үләннәр эзли иде, таба иде дә киптереп сандыгына сала иде. Бервакыт ул миңа энҗе чәчәгенә (ландышка) охшаган, әмма зуррак үсемлекне күрсәтеп:

— Менә, улым, бу олы авыру үләне булыр, ул «Сөләйманның йөзек кашы» дип атала, — диде.

Бәлки ул бу үләнне ничек, кайсы төшен дәвага кулланырга икәнен дә әйткәндер. Хәзер дә шул үләнне очраткан чакларда әби сүзе искә төшә. Аның сандыгында артыш таяклары, сөйдергеч бөтиләре, ачуташлар, тагын әллә нинди сәер әйберләр була торган иде. Шулар янында мин тагын патша шешәсендә зәңгәрсу, озынча канатлы кипкән коңгызларны күрә идем. Өч йөз грамм сыешлык шул патша шешәсе шыгрым тулы иде ул матур конгызлар белән.

Ир уртасы булып җиткәч, энциклопедия актарып утырганда «Жуки» бүлегендә мин әбиемнең патша шешәсенә тутырган коңгызын танып алдым. «Шпанская мушка» дип атала икән ул коңгыз. Аны яз көне сирин чәчәк атканда җыеп киптерәләр икән. Ул коңгызның канатында, гәүдәсендә алколоидлар була икән. Ниндидер микъдарда шуны чәйгә, ризыкка салсаң, ир кешенең гайрәте арта икән.

Шуннан соң мин авыл кешеләре арасында таралган сүзнең «Сихерче Мәгъсүмә» бөтенләе белән үк нигезсез түгеллеген аңладым.

Әтине өзлексез төбәк мәркәзенә чакыртып, изалап кайтарганнан соң Мәгъсүмә әби әйткән сүз:

— Илең булса, Иблисең табыла!

Бервакыт ишегалдында уйнап йөрибез, коймага сөялгән көянтә авып китте, мин йөгереп барган унайга көянтәне сикереп уздым. Әби:

— Ай, Ходаем, нишлисең син, җүнсез бала!— дип кычкырды.— Көянтәне атлап чыгарга ярамый! Аягастында яткан бер әйберне дә атлап чыгарга ярамый.

— Нигә?

— Ботыңа кыярак чыгар! Алып куй көянтәне, коймага элеп куй.

— Нәрсә соң ул кыярак? − дим.

— Шеш, кутыр, чуан! − диде әбием.

Шуннан соң беркайчан да минем әйберләр аша атлап чыкканым булмады. Аяк астына көянтә, тырма, балта ташлаган кеше бер гаепле булса, шуны алып куймыйча, атлап йөргән кеше ун гаепле, аңа җәзасы да катырак була: аңа кыйрак чыга икән, кыз бала булса, кысыр кала икән.

Безнең авыл олы юл буенда утырганга, кайчакларда безгә юлаучылар керә иде. Бервакыт урыслар керде. Атларын тугарып, бер урыс каралты-кураны караштырып йөри, әби ул-буны чәлмәсеннәр дипме, болай, хуҗабикә булып күренергә теләпме, ике кулын күкрәгендә кушырып, болдырга басып, урысның нишләгәнен карап тора. Әбинең торышы патшабикәләрнекеннән бер дә ким түгел иде. Урыс мунчаны карап чыкты:

— О—о, у вас и баня белая,— ди.

Әби дәшми, горур гына басып тора. Урыс лапаска кереп чыкты:

— Хороший хлев, и корова у вас есть,— ди.

Урыс карлыган бакчасындагы жиде умартага карап:

— У-у, у вас и пчелы!?— дигәч, әби кушырган кулларын кыймылдатып куйды да:

— Чава тибә минә думал! Бух дал!— диде.

Бу анын: син безне кем дип беллен, без—татарлар шулай яшибез, дип мактануы иде.

Беркөнне иртән әбием мине уята:

— Тор, улым, ана казны ата казга итәргә кирәк!

Мин иренеп кенә торам, аяклары мунчала белән бәйләнгән ана казны сул култык астына кыстырам. Әби сул кулыма бер тәпән катык тоттыра.

— Бар, улым, аталандырганы өчен Тәкә Барыйларына шушы катыкны бир. Катыкны жингән шундук бушатып, тәпәнне юып бирсен.

Киттем. Тәпәнне жингигә тоттырдым.

— Тәкә Барый абый! — дип кычкырдым капкадан керешли.

Өялды ишегеннән атылып Тәкә Барый абыйнын хатыны — жинги йөгереп чыкты.

— Ул нинди Тәкә Барый? — дип кычкырды жинги. — Барый абый диген.

Мин Тәкәнең кушамат икәнен, фермада мал филшере булып эшләгән чагында Барый абыйнын сарык белән мәтәшкәнен дә белмим.

Барый абый үзе лапас авызында күренде.

— Ни булды? — диде Барый абый сабыр гына.

— Әнә, каз алып килгән! — диде жинги.

Барый абый ана казнын аякларын чишеп, ата каз янына жибәрде.

— Карап тор! —диде Барый абый. — Теге елны да әбиең: ата казын ана казыбызны басмаган, казыбыз кысыр калды, дип авыл буйлап сөйләп йөрде...

Мин Барый абыйнын ата казы ана казыбызны берничә тапкыр басканын карап утырдым да, басылган казны култык астына кыстырып, катыктан бушаган тәпәнне тотып, кайтып киттем. Бу юлы казыбыз кысыр калмады, шөкер, бер тәпән катыгыбыз да әрәмгә китмәде. Казыбыз унбер бәпкә чыгарды. Бәпкәләрне тилгән алмасын дип, мин көннәр буе ышнада бәпкә сакладым. Ләкин бәпкәләрнең сигезе генә каз булып үсте. Бер бәпкә чирләп үлде, аны тиреслеккә күмдек. Икенче бәпкәне тилгән алды. Өченчесен, каз булып өлгереп килгәнен мин уен белән мавыкканда төлке алды. Сигез казны өмә белән йолкып, чистартып, какларга элеп куеп, эч-баш-аяк бәлеше ашап, мамыклары сыдырылган каурыйларны сукмак буйлап инешкә хәтле сибеп чыктык. Шулай итсән, икенче елны да каз мул булачак.

Авыл балалары секс белән сабый чактан ук таныша. Әтәч ике-өч минут саен бер тавыкны басканын, ата каз ана казны аталандырганын, бияне дилбегәгә бәйләп, айгыр йөгерткәннәрен без — малайлар көннәр буе карап йөрибез. Без балаларны коедан алмаганнарын да, кәбестә арасыннан тапмаганнарын да, торналар ташлап китмәгәнен дә белеп үстек. Ана карап сексуаль бозыклыклар кылучы булмадык. Без — малайлар кош-кортны, сарык, бозау, жылкы суйганнарын карап үстек, соңра үзебез дә мал чалырга өйрәнеп киттек, бер дә пычак тотып, кеше суеп йөрмәдек. Малларнын аталануын күрмәгәннәр сексуаль садист, маньяк була, мал суеп карамаганнар сәбәпсезгә кеше суя түгелме?

*Куктән өч алма иңәр, дигән. Аның берсе — әкият чыгаручыга, икенчесе — әкият сөйләүчегә, өченчесе — әкият тыңлаучыга.*

Әкиятче Мәгъсүмә карчык сүзе.

Мәүлет айларында, абыстай кайтып киткәч, сәке-сәхнәгә Мәгъсүмә карчык хуҗабикә булып ала. Янында курай, кубыз. Аның бәет әйтүе, әкият сөйләве музыкаль тамашага, бер кешелек театрга әверелә торган иде. Ул бигрәк тә Сак белән Сок бәетен уйнап, җырлап, сөйләп, без сабыйларны гына түгел, олыларны да җылата торган иде.

Сөембикә сабыен кочаклап, манарадан сикереп һәлак була. Сак белән Сок күрешә алмыйча мәңгегә тилмерә. Нык тәэсирле иде ул әкиятләр. Мин гомерем буе шул язмышлар турында уйландым. Каләмгә тотынгач, мин Сөембикәнең манарадан егылмагынын, әсирлеккә озатылганын белдем.

Казан халкы Сөембикәнең әсирлеккә озатылуын үз күзләре белән күреп торган, ни өчен соң халык аның манарадан ташлануы турында кызганыч бәет чыгарган?

Халык үз хыялын язган. Аның шулай һәлак булуын теләгән. Гүзәл ханбикәнең Иван колиһәсе булуын теләмәгән. Һәм үз фаразын иҗат иткән.

Тарихи чынбарлыкка караганда әдәби хакыйкать куәтлерәк килеп чыккан. Димәк, иҗатчының тарихи фактлардан читкә китәргә дә хакы бар?

Иң нык тәэсирлесе — «Сак-Сок» фаҗигасе. Композитор-галим Шамил Шәрифуллин Сак-Сокның егермедән артык көен туплаган шәхес. Нинди байлык. Әбием уйнаган көй дә аның мирасында бар. Шамил аны минем уйнаудан язып алган иде.

*Татар халкының иң борынгы әдәби әсәре кайсысы? дигән сорауга мин: «Сак белән Сок» дим.*

Аңа иң кимендә ике мең яшь, эзләнә китсәң, бәлки, өч-дүрт мең ел да бардыр.

Бәетнең Исламга кадәр үк халык арасында таралган булуына дәлилләр әсәрнең үз эчендә ята. Ислам дине пәйда булганга мең дүрт йөз егерме, Идел буендагы бабаларыбызның Исламны рәсми кабул иткәненә мең өч йөз җитмеш җиде ел гына. Әгәр дә «Сак-Сок» моннан сигез йөз яки мең ел элек кенә иҗат ителгән булса, без анда «бисмилла, Алла, Коръән» сүзләрен очраткан булыр идек. Ислам кергәч, бер генә әсәр дә бисмилласыз башланмаган. Әсәрдә Исламның тәэсире сизелми. «Мәдрәсәләрдә пыяла ишек» сүзе бер караганда: әсәр Ислам кабул ителгәннән соң язылган, дип уйларга да форсат бирә кебек. Ләкин әсәрнең сюжеты, темасы, чишелеше: «мәдрәсә, мәчет» сүзләренең соңгы нөсхәләрендә генә куллана башлаган, дип уйларга җирлек бирә. Мәгълүмдер ки, көе борынгы булып та, сәяси мохит үзгәргәннән соң, җырларның сүзләре үзгәрә килгән, яңа сәясәткә кулай текст барлыкка килгән. Сүз өчен җавап бирәсе була, музыкада сәясәт төртеп тормый.

Коръәнгә кадәр татар халкының конституциясе, яшәү кануннары, әхлагы, тәрбия кагыйдәләре шушы бәеттә — «Сак белән Сок»та тупланган булган. Ихтимал, «Сак-Сок» ниндидер бер олы, озын, кануни әсәрнең бер өлеше генәдер. Шушы өлешендә генә дә без яшәү рәвешенең нинди кагыйдәләргә буйсынганын чамалыйбыз.

Ике туган талашмаска, бер-берсен рәнҗетмәскә тиеш!

Бала ана сүзеннән чыгарга тиеш түгел!

Ана—ул изге зат — бала аны борчырга, ана каршы килергә, ананы рәнҗетергә тиеш түгел!

Ана баласын каргый икән, үз башына булыр! Димәк, ул заманнардагы әхлак буенча: каргану ярамаган эш саналган.

Кызып китеп, ана кеше газиз балаларын каргап ташлый да, балалары ике кошка әверелеп, урманга очып китkәч, сонра кара кайгыга сабыша, үкенә. Ягъни, кылган языгынын җәзасын шундук татый.

Балалар да бер тимер ук өчен сугышып, аналарына хәсрәт китергәннәре өчен үкенәләр. Ләкин ананын ялварулары да, балаларнын теләкләре дә кабул булмый. Алар шулай мәнгегә аерылалар. Кайтарып ала алмаслык үкенеч, аяныч. Кара тәкъдирле балалар, кара тәкъдирле ана белән ата. Атанын роле әсәрдә күренми дә, атанын гаиләдәге хокукы юк дәрәҗәсендә. Ата өйгә кайтып керүгә балаларынын каргалган килеш, Сак белән Сок кошларына әверелеп, тәрәзәдән очып чыгып киткәннәре турында ишетә. Ләкин берни кыла алмый. Хәтта хатынын битәрли дә алмый.

Бу—Сак-Сок вакыйгасы—Анабаш (Ана кануны, матриархат) чорында булганга ишарә түгелме? Ананын гаиләдәге хокукы зур икәнлеге ярылып ята, ул каргый, ул ачулана, ул тәртип урнаштырырга тырыша, ялгыша. Ата пассив бер зат кебек күренә.

Әсәрнен чыннан да, бик борынгы заманнарда язылганына тагын бер ишарә бар. Ике ир туган бер тимер ук өчен талашалар. Аларнын башка уклары булмаганмы? Таш башаклы ук, сөяк башаклы ук, җиз башаклы ук. Бүгенге күзлектән караганда, чүпкә дә тормаган тимер ук башы өчен алар кыр талашып, ана тикле ананын каргышына дучар булалар. «Таш гасыр», аннан сон «Бакыр гасыр», аннан сон «Тимер гасыр» килгәнен без яхшы беләбез. Бакыр кораллар кешелек дөньясын «Таш гасыр»дан алып чыккан, тимер табылгач, кешелек дөньясы «Тимер гасыр»га кергән. Ягъни, бакыр укка караганда тимер ук затлырак, кыйммәтлерәк һәм сирәк булган. Димәк, Сак-Сок вакыйгасы Бакыр гасырдан Тимер гасырга күчкән елларда, чама белән дүрт мен еллар әүвәл булган, дип фаразларга мөмкин. Әйтик, тимернен яна гына кулланыла башлаган чорында бер тимер ук ат бәясе торгандыр. Ике ир угланнын чүп өчен түгел, шактый кыйммәт нәрсә өчен талашуы кечкенә нәрсә түгел.

Бәлки, әсәр тар гаилә гаугасын түгел, ике кардәш халыкнын кечкенә бер нәрсә өчен кан дошман булып талашып, аерылышуына кинаядер. «Сок» исемле елга бар Самара өлкәсендә. Шунын белән кушыла алмыйча ага торган Сак елгасы да булгандыр бәлки. Исеме генә үзгәргәндер. «Сак» исемле борынгы бабаларыбыз да булган, далаларыбызда саклаблар яшәгән. Бүгенге көндәге төрки якутлар үзләрен «Саха халкы» дип тә йөртә. Кайчандыр Сок буендагы мишәрләр—татарлар Саха халкы белән бертуган булган, ләкин аерылган, телебез нык үзгәргән, динебез дә уртак түгел. Сак—Сок бәете бәлки бу ыруглар, нәселләр арасындагы котылгысыз гаугаларны, фаҗигага китергән дошманлашуны да күз унында тотадыр?

Инде ин мөһим бер мәсьәләгә тукталмыйча мөмкин түгел. Гаепләләр өстеннән каргышнын алынмавы. Тылсым көче дә, сихер дә, Алла да бу эшкә катнашмый. Ана-кеше: балаларымны коткар, дип бер затка да ялвармый. Күрәсен, Ана каргышына бер затнын да кодрәте җитми. Әсәр шушы фаҗигасе белән озын гомерле булып туган. Сонгы сиксән елларда язылган балалар әдәбияты әсәрләрендәге кебек, бу әкият яхшы тәмамланмый, каһарманнар кушылмый, ахырда сөенмиләр, соныннан: кабат алай эшләмәбез, дип тә әйтмиләр әкият каһарманнары. «Сак-Сок» әсәре фаҗигале азагы белән куәтле дә, шунын аркасында ул мен елларны

узып та, тузмаган. Матур тәмамланган әсәрләр озын гомерле булмый, күрәсең.

Хөрмәтле кардәшем! Фажигасе тетрәндерә әсәрнең һәм син шушы фажигане гомерен буена онытмаячаксың. Бу әсәрне укыгач, бу әсәрне тыңлагач, син инде гамьсез генә яши алмаячаксың. Бичара ана, бичара балалар турында уйлап, син аларга теләктәш булачаксың. Син өч мәсьәләгә җавапны шушыннан табачаксың:

Туганнар белән бозылышмаска. Тату яшәргә.

Анага борчу салмаска. Ана—Изге зат.

Никадәр генә кыен булса да, Ана үз баласын каргарга тиеш түгел. Каргый калса, ул үзенә, бөтен нәселенә җәза чакырган булыр. Һәр каргыш кешенең үз башына була икән.

«Сак-Сок» бәетенең көйләре бик күп. Композитор, галим Шамил Шәрифуллин җыйган. Шуларның иң борынгысы, иң матуры, минемчә, безнең Зәй якларында җырлана торганы. «Сак-Сок» бәете тагын бер фаразга этәрә. Бу әсәр музыкалы, җырлы, уенлы тамаша. Безгә аның аерым өлешләре генә килеп житкәндер, ихтимал. Ләкин бу мең еллар әүвәл думбра, кубыз, курай кебек уен кораллары катнашкан оркестр ярдәме белән башкарыла торган халык тамашасы, музыкаль театры булгандыр.

Мәрхүмә әбием—Мәгъсүмә карчык «Сак-Сок»ны бая санаган уен коралларында уйный-уйный сөйли, җырлый, аңлата торган иде. Аның «Сак-Сок»ны башкаруы бер кешелек театр иде.

Ислам дине татар халкының йолаларына балта чапмаган. Һәрхәлдә, татар халкы мөселман булгач та, Исламгача булган йолаларын ташламаган. Халыкның Исламга кадәр булган изге йолалары: Сабантуе, ияләргә ышану, йөзенче кыл йоласы, хатының белән мунча керү, чишмәләргә хәер салу һәм менә «Сак-Сок» могҗизасы бүгенгә кадәр килеп җиткән. Халык талантлары көйле, җырлы уеннарын, бәетләрен йола буларак башкарган, алар халык театрының башында торган, дип әйтергә тулы нигез бар. Моңа мисаллар күп: «Хан кызы», «Йосыф—Зөләйха», «Таһир—Зөһрә» исемле музыкаль әсәрләр Хан сарайларында, мәйданнарда, халык алдында көннәр буена башкарыла торган музыкаль тамаша һәйкәлләре.

Уналтынчы йөздә Казан хакиме Мөхәммәд Әмин ханның сараенда кыллы, бәрәбанлы, быргылы оркестр, биючеләр, җыручылар булганы мәгълүм. Аларның житәкчесе җыр чыгаручы һәм шул җыруларны үзе башкаручы шагыйрь Голәм Шади булган.

Ихтимал, бу сарай театрының репертуарында халкыбызның үлмәс музыкаль әсәре «Сак белән Сок» тамашасы да булгандыр. Нинди гүзәл әсәр дөньяга чыкмый ята. Юкса, «Сак-Сок» төкәнмәс мәүзугъ булып, татарның һәр төр сәнгатендә лаек урынын алырга тиеш иде. Симфония, опера, балет, драма, кыйсса, телевизион-радио тамашалар иҗат итәлергә тиеш иде сыман. Сәнгатьчеләрнең күңел күзе шушы үлмәс әсәрне күрмәде. Һәм, ниһаять, Татар яшьләре театрының баш редиссеры Ринат Әюповның махсус кушуына күрә, мин «Сак-Сок» исемле пьеса яздым. Бу тамаша 2003 елда дөнья күрде. Әйтергә кирәк, «Сак-Сок»ның тарихта ике нөсхәсе сакланган, киң таралганы — бәет, икенчесе — кульязма сыйфатында чыкканы — дастан. Төп мәүзугъ (тынлаусыз балалар, ана каргышы һәм ул каргышны кайтару мөмкинлеге булмавы) уртак. Ләкин аермасы да кечкенә түгел, дастанда бәеттә булмаган әкияти каһарманнар: Алпамша, Албасты, Шүрәле дә хәрәкәт итә. Яшь тамашачылар театрындагы тамашага дастан нөсхәсе нигез итеп алынды. Бәет нөсхәсен файдаланып язылган «Ана каргышы» исемле икенче пьеса Чаллы драма театрында куелды.

Бәлки әле алга таба симфония дә, балет та, балалар өчен опера да пәйда булыр! Бирсен Ходай!

*Мин әбием сөйләгән риваятьләрне иҗатымда иркенләп файдаландым.*
Әбием Мәгъсүмә 1959 елда вафат булды.
Урыны җәннәттә булсын! Амин!

## Җылан мөгезе

1946 елның җиденче ноябренә каршы таңда минем энем туды. Язга чыккач, әбием мина:

— Улым, урманга бар, кара җыланны үтереп, башын кисеп алып кайт!— диде.

— Нигә кирәк ул җылан башы? —дидем.

— Әнисә апаң сабый чагында аның башлыгына җылан мөгезе такмады атаң белән анаң. Әнисә апаңа күз тиде. Ул гарип калды. Әнәс абыеңның башлыгына да мин җибәргән җылан мөгезен такмадылар, Әнәс абыең да чирләп үлде. Синең башлыгыңа мин үзем җылан мөгезе теккән идем, син миңә, Аллага шөкер, сау-сәламәт. Синең маңгаеңа таккан ул җылан мөгезен югалттылар. Яңасын алып кайтырга кирәк, — диде әби.

— Әби, җылан мөгезен таккач, ни өчен күз тими?— дим.

— Безнең борынгы бабаларыбыз җыланнарны җиңгән халык, җыланнар бала башлыгында җылан баш сөяген күрсәләр: әһә, бу бала безнең нәселне җиңгән халыкныкы, аңа кагылырга ярамый, дип баланы чакмый. Җыланнар Ахырзаманга таба кеше эченә керә барырлар, дигән. Ни өчен кешеләр хәзер гаугалы? Барысының эчендә җылан ята. Эчендә җылан булган кеше башлыгында җылан мөгезе булган балага бакса, сихере дә, күзе дә тия алмый. Җыланның башын кискәч, гәүдәсен кырмыска оясына ташла. Үзең сәрдә җый, букчаң тулгач, кырмыска оясыннан җылан кабыгын алып кайтырсың.

— Әби, җылан кабыгы нигә ул?

— Кирәк! — кенә диде әби.

Мин әби өйрәткәнчә, урманга менеп, җизни бүләк иткән сөяк саплы пәкем белән чикләвек куагыннан ике җәпле таяк-сәнәк ясадым. Безнең урманда җыланнар күп, мин җыланнан курыкмыйм. Җылан күрсәм: камчы-камчы, дим, җыланнар миңа тими.

— Җылан мөгезе таккан башлык киеп үскән баланы җылан чакмый,— ди иде әбием.

Гомумән, җылан өстенә басмасаң, аны йокысыннан уятмасаң, тора салып җылан кешене чакмый, кешегә ташланмый, алар бик куркак була. Кеше күрсә, җылан качу ягын карый.

— Урман кырында бөгәрләнеп, Кояшта кызынып ятучы җыланга чыбык белән сугарга ярамый. Җылан һавага сикерә дә, өстән үзен киерсытучы кешенең күзенә агуын сиптерә, кеше сукырая, — ди әби.

Әбием, һәр нәрсәне риваять, әкият рәвешенә китереп, сабыйны ярамаган эшләрдән тыйган булган икән. Шуңа күрә, мин җыланнарны борчымаска тырышам, кара җыланның арыш арасында ничек итеп тычкан йотканын карап торганым бар. Тычкан йотып, йоклап яткан җыланны да күргәнем бар.

Ләкин бу юлы әбиемнең олы йөкләмәсе бар. Мин кара җыланның башын кисеп алып кайтырга тиеш. Ике җәпле таяк белән миннән качып бара торган җыланны башы белән гәүдәсе тоташкан урыныннан (муеныннан) җиргә «беркеттем» дә пәкем белән башын кисеп алдым. Аны әрекмән яфрагына төрдем. Җыланның гәүдәсе боргалана—боргалана куаклар арасында ята иде, ике җәпле

таягым белән алып, мин җылан гәүдәсен кырмыска оясына ташладым. Гәүдәне шундук кырмыскалар сырып алды. Үзем букчама сәрдә җыярга аланга киттем. Букчам тулгач, кырмыска оясы янына килдем. Җыланның бушаган кабыгын күрдем. Җыланның итен кырмыскалар ваклап-ваклап ташып бетергәннәр иде. Җылан кабыгын алып кайтып әбиемә тапшырдым. Әби бераз вакытлар узгач, миңа тагын урманнан җылан кабыгы алып кайтырга кушты. Үтереп түгел, ике агач арасында җылан кабыгы еш очрый. Җыланнар язда бии. Тәннәре кычыта башлагач, алар иске кабыкларыннан котылыр өчен, ике агач арасына кереп кысылалар да, ышкына-ышкына, боргалана-боргалана үз кабыкларыннан чыгалар. Иске кабык ике агач арасына кысылып кала. Әбием шулай бушаган кабыкны алып кайтып бирергә кушкан иде. Мин ул кушканны эшләдем, берне түгел, ике кабык алып кайттым. Анысын да мин ни өчен икәнен аңламадым.

Кисеп алынган җылан башын әби багана башына Кояшка куйды. Кошлар алып китмәсен өчен, иске себерке белән каплады. Бер-ике көн шулай эссе кояшта торганнан соң, әби җыланның баш сөяген багана башыннан алды. Җыланның баш тиресе кибеп, чатнап-чатнап ярылган иде. Урман чикләвегенең төше чаклы ап-ак матур баш сөяге генә әбинең учында калды.

— Менә шушы була инде ул җылан мөгезе!— диде әби.

Бу җылан мөгезе ике энекәшемнең дә башлыгында булды. Ике энем дә сау-сәламәт үстеләр, аларга күз тимәде, шөкер. Әбинең серле сандыгы Зәкия түтинең өендә иде, янгын чыгып, шул, мин алып кайткан җылан башы янып юкка чыкты. Минем балаларымның башлыгына тегәргә җылан мөгезе калмаган иде. Бәлки шуңадыр да, марҗа хатыннан туган улым Илдар сәламәтлеккә туймады. Инде Нурбәк белән Байбулатка, нишләптер, җылан мөгезе алып кайта алмадым. Ләкин мин әбием әйткәнчә, җылан баш сөяге булмаса да, бу балаларымның башлыкларына артыш таягы тегеп үстердем.

Тора-бара татарлар җылан баш сөяге урынына сабыйлар башлыгына җылан баш сөягенә охшаган диңгез кабырчыгы тегеп куя башлыйлар.

Әбинең сандыгында да, ишек өстендә дә, тәрәзә башында да әбинең артышлары була иде.

— Артыш ул могҗизалы агач!— ди әби.— Артышлы йортка җенияләшмәс. Артыш такканга күз тимәс. Артыш җимешен кайнатып эчкән кешенең бөере авыртмас. Мәет янында артыш яндырсаң, эссе көндә дә мәет кабармас. Артыш яман исләрне куар...

Киемнәр арасында, сандыкта ни өчен артыш таяклары булганын мин соңрак белдем: артыш киемнәрне көядән саклый икән.

Ашаганда кыбырсып утырсаң:

— Аяк болгап утырма! Тамагың туймас!— ди әби.

— Нигә?— дим.

— Синең аяк болгаганыңны күреп, шайтан килер дә, син ашыйсы ризыкны йотар, синең тамагың туймас,— ди әби.

Тырнак кисү дәресе булайрак була иде:

— Улым, тырнагыңны бер урынга җыеп бар.

Мин ул кушканны үтим. Әби киселгән тырнакларны саный:

— Берсе кайда? Монда тугыз гына тырнак, — дип, әби югалган тырнакны таптыра.— Югалган тырнакны шайтан алып, синең ашыңа салыр. Чирең артыр!

Авызыңны ачып, кычкырып искәсәң[5], әби әйтер:

— Улым, искәргәндә, авызыңны ачканда учың белән, җә, кул сыртың белән капла!

[5] искәү – йокы килгәндә авыз ачып сулыш алу; иснәү – ризыкны, хушбуйны иснәп карау.

— Нигә? —дим.

— Син авызынны киереп искәсән, бисмилласыз ачык авызга шайтан кереп китәр. Эчендә шайтан утырган кеше бәхетле булмас!

Үзем бабай булгач та мин әбинен шушы дәресләрен искә төшерәм. Әдәп, чисталык тәрбияләү әнә нинди тәэсирле әкиятләр аша барган искеләрдә, дип куям.

Әбием мин Мәскәүдә укыган чакта, 1959 елда вафат булды. Шәйхетдин кызы Мәгъсүмә карчыкнын урыны җәннәттә булсын!

**Әти**
**(1910 – 1981)**

Әтием Мөхлисулла 1910 елда Шәйхетдин углы Кәлимулла Батуллин курасында дөньяга килә. Бабам Кәлимулла белән әбием Мәгъсүмәнең унике баласы була. Шуларның өченчесе минем атам Мөхлисулла. Мин исән калганнарын гына беләм. Алар бишәү иде. Атам уналты ел укытучы булып эшли. Мина бер яшь тулганда аны әзерлек армиясенә алалар, өйгә кайтам дигәндә генә сугыш чыга. Сугышнын беренче көннәреннән үк Мөхлисулла хәбәрсез югала. Дүрт елга якын хәбәрсез торганнан сон, сугыш бетәр алдыннан гына анының исән хәбәре килде. Озак та узмый, әтиемнән авылга, Шыкмайга ике посылка килеп төшә. Анда мина кыска балаклы (шорты) чалбар, яхшы күлмәкләр, шаккаткыч матур чигелгән ятак җәймәләре бар иде. Хәтерлим әле, бабам әйберләрне сыпыра-сыпыра сукыр күзләре белән җылады:

— И Мөхлисулламны да күрер көннәрем бар икә-ән!

Карт ул вакытта үлем түшәгенә егылган иде инде. Шуннан соң озак та узмастан бабам дөнья куйды. Анын кабере янында мин бик озак басып тордым, каберчеләр, мулла абзый кайтып киткәч тә кузгалмадым. Караңгы төшкәч кенә мине әбием чакырып алды.

Жинү көнен мин Зичәбашта каршыладым. Озакламый сугыштан дәдәйләр кайта башлады. Беркөнне безгә Шыкмайдагы күрше кызы Гөлсинә апа килеп:

— Мөкәррәмә апа, сөенче, Мөхлисулла абый кайтты!— диде.

Әнинен, Әнисә апанын жыенганын көтеп торырга вакыт тар иде, мин аякларым җиргә тияр-тимәс, Шыкмайга чаптым. Өйгә кайтып життем, атылып өйгә кердем. Кара өйнен өч сәкесендә дә сугыш киеме кигән, орден-медальләр таккан абзыйлар утыра, мин:

— Әти,— дип түр сәкедәге иң күп медальле абыйга таба атладым. Шулай булмыйча, минем әтидә генә иң күп медаль булырга тиеш бит инде. Күп медальле абзый ягымлы гына елмаеп:

— Үскәнем, әнә, синең атан, — дип мине ишек катында утыручы, түшендә бер медале дә булмаган бер ир кешегә таба борып җибәрде.

Әти күзләре белән генә елмаеп, мине күтәреп алды да, тезенә утыртты.

Шулай итеп, медальле булмаса да, мин дә әтиле булдым.

Әтиле булдым, шөкер. Әти Зичәбашта укыта башлады. Икенче сыйныфны мин атам—Мөхлисуллада укыдым. Шунысы истә калган, әти мине якламый, билгеләрне арттырып куймый иде. Хәтта ул башка балалар белән чагыштырганда, мина, үз баласына кырысрак та иде. Бу бәлки шулай тоелган гынадыр, әмма мин әтидән ташламалар ясавын өмет тә итми идем. Хәтерлим әле, бер тапкыр мин үземнән күпкә олы бер малай белән сугыштым. Ул дүртенчедә укый, мин—икенчедә, минем бер ел алдан кергәнне дә хисапласак, ул малай миннән байтакка зур булган.

Мин мәктәпкә кишер алып килгән идем, шуны башкалар алдында кимереп йөрим.

— Бер генә тешләт әле, — дип малайлар кишерне байтак кына киметтеләр, алардан соң әлеге олы малай да сорады, ач булгандыр инде, бичара, ләкин мин аңа кишер бирмәдем, дөресен генә әйткәндә, мин саран идем. Шуннан теге малай, исемен хәтерләмим инде, яшен тизлеге белән минем кулдан кишерне тартып алды да, алагаем зур итеп тешләде. Миңа яшькелт төбен генә тоттырды. Башкалар шырык-шырык көлә, җүнсез малай шытыр-шытыр кишер чәйни, мин кулымдагы яшькелт кишер төбе белән тегенең оятсыз чыраена тондырдым. Кишер төбе аның борынына барып тиде, малай ике кулы белән битен каплады, аның борыны каный иде. Әти нәкъ шушы мизгелне күреп алган. Ул мине бөтен малайлар алдында тотып яңаклады. Әтинең кулы каты иде. Сукканда чамалап сукмый. Каты эләктерә.

Шуннан соң әти мине ике тапкыр кыйнады. Алары Шыкмайга кайткач булды. Алары да хәтердә.

Без, ямьле табигатьле Зичәбаш, киң күңелле керәшен халкы белән саубуллашып, үз Шыкмаебызга, төп нигезебезгә кайтып киттек.

Ие, Олыҗы авылыда туган булсам да, мин үземне Шыкмай кешесе дип саныймын. Чөнки минем ата-бабамның төп нигезе шушында, Шыкмайда. Ләкин авыл малайлары, күршедәге яшьтәшләр алай уйламаган, күрәсең. Мин алар өчен килмешәк идем. Олыҗыда яшәп караган, керәшеннәр янында Зичәбашта торган, чәндер бер ят малай. Шуңа күрәдер, башта мине күрше малайлары үз араларына алмадылар. Сабыйлар ясый торган аулагөйләргә мине кертмиләр. Ә минем керәсем килә. Чөнки анда кызык. Миңа уйнарга иптәш кирәк. Башкалар белән чагыштырганда без мул тормышлы идек. Бездә аз-маз шикәре дә, җимеше дә, балы да була. Умартабыз бар. Малайларга мин җә шикәрләтә, җә йөземләтә ришвәт бирә башладым. Шуннан соң гына мине алар үз араларына алдылар. Хисаплы ул шикәрне мин әти-әнидән урлап ала идем.

Шыкмайга кайткач, тормышыбыз рәтләнде. Әби, әти, әни бар дигәндәй. Ризык кытлыгы юк иде безнең өйдә. Сыер, бозау, кош-корт, умарта, дигәндәй, бөтен кеше кычыткан, алабута ашаганда да безнең табыннан ипи, бәрәңге, бал-май өзелмәде. Өс-баш мәсьәләсендә дә әти безне һәрвакыт яхшы киендерә иде. Кайткан елны гына ул миңа карамадан бик матур чабата ясап биргән иде. Мин аның беренче һәм соңгы тапкыр чабата ясаганын күрдем. Минем аякта кышын киез итек, язын күнитек булды.

Булдыклы кеше иде минем әти. Нигә тотынса да, шуны оста башкарып чыга. Тире или, олтан сала, бура бурый, умартачы, балыкчы.

Әти җор телле, шаян кеше булса да, өйдә кырыс иде. Аеруча миңа кырыс иде ул. Ни өчендер, сәбәбен әйтә алмыйм, аның миңа «улым» дип эндәшкәне булмады. Өс-башымны яхшы карады, яхшы ашатты, ни кирәк, шуны алып бирә иде, ул мине сәпитле, соңыннан матайлы итте, гармун алып бирде. Ләкин безнең арада ниндидер салкынлык ята иде. Ул мине бер яшьлек чагымны хәтерли, мин аннан башка алты ел үскән, ул да миңа ят бер абый кебек, мин дә аңа ят бала кебек идем. Мин ут өертеп сәпиттә чапканда, дуылдап матайда йөргәндә әти башкалар алдында:

— Малай булдыра! — дип мактана иде.

Кырыс булса да, ул миһербанлы, ярдәмчел кеше иде. Әни бәбигә узгач, әти хатын-кыз эшен үз өстенә алды. Су ташый, әнинең күлмәген киеп, сыерны үзе сава. Юкса, ирләр киеме кигән кешегә сыер саудырмый. Миңа шунысы кызык була торган иде, әни күлмәген киеп, әнинең алъяпкычын бәйләп, әти сыер савып йөри, мин әтигә күрсәтмәскә тырышып кына кыты-кыты көләм. Авыл абзыйлары әтинең судан кайтып килгәнен күреп:

— Мөхлисулла абзый, күкәен өзелеп төшеп калмасмы соң? — дип шаярта торганнар иде.

Ләкин атам андыйларга игътибар итми яки:

— Төшмәс, иншалла, нык ябыштырылган ул! — дип шаян җавап кайтара.

Ул 1932 елда иң беренче булып сәпит алган кеше. Шушы сәпите белән ул Сарман төбәгенең Яңа Имән авылы кешесе, Даут картның Мөкәрәмә исемле төпчек кызын утыртып алып кайткан кеше. Ул сәпиттә әле мин дә йөрдем. Сәпитне миңа тапшыргач, иң беренче булып матай алган кеше ул—Мөхлисулла. Матаен миңа биргәч, иң беренче булып машина алган кеше ул—минем әти. Кунак җыя иде, бал аерткан көнне күрше-күләнне бал белән сыйлый иде. Аш-суга оста иде. Ит ашларын аның кебек тәмле әзерләүче юк иде авылда. Камыр ашларының остасы әни булса, ит ризыкларының остасы—әти иде.

Кулына гармун алса, саратскиймы ул, тальянмы, хромкамы, келтерәтеп кенә тотып уйнар иде, мәрхүм. Җыр башласа, ана чыккан кеше юк иде. Бәлки бу миңа гына шулай тоелгандыр, әмма мин сөйләгәннәрнең барысы да дөрес, ул эшле-ашлы иде.

Җылкы суюу ул вакытта теләсә кемгә тәтеми иде, әти җаен таба иде, ат сатып ала иде дә, шуны уҗымда симертеп, Яңа ел алдыннан чала иде дә, казы эшли, бастырма ясый иде.

Алты почмаклы өйдә фикус, инҗир, кына, яран гөлләре чәчәк ата. Бәйрәмнәрдә өйдә радио яки патефон уйный, әбинең кубызы, курае яңгырап тора. Бәйрәм саен әти кунак җыя, абзар тулы мал-туар, сәпит, матай. Бакчада җиде баш умарта. Әти кайтканнан бирле табыннан бал-май өзелми. Барыбызның да өс-баш каралган. Әлбәттә, сугыштан соңгы авыр елларда Плинний Мөхлиснең башкалар белән чагыштырганда байларча тормыш корып җибәрүе күпләрнең эчен пошыргандыр. Бер генә мәҗлестән дә калмаган бер абзый — Мутай — әтинең ни сөйләгәнен НКВДга җиткереп торган. Ул абзый үзе дә укытучы иде. Гадәттә, андый астан чагучылар фәкыйрь тормышта була. Мал-туары юк, кайгысы да юк. Булса ашый, булмаса, кеше саен туенып йөри. Кәлимулла Мөхлисенең бар ягы да җитеш булуына әнә шундыйларның ачуы килә иде. Бал аерткан саен, җылкы-мал суйган саен Мөхлисулла мул табын әзерли. Мутайны да чакырырга онытмый. Табындагы һәр ризыкны мактый-мактый ашый, әтинең салпы ягына салам кыстыра. Табын янында әти хуҗа, ул кунак сыйлый, үзе кызык мәзәкләр сөйли, гармун уйнап җырлап та җибәрә. Мутай кебекләр икенче көнне каядыр, кемгәдер барысын да әләкли. Әтинең һәр уңышыннан көнләшеп, әтинең һәр кайгысына сөенеп яши андыйлар.

Атам кояз-пөхтә кеше иде, күнитеген ялтыратмыйча, чалбарын үтүкләмичә, күн түбәле каракүл бүреген «чөшкенләмичә», урамга чыкмас.

Бер елны безнең абзарда ике сыер, өч бозау булды. Сөйләсәң, кеше ышанмас, әмма шулай булды. Күп кешенең бер сыеры да, бер бозавы да булмаганда, бер капкадан өч бозау чыгып, өч бозау кайтып керсен әле. Үгез бозауны мин атланырга өйрәттем дә, ике тана бозауны шуның белән куып-көтеп йөрим. Уенга мавыгып, бозауларны күз уңыннан ычкындырганмын, өч бозауны да пүләвәй Нури тотып япты. Өч бозау өчен дөнья акча түләргә кирәк. Дөресен генә әйткәндә, бозаулар уҗымга кермәгәннәр иде әле. Нури аларны уҗым кырыеннан куып алып китте, ул белә—бу Плинний Мөхлис Батуллин бозаулары. Нури үзе фәкыйрь, малы юк, Мөхлисулла ике сыер тота, өч бозавы бар, җылкы симертә. Бу хәл Кәлчүрин Нуриныкын гына түгел, күпләрнең эчен пошыра иде. Әсирлектән кайтып, Мөхлисулла мул

тормыш корып җибәрде. Аның бозауларын ужымга кермәсә дә ябып була. Аны яклаучы булмас!

*Бу вакыйгаларны мин «Юл буенда зәңгәр чәчәк» кыйссасына керттем.*

Әтинең хәлкәйләрен мин байтак вакытлар узгач кына, үзем ата булгач кына аңладым. Әсирлектән кайтып төшкәч, аны НКВД атна саен чакыртып сорау ала, кыйный торган була, янәсе, ул немец шпионы. Томанлы гына хәтерлим әле, әти НКВДга киткәч, өйне кара кайгы баса иде, әти кайтырмы, юкмы, дип кан калтырап көтә идек. Берничә көн узгач, әти кайтып төшә, ачулы, кырынмаган, ябык, йончылган. Өйдә шомлы тынлык. Әти сөйләми. Без сорашмыйбыз. НКВД кыйнагач, калхуз җитәкчеләре кыйный да кыйный инде. Әтине генә түгел, әтинең апасы Зәкияне дә кыерсыталар. Чабатасына иярә кайткан арыш бөртекләрен күреп, Зәкия тутамны төрмәгә утырттылар. Аның теле бик әче иде, ни уйласа, шуны кычкырыр иде, мәрхүмә. Ире фронтта үлгән, балалары юк, шыр ятимәнең бөтен милкен алып, үзен төрмәгә утырттылар председательләр. Йөге белән үз амбарына калхуз икмәген ташыган председатель иректә калды, бер уч арыш өчен Зәкия түти ун елга кереп утырды. «Зингер» аяк машинасы, идәннән түшәмне терәтеп торучы, кысасы кызыл агачтан эшләнгән затлы көзге, патефон, грамофоннарны, чешский урындыкларны селки-селки саттылар. Зәкия тутамның буаз сыерын әби үзенә яздырып, көчкә алып калды. Шулай итеп, безнең ишегалдында ике сыер пәйда булды.

Менә шул, бозаулар тотылган көнне әти мине таяк белән ярды. Һич үпкәм юк атама. Мин аны аңлыймын. Бүген-иртәгә төрмәгә алып китәрләр дип яшәгәндә, бакчаңны кискәндә, укытучылыктан куганда, шул кайгылар өстенә тагын өч бозауны Нурига биреп җибәргән баланы ничек иркәлисең? Аларга сугасын ул миңа сукты. Аларга суксаң—төрмә, үз балаңа суксаң, суд юк.

Зәкия тутамның ул сыеры күбенеп үлде. Көтүче Сантый сыерның лүтсирнага кереп калганын күргән, куып чыгармаган, авылга кайтып, безнекеләргә әйтмәгән. Бәлки әйтмәскә кушылгандыр. Янчык Сәләхи бабайлар шул сыерның түшкәсен тураклап, кар базына салдылар да, кыш буе ашап чыктылар. Бозауларның да бәрәкәте булмады, ике бозауны да председатель куштаннары җитәкләп алып чыгып китте. Бозаулар калхузда мантымады, бичаралар, кыш көне ач хайваннар фермада катып үлде. Шул елны халыктан талап алынган кырыклап бозау үлде, оятсыз коммунистлар җавап бирмәде. Бер уч арыш алган Зәкия түти төрмәдә чери калды.

Әбием кешегә ишеттерми генә:

— Илең булса, Иблисе табыла!.. Камунислар алар тәмуг кисәүләре. Алдакчылар, әхлаксызлар. Ленины да, Сталины да кяфер, бер җәзасын алырлар әле, Аллаһ боерса,— дип үзалдына гына сукрангалаганын еш ишетә идем.

Шуннан соң мин китаптагы Ленин белән Сталин рәсемен базга алып төшеп яндырдым. Бик шомлы эш майтардым мин ул вакытта. Капканы, ишекләрне бикләдем. Рәсемнәрне, шырпы кабын базга, баз эчендәге чокырга алып төшеп, курку катыш ләззәт белән ике кяферне дә яндырдым. Әти өстендә сәяси болытлар куера барган вакыт булганын мин соңыннан гына аңладым. Мин дүртенчедә укыйм. Әти белән әни башлангычларны укыта. Укытучыбыз Могинә апа. Могинә апа безнең авылга килеп, Аюкин Әхнәф абыйга кияүгә чыккан иде. Ленинның туган көне турында сөйли Могинә апа. Мин шунда кул күтәрәм:

— Ырабит үскәнем, синең нинди соравың бар? — ди Могинә апа.

— Минем әби әйтә, Ленин ул кяфер, ди, шул дөресме?— дидем.

Могинә апа бер агарды, бер күгәрде дә:

— Балалар, дәрес тәмам, — дип чыгып йөгерде, ул әти янына киткән дә:— Малаең шулай-шулай дип әйтте, дигән.

Өйгә кайтсам, әти әнине бозау мунчагы белән кыйный, мине дә тотып алып, мунчак белән рәхәтләнеп ярды:

— Мин болай да кыл өстендә яшим, синең малаең «Ленин кяфер» дип класста кычкырып утыра икән, — дип әнине ачулана.

Мин көчкә әти кулыннан ычкынып, абзарга чыгып йөгердем, бичара сабый, абзарга качып котылып буламыни, оекчан, яз көне аяк асты сулы кар, тирес. Әти абзарда да мина шактый каты төшерде. Мин ул көнне өйгә керергә куркып, күрше Әхмәтдин абзыйларның җылы мунчасында төн чыктым.

— Әйе, Ленин кяфер, ул мөселман түгел, кяфер ул мөселман булмаганнарга әйтелә торган сүз, балалар! — дип аңлатырга Могыйнә апаның да, әтинең дә белеме җитмәгән.

Әти кайтты сугыштан, әти белән бергә өйгә шом белән гаугалар да кайтты. Җиде яшемә кадәр мин кыен күрмичә тыныч яшәгән сабый, әти кайтканнан соң боегып калдым. Өйгә кайтасы килми, кайтсам, тизрәк чыгып китәсе килә.

— Әтиең сугыштан бик холыксыз булып кайтты, — диде әби.

Әтинең нинди шартларда әсир төшүе турында мин бик соң гына ишеттем, анысы да әтине җирләгәч, әни авызыннан.

Мөхлисулла Батуллин Суслонгерда була. Сержант дәрәҗәсендә хезмәт итә. Суслонгер дигән шомлы, серле җир турында бүгенгә чаклы юньле-башлы дөрес мәгълүмат юк. Саботажмы, корткычлыкмы ул, әллә теге якка сатылганнар идарә иткәнме Суслонгерда, шайтан белсен. Әмма андагы командирларның рәхимсезлеге, караклыгы турында ишеткәләгән бар. Фронтта солдатлар кан коя, Суслонгерда командирлар солдат өлешен ашап симереп ята. Солдатларны кыйныйлар, юк кына гаебе өчен дә атып үтерәләр. Солдатка кортлы ит, сасыган ризык ашаталар, үзләре көне-төне бәйрәм итәләр, типтерәләр.

— Табактан төшкән тере кортлар аш өстәленең ярыкларына кереп кача иде, шул кортларны әбрәкәй себерә торган каты себерке белән себереп төшерәләр иде, — дип сөйләгән әти.

Әти төнге каравылдан кайтып килгәндә Зуев исемле исерек командир бәйләнә башлый моңа:

— Сержант, нигә син соңга калып сәлам бирдең?— ди.

— Бездә шундый әйтем бар, — ди Мөхлис.— Исереккә сәлам бирмә, ул бирсә дә син алма! Хәтта ул синең командирың булса да!

— Малча-ать! Смирна-а! — дип акыра Зуев, күп солдатларны кыйнап имгәткән командирның үзенә янаулы атлаганын күреп, Мөхлисулла пистолет түтәсе белән Зуевның янак сөягенә суга.

Әтигә трибунал. Атарга. Ләкин хәрби прокурор үлем җәзасын штрафбатка алмаштыра. Ул вакыттагы штрафбат — үлем, дигән сүз була. Әтине җәһәннәмнең үзенә, иттурагычка куялар. Аннан исән чыккан кеше булмый. Сугышка беренче керүгә үк штрафбат камалышта кала, яртысын ярманнар кырып сала, артка чиккәннәрнең барысын да заградотрядтагы үзебезнекеләр кырып ташлый, берничә кеше белән әти яраланып, әсир төшә.

Еллар узгач, Матбугат йорты коридорында фронтовик язучылар белән Суслонгер турында сөйләшеп торганда язучы Гариф Гали болай диде:

— Һай, кабахәт урын иде ул Суслонгер. Зуев исемле бер командир бар иде. Канэчкеч, рәхимсез кеше иде, күп солдатның башына җитте ул кабахәт.

Ну, бер татар аның яңагын сугып сындырды, пистолетының түтәсе белән яңак сөяген чәрдәкләде. Шәп итте! Аны атарга хөкем иттеләр. Һай батыр адәм иде ул солдат. Кайларда икән аның кабере?

— Минем әти ул — Мөхлисулла Батуллин! — дигәч, Сибгат абый да, Гариф абый да беравыздан:

— Китаннан!— диде.— Кайда, ничек аның язмышы?

Әтинең күргәннәрен, сугыштан соң ватанына кайтып, тагын ике ир бала атасы булганын сөйләп бирдем. Туган авылы зиратына җирләнгәнен әйттем.

Шунда Сибгат абый сабыр гына әйтеп куйды:

— Син атаңа охшагансың икән!— диде.

Бервакыт төнлә уянып киттем, әти белән әни пышы-пышы сөйләшеп ята. Әти әйтә:

— Зәки миңа: син плинний башыңнан сөйләшеп торган булма, диде... Мөкәр, әллә язгы ташу вакытында үтереп суга ташлыйммы шуны?

— И Мөхлис, кулыңны пычратма, үзе дә чукынып әле бер, — ди әни.

НКВДга чакырмый башласалар, әти күзгә күренеп үзгәрә, ешрак елмая, шаян сүзләр сөйли, җае чыккан саен мәҗлес җыя. Кичләрен ул каравыл өенә китә. Мин дә аңа ияреп барам. Барысы да сугышта күргәннәрен сөйли, барысы да батыр, кайсы медальне ни өчен биргәннәре турында сөйләп мактанышалар. Минем әтинең бер медале дә юк. Ул әсирлектә күргәннәре турында сөйли. Әти сөйли башласа, кешеләр авызларын ачып тыңлый, кемдер маҗарасы өчен әти хикәясен тыңлый, кемдер яшерен җасус буларак әтине тыңлаган. Әтинең сөйләгәнен органнарга:

— Батуллин Мөхлис фашистларны мактап сүли, — дип җиткезә торган.

Чыннан да, әти бик саксыз кыланган икән шул шомлы заманда да. Әти герман техникасына, германнар тормышына гашыйк кеше иде.

— Һәй,— дип башлый сүз остасы Мөхлисулла.— Нимес бит ул бәрәңгене дә пычак белән әрчеми.

Әти шушы урында юри туктап тора. Кешеләрнең кызыксынуы артсын, янәсе. Берсе түзми:

— Бәрәңгене пычактан башка пычагым белән әрчеп буламыни тагын?— дип ышанмаганлыгын сиздереп куя.

— Машина белән әрчи нимес бәрәңгене! — ди Мөхлисулла.

Тыңлаучыларның күбесе «машина» дигәч тә катлаулы зур комбайн буларак күз алдына китерә.

— Булмас,— ди кемдер.

Әти ышандырырлык итеп, төзәтмә кертә:

— Ит тарткыч хәтле генә нәмәрсә инде ул, шул электрга тоташтырылган.

Электр күрмәгән авыл кешесенә бу могҗиза кебек тоела иде.

— Нимеснең балалары мәктәпкә җәяү йөрми, һәрбер балада сәпит. Өйдә ничә кеше бар, бөтенесенең дә сәпите бар! — дип дәвам итә нотыкчы Мөхлисулла.

Районында ике-өч сәпит булган чакта мондый хәбәр могҗиза булмый, ни булсын?

— Мәктәп ишегалдына киләләр сәпиттә, сәпит терәтеп куя торган җайланмалары бар. Һәр бала үзенең җайланмасына сәпитен кыстырып куя да укырга кереп китә, дәресләр беткәч, һәркем үз сәпитенә атланып кайта.

Кемдер сызгырып куя, янәсе, Мөхлисулла шыттыра.

— Урлап алып китмиләрмени?— дип сорый кемдер.

— Ниместә караклык юк, — ди әти.— Урамда алмагачлар үсеп утыра, шырт алма гына, ник бер бала алмага кагылсын.

Бу хикәягә дә кемдер ышана, кемдер Мөхлисулланың чираттагы ялганы, дип уйлый.

— Нимес бит ул тамагы кипкәндә безнең сыман су эчми. Суны алар хайванга гына эчерә.

Мөхлис хикәясен юри өзә, ул сорау көтә, сорау озак көттерми, кемдер:

— Ни эчә соң алар?— дип сорый.

— Жимеш суты эчә нимес. Баласы да урамнан уйнап, кибегеп керсә, графинадагы салкын жимеш сутын эчә... Нимес икешәр йөз литр жимеш суты ясап куя. Йөземнән, алмадан... Нимес кибеттән аракы сатып алып эчми ул, икешәр-өчәр йөз литр вино ясап, базына төшереп куя да, үз виносын эчә... Нимес карчыгы базарга сәпиткә атланып бара... Кәржинен багажнигына куя да, кирәкле жимешләрен, ризыгын төйи дә сәпитенә атланып кайтып китә...

«Нимес карчыгы» дигәч, без Бәдыйгелжамал әби кебек карчыкны күзаллыйбыз һәм татар карчыгы Бәдыйгелжамалның сәпиткә атланып, Бишавыл базарына барганын күзаллап, ду килеп көләбез. Мөхлисулла эстрада концертын дәвам итә:

— Нимес ул сәпит әйләндерергә дә иренә. Аның сәпите үзе йөри,— дигәч, барысы да тел шартлата, могжиза көтә:— Ничек үзе йөри соң ул?— дигән сораулар ява:— Үзе йөри, каз йомыркасы кадәр матур куйган да, пытыр—пытыр килеп, шул матур нимесне тартып бара...

— Мөхлисулла абзый, әйт әле, нимес белән безнең кешеләр арасында аерма бармы? — дип кычкыра тиктормас Сәлмән.

Мөхлисулла сорауга тәфсилләп җавап бирә:

— Алар да ике куллы, ике аяклы, ләкин аларның башы да бар, җәмәгать! Аерма бар, әлбәттә; нимес иртән иртүк уянгач та, түшәгеннән тормастан уйланып ята: бүген кемгә нинди яхшылык эшлим икән, ди. Ә Шыкмайда кайберәүләр иртән: кемне сатыйм, кемгә нинди этлек эшләп була бүген? дип уяна.

— Мөхлисулла абый! — ди Сәлмән. — Син плиндә нимес өтерманендә утыргач, каян беләсең боларны?

— Өтермәндә утырмаган ул! — ди Пумпа Әхәте. — Рәхәтләнеп ирекә йөргән.

— Дөрес! — ди эти. — Мин өч ел буе бер фрауның бакчасын, дуңгызларын карап тордым. Аның ире сугышның беренче көнендә үк һәлак булган.

Әхмәт абзый Мохтаров кеткелдәп көлә:

— Мөхлис бит ул, фрауның дуңгызларын гына карамаган анда, фрауның үзен дә караган! — ди.

Каравыл өе дәррәү көлүдән сискәнеп куя.

— Нигә, — ди Сәлмән. — Мөхлисулла абыйга утыз бер яшь кенә булган. Самый жегет чагы.

Көлү кабатлана.

Чыннан да, бу шаяртуларда дөреслек бар шикелле.

1996 елда мин йөрәгемә гамәлият ясатырга Һерманиягә, Һамбург каласына барган идем. Бер ай яткannan соң, иртәгә кайтып китәсе кичне минем бүлмәгә бер авыру нимес кешесен керттеләр. Ул нәкъ миңа охшаган иде. Шул ук сакал шәкеле, күзлек, кап-кара кашлар, көлгәндә тешләре энҗе кебек тезелешеп балкый. Буе да бер. Ул 1943 елгы булып чыкты. Әти 1945 елга чаклы фраула хезмәттә тора. Бу минем энекәшем булып чыга түгелме соң? Тимун исемле иде ул, йокларга ятар алдыннан ул миңа хатыны белән төшкән фотосурәте чыккан журнал бирде. Фотодагы

нимес нәкъ мин, хатыны да минем Рузиямә охшап тора. Ул рәсемне мин Казанга да алып кайттым.

Бу кеше таң алдыннан хырылдый башлады, аппаратлар кызыл утларын яндырып, тревога сигналы кычкырта башлады, аны ашыгыч рәвештә каядыр алып киттеләр. Бәлки ул үлгәндер, икенче көнне мине аэропортка илтеп куйдылар.

Әти эстрада артистларыннан да, тел бистәләреннән дә шома сөйли, кызык итеп сөйли торган иде әсирлектә күргәннәрен. Аның хикәяләрендә энә очы хәтле дә арттыру да, ялган да булмаган. Без мокытларга гына ул кеше ышанмаслык арттыру булып тоелган.

— Сез, — ди әти беркөнне өйдә кунак җыйгач. — Татарстанда чыккан аракыны эчмәгез, Татарстанда чыккан теш парашугын кулланмагыз!

— Нигә? Ни өчен? — дип гаҗәпләнәбез.

— Татарстанда аракыга ирләрне көчсезләндерә торган дару кушалар! —диде әти.

— Ни өчен?

— Татарлар үрчемәсен өчен!

— Татарстанда татарлар гына яшәми, Татарстан аракысын татарлар гына эчми, урысы, чуашы...

— Йөз илле миллион урысның Татарстандагы өч миллионы бетүдән урыс кимеми! Ә татар бетә! — диде әти.

— Ә теш парашугының ни катнашы бар?

— Теш парашугына да тешләрне черетә торган нәстә салына! Теш черегәч, кешенең ашказаны бозыла, халык чирли башлый. Милләт какшый.

Шушы сөйләүләрдән соң әтине атналар буе Зәйдә яткыралар иде. Ул аннан тагын да ябыгып, кыйналып кайта. Атна буе шомланып әтинең кайтуын көтәбез. Өйдә кечкенә генә бер ярамаган эш булса, вакытында ашарга пешмәсә, әти кыза, НКВДга, коммунистларга булган бөтен ачуын бездән ала иде.

Озакламый уналтышар ел балалар укыткан әти белән әнине укытучылыктан сөрделәр: фашистларда әсир булган кеше совет балаларын тәрбияләргә хакы юк. Әти мәктәпнең ат караучысы булып, әни гап-гади колхозчы булып эшли башлады.

Бәла артыннан бәла килә торды, Зәкия апа байтак еллар утыргач иреккә чыгып, хуҗалыгын торгызып, кайбер ирләрнекенә караганда да яхшы каралты-кура житкезеп, сыерлы, маллы булып яши башлаган иде, аны икмәк урлауда гаепләп, тагын төрмәгә утырттылар. Бу юлы да иңрәеп казанган малларын конфисковать иттеләр.

Күп тә узмастан, әтине дә төрмәгә яптылар. Ул Бөгелмә төрмәсендә утырып чыкты.

Бервакыт төрмәдән кайтач, каравыл өендә Мөхлисулла белән Сафин Зәки телгә киләләр. Гауга вакытында Зәки ни әйтергә сүз табалмагач, әтигә:

— Һәй, син плинний, төрмә кошы белән сөйләшеп торган мин җүләр! — дип ычкындыра.

Әтинең шулкадәр ачуы чыга Зәкигә, ул саклык чараларын онытып:

— Мин җүләр, анысы бәхәссез, ә менә мин дүрт ел гына ниместә, бер ел гына монда утырган кеше, сез гомерегез буе плиндә, гомерегез буе төрмәдә утырасыз! — дип кайтып китә.

Мутаймы, әллә Зәкиме бу сүзләрне тиешле жиргә житкезәләр. Әтине тагын утлы табага чакырталар.

— Син ни әйтергә теләдең ул сүзләрең белән? — дип өстәл төяләр.

Мөхлисулла дәшми, тагын ничә ел бирәселәрен чутлап утыра.

— Гражданин Батуллин! — дип кычкыра тикшерүче. — Җавап көтәбез! Сез советлар илендәге барлык кешеләр дә төрмәдә утыра! дип әйттегезме?

— Юк, мин алай әйтмәдем, гражданин следователь! — ди Пленний Батуллин.— Мутай белән Зәки Сафин кебекләр хорафатларга инану әсирлегендә яши, дип әйтергә теләдем. Они в плену суеверий, дидем. Коммунист кешегә хорафатларга ышану ярый торган эш түгел, дидем.

— Ә нинди хорафатларга ышана алар?

— Зәки: зират өстендә убыр күрдем дип, бөтен авылны куркытып бетерде.

Бу юлы кыйнамыйча гына әтине чыгарып җибәрәләр.

Аллага шөкер, әтинең тапкырлыгы аны зинданнан коткарып кала.

Колхоз җитәкчеләре ничекләр итеп мыскыл итми иде безнең гаиләне. Әтине генә кыерсытканнары җитмәгән, бригадирына чаклы әнигә бәйләнә, янәсе Мөкәррәмә Батуллина урак урганда нормасын арттырмый. Батулланың малае чалгы белән, ярамаган җирдән печән чабып алып кайткан. Берсендә бригадир Карун Габделхак чалгымны кулымнан тартып алып, тау башыннан упкынга ыргытты, сынган чалгымны күтәреп, җылап кайтып киттем. Бакчаны кисеп, Мәрәс күле буеннан казып булмый торган, бәрәңге утыртырга сазлы җир биреп, мыскылладылар. Мал асрарга кечкенә мөмкинлекне дә кысып бетерделәр. Шуннан соң әти комбайнерлыкка укып чыкты. Ләкин монда да күңелсезлекләр сагалап тора иде әтине. МТСның иң иске комбайнын аңа бирделәр, әтинең эшләре бармый, комбайн тиз ватыла, запчәсләрне башкаларга, плиндә булмаганнарга, телсез-тешсезләргә бирәләр. НКВДдан ук: «Мөхлисулла Батуллинга ватык комбайн бирегез», дип әйткәннәрдер, дип уйламыйм. Әмма «егылганны түбәлә» ысулы өстән кушмасалар да яхшы эшли торган иде ул чакта.

Түзмәде әти, 1959 елда йортын-җирен, мал-туарын сатып, читкә чыгып китте. Һәм гомере буе Пермьдә балта остасы булып эшләп, дистәләгән йортлар җиткезеп, мул тормышта яшәде. Әти үз көче белән Пермьдә ике катлы йорт салып керде, җылкы асрады, абзары тулы мал булды, машина алды, өенә телефон керттте. Мул яшәде ул. Әти авылдан Пермьгә күчкән елны ук тазара башлады. Ашау мул, йокысы шәп, чөнки аны астан чагучылар авылда калды. Гонаһысына кермим, чагучылар алар авылында ике-өч булгандыр. Гадәттә, алар куштаннар арасында була. Гомумән, авыл халкы әтине бик хөрмәт итә иде.

1981 елда җан бирер алдыннан әти әйткән:

— Мине Шыкмайга алып кайтам, дип мәшәкатьләнмәссез, расхуты күп булыр, шушында гына, татар зиратына җирләрсез,— дигән.

Әтине чит җирдә калдырмадык, алып кайтып, Шыкмай зиратына җирләдек. Мөхлисулла борынгы туганы Батут, атасы Кәлимулла, анасы Мәгъсүмә, абыйсы Әхмәтдин, кызы Әнисә белән бер каберстанда ята, шөкер. Урынын җәннәттән әйләсен!

Бик сагына иде ул туган ягын. Ел саен машинасына утырып кайта иде. Беренче булып сәпит алам, диде—алды, матайны да ул беренче алды, машинасын да беренче булып алды. Беркемнән үч алмыйча, беркемне гаепләмичә, мул акча белән кайтып, барысын да сыйлап, күңел ачып, тагын Пермьгә китәр иде, мәрхүм.

Аны җирләшүдә авылның бөтен ирләре (50 дән артык ир-егет) катнашты. Мәрхүмгә, әтигә күпме җәфалар күрсәткән элеккеге колхоз председателе дә зиратка килгән иде. Кайнар Гыйлаҗи малае Мөнип:

— Синең Мөхлисулла абый кабере янында басып торырга хакың юк! — диде.

Беркем бер сүз әйтмәде. Сәгыйрь тын гына читкә китеп басты. Мин

картны кызганып куйдым, хәтта Мөнипкә бераз гына ачуым да килгән иде. Бөкшәеп беткән картка бик читен булгандыр. Ләкин Сәгыйрь кайтып китмәде. Зиратта калды. Кабер өстендә балчык тавы хасил булганчыга чаклы ул бераз читтәрәк торды да, садака өләшә башлагач, якын килде. Без — этинең өч улы — мул итеп гүр садакасы тараттык. Сәгыйрьне дә читтә калдырмадык. Зәкия түтинең әйткәне искә төште:

— Аның белән пычранма! Алла бирсен җәзасын!

Шулай итеп, эти фашист тоткынлыгын да, совет төрмәсен дә күреп, авылыннан тибәрелеп тә, барыбер туган авылының зиратына, борынгы бабалары яткан туфракка җирләнде.

Авыр туфрагың җинел булсын, эти!

## Әни
## (1914)

Әнинең әнисе Орантамак авылыннан Сарман төбәгенең Яңа Имән авылына килен булып төшкән. Әнинең этисе Даутның балалары бик күп була, шуларның сигезе исән үсә. Әнием Мөкәррәмә төпчек кыз. Даут бабай үлеп китә, әби дә вафат була. Олы балалары кайсы өйләнеп, кайсы кияүгә чыгып, тарала, кайсылары, ачлыктан качып, Урта Азия якларына чыгып китәләр. Әнием—сабый сигез яшендә ятим кала.

Бабай белән әби бәхетле була, алар «калхузлашу» дигән талауны күрмичә фани дөньядан китеп котыла. Алар үлгә Даут йортын талау башлана. Ятим калган балаларның авызыннан ризыклар тартып алына, маллар сәвиткә китә. Әниемнең ятимлек чоры башлана. Ул кайда бала карап, кайда асрау булып үз тамагын үзе туйдыра башлый.

Башлангыч белемне авыл мәктәбендә алып, үсмер кыз булып җиткәч, Мәкәррәмә тракторчылар әзерли торган курсларга китә. Курсларны уңышлы тәмамлап, Мәкәррәмә «кызыл яулыкчы» кызлар белән беренче тракторларны Сарман МТСына алып кайтучыларның иң алда йөрүчесе була.

Кызыл яулык бәйлә дустым,
Кызыл яулык килешә,
Кызыл яулык бәйләгән кыз
Теләгенә ирешә.

Икенче тракторда аның ахирәте Бистебашы кызы Мөшәрәфә Исламова була. Аларны олы тантана белән Юлтимер авылында каршылыйлар. Аннан соң «Татарстан» совхозына эшкә юллыйлар.

Өстәлләргә кызыл җәеп,
Туйлар ясарбыз әле.

Ул вакытта халыкны, зәвыкны кызыллаштыру сәясәте тармак җәя. Чыннан да кызыл яулык бәйләү, балаларның муенына кызыл галстук тагу, өстәлгә кызыл җәеп, табынга аракы куеп, муллasыз, никахсыз комсомол туе узгару, өстәлгә кызыл җәеп, җыелышлар узгару дисеңме, сәхнәләргә кызыл пәрдәләр элү дисеңме, кызыллашты дөнья һәм мөселман-татарның төскә булган мөнәсәбәте дә үзгәрде, яшел, зәңгәр, ак төсләр урынына киемнәрдә, өйләрдә кызыл, кара, конгырт төсләр күбәйде.

Шулай итеп, әнием кызыл яулык бәйләп, корыч айгырны авызлыклап, Күперле авылына алып кайта. Тамак хакына кызлар җир сөрә, ашлык суктыра. Ачлык, юксыллык аркасында «кызыл яулыкчы»лар таралып бетә, бер-ике ятимә кыз белән әнием генә тракторлар янында кала. Аларның

барыр җире булмый. Шул елда башлангыч мәктәп укытучылары хәзерләү курслары ачыла, әнине бик теләп шунда алалар. Курсларны тәмамлап, әни мөгаллимә булып эшли башлый. Шунда, Алабуга шәһәрендә белем күтәрү курсларында әнием белән әтием таныша һәм гомерлеккә кушыла да. Ут белән су кушылган кебек була бу никах. Мөхлисулла хәрәкәтчән, кызыш, мактанчыграк холыклы, оста мәзәкче, гармунчы, ни тотса шуны башкара торган кунакчыл кеше, Мәкәррәмә салмак, ятимлек боеклыгы йоккан, аз сүзле, карышмый торган, сабыр хатын, тормыш корып җибәрәләр. Әнинең сабырлыгы гаиләдә чыккан хәтәр гаугаларны зурга җибәрмәгәндер, дим. Әти тузынган чакта әнинең тавышы чыкмый. Әти хаклы булмаса да, әни дәшми, ире сабырлангач, тавыш тынгач, җае чыккач кына әни сабыр гына әтигә эшнең асылын төшендерә башлый. Әти тузынып арган, әнине дәшмичә генә тынлый. Еш кына әти дәшмичә генә гаебен таный иде, шикелле.

Мәкәррәмә хатирәсе:

— Сарман төбәгенең Яңа Имән авылында Зәки исемле байлар бар иде. Ул миңа ага кеше иде. Мин атасыз-анасыз, кара ятим калгач, алар мине төрле эшкә кушалар иде. Каз көтәргә, ашлык көшелен сакларга, үзләре берәр җиргә чыгып китсә, өйне эчтән бикләп, йорт сакларга кушалар иде. Алар янында минем өс-башым житеш була иде. Күлмәкләр, өс киемнәре, тула оеклар тегеп бирәләр иде. Зәки агам Яңа Имәндә ташчылардан шәп амбар салдырды. Ул таш амбар хәзер дә исән әле. Сәүит чыккач, байларны туздыра башладылар, Зәки абый Зәй төбәгенең Бура-Киртә авылына качты. Мин Чаллыда укытучылар курсларында укып йөргәндә Зәки абыйларга — Бура Киртәгә кайтып йөри идем, Мөхлис шунда минем янга килеп киткәли иде. Сәпитенә утыртып, ул мине Шыкмайга Бура-Киртәдән алып кайтты.

Әнинең балаларына кул күтәреп сукканын мин хәтерләмим. Аның ачулануы да:

— Чукынмыш бала!— дип бер кычкырудан ары китми иде.

Шулай да мин арада иң олысы да, иң чытлыгы да, аны чыгырыннан чыгаргач, әни түзмәде, мич авызына кибәргә куйган олтанлы итекне алып, күтемә берне сукты. Авыртмады. Ләкин әнинең бердәнбер сугуы уелып истә калган. Мин бу турыда көлеп-шаярып әнигә сөйләгәнем бар. Хатирәмне ишеткән саен әни:

— Бигрәкләр җәрәхәт булып калган икән, мин аны хәтерләмим дә!— дип үкенгәндәй әйтеп куя.

Юк, рәнжемим мин ул олтанлы итеккә. Истәлек буларак кына сөйлим. Әтинең каты-каты сукканнарының күбесе онытылган, ә менә әнинең шушы олтанлы итек белән «иркәләве» онытылмаган. Чөнки әнинең балага кизәнүе — ул гадәттән тыш хәл. Авыртмаса да, истә калган.

Әниебез бәхетле ана. Авырулары сәбәпле иртә вафат булган ике баласыннан башка, өч улы да исән, өчесе дә югары белем алды. Өчебез дә беркайчан да әнигә кайгы ташымадык. Беребезгә җитмеш дүрт, икенчебезгә алтмыш алты, төпчегебезгә илле алты яшь, барыбыз да аек, шөкер. Әниебез туксан сигезне тутырды. Әниебез Миләш пүчинкәсендә үз йорты белән тора. Мунчасы, бакчасы бар, газ кергән, телефон кергән авыл йортында яши. Уртанчыбыз Чаллыда яшәгәнлектән, аны карап тора, азык-төлек, он-шикәр-барчасын да Сәйрүс энекәш кирәгенчә китереп тора. Әниебез мохтаҗлык кичерми. Барыбызның да тормышыбыз көйләнгән, Аллага шөкер. Сәйрүс—инженер, Рәсим-төпчек—инженер гаиләсе белән елга икеөч тапкыр Пермь шәһәреннән кайтып, әнинең хәлен белешеп тора. Алар кайтканда без дә бөтен гаиләбез белән әни йортына җыелабыз. Мин инде җае чыккан саен, йомыш белән Зәйгә, Сарманга баргалаган чакларда да әни янына кермичә китмим. Әни үзе дә еш кына Казанга килә. Әнинең

картлыгы—бәхетле картлык, Аллага шөкер! Аллаһ Тәгалә әнигә сәламәтлек, озын гомер биргән, ул балаларының, киленнәренең, оныкларының игелеген күрә.

Без дә әнинең бәхетенә куанып яшибез.

*Бу китапны әзерләгәндә (2010) әнигә 98 тулып килә иде, ул әле һаман сәламәт, күзе яхшы күрә, ул көне буе китап укый, йокысы яхшы, ашавы әйбәт.*

## Мәхәббәт бөреләре. Аннук

Мин гашыйк булган беренче кыз Зичәбаштагы Аудиттинең Аннук исемле кызы булды. Аннукка җиде, миңа алты яшь булгандыр ул чакта. Аннукның куфайкасына, яулыгына чаклы ярата идем мин. Кышларын өйдә суык, әни Зәйгә китеп соң кайтасы көннәрдә безгә Санук апасы белән Аннук кунарга килә иде. Без куфайкалар кигән килеш йоклый идек. Мин кыр талашып Аннук янына ята идем. Аның исе, аерым бер тәмле ис иде, ул Аннук исе генә. Андый ис башка берәүдә дә юк. Мин Аннукны эзләп, Аудитти өенә дә барып керәм, Аннук өйдә булмаса, аны эзләп чыгып китәм. Аны күргә каршы йөгерәм, кочаклыйм, үбәм. Ие, менә шундый булды ул минем беренче тапкыр гашыйк булуым. Зичәбаштан киткәч тә мин Аннукның тәмле-матур яңакларын, аның куфайкасының йомшаклыгын, яулыгының назларын оныта алмыйча яшәдем. Бишавылында укыганда, миңа унбиш яшьләр булгандыр, Зичәбаштан килеп укый торган җегетләр әйтте:

— Аннук Югароч Түлегә кияүгә чыкты! — диделәр.

Түленең әнисе караучысыз калган иде бугай, Түлегә дә ул вакытта унҗиде тулар-тулмас булгандыр. Икесе дә үсмер иде инде.

Бу мәхәббәттә минем беренче югалтуым иде.

Шуннан соң минем мәхәббәт тарихым гел югалтулардан гына торыр. Ләкин ул югалтулар фаҗига төсен алмады, шөкер. Шулай кирәк булган.

Аннук Түлесеннән күп балалар тапты, бер кызы итальянга кияүгә чыгып, Италия ватандашы булып яши, диләр. Түле алтмышны узып, авылда, Зичәбашта вафат булды. Авыр туфрагы җиңел булсын.

## Могинә апа

Икенче тапкыр мин өченче сыйныфта Шыкмайда (1948) укыганда укытучым Могинә апага гашыйк булдым. Могинә апа үзе бу турыда беркайчан да белмәде. Могинә апа каяндыр читтән килгән мөгаллимә иде. Чәндер, озын буйлы. Ак чырайлы иде ул. Бик матур иде укытучыбыз. Ул явыз түгел. Ләкин без—ташбашлар әллә нинди сабырларны да чыгырыннан чыгара алабыз. Әнә, Исмәгыйль Гарифуллин без диктант язганда сыер булып мөгрәп утыра. Эше юк. Диктант язарга аның ни каләме, ни карасы юк. Эшсезлектән нишләсен, сыер булып мөгри, сарык булып мәэлди. Оста мөгри, оста мәэлди. Безгә кызык, диктант язу өзелә. Могинә апа:

— Житте, Исмәгыйль, туктыйсыңмы син, юкмы?— ди.

Исмәгыйль туктый, ләкин бераздан соң тагын, мөгри башлый. Могинә апаның ачуы чыга. Ачуы чыкса, Могинә апаның ак йөзе алсулана. Алсу яңалары белән Могинә апа тагын да матурая. Мин аның алсу яңакларыннан үбәргә хыялланып утырам. Исмәгыйль мөгрәми. Мин аның мөгрәгәнен көтеп утырам. Хәйрулла да эшсез, аның да язу карасы юк. Аның артындагы партада утыручы кызлар аңа кара бирми. Хәйрулла бер җай табып, тиз генә

кызларның кара савытын ала да эчеп тә бетерә. Хәйрулланың авызы шәмәхәгә буялган. Кызлар жылый, диктант язарга кара калмаган. Хәзер Исмәгыйль генә түгел, Хәйрулла да, Фәридә белән Бибинур да эшсез кала. Без чыдый алмый көләбез. Могинә апа тагын кызара. Йөгереп килеп Хәйрулланың янбашына төртә, Хәйрулла каеры тун кигән, Могинә апаның төртүе ана сизелми дә. Мин һаман Могинә апаның алсу яңакларын үбәргә хыялланып утырам. Исмәгыйль дә, Хәйрулла да тәртип бозмаганда Могинә апа ак чырайлы була. Ярты матур. Их, тагын берәрсе берәр нәрсә эшләсен иде дә, Могинә апаның яңаклары тагын алсуланып иде, дип көтәм. Юк, берсе дә мөгрәми дә, язу карасын да чөмерми. Алдан әйтеп куям: Хәйрулла үскәч, шул Фәридәгә өйләнде, алар озын гомер кичерә, бик күп балалары булды. Хәзер өйләре тулы оныклар. Хәйрулла авылның иң алдынгы тракторчысы. Исмәгыйль читкә китте. Маржага өйләнде. Авылга сирәк кайта. Кайтса да ялгызы гына кайта. Авылда ямь тапмыйча, китеп тә бара.

Исмәгыйль мөгрәми, эт булып өрми. Могинә апа ак чырайлы ярты матур. Аның алсу яңакларын күрергә теләвем шулкадәр куәтле иде ки, мин Исмәгыйльнең аркасына шап итеп суктым. Куфайкадан тузан болыты күтәрелде. Бу эшемне күреп, Могинә апа кызарды, йөгереп килеп, такыр башыма, урта бармагының сөяге белән чүкеде, мин болай да кысталып утыра идем, боелыгым тотмыйча, астым юешләнде. Гыйшык ул бик тә яман нәрсә.

Дүртенчедә укыганда булды бу хәл. 1949 елда.

— Балалар! — диде Могинә апа. — Иртәгә диктант язабыз, диктантыгызны РОНО дан килгән вәкил тикшерәчәк, әзерләнеп килегез.

Язу карасына кытлык чак. Галимжан чүлти шешәсе тутырык кара кара алып килгән. Галимжан юмарт кеше, карасы булмаган мескеннәренең буш савытына кара салып чыкты.

— Каян алдың бу караны? — дигәннәргә Галимжан горур гына жавап бирә: — Пирмедән Галәлетдин абый жибәрде, — ди.

Могинә апа да, без дә бик сөендек. Диктант язмаган кеше калмады. Могинә апа матур, куе кара белән язылган диктант язылган дәфтәрләрне жыеп алды. Галимжан көн каһарманы иде. Аны мактыйбыз, кемдер аңа үз ипиеннән кыерчык сындырып бирә, кемдер аркасыннан сөя. Галимжан юксылларга ярдәм итә алганыннан бик канәгать, бәхеле иде.

Икенче көнне мәктәпкә килсәк, Могинә апа белән РОНО кешесе безне көтеп тора икән. Могинә апа каушаган, вәкил ишекле-түрле йөри.

— Безобразие! — кебек сүзләр ишетелә.

Могинә апа дәфтәрләрне алып селки-селки:

— Бу нинди хулиганство? — дип безне сүгә.

Диктант язылган дәфтәр битләре ап-ак иде. Ярты класснын диктанты юкка чыккан. Галимжан да аптыраган.

— Мин ул караны мич юллыгындагы корымнан ясаган идем, — диде Галимжан еламсырап. — Күп итеп шешәгә тутырдым да, су белән болгаттым.

Төн буена корым кипкән дә коелып та беткән, дәфтәрне ачкан саен вәкил алдына шыбырдап корым коела башлаган. Үз каралары белән язган кызлар «бишле» алды, Галимжан карасы белән язганнарга «берле» куйдылар.

Могинә апа безнең авылның Аюкин Әхнәф абзыйга кияүгә чыгып, Шыкмай килене булып калды. Аларның ике улы туды. Әхнәф абый күптән вафат инде. Могинә апа хәзер Чаллыды тора. Ике улы да Чаллыда яши.

Ул да 90ны узып, 2009 елда Чаллыда гүр иясе булды. Тәки Могинә апа минем аңа гашыйк булганымны белми китте. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәжигун!

## Әлфирә

Өченче тапкыр мин Ижаудан Маһинур түтиләргә кайтып йөри торган Әлфирә исемле кунак кызына гашыйк булдым. Шәһәр кызы, киеме дә, сөйләшүе дә, елмаюы да әллә ничек, ягымлы, матур иде шул Әлфирәнең. Мин аның рәсемен ясап, диварга кадаклыйм. Аңа ошарга тырышып, чәчемне дә каз маена буяп, елтыратам. Су коенганда аңа охшарга тырышып, су астында озаклап торам, ничек тә булса, Әлфирәнең игътибарын үземә тартырга, кызны үземә каратырга исәп. Юк, Әлфирә миннән көлә генә. Үсмер чактан жегет кисәгенә әвереләдек. Кызга гашыйклар бер мин генә түгел идем: Эшмит Сафиуллин белән Рәсүл Сәгыйдуллин Әлфирәне аулыйлар. Мин арткы планга күчтем, кызга өмет итүчеләр икәү калды: Эшмит белән Рәсүл. Рәсүл гадәтенчә сугышып, кыз игътибарын яуламак була. Ләкин Шмит мин түгел, таза беләкле. Аннан соң ул гармунчы. Рәсүл белән без конкурстан узмадык. Әлфирә Эшмит белән йөри башлады. Алар бик яратышып, озак йөрделәр. Мин инде жинелүем белән килештем. Әмма Рәсүл:

— Әлфирә барыбер минеке булачак, — дип ант итте.

Эшмит авылда юкта Рәсүл бер-ике тапкыр Әлфирәне кичке уеннан озата да кайтып карады. Әлфирә агалары белән кайтып китә иде. Рәсүлне Әлфирәгә янына жибәрмәделәр. Эшләр шуңа кадәр барып житте: Эшмит белән Әлфирә өйләнешергә уйлый башлады. Ләкин язмыш үзенчә хәл итте. Әлфирә беркемгә дә булмады. Әлфирә безнең авыл жегете Аюкин Рәйханга кияүгә чыкты.

Рәсүл, китап укый торган, әдәби зәүкы булган бер кеше иде. Ләкин тормышы барып чыкмады. Милициядә эшләгәндә шайтан суы белән дуслашып, эшсез, гаиләсез калды. Күптән вафат инде. Чир аны бик иртә алып китте. Авыр туфрагы жинел булсын!

Эшмит Алабуга кызы Асия ханым белән бик матур гаилә корып, бик яратышып яшиләр. Асия ханым балалар табибәсе, Эшмит гомере буе музыка укытучысы булып эшли. Эшмит булдыклы гаилә башлыгы булды. Тормышы мул, шөкер.

Алтмышка житеп килгәндә Әлфирәне бер-ике тапкыр авылда очраттым. Ул элеккеге кебек матур елмая, бит очында чокырчыклар хасил була. Яшьлек хисләре матур булып узган гомердә калган. Ул да тулышкан, мин дә аксакаллы булганмын.

## Икенче Әлфирә

Ул Алабугада китапханәчеләр техникумында укый иде. Үзебезнең авыл кызы Әлфирә Хәбибуллина. Мин аны иплелеге, тыйнаклыгы, матур биегәне өчен яраттым. Мин — гармунчы сыныгы егетләрне, кызларны клубта биетәм. Әлфирә биегәндә тагын да дәртлерәк уйнарга тырышам. Бу бию көен мин башка кызларга уйнамыйм. Бары тик Әлфирәгә генә уйныйм. Ул Алабугада чакта бию көе ял итә. Әлфирә кайткач, аны берәрсе биергә чакыргач, аның өчен генә саклаган бию көе яңгырый. Уен таралгач, мин Әлфирәне озата кайтам. Аларның капка төбенә килеп туктыйбыз да сүзсез калабыз. Ни телчән булсам да, мин Әлфирә янында сүзсез калам. Кочакларга маташыр иден, кулда гармун. Гармун комачаулый Әлфирәне кочакларга. Әлфирә дә: мә, мине кочакла, дип тормый, әкрен-әкрен генә миннән ераклаша, капкадан кереп китәргә чамалый. Икенче көнне мин гармунны Галимжанга биреп, Әлфирәне гармунсыз гына озата барам. Ләкин Әлфирә кочаклатмый, кочаклатмый да сөйләшми дә. Ул кереп китә, мин кайтып китәм.

«Әлфирәгә мин ошамыйм, ул мине яратмый икән» дигән нәтижәгә килеп, мин кабат аны озатмас булдым. Бу мәхәббәт шулай бөреләнмичә генә сүрелде, сүнде.

Мин кечкенәдән мактанчык идем, бер кешедә дә сәпит юк, миндә бар, мин шул сәпиткә атланып, урамнарны кырыкмаса-кырык әйләнәм, кешеләрнең ачуы килә. Күн итек белән каракүл якалы пәлтә берәүдә дә юк, миндә бар. Патефон берәүдә дә юк, мин тәрәзне шар ачып, патефонны тәрәзә төбенә куеп, урам якка каратып, патефон уйнатам. Матай берәүдә дә юк, мин көн туса, йомышлы-йомышсыз матайга атланып, пытыр-пытыр чабам, капка төбендә утыручы эшсез картларның мона эче поша, яшьләр көнләшәләр.

Мина калса, Әлфирә минем әнә шул кумпыклыгымны[6] өнәп бетерми иде.

### Шәфкать туташы

Бу юлы мин алдагыларына караганда житдирәк гашыйк булдым, ахры. Унынчыны бетергәч, мин бер уку елы Кадер авылында укытучы булып эшләдем. Шул елны көзен Бишавылы хастаханәсенә Алабугадан фельшер-акушерлыкка укый торган берничә кыз практикага кайткан иде. Мин шуларның берсенә гашыйк булдым. Аның исемен хәтерләмим, шуна күрә, без аны Табибә дип кенә атыйк. Ул кыз миннән ике-өч яшькә олы иде. Мин хәзер картлыгым белән уйлап куям: ул нинди дәрт булды икән. Ярый, дәресләрдән соң көн саен мин сигез чакрым араны узып, Табибә белән күрешергә барам. Ул да мине көтеп ала. Без төне буе кочаклашып, хәлдән тайганчы үбешеп чыгабыз. Тан алдыннан мин тагын сигез чакрымны тырт-тырт атлап кайтам да, дәрескә кереп китәм. Монысы да ярый. Яз житте, ташу вакыты, юллар өзек. Кадер белән Ашыт арасында ике жирдә котчыккыч ташу, бозлы салкын су. Мин шул ташу аша чыга идем, кулымда колга. Ерып чыксам, кием чылана. Аргы якта коры утраучык бар. Чишенеп, ялангач калып, киемнәрне колга белән шул коры жиргә атып, үзем бозлы суны ерып чыктым да, коры киемнәрне киеп, Бишавылына, мәгъшукам янына киттем. Мин килеп кергәч, Табибәм артына утырды. Бу юлны кошлар гына уза ала иде. Иртән Кадер авылына кайтканда су кимегән була, аягасты коры була.

Ташын кызса, ташуны йөзеп чыгу берни дә тормый икән.

Бер кичне хастаханәгә мәгъшукам янына килсәм, ул әйтә:

— Синен әниенне китерделәр, ул бүген сина эне алып кайтты! — дип ушымны алды. — Бар, ананның хәлен белеш!

Мин — дивана әнинен хәлен белешергә кермәдем. Хәзер дә үкенәм. Имеш, әни 44 яшендә бәбәй алып кайткан, тузга язмаганны. Ул вакытта әни мина бик олы яшьтәге хатын булып күренгәндер, ахрысы. Ләкин соныннан мин шул энемне үлеп яраттым, ана исемне дә үзем сайладым — Рәсим! Шундый матур, чын татар исеме куйдырганга Рәсим мина гомер буе рәхмәт укыды.

Безнен бу «мәхәббәт» алга таба ни булып бетәр иде икән, белмим. Мин Мәскәүгә укырга киттем. Бер-ике хат алыштык та бу гыйшык шуның белән бетте. Шуннан сон Табибәне очратканым булмады.

### Мөзәянә

Алтынчы тапкыр мин жегет булып килгәндә кунак кызына гашыйк булдым.

Безнең авылга калхуз председателе итеп Карман авылы кешесе Шәйхулла абый Шәяхмәтне китереп куйдылар. Шәйхулла абыйны халык ярата иде.

[6] кумпык – мактанчык, кыланчык.

Усал иде ул. Кырыс иде. Ләкин халык аны һаман хөрмәтләп искә ала. Беләсезме, ул башка председательләр кебек карак түгел иде, калхуз малын урламый иде. Председательлектән алып, аны Кадер мәктәбенең директоры итеп куйдылар. Ул анда да гаделлеге белән хөрмәт казанды. Бәлки аны шул гаделлеге харап иткәндер дә, өстеннән җыен юк-бар язып, аны тагын урыныннан алдылар. Барысына да төкереп, ул балта остасы булып китте. Шәйхулла абый күптән мәрхүм инде. Йорт җиткезгәндә башына бүрәнә төшеп, ул һәлак булды. Урыны җәннәттә булсын!

Шәйхулла абыйның Мөзәянә исемле сеңлесе безнең авылга кунакка килә иде. Авылда шундый гадәт бар: кунак кызын кем тота? дип кыз бүлешәбез. Рәсүлнең дә күзе төшкән бит Мөзәянәгә. Рәсүл әйтә:

— Кыз минеке! — ди.

Мин әйтәм:

— Мөзәянә белән без инде сөйләшеп тә куйган идек! — дим.

Рәсүл әйтә:

— Алайса, сугышабыз! — ди.

Сугышырга китсә, Рәсүл мине җиңә. Авыл егетләренең күпчелеге минем якта, эшне сугышка җибәрмәскә тырышалар. Рәсүлне минем янга да, кыз янына да җибәрмиләр. Бик озак тарткалаша торгач, Кайнар Гыйлаҗи Мөнибе әйтә:

— Егетләр, тотыйк та Мөзәянәнең үзеннән сорыйк: ул кем белән йөрергә тели?

Шулай иттеләр дә. Мөзәянә шундук минем якка күчте. Шулай итеп, Мөзәянә минем йөри торган кызым булып китте. Ул күп мәртәбәләр безнең авылга тагын кунакка килде. Миңа бу кызның иплелеге, кычкырып көлми, елмаеп кына, салмак кына көлүе дә, аксыл чәчле, зәңгәр күзле булуы да, йөрешенең, аяк басуының килешле булуы да бик ошый иде.

Председатель сеңлесе буларак, мин Мөзәянәне трантас җигелгән айгыр белән Карман авылына илтә баргаладым. Беренче тапкырында бик кыен булды. Безне председатель айгыры кыен хәлгә куйды.

Трантаста парлап утырабыз, Мөзәянә патша кызы кебек матур күренә. Дилбегәне бушатуга айгыр Карман ягына оча, айгырны тыя төшәм, юл уртасында айгырым «шырт-шырт» тавышлары чыгара башлады. Мин оялдым, Мөзәянәгә кыен, икебез дә ни әйтергә белмибез. Шул гына җитмәгән, айгыр туктап койрыгын күтәреп, деренен коя башлады, аннан соң шарлама тавышы ишетелде, ат бушана иде. Мөзәянәм басу-кырларга бага, офыкка карый, мин: бу оятсыз хайван кайчан эшен бетерер икән, дип көтәм. Шучак мин нишләргә белмәгәнлектән, чыпчык котырса ябалакка ташлана, дигәндәй:

— Аһ, оятсыз! — дип айгырга кычкырдым. — Ничек оялмыйсың син, арбаңда кунак кызы Мөзәянә утыра!

Мөзәянәм рәхәтләнеп көлә башлады, икебезгә дә җиңел булып китте.

Бу сүз кызны чыгырыннан чыгарды, юл буе көлешеп бардык. Яшьләр шундый очракларда бик оялалар. Аларны алдан ук тәрбия итәргә кирәк. Ул эшләрнең табигый икәнен, оят түгеллеген ата-ана, мәктәп өйрәтергә тиеш. Шуннан соң Мөзәянә белән безнең ара тагын да якынайды. Мөзәянәне мин тагын ат белән озата бардым. Айгыр ни генә кылса да, безгә кыен түгел иде инде.

Мөзәянәнең абыйсы да, җиңгәсе дә, минем әти-әни дә—бөтен авыл безнең йөргәнне, бер-беребезне көтеп алганыбызны белә иде. Мин аның туган авылына Карманга да барып йөрим. Гармунымны сыртыма асам да, атайның матаена атланам да, Карманга китәм. Шунысы кызык, башка авылларда кыз артыннан килгән егетне кыйнап, куып кайтаралар.

Карманда мина мөнәсәбәт гел башкача булды. Мин клубка килеп керсәм, шахматлы уйнап утыручы жегетләр, аягүрә басып:

— Уйныйсынмы?— дип сорый.

Мөзәянә белән фәлән көнне Карманда күрешергә дип хат алыштык, ул Алабугада китапханә техникумында укый иде. Атайнын матаена атланып, дустым Нурзаһитне дә утыртып, ун чакрымлык Карманга чыгып киттек. Карманга житкәндә бензин бетте. Карангы төн. Мөзәянә дә кайтмаган булып чыкты. Авыл йоклый. Мин тоттым да бер йортнын тәрәзәсен шакыдым, эчтә тавыш ишетелгәч, хәлне сөйләп бирдем. Бер жегет тәмле йокысыннан торып, бензин табып, автол кушып, бакны тутырып, кайтарып жибәрде. Кичке уенга Карманга килеп, гармун уйнап китә торган идем. Мине монда булачак кияү кебек хөрмәтләп каршы алалар, кунакка чакыралар иде.

Унынчыны бетергәч тә мин Алабугадагы ике еллык Милиция мәктәбенә имтихан тоттым. Монда керергә теләвемнен сәбәбе матди як иде. Әтинен эшләре авылда яхшы бармый иде. Тормышыбыз начар булмаса да, акча мәсьәләсе бик кысан иде. Милиция мәктәбендә ашау, кием, торак бушлай, шулар өстенә аена дүрт йөз сум акча бирәләр. Кердем мин Милиция мәктәбенә. Унжиде яшьлек малай идем әле мин ул чакта. Кыскасы, мин олы яшьтәге агайлар янына барып эләктем. Хатын-кызлар, мәхәббәт, гаилә, хыянәт кебек төшенчәләр турындагы беренче сабакларымны, ягъни, сексуаль тәрбия турында теортик дәресләрне мин шунда милиционерлар арасында алдым. Казармада егермеләп кеше йоклыйбыз. Һәр кич йокларга яткач, ирләр хатын-кызлар турында сөйлиләр. Һәркем үзенен маржалары, мажаралары турында сөйләп мактана. Монда берничә ел милиционер булып эшләгән сержантлар, старшиналар, лейтенантлар кереп тулган. Хәтерлим әле, кыска гына буйлы татар кешесе, участковый булып эшләгәндә үзенен ничек итеп бер кызны бүлегенә алып кереп, куркытып, үзе белән йокларга мәжбүр иткәнен сөйләде. Бер сержант ничек итеп, бер хатынга кызыгып йөреп тә, жаен табалмагач, хатыннын ирен вакытлыча төрмәгә ябып, хатын куенына кергәнен сөйләде. Минем тумбочка өстендә Мөзәянәнен рәсеме тора иде, шуна карыйлар да:

— Һәй, жегет, син монда казармада ятканда Мөзәянән...— дип ачыктан-ачык оятсыз сүзләр белән хакәрәт кылалар иде.

Шуннан сон мин төннәр буе йоклый алмый идем. Бәлки жылаганмындыр да, һәрхәлдә, минем ут йотып, пошырынганымны сизеп, күрше ятактагы өлкән сержант Фоат абый сабыр гына мине юата башлады:

— Син, энем, аларнын сөйләгәненә игътибар итмә, алар булганын да, булмаганын да сөйли, баксан, әле лейтенант гомерендә бер хатын да кочып карамагандыр. Алар тормышка ашмас хыялларын гына сөйли, —диде.

Фоат абыйнын тумбочкасында хатынынын, ике кечкенә кызынын рәсеме тора иде. Фоат абый Уфада тимер юлда милиционер булып эшләгән. Офицер дәрәжәсе алыр өчен монда укырга килгән.

Гомерем буе шушы кешенен якты сурәте күз алдымнан китмәде. Ие, теге абзыйларнын да күбесе кабәхәт булмагандыр. Тәк сибә, шаукымга бирелеп кенә кабахәт мәзәкләр сөйләгәннәрдер, ихтимал. Әмма үсмернен зәгыйфь рухында хатын-кызга ышанычны ныгытыр өчен бер Фоат абзый житкән икән. Кайда икән ул яхшы кеше? Анын язмышы ничек булып бетте микән? Ничек кенә булмасын, тормыш нәжескә каршы саф әхлакны да китереп куя, шөкер.

Ие, барысы да булды бу гомер эчендә. Әхлаксыз хатыннарга да гашыйк булган чаклар булды. Аларнын хыянәтен дә күрдек Мәскәүдә яшәгәндә. Ләкин тормышнын ямен, хатын-кызга булган соклану вә ихтирамны алар гына таптый алмый.

Рәхмәт сиңа, өлкән сержант Фоат абый!

Мин Милиция мәктәбендә озак укый алмадым, китәргә мәҗбүр идем, сәбәбен дә әйтә алам. Корал складында эшләгәндә мин бер пистолет, бер тартма капсуль-детонатор, бер мылтык хәнҗәре, бер компас яшереп алып калган идем. Шул фаш ителде дә:

— Бу үсмер әле милиционерлыкка өлгереп җитмәгән,— дип мине мәктәптән чыгардылар.

Шуннан соң мин авылга кайттым. Бер ел укытучы булып эшләгәннән соң мин Мәскәүгә укырга киттем. Мөзәянә укуын бетереп, Ашытка вакытлыча эшкә кайтты. Арада хатлар йөри башлады. Хатлар сирәгәя торды, соңгы хатта Мөзәянәнең Ашыт җегете, гармунчы Әбүзәргә кияүгә чыкканы мәгълүм булды. Ул кызны урлап алып кайткан икән. Мин җәйге каникулны зарыгып көттем. Авылга кайттым да, әтинең матае белән барып, Мөзәянәне урлап кайтырга булдым. Мөзәянәне Ашыттан Тәкмәккә күчергәннәр икән. Матайга атланып Тәкмәккә чыгып киттем, кыз, дөресрәге, кеше хатынын урларга. Ярты юлда матайның арткы тәгәрмәче җибәреп, кире борылдым. Тәгәрмәчне ямарга әсбаплар юк. Яннан тәгәрәтеп, этеп, көчкә кайтып җиттем.

Кеше хатыны урланмый калды. Мин Мәскәүгә киттем. Озакламый Әбүзәр кинәт дөнья куйды. Авыру булган икән, бичара. Мөзәянә тол калды. Ул да ире үлгәч, Мәскәүгә укырга килде. Без анда бер тапкыр күрештек. Ул да салкынайган булыпмы, мин дә инде аннан бизгән идемме, белмим, Мөзәянә казакъмы, кыргыз җегетенәме кияүгә чыгып, Урта Азиягә китте. Тормышы көйләнгән, дип ишетелгәне бар. Бирсен Ходай.

### Сәхилә

Хәзер уйлыйм: әгәр дә бу кызларның берәрсе миңа кияүгә чыккан булса, бәхетле булырлар идеме икән? Мин алар белән бәхетле гаилә кора алган булыр идемме икән? Шикле фараз. Бу кызларның барысы да миннән берике яшькә олы иде. Мин әле өлгереп җитмәгән үсмер. Алар инде өлгергән хатын. Минем гаилә корырлык тәҗрибәм дә, малым да, йортым да юк. Һичшиксез, гаилә таркалачак иде. Миңа чыкмаулары аларның бәхете. Минем дә бәхетем. Шуңа күрә, мин аларның барысына да, миңа кияүгә чыкмаганнары өчен, рәхмәт укыйм, аларны шуның өчен хөрмәт итәм.

Биш ел буена Мәскәүдә минем җитди мавыгуым булмады. Мәскәүдә акчасыз, яхшы киемсез син мәгъшукалы булам, димә. Миндәйләргә бигрәк тә рәт юк. Мәскәү марҗалары минем ишегә борылып та карамый. Ни буй, ни кием, ни акча, ни нәрсә... Аннан соң, сексуаль интуициясе булган хатын-кызның игътибарын минем кебекләр җәлеп итә алмый. Хатын-кыз бәлки акылы белән ул турыда уйламыйдыр да, әмма аларның сексуаль интуициясе яхшы лазерлар, шәп ультратавышлар белән коралланган. Алар үзләренә нинди ир кирәген узып киткәндә җенси локаторлары белән сизә. Шуңа күрә, миндәйләрдә андыйларның карашы тоткарланмый. Шуңа күрә, мине иргә санап, минем белән гыйшкый мөнәсәбәткә кергән хатыннарга мин һәрвакыт рәхмәтле булдым.

Ие, Мәскәүдә укыганда мин шугалакта тәтке шуып йөргәндә бер татар кызы белән танышкан идем. Без анда Дунай белән икәү идек. Миндә нинди гадәтләр инде ул. Бер-ике тапкыр очрашуга ук мин кызга күнегәм, ярата башлыйм кебек. Бу юлы да шулай булды. Яшь күңел мәхәббәт тели, булмаган мәхәббәтне уйлап чыгарып, шул уйдырмага ышанасы килүме ул, белмим. Сәхилә исемле бер кыз иде ул. Ул өенә алып кайтып, әтисе-әнисе белән дә таныштырды, минем әни Мәскәүгә килгәч, кунакка алдырдылар. Эшләр өйләнешүгә таба бара иде. Рас өйләнешәсе булгач, мин четерекле

мәсьәләдә аны ашыктырмыйм. Ягъни, безнең арада Әфләтун мәхәббәте иде. Әнигә бүләкләр алып озаттылар.

Бәхетем бар икән! Эш никахка барып житмәде, шөкер.

Нindидер бер бәйрәмдә, Яңа Ел булса кирәк, йөргән кызларыбызны чакырып, мәжлес оештырырга булдык. Ни өчендер, бер генә жегетнең дә кызы килмәде. Минем Сәхиләм килде. Арабыздан Дамир исемле бер жегет мине аеруча кыстый-кыстый, шәп сыйлады. Мин уянып киткәндә, Сәхилә юк. Кайтып киткән. Өйләренә киттем. Аңлашкан булдык. Очрашкалыйбыз. Көннәрдән бер көнне дусларымның берсе әйтә:

— Синең Сәхиләң Дамир белән очрашып йөри, сине төп башына утыртырга аларның исәбе, — диде.— Мин аларның телефоннан сөйләшкәнен ишеттем. Алар синнән качып очраша.

Мин моңа ышанмадым, әмма күңелем шикләнергә боерды. Теге дустым мине алар яшерен очрашачак урынга алып барып, читтән генә күрсәтте. Ие, метродан Сәхилә чыкты, Дамир янына килде, алар үбешә дә кочаклашып, каядыр китеп барды. Дамир тулай торакка таң алдыннан гына кайтты.

Шулай итеп, мәсьәлә хәл ителде. Ләкин мин Дамирның үзенә берни әйтмичә, Сәхиләнең өенә барып, сабыр гына барысын да сөйләдем дә чыгып киттем. Без шуннан соң кабат очрашмадык. Ни гажәп, Дамир белән дә аларның арасы өзелде. Шулай итеп, мин беренче тапкыр хатын-кыз хыянәтенең ни икәнен татыдым. Никах булмый калды. Башта авыр булды. Ләкин:

— Ярый әле, өйләнешкәч булмады бу хәл,— дип үземне юаттым.

Без училищене бетереп Казанга кайтып киттек. Озак еллар узды. 1965 елда мин Югары режиссерлар курсларына укырга янәдән Мәскәүгә киттем. Мәскәүдәге иске танышларым мине кунакка чакырды. Мин циркта эшләүче һава гимнасткасы белән чакырылган жиргә киттем. Миңа егерме сигез яшь иде ул чагында. Һәм шул мәжлестә Сәхилә карчыкны очраттым. Чыннан да карчык кыяфәтле иде ул, таушалган, чыраен жыерчык баскан. Күз төпләрендә күп йөргән, күп эчкән, күп тарткан хатыннарга гына хас түгәрәкләр. Ул унайсыз хәлдә иде. Сәхилә елмаймады, берни сорашмады, мин дә битараф калдым. Кешеләр безнең таныш икәнебезне дә абайламадылар.

Ул ялгыз һәм бәхетсез иде.

Шуннан соң мин Сәхилә белән кавыштырмаганы өчен Аллаһы Тәгаләгә өзлексез рәхмәтләр укыдым.

## Ялгышу

Училищене тәмамларга ярты ел калгач булса кирәк, мин бер кыз белән таныштым. Безнең очрашулар бик куе, дәртле иде, кайтып китәр алдыннан шул маржаны ташлый алмыйча, өйләнешеп, Казанга кайтып киттем. Беренче олы ялгышуым икәнен мин бер ел торганчы ук аңладым, ләкин соң иде инде, Казанга кайткач, ул татарча өйрәнер, мине аңлар, дип ялгыша идем. Юк, ул начар хатын түгел иде, әмма милли мәсьәләне аңлавы аңа кыен иде, милли мәсьәләне аңлауның ул хатынга кирәге дә юк иде. Чөнки мохит аларныкы. Шулар өстенә матди кысанлык, фатир булмау безнең болай да катлаулы тормышыбызны тагын да катлауландыра бара иде. Әйе, икесе дә татар булганнар да сыеша алмый. Аларның да ачуланышырга туксан тугыз сәбәбе бар. Әмма ике милләт вәкиле өйләнешсә, шул туксан тугыз сәбәпкә йөзенчесе, иң хәтәр сәбәп — милли мәсьәлә килеп өстәлә. Монысы инде тегеләреннән дә житдирәк һәм чишелә алмый торган мәсьәлә. Вакытлыча гына торырмын да хатамны төзәтермен, дип яши торгач, унжиде ел узган-киткән, берничә тапкыр мин аннан китеп карадым, торырга урын булмагач,

гаепле мәче сыман, кире кайттым. Кире кайткан ирне башта яхшы каршы алсалар да, тора-бара аңа ихтирам бетә. Ул ике яшькә миннән кече булса да, тормыш алып баруда анда олы хатыннар психологиясе иде. Ул йортны алып барырга тырыша, мин вакытлыча яшим, дип йортка игътибар бирмим, үз эшем белән мәшгуль. Ике бала үсеп килсә дә, фатир җае чыгуга ук без аерылыштык. Аерылышуга гаризаны ул язды. Мин сүзсез риза булдым. Мин аларга Союз биргән ике бүлмәле фатирымны биреп, үзем театрның тулай торагы хисапланган уңай шартлары булмаган бүлмәдә калдым. Балалар ата югалту хисе кичермәде. Аналары мәгънәле булып кала белде, аларны миңа каршы котыртмады, балалар гел миңа килеп йөрде, һаман да килгәлиләр. Хатыным Рузия дә акыллы була белә, балалар килгәч, караңгы чырай күрсәтми, алар дустанә мөнәсәбәттә. Чит илгә чыккач та, кулга акча төшкәләгәндә дә Рузия аларны бүләктән калдырмый. Мин онытсам да, ул искә төшерә:

— Карале, әтисе, Илдар белән Иркәгә менә боларны алсак, ничек булыр икән? — дип хатыным үзвакытында киңәш итеп өлгерә.

Мондый киң күнеллелек, ир психологиясен анлап эш итү бик сирәк хатыннарда гына була торгандыр ул. Һәм хатыным Рузиянең шушы киң күнеллеге мине аңа тагын да ныграк бәйли, мин Рузияне тагын да ныграк яратам, хөрмәт итәм. Әгәрен ки, Рузия ул балаларга кырыс яки битараф булса, күнелдә юшкын калыр иде, мин Рузиядән әкренләп суына башлаган булыр идем. Ихтимал.

Аяз Гыйләҗ әйтмешли:

— Батулла хәзер, кәләпүш киеп, кулына тәсбих асып, татар хатынын култыклап, мулла песие булып йөргән була, унҗиде ел марҗа ... кочып ятмаган, диярсең, валлаһи.

Дөрес, шулай. Әмма мин боларны башкаларга сабак булсын, минем хатамны кабатламасыннар дип сөйлим. Без мәсьәләне уртага салып, килешенеп аерылыштык. Хатабызны соң булса да төзәтергә тырыштык.

Иртәрәк аерылышкан булсак, яхшырак булыр иде дә, әмма бу аерылу икебез өчен дә бик кулай булды. Бу аерылышу үз гомеремдә минем дөрес атлаган адымымның беренчесе шулдыр. Икенче дөрес адымым—Рузиягә өйләнү булды. Әмма Рузиягә хәтле килеп җитәргә сигез елның узып китәсе бар әле.

Бая әйткәнемчә, чыннан да, егерме җиде-егерме сигезләргә кадәр, хатын-кызларның карашы миңа тукталмый, шуып кына уза торган иде. Егерме сигезне узгач, күрәсең, миңа җегет кыяфәте керде, хатын-кызлар кытлыгы миннән китте. Юк, миңа вакытлыча гына мәгъшукалар түгел, хатын булырдай зат кирәк иде. Мин андый затны бик тиз табармын, дип тагын ялгыштым, хатын эзләп җиде-сигез ел үтте-китте. Хатын-кыз белән танышканда ук мин:

— Бу әнигә килен, миңа яхшы хатын булырлыкмы? — дип максат тота идем.

Кырык яшьтә мин буйдак-тол калдым. Бервакыт Мәскәүдә, 1979 ел булса кирәк, Гөргөри, Рөстәм (Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалим)—өчәү сөйләшеп утырабыз. Гөргөри дә, Рөстәм дә аерылган, мин дә буйдак.

— Җегетләр, мин, һичшиксез, өйләнәм!— дидем.— Татар кызына өйләнәм. Алла боерса, һичшиксез, ике балабыз булачак.

Чыннан да, мин сүземдә тордым. Миннән соң Рөстәм, аннан соң Гөргөри өйләнде. Гөргөридә ике угыл, Рөстәмдә — бер кыз. Миндә ике олан. Ләкин Рөстәмнең бер кызы безнең дүрт угылны да орып бирергә охшап тора. Алсу—бик сәләтле рәссам.

— Батулла, синең ничә хатының булды?— дип сораганнарга җавап:

— Бер!.. Никахлы, ЗАГСлы бердәнбер хатыным — Рузия генә. Калганнарының никахы булса, ЗАГСы, ЗАГСы булса, никахы юк иде.

Ярты сүздән аңлый торган, синең өчен яна-көя торган, мин эзләгән зат менә шушы—Рузия булган икән. Менә без никах белән, ЗАГС белән үндүрт ел торабыз. (Хәзер 26 ел инде.) Безнең олыдан кубып бер генә тапкыр да ачуланышканыбыз юк. Минем кызыш холкым белән дә безнең өйдә тавыш чыкканы юк. Кеше ышанмас. Ләкин бу шулай.

Элек гашыйк булганнарыма мин бүген елмаеп багам. Яшьлек мавыгуы булган. Мәхәббәт түгел, мавыгу, вакытлыча гашыйк булу.

Менә без «Мәхәббәт» дигән бүлекнең азагына килеп життек: соңгы мәхәббәт ул— чын һәм беренче мәхәббәт.

Разил Вәли әйтмешли:

— Бер мәхәббәт табар өчен бу гомерем житәрме?

— Житәр! Соңгысы булыр ул чын мәхәббәт!

Хатын женесенең—ирләргә, ирләрнең хатыннарга тыйлыккысыз тартылуы кешенең, хайваннарның, бөжәкләрнең канына салынган. Кемдер үзенең женси гайрәтен, женси ихтыяжларын канәгатьләндерү өчен көнтөн хатыннар артыннан чаба. Аңа хисләр дә, мәхәббәт тә кирәк түгел, аңа ошыймы ул хатын, ошамыймы, матурмы ул, ямьсезме—ул кешегә шәһвәти дәрт таләбен үтәргә кирәк. Ул әхлак дими, канун дими, женси ихтыяжын канәгатьләндерергә тиеш. Хатынны ризалатыпмы, көчләпме—аңа барыбер. Үзенә ләззәт биргән хатыннарны андый кеше эше беткәч үк оныта.

Бар романтика, хиссият, мәхәббәт эзләүчеләр. Бар табигать, Алла тарафыннан бирелгән үрчү теләге аша өйләнүчеләр һәм ипле, матур гаилә коручылар. Алар кино-китап мәхәббәте турында уйламый да, өйләнергә кирәк булганга өйләнә, үрчергә кирәк булганга, үрчи, хатынын, балаларын ким-хур итми, каралты-курасын, малларын булдыра. Сау-сәламәт гаиләгә баш була.

Чыннан да, әгәр бары тик мәхәббәт белән генә өйләнергә кирәк икән, кешелек бетәргә мәхкүм булыр иде. Безнең төп максатыбыз — үрчү. Мәхәббәт эзлим дип гомер узып китәр иде, син буш, кысыр бер кирәксез затка әверелер идең. Бер мәхәббәт таба алмасыңа шикләнә башлагач, тотарга да өйләнергә, шул хатынны хөрмәт итеп яшәргә кирәк. Бәлки тора-бара, балалар тугач, мәхәббәт үзе килер. Мин андый бәхетле гаиләләрне бик күп беләм.

Тулы бәхетле булсын өчен кешегә өч нәрсә кирәк. Яраткан эше, яраткан яры белән яшәү һәм ватанының ирекле булуы. Минем яраткан эшем бар, шөкер. Минем өемдә нур вә жылылык. Ләкин халкымның азат булуына ерак әле. Мин бәхетсез түгел. Әмма тулы бәхет өчен өченче шарт юк. Әнә шул өченче шарт өчен мин ижатымны, гамәлләремне багышладым. Анысы да үзенә күрә бәхет.

Өемдәге вакыт-тәртип минем ижатыма ярашлык итеп корылган.

Кешелек:

— Нәрсә соң ул мәхәббәт? — дип сораудан туктамый.

Аны һәркем үзенчә аңлатып карый.

Мәхәббәтнең формуласын мин дә төзеп карадым.

Бер-берең ошау,
Бер-береңә ияләнү,
Бер-береңне ярата башлау,
Бер-береңне сөя башлау,
Бер-береңә ярашып яшәү —
МӘХӘББӘТ.

Сөю яратудан өстенрәк.

Яраклашып яшәү түгел, ярашып яшәү була мәхәббәт. Яраклашу яратмаганда була. Ир-хатынын яки хатын ирен сөйми, әмма балалар хакына сөймәгән кеше үзенең сөймәгәнен күрсәтми, тормышны алып бара, ата һәм ир вазифаларын төгәл башкара. Ягъни, алар яраклашып яши. Мин андыйларны бик хөрмәт итәм. Иремне сөймим, хатынымны яратмыйм, дип алма кебек матур балаларны ятим итү олы хата. Яраклашу – приспособление, ярашу – ярату, ансамбль.

Ярашып яшәү ул башка. Бер-береңә ярап, ярашып, яратышып яшәү — мәгънәләрен үз эченә ала «ярашу» сүзе.

«Мәхәббәт» сүзенә шуларның барысы да сыя. Яки шулардан: ошау, ияләнү, ярата башлау, сөя башлау, ярашудан Мәхәббәт хасил була.

*Мәхәббәт ул тәкърарлек тавышыдай моңлы-сагышлы. Мәхәббәт ул тургай кебек жилкенә, жилкендерә. Мәхәббәт ул сандугачтай өзелә, өзелдерә. Мәхәббәт ул ерак йолдыз кебек серле, салкын, буй житмәс шәй. Мәхәббәт ул диңгез кебек шомлы, гайрәтле. Мәхәббәт ул әҗәл кебек, барыбер бер килә, килә дә алып та китә.*

## Һөнәрле як

Кадер авылы борын-борыннан чыбылдык сугу белән дан тотты. Ашыт палас-келәм туку белән атаклы, Шыкмай тимер чүкү белән көн күргән. Урам саен алачык, алачык саен өчәр-дүртәр тимерче иде безнең авылда. Иртән иртүк торсаң — шаккатарсың! Тимерче агайлар сандалга салып тимер таптыйлар, чалгы чүкиләр, урак тешиләр, сабан төрәне ясыйлар. Исеңакылын китәрлек гаҗәеп бер музыка инде ул тавышны тыңлый белсәң: чаң да чаң, чең да чең! Бистебашы кап сугу остасы иде. Шыкмайда Шәмси түтинекеләр талчыбыктан кәржин үрү эшенә маһир.

Ашыт авылы барысын да уздыра иде. Башка авыллар керәчин якканда, керәчине булмаганнар сукыр лампа яндырганда, сукыр лампасы булмаганнар чыра яндырганда Ашытлар электр якты. Бар иде Ашытта шундый бер булдыклы председатель Закир абый Сәлимов. Шыкмайлар бәрәңге кушкан ипи ашаганда, Бишавылы алабута кушкан кара ипи ашаганда Ашытлар бодай күмәче, калач ашый иде. Зичә суын буып, өч чакрым арага баганалар утыртып, ул Ашытка электр кертте. Сугыш еллары, сугыштан соңгы еллар бит ул! «Коммунизм ул социализм плюс электрофикация всей страны» дигәнне искә алсак, Ашыт коммунизмга килеп житкән иде инде. Закир абыйның тагын бер олы эшен искә төшерми булмый, дусларым. Ләлә Тажетдинова атаклы галимебез Тажетдин Ялчыгол нәселеннән, Ашытка килен булып төшкәч, сугыш вакытында ат жигеп колхоз эшенә йөри икән. Ирләр житмәү сәбәпле Ләләгә ике ат тапшыралар, арбаларга сугылган арыш төяп, икенче атның тезгенен беренче арбага бәйләп, олау итеп икмәк ташыганда арттагы ат алдагы арбадагы арышны күп итеп ашый да күбенеп үлә. Эш зурга китсә, Ләләгә кимендә ун-унбиш ел төрмә булачак. Закир абзый мал духтыры Тиканга йөгерә, Тикан атны ярып карый да «чир таба», имеш, ат арыш ашап күбенмәгән, аның йөрәге хәлсез булган, дип справка бирә. Шулай итеп, Закир абзый Ләләне төрмәдән коткарып кала. Ашытлар барысына маһир халык.

Ашыт кешесе, профессор Гамир Мөбарәкҗан сөйли:

— Закир бабай ул аналитик акыллы, кырыс, әмма миһербанлы, гадел житәкче иде... 1942-45 елларда күрше авылларда атлар кырыла башлады, бездә дә күтәрмәгә калган атлар күбәя башлагач, Закир бабай атларны картларга таратты, ягъни ул кечкенә НЭП ясап алды, хужалыкта атка

ни дә булса эләгә, колхозның ашатыр курмысы юк. Шулай итеп, Закир бабай атларны саклап калды. Бу законга сыймый торган эш иде, колхоз атларын шәхси хуҗалыкка бирү ул — җинаять санала иде. Закир бабай тәвәккәлләде дә атларны саклады. Башка авыллар чана тартып, симәнәгә ташыды, Ашытлар ат җигә иде. Закир бабай СССР Югары Советы депутаты булды. Аның улы Габделхак Зәйгә электростанция салып бирде, аның улы Махиян да бик булдыклы ир кеше, аның оныгы Альберт ике аягы булмаса да чана, кашовкы ясый. Закир бабайның балалары, оныклары үзенә охшаган, унганнар, нәсел нык, таза. Закир абый сугыш вакытында карабодай үстереп, шуның янына умарталар куеп, күп бал җыйдырта иде, халыкка бал тарата иде, карабодай өләшә иде, халыкны ач калдырмады ул. Үзенең каралты-курасы гап-гади, ул урлашмады, урлатмады. Ашарына булмаса гына халык урлый ул. Закир ага ул чын шәхес, олы йөркле адәм була белде.

Шыкмай да Ашыттан калышмый иде, безнең авыл осталары ясаган чиләкләр! Чиләктәге бизәкләр! Ул көянтәләр! Көянтәләрдәге чәчәкләр! Чәчәкле көянтәне иңгә салып, бизәкле чиләкләрне көянтә башындагы җиз ыргакка элеп, яшь киленчәкләр чишмәгә су алырга төшәләр. Башларындагы ука белән чиккән энҗе-калфак, калфак өстеннән шәлъяулык. Киленнәрнең өсләрендә уникешәр кат бәбәйтәкле озын күлмәкләр. Күлмәк өстеннән бөрмә билле бәрхет камзул. Аякларында атлаган саен шыгырдап торган читекләр. Билдән узган чем-кара толымнарда чулпылар чылтырый. Көянтәне назлап кочкан беләкләрдә йөз кашлы, мең бизәкле беләзекләр. Чиләк бавын сыйпап баручы бармакларда алтын балдаклар, асыл ташлы йөзекләр елкылдый. Түм-түгәрәк, матур колак очларында асылмалы затлы алкалар, «менә-менә өзелеп төшәбез», дигәндәй, атынып баралар.

Бура-Киртә гомер-гомергә чана ясады. Төшемле һөнәр. Жылкы сую һәркемгә дә тәтеми, Бура-Киртә кешеләре ун чанага бер жылкы сатып алалар да симертеп суялар. Машалла!

Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс! дигән мәкальне безнең авыл кешеләре чыгарган, дип сөйлиләр. «Егет кешегә житмеш төрле һөнәр дә аз!» дигән мәкальне дә безнең авыл картлары әйткән, имеш. Чыннан да, нәрсәгә генә тотынсалар да безнекеләрнең кулы ут уйната торган иде.

Сугыш елларында, кием-салымга кысан чакларда да, безнең авылда чабата кимәделәр... Киюен киделәр инде анысы. Тик нинди чабата бит! Урман каешыннан, ягъни карамадан үрелгән, сүс киндерәле, табанына киез олтан салып, имән күтәртмә белән биек үкчәле иттереп ясаган чабаталар иде алар. Ул чабаталарның шыгырдаганын бер чакрымнан ишетеп, «әнә, Шыкмайлар килә!» ди торганнар иде.

Уен уйнау, күңел ачу ягына килгәндә дә һөнәрлеләрне узган кеше булмас. Башка авыллар гармунчыга аптырый, туй булса, концерт-фәлән куя башласалар, Һөнәрлегә килеп егылалар. Ә бездә гармун уйный белмәгән бер генә кеше дә юк! Ышанмасагыз, әйдә югары очтан өй борынча санап төшик... Миңнәхмәт — уйный. Гандилләр өй эчләре белән атаклы гармунчылар иде. Чокыр эче Нурзаһит гармун тарта. Әхмәтжан балалары, Усманныкылар Дәүләтша абыйлар саратский, казанский, тальянкалардан алып, баянга хәтле сыздыралар. Гармун күрегеннән түбәтәе күренми, һөнәрле баласы ду китереп «Әпипә»гә биетә. Нишләтәсең инде аны?! Уйнагач уйный! Түбәноч сукыр Кәлимулла Мөхлисулласының малаена чаклы әргән шыелдата. Ничек кенә шыелдата әле! Кадер авылына кунакка барып, сигез телле бозык гармуннарын уйнап, бөтен авыл халкын шаккатырып кайткан.

Ә сүзгә килгәндә! Ай-һай-һай! Ул сүз осталарын, мәкаль-мәзәк әйтүче, әкият-бәет чыгаручыларны тыңласагыз! Тапкыр сүзле, җор телле шул безнең авыл кешеләре. Бер Мирза Сәлимовның теле генә дә ни тора! Борынгыдан

килә, оланнар, ата-баба, әби-карчыклардан килә бу йола уеннары... Әкият дигәннән, безнең авыл әкиятчеләренә чыккан кеше юк. Шулар арасында иң остасы Мәгъсүмә әбиегез булыр. Ашытта аның сеңлесе бар ие, Камәр түти, анысы курай белән кубыз уйнап, төбәк ярышында җинеп, авыл клубына баян алып бирде....

Безнең авылдан ничә профессиональ музыкант чыккан әле? Рәшит Таймасов – гобойчы, Эшмит Сафиуллин — баян укытучысы, эстрада музыканты, Фәрит Таймасов музыка укытучысы... Өч урамга өч профессиональ музыкант җиткән. Эш күплектәмени? Эш сыйфатта бит, җәмәгать. Ә оста гармунчылар халык арасында калды: Хөснулла, Өлфәт, Гандил Маликовлар, бертуган Хөҗҗәт, Зөфәр абыйлар, Хәниф Таймасов, Дәүләтша Усмановлар... Шыкмайның горурлыгы!

## Гармун

Безнең авыл гармунчылар авылы. Шыкмайда гармун уйный белмәгән кеше бик сирәк булгандыр, дидек.

Чос Дәүли. Безнең якта кулы эшкә ятышлы, төз атучы мәргәнне, балта остасын «Чос кеше» диләр. Дәүләтша Госманов (Усманов) аның тулы исеме. Бик тә чос кеше иде, мәрхүм. Шыкмай гармунчылар авылы, ләкин Дәүли абый гармунчыларның да гармунчысы иде. Бөтен төрле гармуннарда, эскрпкәдә, мандолинада да оста уйнавы өстенә ул гармун ясаучы буларак дан тоткан кеше. Аларның өенә барып керсәң, сәке йөзлегендә нинди генә кораллар юк: кечкенә чүкеччекләр, боргычлар, шөрепләр, гармун телләре, җиз калай кисәкләре, еллар буе киптерелгән агач планкалар. Ясалып бетмәгән күрекләр... Агач диварлар тулы әллә ничә төрле сәгать, төзәтелгәннәре келт-келт итеп йөри, йөрми торганнары чиратта тора. Шәһәр остаханәләрендә «төзәтеп булмый» дип кире кайтарылган катлаулы сәгатьләрне Дәүли абый гына терелтә иде.

Клубта, җыеннарда мәйдан уртасында, концертларда өздереп гармун уйнаса да аның йөргән кызы булмады. Чөнки Дәүли абыйның муенында тилчәсе бар иде. Шул тилчә кайчакларда шулкадәр азып китә ки, муендагы җәрәхәтләр эренли, кайчакларда җәрәхәтләре корый, кибә, шул чагында Дәүли абый кеше арасына чыга, уен уртасында гармун тарта.

Безнең авылда Сабантуе көнне көрәш беткәч, ат чабышлары тәмамлангач, бөтен халык урам буйлап аска, Кызылтау ягына күченә, урамны инләп-буйлап яшьләр җырлап Тау уртасына уенга төшә. Җырчы егетләр тезелгән рәтнең сул кырында гармунчы Дәүли абый, өздереп үзе ясаган гармунда уйный. Егетләр муен тамырларын кабартып, бар көченә акырып җырлый. Мин — ун яшәр сабый — Дәүли абыйның уйнавына сокланып яннан барам.

Ул вакытта җәй уртасында сукыр черки күп була торган иде. Кыска, кечкенә черки тәнгә талпандай кадалып канынны эчә, астына сидерә валлаһи. Күрәм, Дәүли абыйның муен җәрәхәтенә дә берничә сукыр черки ябышкан. Дәүли абый чыдый алмый муенын боргалый, алай итә, болай итә, черкиләр уйламый да, кан эчә. Сул кулы белән черкине куып җибәрер иде, сул кул гармун тарта, көй-җыр бозыла. Дәүли абый чандыр-озын буйлы, черкиләрне куып җибәрергә минем буй җитәрлек түгел. Җаен таптым бит тәки, алгарак барып, капка төбенә куелган утыргычка менеп бастым да гармунчы килеп җиткәнне көтәм. Дәүли абый минем турга килеп җиткәч тә, бераз үрелә төшеп, кабахәт черкиләрне сыттым, икесе очып китте, икесе дөмекте, Дәүли абыйның рәхмәтле карашын күреп, сөендем. Дәүли абый иркенләп, елмаеп уйный башлады. Сәрвәри ботагы сындырып, кечкенә себерке ясадым да уенлыкка чаклы мин гармунчының җәрәхәтле муеныннан черкиләрне куып бардым.

Тау итәгендәге уенлыкка елга аша чыгасы, басма салынган, жырчылар рәтне бозып, жырлаудан туктап, бер-бер артлы басма аша чыга башладылар. Шулчак басма жимерелде, иллеләп кеше суга чумды. Дәүли абый да гармуны белән Зичә суына барып төште, яхшы-матур күлмәкле кызлар, яхшы чалбар кигән егетләр суда быкырдаша, батучы булмады, барысы да йөзеп чыкты, гармун гына су өстендә йөзә калды. Дәүли абый йөзә белми торган сабый кызларны коткарып йөри. Акырыш, кычкырыш, көлеш. Мин суга атылдым, гармунны куып житеп яр кырына алып чыгып Дәүли абыйга тапшырдым.

— И-и, Дәүләтша, гармунын жебер инде, уйнамас, — диләр.

Дәүли абый елмая:

— Бу гармун жеби торганнардан түгел! — диде.

Чыннан да бераз кипшергәч, гармун тагын уйный башлады.

Басма аша чыга алмаганнар буадан әйләнеп Тау ягына чыктылар, уен шәп булды.

Басманың терәкләрен Мирза Сәлимов кичтән үк кисеп куйган икән дип сөйләделәр.

Дәүли абый боек кеше иде, әллә авыруы аны боеклаткан, ул Фирме якларына чыгып китте. Шәһәрдә дәвачылары яхшы булганмы, Дәүли абыйның тилчәсе корыды, жөйләре генә калды. Шунда ул Гөлирә исемле бик матур бер татар кызына өйләнде. Үлем түшәгенә егылгач (Дәүли абыйга 70 яшь иде) мин аның янына Фирмегә бардым. Гармун ясатырга исәбем бар иде.

Дәүли абый урыныннан тора алмый иде инде: рак.

— И-и, Ырабит энем, — диде авыру. — Авылдаш... Әзер телләрем дә бар, ясаган булыр идем, бушка... бүләк итеп ясаган булыр идем... Мин... киткәч... Гөлирә жиңгән иң яраткан гармунымны сиңа бирер... Суга манчып алсаң да, кыш көне урамда уйнасаң да телләре бозылмый аның...

Мин китеп ике атна торгач, атаклы гармунчы, чос Дәүли абый гүр иясе булган. Урыны жәннәттә булсын!

Гөлирә жинги иренең васыятен тотты, Пермьдә яшәүче энем Рәсим ул гармунны алып килеп миңа тапшырды.

Шулай итеп, 1948 елда Зичә суында йөзеп, үзем алып чыккан гармун, һәр теле, һәр бакасы Дәүли абыйның үз куллары белән ясаган гармун миңа калды.

Эчем пошканда мин шул гармунны кулыма алам. Теленә басуга, күреген тартуга ук күз алдымда Шыкмайның Кулибины — Дәүләтша абый Усманов сурәте, аның моңлы йөзе барлыкка килә.

Дәүли абый гармун ясый, хәтта баян да ясаганы булды аның. Дәүли абый фәкыйрь каралты-кура баласы иде, затлылык бу нәселдә булган, әмма атасыз калу, ятим булу аларны затсызлар рәтенә куя язган иде. Аның анасы Мәкәррәмә түти дә бик боек хатын иде. Дәүли абыйны боек итүче тагын бер нәрсә бар иде. Аның муенына тилчә чыккан, шул тилчә һич корымый аптыратты. Әти әйтә иде:

— Дәүлинең бабасыннан килә бу чир. Атасы сәламәт булды, бабасы тилчәле иде. Дәүлинең балаларында тилчә булмаячак, әмма оныкларында шушы авыру кабатланачак, — ди иде.

Дәүли абый кулында сандугачтай сайрый-сайрый дистәләгән туйлар узгарган атаклы гармун минеке булды.

Үсмер чакта минем иң олы хыялым гармунчы булу иде. Әбием, бабам, әтием, агам гармунчы булса да, миңа жыр һәм гармун уйнау сәләте бирелмәгән иде. Әнинең жырга сәләте чамалы булгангадыр инде. Ихтимал, шуңа күрәдер, минем колакка аю гына түгел, фил баскан иде. Ни гажәп,

ике энемнен дә җырга сәләте юк. Минем балаларымның да җырга һәвәслеге чамалы.

Ул сәләт миндә дә чамалы иде. Әмма миндә ниндидер үҗәтлек бар иде. Өйдә патефон да тыңлыйм. Җырулар тыңлап, җырчыларга сокланам. Ялгыз калган чакларымда үзем дә җырлап карыйм. Әбинең курайларын интектерәм. Ләкин «Сарман»ны башлап, «Минзәлә», «Шөгер»ләр аша «Арча»га барып чыгам. Әти сугышта чакта гармуннарын сатып, онга алмаштырганнар. Унынчыда укыганда әтидән гармун сорыйм. Әти:

— Көй белмәгән башыңа гармун алыйммыни?—ди.

Авылга концерт килсә, анда яңа җыр башкарылса, клубтан таралганда Өлфәтләр, Нурзаһитләр, Гандилләр шул яңа көйне җырлап кайталар. Музыкантлар телендә бу «абсолютный слух» дип атала. Мин шакката идем. Нинди илаһи куә бирелгән бу кешеләргә. Ә мин кимсетелгән гарип кебек, әңгерәеп кайтып барам. Бер көйне күңелгә бикләр өчен мина атналар, айлар кирәк була иде.

Унынчыда укыганда булды бу хәл. Бишавылында Микайла җизни белән Әрҗүдә тутам үз өйләре белән тора, мин исә чыгарылыш сыйныфында укыганыма күрә, өч чакрым йөрмәс өчен, шуларда торам. Җизни авыл кибетендә эшли. Кибеткә җиз телле, ике рәтле матур гармуннар кайтты. Бәясе, ул замандагы акча белән, биш йөз дә дүрт сум. Укытучының уртача бер айлык хезмәт хакы. Минем гармунлы булырга теләгәнемне сизенеп, ахрысы, җизнәм шул гармуннарның берсен өйгә алып кайтты. Аттестатка әзерләнәсем дә бар, әмма мин гармунга чат ябыштым. Кунакка килгән әбием Мәгъсүмә минем гармун интектергәнемне күреп-ишетеп, бик күңелсез утырды. Шулай байтак утырганнан соң, әби:

— Улым, син көйләрне катыштырып уйныйсың. Син гади генә бер җыру көе, бер бию көе уйнарга өйрән. Мәҗлестә бер җырлата, бер биетә алсаң, сиңа шул җиткән! — диде.

Чыннан да, әбинең шушы дәресеннән соң мин «Аламагачлары»ның, «Бишле бию» көенең киртәсенә керә башладым.

1954 елны бетереп, 1955 елга чыгасы Яңа Ел бәйрәмендә җизни кунаклар җыйды, әти белән әни дә кунакка килде. Әти гармунны күрде. Дәшмәде. Мәҗлеснең кызган чагында җизни миңа ым какты, мин «Алмагачлары»н тартып җибәрдем. Ирләр җырны күтәреп алды. Аннан биюләр башланды. Мәҗлес азагында әти:

— Гармун синеке!— диде.

Шунда әти җизнигә гармун бәясен түләде. Шулай итеп, мин гармунлы булдым. Җәй көне инде, ягъни биш айдан соң мин яшьләрне клубта биетә, армиягә китүчеләрне «Шахта» көе белән озата башладым. Хәтта мин гармунчы сыныгы булып, агитбригада сәхнәсенә дә мендем. Без агитбригадага берләшеп, Солтангәрәй җизниләр белән авылларда бер атна йөргән идек. Хәзер мин аңлыйм, минем гармунчылыгымны кешеләр гафу иткәннәр, ярар инде, шулай быкырдатса да ярар, дигәннәрдер кебек. Әмма минем колак гармун авазына, җыр тавышларына битараф булудан туктады, мин һәр музыканы тыңлыйм, аңларга тырышам, кайсыларын отып алам, ялгыз калгач көйлим, моңаям. Шулай итеп, үҗәтлегем аркасында мин үземне көй аңламау кимчелегеннән коткарып калдым. Йөрәгемә, күңелемә татар моңы кереп ятты.

Яши-яши, тора-бара эчемдәге шул моң калдыклары хис булып әсәрләремә төшә башлады. Беренче гаиләдән аерылгач, мин байтак кына ялгыз яшәдем. Дүрт ягым кыйбла, үз белдегем белән яши бирәм. Чаллыдан әни еш килә. Минем буйдак, ялгыз гомеремне бизәргә тели. Мин өс-башымны да карамыйм, ни эләксә шуны киеп чыгам. Әнигә бу бик авыр тоелган, ахрысы:

— Улым, синең кебек кешеләр озын, күн пәлтә киеп йөри, син дә алып ки, биш йөз сум гына тора бит ул, — диде.

Әни тынычланып китсен, дип мин биш йөз сум акча тотып, Бет Базарына (Талкучка) киттем. Күн пәлтәләр сатып торучылар янына килдем. Бик матур, үземә килешеп тора торган дүрт йөз сумлык пәлтәне кидем. Тирә-юньдәгеләр:

— Ал, Батулла абый, сиңа суйган да каплаган!— диләр.

Шулчак базарның аргы башында кемдер тальян уйный башлады. Тәнем куырылып килде. Күңелем жирси, күңелем шул моңга алгысый башлады. Кемдер авыл көен нәкъ Хәснулла абый кебек итеп уйный. Пәлтәне салып хужасына тоттырдым да, мин хәзер киләм, дип гармун тавышы ишетелгән якка киттем. Гармун тоткан биш-алты кеше арасында берсе «Вараксин» уйный иде. Оста уйный. Күңелем тулды.

— Шәп гармун!— дип пышылдашалар янымда.

— Ничә сум?

— Йөз илле!

Мин аны-моны уйлап торыр халәттә түгел идем, акчамны санап, гармун хужасына тоттырдым да:

— Гармун минеке!— дидем.

Гармунны алып, сөенечемнән жылап, пәлтә сата торган урынга киттем. Мин таманлап караган пәлтәдән жилләр искән, аның каравы өч йөз сумга тач күнгә охшаш пәлтә бар, таман гына. Ул тиз ертыла торган ясалма күн булып чыкты, әмма килешә иде үземә. Мин шул ясалма пәлтәне киеп, гармунымны тотып әни янына кайттым.

Әнием сөенеп Чаллыга кайтып китте. Ләкин ул пәлтә озын гомерле булмады, бер-ике тапкыр кигәч, әтәч тиресе кебек юка, чыдамсыз «күн»е умырылып төште. Әрәмгә китмәде, мин аны бөгәрләп, машина утыргычына салдым.

Мин ике рәтле гармунда уйнарга шактый остарып беткән идем инде, әмма тальян тотканым булмады. Шул көнне үк мин гармунга ябыштым. Могжизалы кич иде ул. Әнине озатып кайткач, мин тальян гармун колына әвереләдем. Күңелдә, хәтердә онытылыр дәрәжәдә посып яткан, авылымда сабый чакта ишетелгән көй сыныклары, моң калдыклары уяна, жанлана башлады. Һәм мин Хөснулла абыйның серенә төшендем. Хөснулла абыйның бармаклары гармун телләре буйлап жинелчә генә йөгерә торган иде. Өске телләргә менеп житкәч, кирәкле тавышка тел калмый, шуңа күрә, Хөснулла абый бер октавага аскы рәтләргә төшеп китә торган булган. Көй өзелми, бармаклар төртелми. Мин Хөснулла абый уйнаганга якын итеп уйнау мөмкинлеген таптым. Ялгыз чакларымда, үзем уйнап, үзем жылап утыргалый башладым. Бу бәхет иде. Мин илаһи моңның серенә төшенә алырдай кеше идем. Мин үземнең моң ишетеп жылардай хисле кеше икәнемне аңладым. Ижат кешесе өчен моннан да олы ачышның, моннан да олы бәхетнең булуы мөмкинме!

Мин Сальерины тулысы белән аңладым.

Аллаһ биргән зәгыйфь сәләт оеткысын камилләштерү, сәләтлеләр дәрәжәсенә күтәрелү өчен үҗәтлек, тырышлык, каһарманлык кирәк икән.

Яши торгач, минем кулга тагын бик яхшы гармун килеп эләкте. Сөенеп туя алмыйм. Өздерә гармуным. Керәшен халык язучысы Гөргөри белән минем «Жигуле»гә утырып, Татарстан буйлый сәяхәткә чыктык. Әлмәт тарафына узып барышлый Шыкмайны да тау башыннан Гөргөригә күрсәтергә булдым. Без әле генә, таң алдыннан Чаллы Сабан туе мәхшәреннән чыккан идек.

— Гөргөри, Зәкия апа янына кермибез, Татарстанны әйләнеп чыккач кына без аңа керербез, — дидем.

Шыкмай йоклый, Зәкия апа да йокыдадыр. Бу тау башыннан һәр Сабан туе кичендә гармун уйныйлар иде, мин дә уйнарга булдым. Онытылган гадәтне янадан кайтарырга иде исәп. Гармунымны киереп тартып мин сугышка озату көен уйнадым.

— Мин уйнаган көй кешеләрнең төшенә керсен, яшь чакларын сагынып, жирсеп искә алсыннар. Каян ишетелә икән бу тылсым, дисеннәр.

Байтак уйнаганнан соң гармун моңын кешеләрнең төшендә калдырып, без Әлмәткә китеп бардык. Әлмәтне, Сарманны, Чаллысын, Минзәләсен әйләнеп, бер атнадан соң Шыкмайга, Зәкия апа йортына кайтып төштек. Зәкия апа үзенең «фирминний» ризыгын — каклаган казын чыгарып утыртты, табын мул. Мин һаман Зәкия апа авызыннан төшендә ишеткән тылсымлы гармун турындагы соклану сүзен көтәм. Шулай сөйләшеп утырганда Зәкия апа әйтеп куйды:

— Беркөнне бер тилесе төне буе тау башында гармун уйнады, халык арган, иртән эшкә чыгасы, ә ул ахмак гармун тартып, кешеләрнең йокысын өзә! Әле юньләп уйный белсә икән!

Керәшен халык шагыйре Гөргөри пошкырып көлеп жибәрде, авызындагы каклаган каз кисәге дә чыгып очты бугай. Минем ачу чыкты.

Ләкин мин Шыкмайга кайткач, Сабан туенда һәрвакыт гармун уйныйм. Халык тынлый. Гармунчы Хәниф Таймасов минем гармунга кызыгып карап тора, мин рәхәтләнеп аңа гармунымны сузам. Хәниф абый өздерә минем гармунда!

— Тальян тавышы ишетелмәгән Сабан туе туй түгел ул! — ди Хәниф абый.

Һәр елны мин авылыма Сабан туена гармунымны алып кайтам.

Миннән оста уйнаучылар уйнасын! Бура-Киртәнең Харис Әхмәдиев, Шыкмайның Хөснулла Маликов, Ашытның Әнәс абый кебек тальянда моңлы уйнаучыларны мин бик сирәк очраттым үз гомеремдә. Аларга гармун жәлке түгел, уйнасыннар!

Эшем бармаганда, эч пошканда яки куанычлы вакытларымда мин тальянымны алып, моңаеп утырам. Моңая-моңая күнелем тула, авыл искә төшә, шушы көйне уйнап сугышка, үлемгә киткән абзыйларның язмышы бәгырьне телгәли башлый, күздән яшь ага. Мин уйныйм да уйныйм. Шулай монланып утырганда бүлмәмә улым Байбулат килеп керде, битемнән аккан күз яшьләремне күргәч, ул аптырады, елмайды, аннан гажәпсенеп сорады:

— Әти, син ни өчен жылыйсың ул? — диде.

Мин гармунның тарихы, сугышта үлгәннәрнең фажигасе, тылда калганнарның әче язмышы турында сөйләдем, улым игътибар белән тыңлады. Мин тагын озату көен уйнарга тотындым. Байбулатның да күзе дымлы иде, ул тальян моңын, татар моңын, татар фажигасен аңлады кебек. Хәзер инде ул тальян тавышына битараф калмас, дим.

*Ахыры киләсе санда*

Гөлзадә
Бәйрәмова

# ИЛ КАДЕРЕН БЕЛЕР — ИЛСЕЗ КАЛГАН

*(Система корбаны булган әтием истәлегенә)*

I

**Татар авылының тамыры корый,**
**Гореф-гадәтләре югала.**
**Яңа буын!**
**Нигә битараф сез барчасына —**
**Ә сездән соң җирдә ни кала?**

**Оптимизация, имеш, глобальләшү —**
**Сүзләре үк ят бит безләргә.**
**Милләт булып җирдә яшим дисәң,**
**Үз юлыңны кирәк эзләргә!**

**Үз сүзләрен әйтә белсен икән**
**Түрәләргә гади халык та.**
**Иманаңны тартып алалмаслар —**
**Сатмас һәм сатылмас булсаң**
**Иманыңны олигархка!**

**Бер кап чәйгә, онга һәм ярмага**
**Алдадылар әүвәл халыкны.**
**Кибет киштәләрен бушаттылар,**
**Алып атып бәя-ярлыкны.**

**Кайгыртучан ата булып шулай,**
**Уйнадылар хаким-түрәләр.**
**«Җир — халыкка!» шигарен дә, әнә,**
**Кире яктан хәзер эләләр.**

**Инвесторлар, әти, каты куллы,**
**Сезнең ише генә түгелләр.**
**Сез халыкка диеп тырышкансыз,**
**Алар исә**
**Кесә ягын каера белерләр.**

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА – *шагыйрә; берничә китап авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Татар булса икән инвесторы,
Урыс, диләр, Мәскәү токымы.
Кабатлана икән җирдә тарих —
Алпавытлар торып утырды.

Мәскәү миллионерына нигә аңа
Синең авылыңның тарихы?
Корал белән түгел, акча белән,
Буйсындырды бүген халыкны.

II

Дөнья шулай татлысыннан бигрәк,
Ачыларын күбрәк ашата,
Падишаһ та ясый, мәхбүс-кол да,
Зинданнарга салып таптата.

... Ул елны да көннәр матур килә,
Күкрәп үсә ашлык-игеннәр.
Иген генәме соң! Муллык һәм бәрәкәт —
Уңышлардан башлар әйләнер!

Бизмән-үлчәүләрне көйләгәндә,
Оныттылыпмы әллә үткәнсең,
Бер уч ашлык җиткән синең башка —
Төрмә кошы булып киткәнсең.

Берәү сөенгәндә мул уңышка,
Берәү донос язган төн буе:
Симәнәгә, имеш, бик аз калган,
Ни чәчәрбез, диеп, бу елны?..

Илдә сугыш бара. Аның әле
Яше җитми, бераз кечерәк...
Донос язар өчен яшь кирәкми,
Җитә икән бары көнчелек.

Картлыгында ул да михнәт күрде,
Килә җәза — күпме илермә.
Бакыйлыкта очрашсагыз, әти,
Үтенеп сорыйм, зинһар, кул бирмә!

Юк, юк, әти, дөрес әйтмим бугай,
Кичерә алсаң, кичер, вакландым.
Тигезләде дөнья һәммәсен дә,
Синең исем күптән акланды.

Ә бит мине сиңа охшаган диләр,
Туры сүзле, ялган-риясыз...
Гадел булу сине мәхбүс итсә,
Ә мин калдым нигез-оясыз.

...Бер төш сөйлим әле, әти, сиңа:
Яна икән нигез-курабыз!..
Беркем килми ярдәм итешергә,
Тик икебез генә,
Бер-беребезгә карап торабыз.

Арлы-бирле чабам, оран салам:
«Эчегездә юктыр җаныгыз!»
Озак тормый яман хәбәр килде:
«Өегезне сүтеп атыгыз!»

Инвесторга, имеш, матур авыл кирәк —
Чүп-чарларсыз, ватык-җимерексез.
Шаһгалиләр табылыр һәр заманда,
Үз туганың булса игелексез.

III

«Туган якның җилләре дә назлы...»
Әллә үзем әйттем, әллә ишеттем.
Басып торам урам уртасында,
Кагарга, дип, кайсы ишекне.

Үз телемдә әгәр сәлам бирсәм,
Нинди телдә булыр җавабы?
Оныклары инде танымаслар,
Таныганнар — кая алары?

Чит кавемнәр хуҗа булып йөри
Татар авылының түрендә.
Әрмән дә бар, диләр, үзбәк, таҗигы да,
Чегәне дә хәтта күренә.

Киереп ачып читән-капкаларны,
Мал кумыйлар хәзер көтүгә.
Шәһәр дисәң — шәһәр түгел үзе,
Авыл дисәң — бара бетүгә.

Җәйге хозурлыкка хозурланып,
Кармак салып елга-күлләрдә —
Утырулар бүген чикләнелгән
Һәр рәхәткә кирәк түләргә.

И табигать!
Аллаһ биргән байлык. —
Суың-җирең, урман-кырларың.
Үзләштерер өчен сине адәм
Нинди хилафлыклар кылмады!

Буе җитсә күкнең катларына
Хуҗа булыр иде анда да.
Җылы, яктылыгы, нуры өчен
Салым салыр иде
Кояшына, хәтта Айга да!

IV

... Ялгыз бер йорт тора чат башында,
Тәрәзләргә пәрдә тартмаган.
Капка келәләре төшерелгән,
Монда бүген беркем кайтмаган...

Керү сукмакларын әрем баскан,
Аралыймын аны як-якка.
Тигәнәге сарыла бәгыремә,
Әрем исе әрни йөрәктә.

«Иле кайда — иблис шунда» әйтеме
Гаиләне дә читләп үтмәгән.
Кемдер — корсак колы, икенчесе
Матди байлык белән чикләнгән.

Татар авылы. Күпме нигезләрнең
Тамырына балта чабыла.
Капка-коймаларын җимереп атар
Кешесе дә шундук табыла.

Һәр нәселнең була дәвамчысы,
Ышанычын аклый алырлык.
Туган нигезләрен сакламаган,
Идел-Йортны яклый алырмы?!

V

«Урманнарга керсәң, сызгырып кер,
Уянмаган кошлар калмасын...»
— Сызгыр әле, кызым, яңгыратып бер,
Их, малай булып калган туасың! —

Дия идең миңа һәрчак шулай,
Урманнарда печән чапканда;
Йөк өстенә йөгереп менеп китеп,
Бастырыкка аркан такканда...

Син бер куллы, ә мин яшь кыз бала,
Сабыйлыгы чыгып бетмәгән.
Сәнәк-тырмаларым онытыла
Җир җиләге күренеп киткәндә.

Туры да гына атны туры тотып,
Дилбегәне урап кулыңа,
Тормыш йөген салып иңнәреңә,
Алып чыктың безне хак юлга.

Ата кадерен — ата булган белер,
Йорт кадерен белер — йорт корган,
Ил кадерен белер — илсез калган,
Җир кадерен белер — җирсегән.

Тел кадерен белер Ватаныннан
Кимсетелеп читкә этелгән.
Сүзем дога булсын,
Туган туфрак өчен
Шәһит киткән газиз әтиләр!

***Редакциядән:***

*Озак еллар журналда эшләгән каләмдәшебез бу айда үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

Хәсән
Сарьян

# ЗӘҢГӘР КҮЛ САГЫШЫ

**(Төнге каравылчы)**

1

Кыштан бирле быел җәй Кырымга, дингез буена китәрбез дип, алдан ук кычкырып килдек-килдек тә, көне житкәч кенә кире уйлап, үзебезнең Башкортстанга — Илешкә генә кайтырга булдык. Дингез дип, кояшына кызынам дип, мыжгып торган галәм эченә кысылып барып ятканчы, авылда, ичмасам, берүземә бер Агыйдел! Түшәктәй комында теләсәң буй, теләмәсәң аркылы ят — берәү дә синең башыңнан атлап йөрми.

Кайтуны шулай кичтән хәл иттек тә, таңнан торып мин билетка киттем. Беренче, икенче класс дип авыз ачасы да түгел, — ике-өч көн элек сатылып беткән, — өченче классына да чак эләкте: соңгы ике билетны мин алдым.

Шул көнне үк җыенып, сәгать өчкә пароходка төштек. Халык утырган иде инде, без кергәндә каютадагы сигез урынның алтысын биләп алганнар, безгә ишек катындагы югары сәкеләр генә калган иде. Кереп унга-сулга күз аткан арада, аскы буйда утырган яшь кенә ике егет, безне генә көтеп торган шикелле, сикереп торып, урын бирделәр.

— Икесен дә алыгыз, абый.

Каршы як сәкедә яткан ир дә:

— Алыгыз, алыгыз. Малайлар яшь әле, өстә дә ятарлар, — диде.

Бу аларның әтиләре иде булса кирәк. Ул инде урап куелган матрасны өстән алып, шул көе генә баш астына салган да, берүзе бер сәке булып сузылып яткан, аяклары хәтта сәкедән дә артып киткән иде. Ул безне шулай, чалкан яткан килеш, бер генә бөртек җиребезне дә калдырмыйча күзеннән үткәрә башлады. Аның тишеп каравын мин хәтта арка миләрем белән сизеп тордым.

Каютада тагын бер әби белән бер кыз бала да бар иде кебек. Ләкин мин аларның берсенә дә игътибар итмәдем. Без әйберләрне урнаштырдык та икенче катның палубасына мендек. Анда — китүчеләр, ә дебаркадерга озатучылар тулган иде. Пыяла вокзал каршындагы причалларга су өстеннән таудай калкып менгән дизель-электроходлар килеп туктаган. Безнең пароход кына алар янында бөтенләй бәләкәй булып, суга ябышып тора, кергән-чыккан кешеләре дә ничектер аска — подвалга төшеп китәләр сыман иде.

— Теге кешегә ныклап карадыңмы син? — диде хатын.

— Нинди кешегә?

— Каютадагы сон...

Мин ул кешене оныткан идем инде.

— Ике аягы да протез бит, — диде хатын. — Әнә теге кыз да аныкы, ахры. — Ул баш изәгән якка әйләнеп карадым. Бездән биш-алты кеше аркылы, бая безгә урын биргән ике егет уртасында сигез-тугыз яшьлек бер кызкай басып тора иде.

Мин сүз катмадым, карадым да куйдым. Үземә бер дөнья ачкандай, исем китеп, куласа төбеннән сызгырып чыккан пар тавышын тынлый идем, кабат шуңа бирелдем.

Ул арада китәр вакыт та җитте. Капитан үз урынына менеп басты. Дебаркадердагы карт матрос, берәм-берәм чишеп, авыр трапларны сөйрәп алды. Аннары йөгерә-атлый барып, борындагы чуен тумбадан сүс арканны ычкындырып җибәрде. Куласа бер-ике канаты белән генә артка ишеп, тигез су өстен болгатып алды да туктады. Пароход, этеп җибәргәндәй, борын ягы белән дебаркадердан аерыла башлады. Шуннан соң гына койрыкны чиштеләр. Пароход без басып торган якка бик нык кыегаеп, әкрен генә кузгалып китте. Моннан да, тегеннән дә кулдыр, яулыктыр селки башладылар. Безнең балалар берсе читтә, берсе ялда — безне генә беркем озатмый иде. Мин халыктан күзне алып Казаныма карадым: кояшка чагылып, нурланып яткан өйләр, сарайлар өстендә башларын горур чөеп үрә каткан чиркәү манаралары йөзә; шулар янында бер Сөембикә манарасы гына, монсу йөз белән кыегая төшеп, түзем аналарыбыз шикелле, тын гына, берүзе бер читтә басып тора. И Казан, Казан... Ярый әле җан кебек күргән син бар...

Безнең пароход, аварга житешеп, дулкын юлына аркылы куелган биек дамбаның теге ягына борылды. Тиздән тураеп, Агыйделенә кайтып житәргә ашкынгандай кызулап, Идел эченә таба юл алды. Казан икенче якка күчте. Без ул якка чыкмадык: ул яктан инде барыбер Казан күренми — бар нәрсәне стенадай дамба каплап, аның өстеннән тик вокзал түбәсе белән порт краннары гына күренсә күренә иде.

Без каютага төштек. Әле берсе дә тыштан кермәгән, теге кеше генә һаман сәкесендә ята иде.

— Калдымы Казан? — диде ул.

— Калды... — дидем мин. — Ә сез нигә чыкмадыгыз соң?

— Аяклар бетте, абый, аяклар! Чие чыкты Казанда йөреп. Көчкә кереп егылдым.

Кинәт карауданмы, йөрәгем жу итеп китте: аның бая гына сәкедән артып торган ике аягы берьюлы, кисеп ташлагандай, кинәт юкка чыккан, ә стена буенда тимерләрен ялтыратып ике протез сөялеп тора иде. Шунда мин үзем дә сизмәстән аның йөзенә карадым — кисәк борылудан хәтта муен сөякләрем шыртлап куйды. Мин ана әле ныклап караган кеше түгел, күзләрем бая да, жинел болыт күләгәседәй, шуып кына үткән иде. Инде ныклап карадым. Аның йөзе дә, юк аяклары да мина ничектер бик таныш тоелды. Тик каян таныш, ничек таныш? Шулай дип уйлавым булды — кылт итеп исемә дә төште. Тукта, бу бит... бу бит...

— Сез Башкортстаннан түгелме соң?..

— Әйе, Башкортстаннан, — диде ул. Жәлт кенә башын күтәреп мина текәлде.

— Зәңгәр Күлдән бит?

— Әйе, Зәңгәр Күлдән.

Яткан жиреннән кубып торды да, кул чугыдай гына калган ике балтыр киселдеген аяктай асылындырып, сәкесенә утырды. Ә күзләре баягы ише генә түгел — буйдан-буйга ярып төшкәндәй иде.

— Үтер, танымыйм, абый, — диде ул.

— Танымыйсыңдыр шул. Мин сездә бер генә кич кунып чыккан идем. Байтак ел инде.

Ул иркен сулап җибәрде.

— Командировкага-мазарга килгән идегезмени?

— Шулайрак. Сезнең авылда безнең студентлар эшли иде. Мин шуларның эшен карарга барган идем.

— Булгандыр, — диде ул. Бөтенләй тынычланып, арткарак шуыша биреп утырды. — Студенты да, башкасы да... күп булды инде бездә. Барысын да ничек танып бетерәсең.

— Шулай... — дидем мин. — Барысын да танып бетереп булмый...

Күңелемә, иртә таңдай ачылып, моннан күп еллар элек булып үткән бер көн килеп төште.

## 2

Әйе, төп-төгәл ун ел гомер үткән икән шул. Тик әле июль, ул вакытта сентябрь иде. Мин үзем дә Уфада тора идем.

Шулай беркөн мине ректор чакырып алды да бер колхозда эшләп яткан студентлар янына барып кайтырга кирәклеген әйтте. Ничегрәк эшлиләр, ничегрәк ашаталар, колхоз канәгатьме, — гомумән, барысын да белеп, ярдәм кирәк булса, ярдәм итеп кайтырга кирәк иде.

Иртәгә чыгасы газетада минем бер теоретик мәкалә басылырга тиеш иде, шуны укып китим инде дип, институттан туры редакция ягына борылдым. Барсам, фән һәм культура бүлегендә безнең студент Фәйрушин утыра. Мине күрү белән торып басты.

— Исәнмесез, абый!

— Сез нишләп монда, Фәйрушин? — дидем мин.

— Минә шигырь бирергә генә кайткан идем, абый. Мин председательнең үзеннән сорап кайттым, бүген үк китәм.

Алар курсы мин барасы колхозда эшли икән. Колхозы да ерак түгел — су транспорты белән ике генә сәгатьлек юл икән. Фәйрушин миңа рейсларына кадәр әйтте.

Иртәгесен мин унбердәге рейска гына өлгердем.

Мәнә мин Агыйдел белән өскә күтәреләм. Дизель моторы талгын гына тибрәтеп, йокы китергеч тавыш белән гүләп бара. Салонда һәммәсе авыл халкы. Идән тулы сөт-катыктан бушаган чиләк, бидон. Аларга да, эреле-ваклы капчыкларга да булкидыр, сушкидыр тутырганнар. Пристань саен чиләкләр кимеп, салон бушый бара. Ниһаять, Уфадан чыкканга ике сәгать үтеме-юкмы, безнең елга трамвае мин төшәсе пристаньга да барып житте — кызыл балчыклы текә яр читенә борынын төртеп туктады. Халыкның күбесе шушында төште. Чиләкләрен көянтәләп, капчыкларын биштәрләп алган хатын-кыз, ярга менү белән туктап та тормыйча, иркендә кычкырып сөйләшә-көлешә авыл ягына элдертте, артларыннан куып та житәрлек түгел.

Яр башында, жигүле күк алаша янында, күзлекләрен елтыратып Фәйрушин басып тора иде. Минем аптыраулы карашымны сизеп, җавап бирергә ашыкты:

— Сезне каршы алырга төштем, абый. Мин бая да төшкән идем әле.

— Шулай бушка ат йөртәләрмени?

— Һәй, атның кадере юк монда, абый... Гомумән, колхоз турында тетеп мәкалә язарга була. Әнә бит студент эшли — халык шәһәргә йөри, катык сата...

— Анысы безнең эш түгел, — дидем мин. Туктап, тирә-ягыма күз салдым.

Безнең аста көндезге кояшка жылынып, иркәләнеп Агыйдел ага. Җәй коры килү сәбәпле, ул быел бик нык кайткан, саеккан, ләкин суы, катер артыннан яр читләп дулкын йөгереп үтүгә карамастан, аяз күк йөзедәй саф,

чиста иде. Каршы якта куе урман каплаган тезмә таулар сузылып киткән. Агачларга инде саргылт төс кунган, тик урыны-урыны белән генә карасу яшеллек сакланып, алары йә юкә, йә имән булырга тиеш иде. Таулар — арьякта, көнчыгышта. Ә бу якта — тигезлек, ялан, ялан. Ул тигезлек төньяк-көнбатышта рәшәләнеп торган икенче бер тауга тоташып бетә. Анысы — Уфа тавы. Бөтен бер шәһәрне һәр яктан да күренер биеклеккә күтәргән тау, күксел болытка охшап, бик ерак офыкта кабарып тора иде.

— Аяз кичләрен утлары да җемелдәп күренә, — диде Фәйрушин.

Без кузгалдык. Күк алаша әкрен генә юыртып бара. Ләкин өч-дүрт йөз метр да китмәгәнбездер, куе таллык, камышлык белән каймаланган бик зур күлгә килеп чыктык. Аның бер башы күренеп тора, икенче башы борылып күздән югала иде.

— Зәңгәр Күл шушы инде, — диде Фәйрушин.

Аргы якта, күл буенда, такта, шифер, калай түбәләре белән кояшка чагылып, зур гына бер авыл җәйрәп ята. Ләкин мине күлнең өстендә дә, читендә дә бер көймә дә юклыгы гаҗәпләндерде. Кызык: үрелеп буй җитәр авылга барыр өчен күпме урарга кирәк! Без уңга борылдык та күлнең карт өянкеләр үсеп утырган башына юнәлдек. Катыкчылар инде җәяүләп тә байтак җир киткән, алар моннан җилгә җилфердәп кенә баралар кебек күренәләр. Ниһаять, без дә, бер чакрым араны ике-өч чакрымга озайтып, авылга килеп кердек. Фәйрушин мине туп-туры идарәгә алып китте. Председатель белән таныштырды. Председатель утызменченең берсе булып Уфаның үзеннән килеп эшли икән. Озын буйлы, карап торуга ук әзмәвердәй таза, чибәр кеше. Яшькә дә кырык тирәсендә генә булса булыр. Ул үзенең студентлардан канәгать икәнлеген әйтте.

— Студент нәрсә — килә дә китә. Аның менә мондагылары... — Ул әйтеп бетермәде. — Ярый, йөреп кайтыгыз, алайса, — дип, мине Фәйрушинга тапшырды.

Фәйрушин монда бөтенләй үз кешегә әйләнгән, монысына Гыйльман абзый, тегесенә Сирай абзый дип кенә дәшә. Безнең күк алаша, тугарылмаган килеш, печән ашап тора иде. Без утырдык та басуга киттек. Студентның һәммәсе бәрәңгедә. Колхозның бәрәңге җире күп — монда бер группа, тегендә бер группа, ат белән йөреп тә көн кырда, студентлар янында үтте. Бары да эштә иде.

Кояш «куянга атланып» баюга киткәндә генә, без идарәгә кайттык. Председатель белән тагы бер сөйләшим дисәм — районга киткән булып чыкты. Инде мина да кичке рейс белән кайтып китәргә мөмкин иде. Ләкин Фәйрушин да, идарәдәгеләр дә калырга кыстадылар: бүген студентлар концерт куя, карап китегез инде, диделәр. Кайтып кундың ни дә кунып кайттың ни — барыбер түгелмени дип, мин калырга булдым. Без идарәдә сөйләшеп утырганда, Фәйрушин каядыр югалып торды — квартирына барып килгән икән.

— Булды, — диде ул. — «Профессор» белән сөйләштем.

— Нинди профессор? — дидем мин, аптырап.

— Әй-лә, безнең квартир хуҗасын шулай диләр. Әйдәгез, абый, концертка чаклы тамак ялгап, ял итеп алырсыз.

Без идарә турындагы киң тыкрыктан икенче урамга чыктык та, борылгач байтак китеп, җилкапкалы бер йортка барып кердек. Өч ягында икешәр тәрәзә, дүртенче ягына такта чолан сугылган шифер түбәле уртакул бер өй иде бу. Каралты-курасы тәзек. Мәгәр күзгә иң ташланганы — ишегалдының юып-ялап куйгандай чисталыгы булды. Без кергәндә бер ир япма лапас астында тимерле арбага тимеркүк ат җигеп тора иде.

— Мин әйткән абый шушы инде, — диде ана Фәйрушин. — Безнең укытучы.

— Зур кеше алып килгәнсен икән, энем, рәхмәт, — диде ул Фәйрушинга. — Барыгыз, өйгә керегез, монда өстегез пычраныр-нитәр.

— Мондый ишегалдында ятып аунасаң да пычранмас, — дидем мин.

Ул көлде.

— Төнге каравылда йөргәч — көндез эш юк. Китап укыйм да ишегалды себерәм.

Без өйгә кереп киттек.

— Шул инде «профессор», — диде Фәйрушин. — Укымаган китабы юк. Әллә ниләр белә, сораша китсә, җавап биреп кенә бетермәле түгел. Апа гына бераз ни... кара.

Ишекне ачу белән, уң куллагы зур мичтән эссе катнаш яна пешкән ипи исе килеп бәрелде. Мин чишенеп түргә уздым. Урам яктагы түр почмак белән тәрәзә арасы идәннән түшәмгә кадәр китап белән тулган иде. Моны күргәч, күнелемә мич җылысыннан да болайрак җылы килеп кунды. Безнең арттан ук диярлек хуҗа үзе дә керде. Уң кулында кәкре башлы таяк, ә протез аяклары атлаган саен шыгырдап куя иде.

— Самавырны алып чык әле, энем, — диде ул Фәйрушинга. — Әйдә, хуҗа бул.

Фәйрушин шаулап торган иске самавырны өстәлгә китереп утыртты. Хуҗа кучкардан алып яна икмәк кисте. Бал, май өстәлдә иде инде. Без чәйгә утырдык.

— Аяклар сугышта калдымы? — дидем мин.

— Сугышта, — диде ул. — Кырык бишенче елның февралендә Курляндиядә калдырдым. Эре калибрлы пуля белән чәпәделәр. Хуҗа Насретдин әйтмешли, мин аякны биргәч, сугышы да бетте.

— Үзегез ничәнче елгы соң?

— Егерме алтынчы мин.

— Сугыш сезгә дә нык эләкте шул.

— Эләкте! Ярый әле, контузияле булса да, баш исән кайтты.

— Шулай. Минем энекәш тә әнә егерме алтынчы елгы иде. Япон фронтына китәбез дигән хаты гына килеп калды. Ә мин үзем менә, сугышның башыннан азагына кадәр йөреп тә, исән калдым.

— Андыйлар да булды.

— Исемегез кем соң әле сезнең, энем?

— Хәнәфи булам мин, абый.

Шулчак, тышкы күтәрмәдән үк дөбердәп, өйгә ике кара малай чабып керде. Берсеннән-берсе уздырып:

— Әни кайта!.. Әни кайта!.. — диештеләр. Аннары киемнәрен унга-сулга атып, чишенеп ташладылар.

— Йөриләр туңып-күгәреп, — диде Хәнәфи. — Йә, кунак абыегыз белән күрешмисез дәмени?

Зурысы, оялып кына:

— Исәнмесез... — диде. Ана бер җиде-сигез, кечесенә дүрт-биш яшьләр иде.

— Кая соң әниегез? — диде Хәнәфи. — Кайта дигән идегез бит.

Шул вакыт, ишек тулып, зифа озын буйлы, кара янып торган тут йөзле, зур кара күзле бер ханым килеп керде. Ул кергәч, аяксыз ире генә түгел — дүрт санибыз төгәл мин дә, озын буйлы япь-яшь студент Фәйрушин да ничектер бәләкәйләнеп калдык. Мин үзем алай беренче күргән кешегә, бигрәк тә хатын-кызга, туры карый алмый идем, әмма бу юлы онытылып аңа текәлгәнмен, билгеле, озак түгел; бер, күп булса, ике секунд. Сизгәч, уңайсызланып, күземне читкә алдым.

Хәнәфи аңа минем кем икәнлегемне әйтте. Ул минем белән елмаеп кына

исәнләште дә, өстеннән салып, түрдәге комод янына китте, күн сумкасын шуның өстенә куйды. Анда китап ята иде.

— Ялыктым инде шушы китапларыгыздан! — дип, малае алдына алып ташлады.

— Ипләп кенә шүрлеккә куеп булмыймыни соң шуны? — диде ана Хәнәфи.

— Булмый. Ятмасын кирәк-кирәкмәгән жирдә.

Анын матурлыгы минем күз алдында кимеде дә куйды.

— Нишләп сонладың? — диде ана Хәнәфи.

— Магазинны бикләп кенә торганда, бер колонна машина килеп туктады. Шоферлары папиростыр, аракыдыр алды.

Хәнәфи башкача төпченмәде.

— Ярый, мина китәргә вакыт, — дип, табыннан кузгалды. Кире мина карап: — Исәр кеше кебек сорыйм әле: сез кайчан китәсез, абый? — диде.

— Иртәнге рейс белән.

— Нигә бик тиз?

— Башкача вакыт юк, тегендә дә эш.

— Кызганыч, — диде ул. — Сез галим кешедер, тарихчы да булгач, сөйләшәсе, сораштырасы сүзләр бар иде.

Юкса авылга әллә кемнәр килә — барысына да план кирәк, куарга кирәк, аларга синең тарихың-ниең бармы да юкмы. Жанга әүкат алырдай кеше дә юк...

Мин аны озата чыктым. Тимеркүк ат, печән ашавыннан туктап, тик кенә карап тора иде. Хәнәфи ана су эчерде дә, аркалыгын күтәреп, утырырга жайлап, лапас астыннан алып чыкты.

— Ярый, исән булып торыгыз инде, абый. Икенче шулай безнең якларга килеп чыксагыз, туры үзебезгә төшегез — инде белдегез.

Ул капканы үзе ачып, үзе ябып чыгып китте. Көзге такыр юлдан келтерәп барган арба тавышы басу ягына китеп югалды. Мин өйгә кердем.

Хәнәфи хатыны, ире өчен гафу үтенгәндәй, сүз башлады:

— Әллә минем дивана «профессор» сезне дә ялкытып алдымы? Берәр зур кеше күрсә, чат ябыша. Ул кешенең сөйләшәсе киләме, юкмы — аны белми. Китап укый-укый шулай хыялыйга әйләнеп бетте инде. Берәү булса сыер алыр иде. Ә бу — барлы-юклы пенсиясеннән китап жыя. Башың каравылдан чыкмагач, китап укудан ни файда? Аны безнең укытучылар да укымый — берсендә бер китап юк...

— Әллә бара торабызмы? — дидем мин Фәйрушинга.

— Клубкамы? — диде Хәнәфи хатыны. — Һи-и, әле-е! Жыелыр бу вакытта безнең Уфа катыкчылары, көт! Әле анын клубы да ачык түгел.

— Апа дөрес әйтә, — диде Фәйрушин.

Мин Хәнәфинең китапларын карарга утырдым. Кайда нәрсә күргән, ни очраткан — шуны жыя барган — әлифбадан алып «Зур энциклопедия»нең аерым-аерым томнарына хәтле бар иде.

Мин китап караган арада, Хәнәфиләрдә торган тагы ике студент эштән кайтып керде. Тиз-тиз юынып, өсләрен алыштырып алдылар: икесе дә концертка катнашачак икән. Аларның берсе бик уенчак холыклы, карачибәр башкорт егете иде.

— Бүген сылу апаебызны, агаем күрмәгәндә, култыклап кына алып бараек әле клубка, — дип тыкылдап китте.

Ханым ана тамчы да ачуланмыйча:

— И апаем, апаем! Тел бистәсе! — диде. Аннары мина дәште: — Егетләрегез бик телгә беткән, абый. Укуда да шулаймы?..

Минем мондый уен сүзгә кысыласым килми иде, китап укыган булып, ишетмәмешкә салыштым. Сәгать тугыз тулып килә иде инде, бераздан торып, Фәйрушинга әйттем:

— Кузгалыйк, булмаса. Иртә булса, күл буеннан урарбыз.

Клубтан без бишәү бергә кайттык. Башкорт егете, кайтып керү белән, чишенеп тә тормастан:

— Бая да туйганчы чәй эчә алмадым, — дип, самавыр янартып җибәрде.

Хуҗа ханым:

— Сез бүген, егетләр, абыегыз да булгач, өйдә генә ятарсыз инде, чоланга мин үзем чыгармын, — дип, аларга урынны идәннән күрсәтте. Мина үзләре караватына җәеп бирде. Балалары ишек төбендәге такта караватта йоклый иде инде. Чәйдән соң егетләрнең өчесе дә мич казнасына башларын куеп, идәнгә сузылдылар. Хуҗа хатын утларны сүндереп, чоланга чыгып китте. Көн буе бәрәңге казып, бәрәңге чыгарып эт булган, сәхнәдә дә янып биегән ике егет мендәргә баш төртү белән сеңделәр генә. Алар артыннан — эшләми генә көн уздырган, сәхнәдә дә шигырь генә сөйләп төшкән Фәйрушин да гырлап йокыга китте. Дөнья тынып, өй эченә төн карасы кереп тулды. Күңелне ямансу бушлык биләп алды. Мин, тырышып, кичә генә урамында йөргән шаулы шәһәрне күз алдыма китереп карыйм. Шәһәре килә, шау-шуы килми, кешеләре дә, машиналары да тавышсыз кинодагы кебек телсез-өнсез иде. Тын авыл төнендә колак та, зиһен дә рәхәтләнеп ял итә башлады...

Ике баланың кайсыдыр өзек-өзек кычкырып җибәргән тавышка уянып, күзләремне ачтым. Төн инде авышкан. Ләкин һаман караңгы иде әле. Малайларның берсе шап та шоп бәргәләнә. Әниләре калын өй ишеген ябып чыгып киткән иде, ишетми торгандыр дип уйладым. Ә бала һаман бәргәләнә. Ул ара да булмады, «су» дип әйткән төсле тоелды. Тукта инде, болай ярамый дип, урынымнан тордым. Егетләргә басмас өчен, аяк очларыннан гына үтеп, кухня ягына чыктым. Мич авызына караган тәрәзә буенда өстәл, ә аның өстендә кичтән түгелмәгән самавыр утыра иде. Чынаяк табып, борынынан су агыздым. Шулчак ничектер өйалды ишеге ачылып ябылгандай итте. Үзем дә сизмәстән үрелеп тышка карасам — тәрәзә буеннан ялт итеп ике аягы да исән бер ир үтеп китте. Әле таң сызылып беленә генә башлаган иде, шулай да мин нык шәйләдем: ул көндез күргән председательдәй бик таза, әзмәвердәй кеше иде. Самавырдан аккан су, чынаяк тулып, өстәл өстеннән тама башлагач кына айнып киттем. Су сораган малай тынычлап, стена ягына әйләнеп яткан. Өсләрен генә әйбәтләп яптым да, шырпы сызып сәгатькә карадым. Биш тулмаган иде әле. Без алтыда чыгып китәргә тиеш идек, алты тулсын инде дип, урыныма менеп яттым, йокы качкан иде инде. Аның урынына берсенә-берсе ябышмаган сәер, унайсыз уйлар килеп тулды. Мин күзләремне ачкан килеш караңгы түшәмгә карап ятам. Аннары китап киштәләре ягына борылдым. Китаплар әле үзләре күренми, шулай да мин беләм: анда ике сыерлык китап бар. Тик Хәнәфи сыерга акча җыймаган — китап җыйган. Бу йортта ул гына китап укый. Ә нигә укый?.. Әнә бит хатыны китап укымыйча да яши. Сату итеп кайтты да...

Теге малай тагы сискәнеп кычкырып җибәрде. Әтиләре каравылда. Ул көндез китапларыннан яктылык ала да, шул яктылык белән төнге каравылга китә, тисәләр-тимәсәләр дә, колхоз милкен каравыллый. Ә монда... Ә син соң, Хәнәфи, сугыш туктасын өчен генә унтугыз яшьтә ике аягыңны да биреп кайткан каравылчы энем, өеңдәге хәлләрне үзең беләсеңме соң? Әллә китап укуыңны гына беләсеңме?..

Стена сәгатьләре кәккүкле икән, суга-суга биш кабат кычкырды. Мин артык ята алмадым, торып, Фәйрушинны уяттым.

— Әйдә, энем, кузгалыйк...

Фәйрушин житез егет булып, әкрен йөрүне белми иде — шатыр-шотыр юынып, киенеп тә алды. Ишектән хужа ханым килеп керде.

— Саф һава килешкән миңа: бигрәк каты йоклаганмын бүген, — диде ул. — Кая, әллә чәй дә эчми китәсезме?

— Рәхмәт, чәйләп тора алмыйбыз, — дидем мин.

Тышта ярыйсы ук салкын иде. Җиргә юка гына кырау төшкән. Чыгу белән күзгә суык жил бәреп алды. Сәгать алты тулган иде инде, ләкин Башкортстанның бу якларында сәгать алтыда әле караңгы була. Без сөйләшми генә күл урамына төштек, аннан, сызылып кына атып килгән таң ягына карап, Агыйдел буена юнәлдек. Уфага сөт сатарга баручылар да кузгалган иде инде: алдан да, арттан да чиләк-көянтә күтәргәннәр бара иде. «Бу халыкның һәркайсы сыер тота инде, — дип уйладым мин. — Тик шуларның күпмесе китап укый икән?..» Күлне урап үткәч, соңгы кабат авылга әйләнеп карадым: көнбатыш караңгылыгында әйле-шәйле генә күренгән тын авыл калды. Тик тын идеме соң ул?..

### 3

Безнең пароход Кама Тамагына җитеп килә иде инде. Кеше кулы ясаган чын диңгезне тамаша кылыр өчен, мин икенче катның палубасына мендем. Кояш Иделнең уң ягындагы аксыл таулар тезмәсе өстенә төшеп бара. Коры җирдә хәзер тын алгысыз бөркүдер. Ә су өстендә җиләс. Көнбатыштан йомшак кына җил исеп куя, һавасы да җинелчә дым тартып йомшарган — биткә ягылып китүенә кадәр бүтәнчә иде. Түбәнәеп килгән кояшның алтынсу нурлары, ялтырап яткан озын юл булып, безнең пароходка хәтле сузылып төшкән, су өсте шул буйдан гына икегә аерылып киткән төсле иде. Шәрә таулар, Идел аккан унайга борылып, артка чиккән саен, кояш юлы озыная бара, озыная бара... Идел чикләре дә, әллә кайда күздән югалып, тигез офык сызыгына түгелеп тоташкан иде.

Мин, утырыр җай чамалап, тирә-ягыма каранып алдым. Капитан мостигына менә торган баскыч төбендә ялгызы гына Хәнәфи утыра иде. Палубаның ул өлеше икеләтә кин. Хәнәфи урындыгын тимер челтәр буена тарткан да, үтеп-сүтеп йөрүчеләргә аркасын куеп, Иделнең түбән агымына текәлгән. Янына мин килеп баскач кына, күтәрелеп карады.

— Сез дә чыктыгызмы, абый?

— Чыктым әле, — дидем мин. Бер урындык алып янына утырдым.

Без инде икәүләшеп Идел өстенә текәлдек. Кургашындай авыр су өсте офыкка киткән саен, сөзәкләнеп менгән тау кебек, безнең пароходтан да биек калку булып ята иде.

Күз алдыма бүгенгедәй янарып Хәнәфиләрдә үткәргән төн, аның зифа буйлы хатыны килеп басканнан бирле, мине борчып-тынгысызлап, шушы тоташ диңгез кебек, юлдашым Хәнәфи язмышы биләп алды. Минем әле бервакытта да кеше язмышы белән бу тикле янып кызыксынганым юк иде. Көн артыннан көн кичеп, гомерең эш белән, мәшәкать белән чабып кына үткән бер заманда кеше язмышын каян белеп бетермәк кирәк?! Без бая сөйләшә алмадык. Сүзебез, өр-янадан танышып, «Кая бардыгыз?», «Кая барасыз?» дип сорашудан ары китмәде. Аннары, Хәнәфи минем хатын алдында ничектер кыенсынган, тартынган шикелләрәк иде. Соныннан шаулашып балалары килеп керде дә ашарга утырдылар. Пароход белән поездда шулай бит: кузгалып китү белән халык ашарга керешә. Алардан соң без дә, өсләр алмаштырып, чәйләр әзерләп, бераз капкалап алдык. Казаннан Кама Тамагы ерак түгел — дүрт сәгатьлек юл шулай үтте дә китте. Әле менә ул да ялгыз, мин дә ялгыз, — сөйләшеп утырыр өчен моннан да унай форсат

килерме? Минем хатын бүген чыкмаячак: бик тәпләнеп, тамырланып, китап укырга ятты. Ә Хәнәфинен балаларын әйтәсе дә юк — аларнын үз гаме, үз дөньясы. Инде жаен табып сүз генә башлый белергә кирәк.

— Ни рәхәтләрдә яшәү сон, Хәнәфи энем? Тазалыкмы? Тормышлар иминме?

— Имин генә, абый. Рәхмәт, имин генә. Картларча әйтсәк, сезнең хәерфатихадабыз.

— Киленкәй һаман шул... магазинында эшлиме? Һаман шулай чибәрме?..

Хәнәфием жавапны бик озак көттереп бирде.

— Сез элекке хатыным Гөлбәдәрне әйтәсездер инде, абый... — Ул көрсенеп куйды; көрсенүеннән сагыш бөркелеп чыкты. — Әйе, чибәрлеге күпләргә житәрлек иде... Тик юк инде ул, абый... Юк...

— Ничек юк?! Кем юк? Әллә... ниме?

Хәнәфи баягыча, су белән күк тоташкан беленер-беленмәс сызыкка текәлгән көе, шул сызыкта гомеренен дә Идел суыдай агып киткән бер өлешен күреп торгандай, сүз башлады:

— Менә әле мин сез чыкканда гына, шушы дингезгә карап, әлләниләр уйлап утыра идем. Монда безнен дә Агыйдел суы бар бит! Ләкин кайда ул хәзер? Гөлбәдәр дә әнә шулай юкка чыкты. Улмы, минме — кайдадыр ялгыштык без. Шушы кадәр дәрьядан Агыйдел суын аерып алып булмаган шикелле, кайвакыт мин дә кайда кем ялгышканлыгын белми аптырыйм. Кем сөйләсә, шуныкы дөрес, ди бит безнең халык.

— Ни булды сон? Сөйләгез. Юл озын, — дидем мин.

— Алайса, тынлагыз. Сез инде — үзебезнең Уфа кешесе. Яшегез белән дә, гыйлемегез белән дә — зур кеше, гаеп итмәссез. Гөлбәдәр дә һәрвакыт: «Тузга язмаган ниләр сөйләп, сорап, зур кешеләрне ялкытма», — дип тирги торган иде. Шул гадәтем бетмәде инде... Ярый, абый, ялыкмасагыз, сөйлим. Кайда дөресе, кайда ялгышы, аерып алып, үзегез хөкем чыгарырсыз.

4

— Мин үзем егерме алтынчы елны туганмын. Әти-әнинең миннән башка балалары тормады: мина кадәр икәү, миннән соңгылары бишәү үлде. Ходаның хикмәте — алма кебек булып бер-ике яшькә житәләр дә, капыл гына үләләр дә китәләр иде. Бер энем генә тугыз яшенә житеп үлде, мәрхүм.

Әтиләр бик каты крестьян иде. Әти ни кушсалар шуны эшли. Урман кисү булса да — ул, юл эше булса да — ул. Ирләрдән берүзе урагына кадәр урды безнең әти. Ул вакытта һәркемгә жир бүлеп бирү бар иде бит. Шулай әни белән икесе бүлеп алырлар иде дә, әти кулмәкләрен салып ташлап, урып китәр иде — артыннан әни көчкә өлгереп барыр иде. Ул чакны колхоз идарәсе каршында, ин өскә самолет, аннан автомобиль, аннан ат, ә ин аста ташбака төшерелгән бер такта була торган иде. Сабандыр, урактыр життеме, шул тактага көн саен һәр бригада үзенә төп эштәгеләрне язып бара иде. Минем әти һәрвакыт самолетта булды. Уныш бәйрәмнәрендә ситсы, постау кебек ин кыйбатлы бүләкләрне дә аңа бирәләр иде. Икмәк күп, колхоз бер хезмәт көненә жиде-сигез килодан да калмый бүлеп барды, ә сугыш башланыр алдыннан унар кило бүлде. Мин боларны бик нык беләм... Аннан инде сугыш чыкты... Әтине беренче елны ук алдылар. Кичен урактан кайтты да иртәгесен сугышка китте. Без дүртәү торып калдык: әни, мин, картәтәй белән картинәй. Сездә ничек дип әйтә торганнардыр, бездә мәгәр әтинен әтисен «картәтәй», әнисен «картинәй» йә «картый» диләр. Төрле халык төрлечә әйтә бит, күрше башкортлар әнә «олатай», «оласәй» ди. Хәер, монын сүзгә катнашы юк.

Әти китте дә юк булды. Ә кырык икенче елның салкын январенда семьяга бишенче кеше — исән калган бердәнбер сеңелем туды. Дөнья көтү әни белән минем өскә төште. Картәтәй белән картинәй үзләре дә бала хөкемендә: берсенә сиксән, икенчесенә җитмеш алты яшь. Ярый әле икесе дә таза, нык, өйгә шулар күз-колак иде.

Әтинең бар хыялы мине укытып инженер итү иде. Каян алган ул аны? Нинди инженер ул? Бүгенге көнгә кадәр башыма китерә алганым юк. Дөрес анысы, безнең нәселдә дә укымышлы кешеләр булган булуын. Картәтәйнең әтисе, мәсәлән, Коръән хаттат булган. Үз гомерендә ул берничә Коръән күчереп язган. Хаттат дигәне, — шулай сезнең кебек бер галим кешедән сорап белдем, — матур язучы дигән сүз икән. Ләкин ул бабабыз ни өчендер үз балаларын уку эзеннән җибәрмәгән. Ихтимал, җибәрергә теләп тә, дөнья мәшәкате баскандыр: авыр гомер итеп, карындык тәрәзәле өйдә яшәп, фәкыйрьлектә үлеп киткән. Әти шуларны уйлады микән, мәгәр мине бик укытасы килгән иде инде. Тик миңа укырга туры килмәде. Сугыш чыккан җәйне генә җиденчене бетергән барлык малайлар, кызлар, сигезенчегә китәсе урынга, әтиләр, абыйлар урынына бастык — печәндә, уракта эшли башладык. Мин башта төрле эштә йөрдем. Аннары, — әллә гәүдәгә дастыен булганга, әллә гектарларны, центнерларны бүтәннәргә караганда тизрәк исәпләп чыгарганга, мине колхоз амбарына кладовщик итеп куйдылар.

Менә сез минем малайларны күрдегез инде: кечесе унбиш, зурысына унсигез яшь. Кайвакыт мин шуларга карап торам да исем китеп уйлыйм: болар кем дә, болар яшендә без кем идек? Алар яшендә инде мин, буй җиткән генә түгел, акыл җыйган ир-егет идем. Дөрес анысы, минем малайлар да әнә буйга нинди сузылып үскәннәр — моржадан туры чыккан тотенмени! Сөйләшеп кара син алар белән малай дип! Күрсәтерләр алар сиңа «малай»ны! Ләкин барыбер алар әле малай гына, ир-егет түгел. Алар гаепләме? Юк. Заманы җиңел хәзер, заманы. Җырлап кына үтмәле. Аннары, без үзебез дә аларга һаман бала итеп карыйбыз, һәр җирдә үзебез эшлибез. Ә алар буйга үсә дә буйга үсә. Ә безнең заман ничек иде?.. Үзегез уйлап карагыз, миңа уналты-унҗиде яшь, ә колхозның акчадан башка бөтен доходы — игеннән алып үлгән сарык тиресенә кадәр — минем кулдан үтә иде. Әле исемә төшсә дә котларым алына: кем теләкләре кабул булып, ялгышмыйча эшләдем икән? Юкса ул елларны документларны ялгыштыру аркасында гына да гаепләнүчеләр аз булмады бит!..

Гөлбәдәр белән без шул елны ныклап яратышып йөри башладык. Мин аны үзем күптән яратып йөри идем инде. Ләкин ул чакны әле мин мәхәббәт тотар яшьтә түгел — бәләкәй идем. Гөлбәдәрнең исемен әйтсәләр дә, ике бит алмам уттай янып чыга иде. Хәзер инде без зур: җиденчене бетергәнбез. Хәзерге яшьләр сыман, урам уртасында үбешмәсәк тә, хәтта бергә йөрмәсәк тә, безне барысы да белә, яратышуыбызны инде үзебез дә яшерми идек.

Гөлбәдәр дә җиденчедән артыгын укымады. Әтисе Шәйсолтан бабай аны күрше авылның рус мәктәбенә биреп караган иде дә, Гөлбәдәрнең укуы бер-ике айдан узмады. Ул вакытта әле җиденчене бетергән татар балаларын рус мәктәбенең бишенче классына гына ала торганнар иде. Гөлбәдәр шунда көзгә кадәр озын буе белән сузылып йөрде дә:

— Шушы буем белән минем билемә дә җитмәгән бала-чага арасында ничек укыйм? Житмәсә, мыскыл итәләр, — дип ташлады да кайтты. Ләкин үзе колхоз эшенә чыкмады.

Урак өстендә, айлы төннәрне, укытучы кызлар, комсомоллар өмә оештырып, безнең ише яшь-җилкенчәкне басуга алып чыгалар иде. Гөлбәдәр дә шунда, мин барган өчен генә барып, ындыр табагында көшел көрәп, минем

белән бер мажарда[1] көлтә ташып кайта иде. Шәйсолтан бабай элек заман Уфаның Кәримов бай магазиннарында малайлыкта йөреп, әз-мәз сату эшенә өйрәнгәнлектән, совет чорында да гомере буе үзебезнен авыл магазинында эшләде. Гөлбәдәр әтисенә охшаган: әтисе дә озын буйлы, бик матур, бик чиста карт иде. Сугышка бармады — яше узган иде инде. Гөлбәдәрне укытасы килеп тә укыта алмагач, үз янында сату эшенә өйрәтә башлады. Бүтән балалары сугышка тикле үк кайсы Мәскәүгә, кайсы Ташкентка китеп беткән; төпчек кызы Гөлбәдәрне янынннан җибәрәсе килмәгәндер инде, күрәсен. Гөлбәдәр сату эшенә тиз өйрәнде. Без сугышка киткәндә магазинда фактически ул сату итә, Шәйсолтан бабай исәптә генә тора иде.

Бергә уйнап үскән егерме дүртенче-егерме бишенче елгы малайларны берәм-берәм сугышка озаттык. Ниһаять, безгә дә чират житте. Мине озак йөртмәделәр — буй килгән, тазалык килгән — кырык өчнең сигезенче ноябрендә алып та киттеләр. Гөлбәдәр мине станциягә чаклы озата барды. Без шул станциядә, минем баш исән кайтса, кавышырга сүз бирештек.

Безне башта алты ай буе сугыш уенына өйрәттеләр дә апрель азакларында фронтка җибәрделәр. Май башларында фронтта идек инде. Мин үзем Великие Луки юнәлешенә эләктем. Шунда Сигезенче ударга катнашып беренче яраны алдым — аяк итенә ябылмалы пуля тиде. Шул тирәдәге госпитальләрдә дүрт ай чамасы яттым да көзен янадан фронтка киттем. Кырык дүртенче ел шулай сугышта үтте. Ә кырык бишнең егерме өченче февралендә, нәкъ Кызыл Армия көнендә, икенче кабат яраландым: әлеге дә баягы аякка. Икесенә берьюлы, эре калибрлы пуля тиеп, чәкән[2] сөяген ватты. Аякның берсен булса да калдырырга бик тырышканнар иде дә — булмады. Башта чәкәннән кистеләр, аннан соң, кара янып чери башлагач, өстән кисеп аттылар. Унсигез ай госпитальдә ятып, кырык алтынчы елның августында гына авылга кайтып төштем.

Гөлбәдәр белән без елга якын хат язышып торган идек. Бервакыт кинәт кенә туктатты да куйды бу хатны. Минем, бер яраланып, янадан сугышка кергән чак иде. Вакыт тигән саен хат язам мона. Җавап юк та юк. Аптырагач, иптәш кызларына яздым. Берсе җавап бирмәсә, икенчесе бирер дип уйлыйм. Чыннан да, берсеннән хат алдым — ул барысын да язган иде... Ул чакны, берәрсе яраланып авылга кайттымы, өйдән өйгә кунак итү, кайгылы баштан күңел ачу гадәте бар иде. Магазинда эшләгәч, аракысы-нисе Гөлбәдәр кулында. Үзе — авылда гына түгел, районда бер чибәр. Аны инде табын күрке итеп йөрткәннәрдер. Ничек кенә булмасын, мине ташлап, үзебезнең авылның отпускыга кайткан бер офицерына кияүгә чыга бу. Бәлки, минем ике аяксыз калу хәбәре дә куркыткандыр үзен. Егет бер аен тутыра да китә. Исән-сау барып життем дигән хәбәр урынына, мескен ата-анасына, Гөлбәдәргә кара читле кәгазь тоттыралар...

Мин кайтып төшкәндә, анын хәлләре әнә шулай иде. Анысы өстенә тагы мин кайтуга әни гарипләнгән — иелеп уракургандагы кебек, билдән бөкрәеп каткан иде. Картәтәй дә хәтерен җуйган — мине танымады. Бу хәлләрне мина, кайгырмасын, борчылмасын дип, госпитальдә ятканда язмаганнар, бөтенесен җыеп, күтәрә алса күтәрер, күтәрә алмаса юк дигәндәй, кайтуыма әзерләп куйганнар иде.

Гөлбәдәр, мин кайтканның икенче көнендә үк, аулак бер вакыт табып, үзе безгә килде. Картәтәйләр алдында:

— Сина саклый алмадым бит үземне, Хәнәфи, саклый алмадым! Күңелем төрле исәпләргә керде дә, алучысы барда чыгып калыйм дидем... — дип өзгәләнеп елады-елады да, бүтән бер сүз әйтмичә чыгып китте.

---

[1] Көлтә арбасы.
[2] Тубык сөяге.

Мин торараштай каткан идем, әни сүзләреннән соң гына кул-аягым кыймылдый башлады. Әни, туксан градуска бөгелеп идән уртасында торган көе:

— И бу сугыш! И бу сугыш!.. — ди-ди сөйләп китте. — Чәнчелде чәнчелүен дә Гитлер явыз үзе — күпме кешене харап иткәч кенә чәнчелде шул... Шушындый, алларында сөяп тотардай чибәр, бәхетсез хатыннар, бәхетсез кызлар бер Гөлбәдәр генәмени соң? Кемнең газиз балалары нишләп бетте диген, ә! Бар да сугыш кәсафәте. Шөкер, бездә болай гына, ә мимеч явыз таптап үткән җирләрдә ни генә булмаган анда... Ярый әле монда без исән, бала-чага исән...

Мине танымаган картәтәй дә:

— Әле дә ярый, Фатих улым, син исән, — дип, миңа әти исеме белән дәште.

Әти миңа, сугышка киткәндә:

— Улым, мин кайтмасам да, сугыш бетү белән укырга тырыш, — дип әйтеп киткән иде.

Менә сугыш бетте. Тик мин генә укый алмадым. Ичмасам, унынчыны бетергән булсам да, әтием жылы җир куенында тыныч ятар иде. Ләкин кая инде! Үзебездә мәктәп юк. Йөреп укырга дисәң — аяк юк. Китеп, ятып кына укыр идем — өйдәге дүрт җанны кем карар? Өй эчендә ничә кеше булса, һәркайсына берәм-берәм карап чыктым. Әнә картәтәй белән картинәй. Болар икесе дә сабый хөкемендә — тугызынчы дистәне кимереп баралар — бүген түрдә, иртәгә гүрдә. Ләкин аларның да тамагы бар. Әнә әни. Ул әле кырык икедә генә. Әмма икегә сынып, инде яртыга әйләнгән. Уфа врачларына илтеп күрсәткәндә әллә тураеп та китәр иде дә бит — аны кем йөртә? Әнә күз төпләре күгәреп баткан дүрт яшьлек сеңелем. Ул әле миннән ашарга сорамый, әнидән сорый, ул әле миннән ятсынып кына утыра. Ләкин аны мин ашатырга тиеш. Мин аны, бүтән туганнарым кебек үлеп китмәсә, укытырга да тиеш. Әтинең теләге миңа булмады, ичмаса, сеңелемә кабул булсын. Шулар кайгысы белән, бәлки, Гөлбәдәрне онытырмын, аңа булган төзәлмәс үпкәм дә басылыр дип уйлыйм. Миңа егерме яшь тә юк, ләкин минем яшьлегем инде беткән, алда дөнья көтү, җан асрау кайгысы гына иде.

Сугышка киткәнче дә әйбәт кенә кладовщик булып эшләгәч, исәп-хисапны да яхшы белгәч, мине фронтовик-инвалид та дип, колхоз канцеляриясенә хисапчы ярдәмчесе итеп утырттылар. Эркелеп кенә эшләп киттем. Эш миннән, мин эштән канәгать дигәндәй, җаена төшә барам. Тик барыбер күңелем тыныч түгел. Әллә укый алмый калганга микән дип тә уйлыйм. Алай дисәң, анысына килештем кебек инде: сеңелемне укытырмын дидем. Әллә юкса тормыш авырлыгыннан, көннекен көнгә көчкә ялгап барудан шулай күңелем сызамы? Алай дисәң тагы, ул авырлык бер миңа гына килмәгән бит — ил белән килгән. Ярый әле безнең өйдә беребез генә үлгән. Өчәр-дүртәр, хәтта аннан да күбрәк кешесен югалткан гаиләләр дә булды бит! Нәрсә, дөнья әллә аларга җиңелме? Юк, ил кайгысы — уртак кайгы. Дөнья авырлыгыннан күңелем сызмый. Бүген җиңеләймәсә, иртәгә җиңеләер, гел болай бармас дим. Минем күңелем Гөлбәдәрне уйлап сыза иде. Оныта гына алмыйм бит! Әлбәттә, сугыштан соң ирләр юк, бик кадерле иде. Мин ул вакытта ирләр кулы тигәнне түгел, ирләр күзе төшмәгән кызларны да таба ала идем. Тик күзем берсенә дә төшми, акылым белән Гөлбәдәрне оныта алсам да, йөрәгемнән йолкып ташлый алмыйм. Ул — минем йөрәгемдә, нәкъ менә шушы төшендә.

Без очрашмаска тырышабыз. Очрашсак та сөйләшмибез. Исәнме, саумы гына. Мәгәр сизәм: ул да сыза. Мин кайтканнан бирле берни̇нди клубка,

бернинди кунак-төшемгә йөрми башлавын ишетәм. Башкасын да ишеттереп торалар: иренең үле хәбәрен алгач, тегесе белән дә, монысы белән дә буталды, диләр. Ямьсезрәк сүз белән әйтәләр, билгеле. Ләкин мин сызам. Балтыр итем кимеп, протезларым бушап калды. Тик берәүгә дә сиздермим. Клубларга йөрмим. Озын кичне үткәрер өчен фото эшенә өйрәнеп алдым. Уфага йөрүчеләр, бигрәк тә күршебез Кыям абзый, базар мәйданындагы фотографлардан теләнә-теләнә кәгазьдер-мазардыр, фиксаждыр кебек нәрсәләр алып кайтып бирәләр. Ачып карап алмагач, билгеле, товарның төрлесе эләгә. Шулай да файдасы бар: ул елларны халык кырылышып дигәндәй карточкага төшә иде. Аз-маз акча юнәтеп, күршебез Кыям абзый белән әнине Уфага алып киттек. Үземә дә протез кирәк иде, монысы бер сылтау булды. Сәламәтлек министрының үзенә кереп, зур белгечләргә күрсәттек. Юк, диделәр, баштарак кирәк иде, хәзер төзәлмәячәк, диделәр. Кайттык шулай, өчебез дә бөгелеп төшеп.

Кырык җиденче елның җәендә картәтәй белән картинәй икесе берьюлы вафат булып, безнең гаилә капыл гына кимеп, бушап калды. Әниемә әллә йорт эше җиңеләерме дип уйлаган идем дә, җиңеләймәде. Мин киптем, миннән яман әни кипте. Ахыры ана йөрәге түзмәде, беркөнне әйтте бу:

— Саргаеп беттең, балам, кибеп беттең, — ди. — Алып кайт, булмаса, Гөлбәдәрне, — ди. — Ул да яхшы ата-ана баласы. Ни булганын син белмисең бит. Бәлкем, ул көчлек белән генә иргә чыккандыр?.. Бары да сугыш бәласе. Сугыш чыкмаса, син болай, ул алай булыр идемени? Үзе риза булса, ал да кайт. Йөрмә сагынып...

Әнием үзе шулай дигәч, капыл бар нәрсә дә үз урынына төште дә утырды. Хатын-кыз хәлен хатын-кыз анламый кем анласын инде! Чыннан да, дим, әгәр бу сугыш булмаса, минем әти үләр идеме дә безнең авылның сугышка киткән йөз алтмыш кешедән йөз утызы үләр идеме? Күпме ана ирсез-баласыз, күпме бала атасыз калды! Күпме бәхетләр җимерелде! Аннан соң, дим, тормыш иптәшең синең белән уртак булган бар нәрсәне гомер буе бергә бүлешеп, кайгысын кайгырышып, шатлыгын шатланышып яшәргә тиеш түгелмени? Кыз булсын дигән булып, кыз алып та, гомер буе утта яшәгән кешеләр азмыни?.. Ярый, дидем, риза булса, алып кайтырмын, дидем. Мал иясендә абынмасын!

Ләкин минем «мал» абынды. Ярый әле ул хәсрәтне әни күрмәде. Ул бичара бөгелгән гәүдәсен озак күтәреп йөри алмады — бөтенләй сынды. Илленче елның кәккүкләр кычкырган ямансу бер вакытында күңелләрне бөтенләй ятим итеп үлеп китте. Ярый инде, беренче балабызны күреп, киленнән бик канәгать булып үлде. Ул исән чакны без бик әйбәт тордык. Гөлбәдәрнең күз күтәреп кемгәдер караганын белмим. Ул һаман магазинда эшли, анда эшләгәч, кергәне-чыкканы белән сөйләшми дә булмый. Илләмәгәр беркем килеп, Гөлбәдәр шулай, Гөлбәдәр болай, дип, миңа әйтмәде. Бәхетсезлек соңыннанрак башланды.

Илле беренче елны колхозга күрше авылны китереп куштылар. Мине хисапчы ярдәмчесеннән гади счетчик итеп калдырдылар. Илле алтыда тагы китереп бер авылны безгә куштылар. Колхоз киңәйгән, зурайган саен, миңа урын тарая барды. Шулай мин бөтенләй төшеп калдым. Мин эшләп килгән барлык урыннарны махсус белемле кешеләр алды. Кайсы читтән килде, кайсы үзебездән укып кайтты. Кыскасы, илле алтынчы елны мин янгын каланчасында утыра идем инде.

Шул елның башында безнең колхозга председатель итеп Уфа кешесен китереп утырттылар. Тупас кына, таза гына адәм иде шунда, беләкләре генә дә тай ботыдай иде. Сез безгә килгән елны шул иде бугай председатель? Күрәм: бу миңа бик яхшы карый башлады — тегесен дә, монысын да биреп тора.

Үзем дә бик хөрмәт итәм моны. Ахырда бу мине, син монда утыра торган кеше түгел дип, юк урынны бар итеп, Уфага бухгалтерлар курсына җибәрде. Шулай киттем мин алты айлык курска. Беренче октябрьдән укый башладык. Минем кебек якын җирдән җыелган кешеләр атна саен кайтып киләләр. Мин аяксыз, кайта алмыйм. Октябрь бәйрәменә генә кайтырмын дим. Аннары, миңа укуы да җиңел түгел: контузия үзен сиздерә башлады. Шулай да — егылып үлсәм үләм — укып бетерергә исәп. Гаиләне карау, бигрәк тә сеңелкәшне укыту, минем өстә. Юкса соңгы вакытларда Гөлбәдәрдән аның өчен сүз ишетә башладым. Җитмәсә тагын, сеңелем кайчандыр ул укымый ташлап кайткан күрше рус авылына сигезенчегә барып керде. Анда хәзер, безнең замандагы шикелле, җиденчене бетергәнне бишенчегә алмыйлар инде. Мәктәбендә дә биш-алты татар гына укымый, классы-классы белән укыйлар. Укытучылары да гел татар диярлек. Ул анда торып укый, димәк, квартирына, ашарына кирәк. Акчаны миннән сорамыйча, җиңгәсеннән сорамас бит инде ул.

Шулай Октябрь бәйрәме дә килеп җитте. Ничектер машинасы җайлы килеп, бер көн элегрәк кайтып китәргә туры килде. Малайлар инде нишләргә белми — сагынганнар. Тик Гөлбәдәр генә әллә ничек аптырабрак киткән шикелле булды. Гадәттә хатын-кыз күңелен генә сизгер диләр. Юк, ирләр күңеле дә бик сизгер ул, тик без аны белгертмибез генә. Дөрес анысы, Гөлбәдәр дә берни белгертми. Шулай да сизәм: элекке Гөлбәдәр түгел. Ул гомумән соңгы елны бик нык үзгәрде. Мин аның хәлен дә аңлыйм, билгеле. Ире гел түбәнгә таба киткәч, аңа да җиңел булмагандыр. Шулай барысын да уйлагач, күңелем утыра төште. Өч көн кунак булдым да дүртенче көнне иртә белән колхоз идарәсенә киттем. Елга трамвайлары туктаган иде инде. Иртәгә Уфага берәрсе бармыймы дип авыз ачу белән, председатель миңа әйтә:

— Әнә, Кыямның барасы бар. Шуның машинасына утырырсың. Башкача, юл төшми торып, Уфага бару булмас, — ди.

Кыям абзый — минем ут күрше. Яшькә әтидән кечерәк булса да, әти урынына күргән кешем. Ул да шунда ук — канцеляриядә. Путевкадыр-мазардыр яздырып йөри.

— Ярый, апай, илтергә булгач, илтергә, — диде ул. — Менә заправкасына барып документларын тутырып-нитеп алыйм да үзем дәшәрмен. Син бар, әзерләнеп тор.

Күрәм, йөзенә уй чыккан. Ләкин без башкача сөйләшмәдек. Мин, председательгә рәхмәт әйтеп, кайтып киттем.

Кыям абзый төшкә хәтле Уфага барып җитәргә тиеш иде, шуңа күрә озакламады, үзләренең капка төбенә кайтып та туктады.

Бер ярты сәгатьтән без Уфа юлында идек инде. Моңа хәтле, апай дип, минем өчен үлеп торган, сөйләшеп сүзе бетмәгән Кыям абзый бүген минем белән сөйләшергә бер авыз сүз тапмый бара. Ни булган моңа?

— Әллә бер-бер хәл булдымы соң, Кыям абзый? — дип тә карадым.

— Юк ла, болай гына, тешем сыкрый... — дип кенә бетерде бу. Ике куллап руленә тотынган да ябышкан. Телен йотканмыни!

Сәгать унберләрдә без Агыйдел кичүенә барып җиттек. «Чеганский» турындагы таш күперне салып бетергәннәр иде инде, ләкин йөртмиләр иде әле. Ә без чыгасы агач күперне аерып куйганнар: соңгы дебаркадерларны затонга ташып йөргән бәләкәй генә бер буксирны үткәрәләр иде. Без алдагы машинаның кузовына төртелеп диярлек туктадык. Безнең арттан — икенчесе, өченчесе... Алда әллә күпме машина буылган. Утырабыз шулай икәү, үпкәләшкән ике бала кебәк. Кыям абзыйның теше сыкрый. Ул сөйләшмәгәч, мин дә кул селтәдем. Яна күпернең күккә ашкан бетон баганаларын санап, биеклеген чамалап утырам. Сүз юктан сүз булсын дигәндәй генә:

— Язгы ташкын чорында да астыннан пароход чыгып китәрлек иткәннәр икән, — дип куйдым.

— И апай, апай!.. — диде Кыям абзый кинәт. — Синдә күпер кайгысы! Өеннән чынлап та берниндн хәбәрсез китеп барасынмыни син? Әллә юри башынны заяга салдыңмы?..

— Нәрсәгә алай дисең әле син, Кыям абзый?.. — Күземне күпердән алып ана текәдем.

— Күрәм, апай, син берни дә белмисең икән, — диде ул.

Тәнем эсселе-суыклы булып китте. Кыям абзыйның юл буена көрсенеп килүен яна гына сизенә башладым.

— Сузма, Кыям абзый, тизрәк әйт!

— Их, апай, апай... Тешем түгел, йөрәгем сызлый минем. Мине гаепләсәң гаепләрсең — әйтми булдыра алмыйм. Гөлбәдәр куенында килмешәк председатель йоклый бит...

Бу хәбәрне башка берәү әйткән булса, мин инде аны бугазыннан буып алып, бәлки, машина астына салган булыр идем. Ләкин гомер буе ут күрше булып яшәгән, беркемгә бер хыянәте тимәгән Кыям абзыйга ничек кул күтәрелсен? Кулымны яксам — кулым корыр, тел тидерсәм — телем корыр төсле. Мин Агыйдел күперенең бетон баганалары кебек каттым да калдым. Сикереп торырга аягым юк, тотынырга кулым юк, сүз әйтергә телем юк. Исән башым белән мәет мин. Алда машина, артта машина, кабина ишекләре ябык, тәрәзәләре ябык, тышта салкын, кара көз. Кабина идәненнән жылы бәреп тора, ләкин минем аяклар сизми: алар туңмый да, жылынмый да торган... Мин бик озак утырганмындыр, машинабыз туңган кешедәй дерелдәп кузгалып киткәч кенә, исемә кайттым. Күперне ялгаганнар, машиналар агылып Уфа ягына чыга башлады. Без дә Фрунзе урамыннан шәһәргә менеп киттек.

— Бу хәлне халык беләме, Кыям абзый? — Телгә килеп әйткән беренче сүзем шул булды.

— Белсә дә, бик азы беләдер, — диде Кыям абзый. — Бүген колхозның Уфага машина жибәрерлек йомышы да юк иде. Шул сине тизрәк олактырыр өчен генә жибәрде аны председатель.

— Шулай да мин аларны үз күзем белән күрергә тиеш!..

— Яхшы. Әгәр укуым кала димәсәң, минем белән кире кайтасың.

— И, Кыям абзый, мондый хәлдән соң нинди уку ди!

Мин укыган жиргә дә, квартирга да кереп тормадым.

Кабина эченә сөяп куелган капчык шикелле — машина кая, мин шунда — тик йөрдем. Кыям абзый ашыкмый.

— Күпер тугызга кадәр эшли әле, безгә барыбер төнсез кайтырга ярамый, — ди. Эшен суза-суза, сәгать алтыны житкерде. Шәһәр халкы эштән чыкты. Без дә бер ашханәгә туктап ашарга кердек. Миндә, билгеле, ашау кайгысы түгел. Мин көндез дә ашамадым. Кыям абзыйның гына ашаганын карап утырдым. Берәү булса инде, бу хәсрәтне аракы белән томалар иде. Ләкин мин аракы эчмим, аракы эчү нәселебездә юк. Кыям абзый ашап чыккач кинәт кенә ашыга башлады.

— Әйдә, кузгалыйк, булмаса. Мондыйда Агыйделне чыгып калу хәерле. Иртә булса, берәр авылга кереп торырбыз, — ди.

Чыннан да, Камышлыга житкәч, Кыям абзыйның танышларына кереп, ике сәгатькә якын анда юандык. Авылга төп-төгәл сәгать бердә кайтып кердек. Күзгә караңгы төн. Күл өсте белән жир өсте бердәй — дегет кебек. Председательнең гаиләсе Уфада, үзе бездә ялгызы гына яши иде. Без аның квартирына кагылып-нитеп тормадык. Кыям абзый туп-туры машинасын безнең капка төбенә китереп туктатты.

— Әйдә, апай!..

Үзе кабинадан сикереп төште дә атылып ишегалдына кереп китте. Мин дер-дер калтырап аның артыннан иярдем. Мин шыгырдап килеп житкәндә, Кыям абзый ишек төбендә тора иде инде.

— Шакы ишегенне.

Мин әкрен генә шакый башладым. Җавап юк. Ныграк итеп шакып карадым — җавап юк. Өйдә җан әсәре барлыгы да сизелми. Ахыры мин, ярсып, ишеккә таягым белән бәрергә тотындым. Шуннан соң гына:

— Кем анда? — дип, Гөлбәдәр килеп чыкты.

— Ач!..

— Синмени, Хәнәфи? Бәй, нишләп кайттың? — Гөлбәдәр ишекне ачты да, берни булмагандай: — Бикләп кер, — дип өйгә кереп китте.

— Ярар, — дидем. Таягым белән башта унга, аннан сулга селтәп суктым. Шунда кемдер минем таяк тиюдән «ыһ» дигән тавыш чыгарды да, мине карангыда стенага сипләп, ишеккә ташланды. Анда аны Кыям абзый эләктереп алды. Ләкин председатель гайрәтле иде — Кыям абзыйны да ишек янагына сылады. Артыннан куа баруның мәгънәсе юк иде.

Без өйгә кердек. Гөлбәдәр өстәлгә капланып елый ук башлаган. Мин лампага ут алдым. Мич буеннан түр стенага чаршау тартылган иде, аны ачып карадым — балаларны үзебезнен урынга салганнар. Ә бу якта — гадәттә ике малай ята торган такта караватка — үзләре яткан.

Мин буылып, йөрәгем ярсып, Гөлбәдәр өстенә килдем. Ярый әле Кыям абзый таягымны тотып алды. Гөлбәдәр инде еламый, такмаклый гына:

— И Кыям абзый! Тәмәке генә кабызып чыгыйм дип кергән иде. Председатель бит! Безгә шундый игелек эшләп, Хәнәфине укырларга җибәргән кеше. Ачмаска кулым бармады... Нишлим соң, нишлим? Шушылай чишенгән килеш идем. Күпме каршы торып карадым... Аттай көчле — кулларымны каерды...

— Анысын белдек, — дидем мин. — Тик ни өчен урын ике кешегә җәюле? Ичмасам, без кергәнче, бер мендәрне җыеп куялар иде аны.

— Ике балабыз хакына гафу ит, Хәнәфикәем!.. — дип, Гөлбәдәр аягыма егылды.

— Житмәсә, исерек! — Мин җирәнеп артка чигендем.

— Их, Гөлбәдәр, Гөлбәдәр... — диде Кыям абзый. Бар сүзе шул булды.

— Кыям абзый, — дидем мин, — илтеп куй мине кире Уфага. Йә бу фахишәгә бер-бер хәл ясармын.

— Син алай бик кызып барма әле, апай, — диде Кыям абзый. — Мин сине илтеп куярмын куюын, хәзер мина председателе дә сүз әйталмас, тик, апай, төн авышсын инде. Агыйдел буенда йоклаганчы, безгә кереп баш төртеп алыйк. Хәленне аңлыйм, шуңа күрә кал димим. Әйдә.

— Китсәгез китегез, кадалыгыз! — диде Гөлбәдәр. Зифа озын гәүдәсе белән үзе минем өскә килде: — Ирмен дип син дә яшисең дөньяда!

Мин актык ихтыярымны җигеп кенә түзеп торам. Әтием кебек Кыям абзый бар, балалар бар. Ярый әле алар уянмады. Уянсалар, безнен янга чыкмый калмаслар иде. Әллә уянып та, мондый елаш-тавыштан куркып, үзләре елап ятамы? Чаршау читен генә күтәреп, малайларга күз салдым. Шөкер, йоклыйлар, бу ямьсезлекне күрмәделәр.

Без ничек кергән булсак, шулай чыгып та киттек.

Кыям абзый хатыны Сажидә апага бер-ике сүз белән генә безнен хәлне аңлатты да, үзе чишенеп йокларга ятты. Миңа да урын салып биргән иде, ләкин мондыйда кем йоклый алсын инде! Мин утырган килеш кенә төн үткәрергә булдым. Сизеп торам: Кыям абзый да йоклый алмый. Ул — шофер, аның мине Уфага илтәсе бар, йокласын иде дә бит

— йоклый алмый. Шулай таң аттырдык та, карга күзе юлга төшкәнче сәфәр чыктык.

— Беркемгә дә сөйлисе булма, ишетсен колагың!.. — дип, Кыям абзый Сажидә апаны да, житкән кызы Гөлфияне дә кисәтеп куйды.

Шул төннән минем башыма сызлау капты. Ун чигәмнән кысып ала да сулкылдапмы-сулкылдый. Аннары менә шушы буйдан, ике каш өстеннән чатнап ярылгандай була. Колагым да шауларга тотынды. Укытучы сөйләгәндә жөмләнең бер яртысын тотам, икенче яртысын тота алмыйм. Бер дә алга түгел — көн саен артка, көн саен ирегә. Атна дигәндә урынга яттым. Кузгалу түгел, башымны да бора алмыйм — күзләрдән ут күренә. «Скорая помощь» килеп салып алып киттеләр мине. Больницадан Гөлбәдәргә хәбәр иттердем. Алма кебек ике улым хакына кичерергә уйлыйм үзен. Кая барасын кичерми? Куып чыгара алмыйм. Үзем дә китә алмыйм. Ике аяксыз килеш кая китәсең? Аягым исән булса да китә алмас идем. Ул ике балага кем атай булыр? Алар өчен хәтта мин Гөлбәдәре белән генә түгел, убырлы карчыкның, гыйфритнең, дәжжалның үзе белән дә торырга риза. Бу дөньяда әллә ни кыра алмадым, инде яшәвемнең бар яме, бар мәгънәсе — шул ике сабыйны, ятим сеңелемне аякка бастыру иде.

Мондый больницада мине озак тотмадылар, контузиягә бәйләп, госпитальгә күчерделәр. Аннан да өйгә хәбәр иттердем. Юк Гөлбәдәр! Әллә, дим, кил дип атап чакырмаганга килми микән? Бәлкем, кылган эшләренә үкенеп, күземә күренергә оялып ятадыр? Күңелемне шулай төрлечә юатам. Ни әйтсән дә, бөтенләй намуссыз, мәнсез, беткән кеше түгел иде ләбаса. Минем янга сирәк-мирәк әлеге дә баягы үз каным — сеңелем килеп йөри. Үзләре укыган авыл янынннан гына диярлек узып киткән поездга утырып килә дә, төнен вокзалда куныш, кайтып китә иде. Мин һаман, ятлап куйган төсле, бер үк соравымны сорыйм:

— Жиңгәң ни хәлдә соң?

— Әйбәт, — ди.

— Апайларың авырмыймы?

— Юк, авырмыйлар, — ди.

— Жингән нигә килми соң?

— Әллә... белмим... — ди. Шулай мин сораганга гына жавап кайтарып тик тора.

Иң азактан мин:

— Жиңгәң килсен, — дип әйтеп жибәрәм.

— Ярар, әйтермен, — дип кайтып китә сеңелем. Тик Гөлбәдәр килмәде, күренмәде.

Госпитальдә мин жәмгысы өч ай яттым. Кергәндә ноябрь азагы булса, чыкканда февраль азагы иде. Мин укыган бухгалтерлар курсының бер ае калган иде әле, шулай да минем өчен юк иде инде ул. «Кайтам, килеп алыгыз» дип хәбәр жибәрдем. Алырга Гөлбәдәр үзе килер, килми калмас дип көтәм.

Бик ямьле, кояшлы, тамчылар тамган бер көнне палата ишек төбеннән генә сестра дәште:

— Зәйнуллин, сезнең янга килделәр!

— Кем: ирме, хатынмы? — дип сикереп тордым.

— Ир, мыеклы бер абый, — диде сестра.

Мыеклы булгач, Кыям абзый инде. Атылып-бәрелеп янына төштем. Ике аягы да протез кешенең ничек атылып-бәрелгәнен күз алдыгызга китерәсездер инде. Беренче соравым:

— Кая, Гөлбәдәр килмәдемени? — булды.

— Ни бит әле, Хәнәфи апай... Гөлбәдәр килә алмады бит әле... — ди бу. Үзенең мыек очлары сикереп-сикереп куя.

Сулышым кабып:

— Тагын ни булды? — дип кычкыра салдым.

Мине дәвалаган врач та шунда утыра. Мин бер ана, бер Кыям абзыйга карап торам. Кыям абзый да бер ана, бер миңа карап алды.

— Син сабыр бул инде, Хәнәфи апай, — ди бу. — Мин үзем кайткач кына әйтермен дип уйлаган идем... Әле менә врач иптәш белән киңәштек тә...

— Сүзенне эт эчәгесе кебек сузма, Кыям абзый.

— Шул инде, апай, Гөлбәдәр китте бит...

Ул моны әйтмәс борын ук йөрәгем кысылып тибә башлаган иде инде. Ә бу хәбәрне ишеткәч, бугазын чалып җибәргән мал кебек тыпырчынып, бәргәләнеп алды да хәлсезләнеп калды. Әкрен генә башым әйләнеп, урындыгым-нием белән суырылып кына каядыр төшеп барам. Шулай да күрәм: врач әзер тора. Сестраның кулында сумы, дарумы. Тик мин нишләптер һушымны югалтмадым. Йөрәгем тагы, әллә кайдан көч табып, терелеп китте. Инде күкрәк сөякләремә бәреп тибә. Тамырларга кан җәелеп, мин тагы үз хәлемә кайттым. Тик тавышым гына беткән иде. Үземә дә чак-чак ишетелер тавыш белән:

— Ә балалар?.. — дип сорый алдым.

— Кайгырма, апай, балалар бездә.

Шунда гына иркен тын алып җибәрдем. Инде Гөлбәдәрнең исемен әйтмичә генә, дөресрәге, әйтә алмыйча, аның кая китүен сорадым.

— Дөрестерме, юктырмы, Ташкент ягына киткәннәр дип сөйләделәр.

«Кем белән?» — дип сорарга телем бармый. Кыям абзыйның үзенең әйткәнен көтәм.

— Кайчан киттеләр инде?

— Шул отчет җыелышыннан соң күп тормадылар. Председательне кабат сайламадык. Ул үзебезнең Фәйзигә эшен тапшырды да, икенче көнне иртәнгә авылдан эзләре суынган иде инде. Олы улың «Әни әллә кая киткән!» дип җылап-шешенеп керүгә, өстемә дә кимичә чабып керсәм — өегездә җилләр исеп утыра. Балалар яткан урын-җир белән, кул да тимәгән килеш, синең китаплар гына калган...

Минем башым иелә бара, иелә бара. Ахыры гәүдәмне тота алмыйча, идәнгә капландым дигәндә, маңгаемнан йомшак кына итеп, салкын куллары белән сестра килеп тотты.

— Менә шулай, Хәнәфи энем, — дип, Кыям абзый сөйләвендә булды. — Әллә соң беразга тагын калып торасыңмы?.. Балалар бездә...

— Юк, калмыйм, кайтам!

Сикереп урынымнан тордым. Үзем: «И Ходаем, баш авыртуы гына кире кайтмаса ярар иде!» — дип, куркып теләкләр телим. Әмма шул минутта, ни өчен икәнен белмим, мин үземне кабаттан да тап-таза итеп сиздем. Әйтерсең лә менә-менә башыма кабарга торган чир утырган җиремдә калган иде.

— Сез борчылмагыз, Надежда Петровна, — дидем мин врачка. — Ике балам әтисез-әнисез анда тилмереп ятканда, мин монда ничек әрнүсез, авыртусыз ятармын икән?

— Да, — дип, врач та килеште. Шундук чыгардылар да.

Кыям абзыйның хатыны Сажидә апа сырхау иде. Колхозда эшләп йөргән кызы Гөлфия без кайтуга мичләр ягып, өйне май кебек итеп куйган. Кайтып керсәм, шаклар каттым! Гөлбәдәр чыннан да өйне генә киеп китмәгән иде. Китаплар, билгеле, аңа бушка да кирәкми. Әмма калган бар нәрсәне төпләп тазарткан, хәтта, Ташкентта агач булмас дип уйлагандыр инде, беләк буе уклауга хәтле алып киткән иде. Шулай итеп, мин, ике аяксыз кеше, ике кулсыз да калдым.

— Берәр төрле язу-мазары юк идеме соң, Кыям абзый? — дип сорыйм.

— Юк, апай, юк, — ди. — Аны үзем дә уйлаган идем уйлавын. Тик бер җирдән дә язу чыкмады. Менә, ничек калган — шулай.

Балалар саргаеп кипкән. Капка шыгырдыймы, ишек ачыламы, ишек-тәрәзәгә ташланып әниләрен көтәләр. Зурысы укый иде, сагыштан укый алмыйча, мингерәүләнеп, артка кала башлады. Укытучылар да, врачлар да киңәш итеп, бер кыш укытмый тоттым. Сенелкәш тә: «Әллә мин дә быелга укымый торыйммы соң, абый?» — дип караган иде, якын да килмәдем. Колхоз ярдәм итә. Кыям абзый көн саен кереп, хәлне белеп тора, аштан-судан калдырмый. Гөлфия дигән җиткән кызы бар дигән идем бит, анысын әйткән дә юк, мине бик якын күреп йөри. Өсне-башны карый, идәннәрне юа, икмәген дә салып бирә. Калган вак-төяген инде үзем дә эшлим. Тик... күңел һаман Гөлбәдәрне юксына, Гөлбәдәрне көтә. Председатель белән торткан кара төнне түгел, аңа кадәр бик күп тапкырлар килгән кояштай көннәребезне уйлап сагынам, сугыш вакытындагы бик авыр, ләкин бәхетле яшьлегебезне сагынам.

Гөлбәдәрнең авылда беркеме дә калмаган иде инде. Әтисе-әнисе сугыштан соң озак яшәмәделәр. Ике абыйсы сугышта һәлак булып, ике апасы бик күптәннән Ташкент янындагы Янги-Юл дигән җиргә барып төпләнгәннәр иде. Аптырагач, аларга язып карадым. Ләкин алардан да хат-хәбәр килмәде. Әйтерсең лә Гөлбәдәрнең бөтен нәсел-ыруы мина каршы аякланган иде. Гөлбәдәрем шулай, үзебезнең Зәңгәр Күлгә төшкәндәй, юкка чыкты. Ахырда мина милиция аша юллатырга киңәш иттеләр. Алар эшне тиз тотты. Ай дигәндә эзләп таптылар моны. Ул чыннан да, мин уйлаганча, Янги-Юлга барып урнашкан, анда да шул сату эшенә кергән. Мина июнь башыннан алимент килә башлады. Ләкин, мин язып та, ни үзеннән, ни апаларыннан хәбәр-хәтер килмәде.

Шулай ике бала белән яшим. Язгы чәчү чорында тагын каравылга чыктым. Малайлар янына Кыям абзыйның кызы Гөлфия кереп куна. Үз анасы чирләш, безнекеләр ятим. Йөри шулай ике дөньяны күтәп. Әнисе таза булса, бәлки, ул да укыган булыр иде. Ләкин хәзер калды инде. Укымый калды. Шул Гөлфиянең җылы сүзе, якын итүе генә минем ямьсез дөньямны ямьләп тора. Мәңге рәхмәттәмен ана.

Печән өстендә мине болынчыларга азык-төлек ташырга куйдылар. Йә алмаш-тилмәш, йә икесен берьюлы, улларымны да утыртып йөртәм. Алар инде, әниләрен оныта төштеләрме, бераз көлә-елмая башладылар. Аларга карап мин шатланам. Ләкин көлә алмыйм. Эчемдә Зәңгәр Күл төбедәй тирән бушлык, сагыш.

Мина хатын димли башладылар. Бер генә балалысын да, бер баласызын да, бөтенләй бала тапмый торганын да димлиләр. Баш кына селкәм. Гөлбәдәрне йөрәгемнән кем алып ташлар да, кем минем аналы ике ятимгә ана булыр? Инде соңгы тапкыр дип, Гөлбәдәрнең апаларына хат язып салдым. Гөлбәдәргә җиткерегез, балаларга аның алименты кирәкми, үзе кирәк, кайчан кайтса да кабулым бар, тик кайтсын гына, дидем. Тагын җавап юк...

Әмма язмыш мин уйлаган-көткән яктан түгел, бөтенләй икенче яктан китереп сукты. Гөлбәдәрнең ялгыш эзгә ныклап басуына бер ел дигәндә, декабрь башы иде инде, Янги-Юлдан фаҗигале хәбәр килеп төште: Гөлбәдәр асылынып үлгән. Соңыннан әз-әзләп башка яклары да ишетелде. Председателе Гөлбәдәр белән бер ярты ел гына торган да кире Уфасына кайтып киткән, ә Гөлбәдәр шул бозык юлын дәвам иттергән. Башын шул юлда харап иткән дә.

Кайгылы хәбәр алган көнне шулай, әллә эчеп онытылыймны, ичмаса, дип, ярты литр аракы алып кайттым. Утырттым шулай өстәлгә. Ике малай

да өйдә. «Нигә болар тынып калдылар әле?» дип, малайларга карасам, икесе берьюлы куркып-агарып миңа текәлеп катканнар. Күз төпләре караеп баткан килеш, борлогып, ниләр күрербез икән дигәндәй көтеп, карап тора башладылар. Мин инде шешәне ачарга дип кулыма да алган идем. Шунда зур улым мич буенда басып торган җиреннән генә:

— Әти, эчмә... Әти... Ятыйк инде... — диде.

Каян кергән диген син аңа бу акыл! Эчмәгән килеш айнып киттем. «Килегез әле монда», — дип чакырып алдым да, икесен ике яктан кочаклап алу белән, елап та җибәрдем. Миңа малайлар кушылды. Шулай өчәүләп туйганчы бер еладык та бетердек. Әниләре барыбер елап кына кайтыр җиргә китмәгән иде инде. Карап тордым-тордым да, өстәлдән аракыны алып, яшереп үк куйдым. Малайларга шундук җан керде.

...Ул елны Кыям абзыйлар гаиләсенә дә бәхетсезлек килде — җәяүләп кенә түгел, машина белән. Колхозларга һәр ел иген өстендә Уфаданмы, Эстәрлетамактанмы колоннасы белән машина килеп, иген ташырга ярдәм итәләр. Колхозның үз машиналары да икмәктә, билгеле. Ул чакта колхоз һәр шофер янына бер грузчик утыртып йөртә торган иде. Кирәге бармы-юкмы, йөртәләр шулай, хезмәт көне бирәләр. Кыям абзый үз янына сигезенчедә укыган малаен алган, ә Гөлфияне теге шоферларның берсе янына утырткан. Нигә алай иткән? Нигә кыз баланы үзе янына утыртып, малаен тегеләргә бирмәгән? Ни булса булган, инде үкенсәң дә — соң. Теге шофер моңа егетмен дигән, яшь, чибәр булган. Кыскасы, уйнап-шаярып башлаганнар да, чын белән бетергәннәр. Бу хәл бөтен авылга фаш булды. Ә теге «егетнең» Эстәрлетамакта хатыны, ике кызы бар икән. Беркөн Кыям абзый безгә кереп, өстәлемә капланып елады.

— Нишләтте бу бала безне? Нишләтте?.. — ди. — Авыру әнкәсен терелгәй кара гүргә тыга бит инде. Сажидә апаң әнә башын да калкыта алмый, түшәктә ята... Киңәш ит, Хәнәфи. Синең башың кайгыдан катса да, безнеке төсле, аракыдан агуланмаган бит, нишлим? — ди.

Агуланган дип, Кыям абзый алай эчә торган кеше түгел. Шулай да бүген шактый салган иде.

— Монысы кайгыдан инде, апай, гаепләмә, — ди.

— Соң, Кыям абзый, — мин әйтәм, — нишләп син алай үз янына малаенны утыртып, чит-ят шофер янына бердәнбер кызыңны утырттың? — дим. Минем дә йөрәк яна. Янмыйча, үземнең туган сеңелем шикелле, күз алдымда бөтерелеп-уйнап үскән кыз бит! Гөлбәдәр ташлап киткәч, карангы көннәремне якты иткән дә — шул; ул булмаса, миңа бәхетсезлек унлата авыр булган булыр иде.

— И Хәнәфи, и апай!.. — дип, Кыям абзый башын гына чайкый. — Барысын да каян белеп бетерәсең? Иртәгә үләремне белсәм, менә бүген кабер казып куяр идем дә бит... Үлмәм дә, каберем авызын ачкан килеш мине көтеп ятар дип кенә куркам...

Мин аңа бер киңәш тә бирә алмадым. Ни киңәш бирим соң инде мин? Закон аша мәҗбүри никах ясагыз да, шуның белән эше дә бетәр, дип әйтер идем... Теге хайванның гаиләсе бар. Аңа хайван дип әйтү генә дә аз!.. Ярый, мин уйлыйм, минем аяк юклыкка сугыш гаепле булсын, дим. Гөлбәдәрнең дә мине ташлап кияүгә чыгуына сугыш гаепле булсын ди. Ул инде, әйдә, Ватан өчен үләргә киткән бер солдатка чыккан ди. Ул солдатка хәләл дә ул. Ә бу сволочька ни кирәк? Аның да ике кызы үсә ди бит. Ул шуларны уйламады микәнни?

Ә монда Кыям абзый башларын өстәлгә бәрә.

— Хур итте бит бу кыз безне, хур итте! — ди. — Затлыдан затсыз туган, дип, менә шундыйга әйтәләрдер инде ул, ди. Әллә бер кызганда, кайтып,

чабып кына үтерим микән? — ди. — Ичмасам, төрмәгә эләгеп, халык күзеннән читтә үләр идем, — ди. Шуннан башын күтәреп мина карады.

Миннән сүз көтә бу. Күзләре хәсрәттән җыерчык эченә чумган. Бу — әтием кебек ягымлы, акыллы Кыям абзый түгел, әллә кем иде. Куркып киттем.

— Юк, Кыям абзый, — мин әйтәм, — мине якын итеп кинәшкә кергәнсен икән, андый кансыз сүзне авызына да алма. Беләм, синең башка минекеннән дә ныграк кайгы килгән. Синең кайгы — минем дә кайгы. Гөлфия минем өчен дә туганым урынына күреп йөргән, яраткан сенелем бит!.. — дидем.

Кыям абзый кинәт бөтенләй икенче, каты күз белән мина карады.

— Хәнәфи, — ди бу, — башыма бер уй төште, әйтсәм, үпкәләмәссеңме? — ди.

— Әйт, Кыям абзый, — мин әйтәм.

— Ал син Гөлфияне, — диде бу капыл. Китереп башыма суккандай итте. — Кулдан кулга киткәнче алып кал...

— Туктале, Кыям абзый, туктале... — дим.

— Туктадым инде менә — сиңа туктадым. Кешедән калган кызын миңа тагарга итә дип уйласаң — үпкәлим.

— Нишләп әйтим инде, Кыям абзый. Эш андамыни?

— Ә нәрсәдә?

— Бу бит йөрәк эше.

— Йөрәк эшен әнә эшләгәннәр инде...

Шулай эчемә ялкын сибеп чыгып китте бу. Гөлфиянең үзенә әйткәнмеюкмы, мәгәр Гөлфия хәзер бер дә элеккечә түгел. Сөйләшми дә, көлми дә. Күз алдымда ябыгып, ямьсезләнеп бара. Мин инде хатын-кызның балага узган чагын беләм, күрмәгән кеше түгел.

Яна ел житеп килә иде инде. Шулай бер кичне бу безгә болай гына керде дә, ишек төбеннән дә узмыйча әйтә:

— Мин берничә көнгә китеп торам, мине югалтма, Хәнәфи абый, — ди.

Мин кыек-мыек кылмыйча, туп-туры сорадым:

— Әти-әниең җибәрәме, әллә юкса үз башың белән барасыңмы?

— Үз башым белән, — ди.

— Утыр әле, — дип утырттым моны. — Син бу адымыңның ахырын уйладыңмы?.. Син бит әле яшь!.. Соңыннан үкенмәссеңме?.. — дип каты гына әйткәләп алдым.

— Бармыйча нишлим соң? — дип, Гөлфия елап җибәрде.

— Әгәр мине тыңласаң, беркая да бармыйсың.

— Ничек?..

— Шулай, баланны үзем карармын... бергә карарбыз...

Гөлфия яшь тулы күзләре белән мина күтәрелеп карады. Күзен күтәргәндә, түгелеп киткәндәй, яшьләре алдына тамды.

— Мин сиңа тиң түгел, Хәнәфи абый... Мин үз намусымны саклый алмадым бит!..

— Безнең язмышлар тиң, — дидем мин.

Гөлфия мина үрелеп тотарлык җирдә генә утыра иде. Бер генә тапкыр булса да чәченнән сыйпап, иңбашларыннан сөеп аласым килә. Бер генә атлам. Ләкин куркам. Хәсрәтле вакытында, зур башы белән нишли бу дип, әллә ни уйлавы бар. Юкса бик якын, бик ягымлы да бит...

— Уйла, сенелем, — дидем мин.

— Болай гына булмый бит әле, Хәнәфи абый. Бер дә уйламастан, бик кинәттән әйттең. Әти ни әйтер?..

— Әтиләрең белән үзем сөйләшәм.

Өстемә генә элдем дә Кыям абзыйларга кереп киттем. Бик җиңел генә сөйләшермен дип уйлаган идем дә, урын өстендә яткан Сәҗидә апаны күргәч, чын-чыннан унсигез яшьлек егет кебек каушадым да калдым. Ни әйтсәң дә, Гөлфия белән минем яшь аермасы унбер яшь.

— Мин менә... Кыям абзый, Сәҗидә апа, ни бит... Гөлфия турысында кердем әле, — дип сүз башладым. — Үзегез беләсез инде, Кыям абзый, Сәҗидә апа... мин сезнең күз алдыгызда үстем. Менә Гөлбәдәрем бар иде... Ул барда да, ул юкта да бозык юлдан йөрмәдем...

Кыскасы, шулай әйләнә-әйләнә үзәккә керергә чамалыйм, Сәҗидә апа түр стена буендагы никель караватта ята. Түр тәрәзә буенда өстәл. Мин өстәлнең бер башында, Кыям абзый икенче башында. Мин Сәҗидә апага йөзем белән, Кыям абзый аркасы белән утырган. Ул, яртылаш әйләнеп, Сәҗидә апага карады, үтә ягымлы тавыш белән:

— Син, әнкәсе! — дип дәште дә сөйли башлады: — Менә Хәнәфи Гөлфиябезне сорап кергән. Ничек уйлыйсың? Әгәр башта минем сүзне ишетәсең килсә, әйтим: мин риза, Хәнәфи үзебезнең кеше. Бозык юлны белми. Җәл, моңа тикле сорый белмәде.

Сәҗидә апаның, сүз әйтәсе урынга, күзеннән сытылып яше ага башлады.

Кыям абзый миңа борылды:

— Ярый, Хәнәфи, син чыга тор, мин үзем җавабын алып керермен.

Мин ул көнне күбрәк йөреп ташлаганмын, ахры, аякларым сызлап тора иде. Сәҗидә апаның яшьле йөзенә карамаска тырышып, атлаган саен шыгырдый-шыгырдый, ишеккә юнәлдем. Гариплегемә текәлеп калган яшьле карашны җилкәм белән сизеп атлаганлыктан, аягым гына түгел, йөрәгем дә сызлап куйды.

Гөлфия һаман шул урынында утыра иде әле. Дөрес, ул инде еламый, яшьләре кипкән, ләкин урыныннан кузгалмаган, мин чыгуны көтеп утыра иде, күрәсең. Ләкин күтәрелеп карамады. Карамавы, бәлки, әйбәт тә булгандыр. Өстемнән салдым да кухня ягына чыгып самавырга тотындым.

— Нишлисең, Хәнәфи абый, кая, үзем, — дип, Гөлфия килеп чыкты да иплэп кенә кулымнан самавырны алды.

— Хәзер әтиең керә, чәй куярга кирәк, — дидем мин.

Башкача сөйләшмәдек. Төрлесе төрле чынаяклар алып, өстәлгә чыгарып куйдым. Авыл җирен беләсез, кирәк чакны гына магазинга чабып булмый, өйдә ни бар, табыныңа шуны чыгарасың.

Кыям абзый озак көттермәде. Гадәтенчә сабыр гына, салмак кына атлап килеп тә керде. Кырынып чиста күлмәкләрен киеп җибәргән.

— Хуш, чәйләр әзерләп йөрисез икән! — диде ул. Йон оекбаш өстеннән генә кигән галошын салып, өстәл янына килеп утырды. — Бүгенге көнне башкасы булганда да мишәйт итмәс иде дә бит, магазины ябык. Ярый, болай да ярар инде, — ди.

Гөлфия берсүзсез чәй ясый башлады. Мин теге яшереп куйган яртыны китереп утырттым.

— Өйдә рюмкалар да калмаган инде, Кыям абзый, гаепләмәссең, — дип, кырлы стаканга аракы салып бирдем.

— Ярый монысы да, — диде Кыям абзый. Стаканын читкәрәк этәреп, бер миңа, бер Гөлфиягә карап алды. — Йә, утырышыгыз. Син дә утыр, кызым.

Гөлфия дә утырды.

— Кызым, — дип, Кыям абзый йомшак кына сүз башлады. — Үзең

беләсең, менә Хәнәфи абыең безгә сине сорап кергән иде. Менә мин үземнән дә, сырхау әниеннән дә ризалыгын алып кердем. Үзең беләсең, монда инде бернинди дә көчләү юк. Кыз бала гел ата-ана янында тормый, вакыты җиткәч, шулай китә инде ул. Ата-ананың ризалыгы булган җиргә китү күңеллерәк...

Минем колагым Кыям абзый сүзләрендә, ә күзем Гөлфиядә. Ул тын гына елый башлады. Күз яшьләре шулай өстәл өстенә тама да тама, Гөлфия аларны, битеннән сөртәсе урынга, өстәлдән сөртеп утыра. Кыям абзыйның да күңеле тулган, күз төбеннән бер-ике бөртек яшен сыпырып төшерде, аннары:

— Ярый, бәхетле яшәгез, — диде дә, сусаган кешедәй голт-голт итеп эчә башлады. Эчкән кешенең рәхәт: шатлыгын да, кайгысын да аракы белән юа да төшерә.

Шул көннән без Гөлфия белән тора башладык. Яңа елда туй сыман бер нәрсә үткәрдек. Беркемне дә чакырмадык. Безнең семья дүртәү. Кыям абзыйларныкы бишәү — бала-чага белән бергә түгәрәкләнеп утырдык та, туебыз шул булды. Туйдан соң Гөлфия тагы бер кабат больница турында сүз чыгарды. Ләкин мин авызын ачырмадым.

— Әтисе бер намуссыз булган икән, аның өчен карындагы сабый гаепле түгел, — дидем.

— Кеше әллә нәрсә сөйләр бит.

— Төкер кеше сүзенә. Әше югы сөйләр, эше бары тыңлап тормас, — дидем.

Пычак тидертмичә, имгәттермичә бәбәй таптырдым шулай. Үзегез күрдегез бит: нинди кыз әнә. Исеме дә — Ләйсән! Аннан башка әле безнең тагы бер кызыбыз бар. Анысы өйдә калды, әнисе белән. Ә без менә дүртәүләп гуләйт итеп йөрибез...

## 5

Хәнәфи сүзеннән туктап, башын артка ташлады. Инде караңгы төшеп, су өсте кара кургаш төсенә кергән, ул хәзер су кебек тә түгел, тун бер матдә кебек. Пароход тирәсендә генә, сыек ут яктысында кыймылдап, өзлексез артка агыла иде. Безнең аста гына, йөрәк типкән шикелле дөп-дөп килеп, куласа әйләнә. Ә пароход ерак маягына турылаган да, бара да бара, бара да бара. Без аны хәтта юл язар дип уйламыйбыз да. Без аның туры барасына ышанганбыз. Чөнки аның маяклары бар. Ә тормышта маяклар бармы соң? Тормыш диңгезе моның ише генәме — тирән дә, киң дә бит ул. Анда утыртып куйган маяклар да юк. Анда синең ышанычың гына маяк. Шул изге ышанычы югалмаса, йөрәге ялгышмаса — кеше бервакытта да адашмый. Менә бит — үз юлы белән барган, аягы булмаса да егылмаган.

Хәнәфи күккә караган иде. Күк йөзе дә су өсте шикелле караңгы. Ләкин ул чиста кара. Йолдызлары да терекөмештәй чәчрәп тора. Хәнәфи күктән күзен алды.

— Менә шулай икән ул, абый. Бәхете дә, хәсрәте дә агач башыннан йөрми икән, адәм башыннан йөри икән ул.

— Шулай, — дидем мин дә. — Берәүнең дә бурасы буш түгел.

— Менә балаларны Казан күрсәтеп кайтам әле, — дип, Хәнәфи оста гына итеп сүзне икенчегә борды. — Юкса бөтен укыган китаплары Казанныкы, ә Казанны күргәннәре дә юк. Үзем дә бик сагынган идем инде. Кара, әйтмәгәнмен икән: сугыштан соң безне Казан госпиталенә кайтардылар. Безнең Башкортстаннан да байтак идек без. Сиксәненче мәктәп, унбишенче мәктәп, тагын ике мәктәп, тагын Мехчылар клубы — бары да аяксызлар госпитале иде. Ундүрт ай яттым мин Казанда. Ул вакытта инде, үзегез

беләсез, Казанны тәрәзә аша гына күрә идек. Шуннан соң егерме ел буена жыендым — егерме ел буе килә алмадым. Быел менә килдем. Малайлар алып килде инде. Аяксыз булсам да, иркенләп карап чыктым. Яңа районнарына бармадым, билгеле. Аларын үзебезнең Уфада да карап була дип, Казанның гел иске урамнарында йөрдем. Малайларга да бик ошады. Казан Казан инде ул! Иске көенчә дә бернинди яңа шәһәреңә биргесез!

Без әле Казанда гына тормадык, шәһре Болгарына да життек. Малайның зурысы тарих, археология белән кызыксына. Безнең авыл яныннан берничә ел элек Уфасыннан да, Мәскәвеннән дә галимнәр килеп, әллә нинди борынгы каберлекләр актарып таптылар. Без аларны бәләкәй чакны әүлия зираты дип йөри идек. Болар скифлар диме шунда, сарматлар диме — шулар каберлеге икән. Шулар янында йөри торгач, минем малай да әвәреп китте. Казанга барсак, Болгарга да барабыз, дип кенә куйды. Юкса болгарлар турында да соңгы елларда күп яза башладылар бит. Болгар дигәннәре, кара син аны, нинди һөнәрле, культуралы халык булган икән лә бит! Әнә безнең Чишмә[3] якларына кадәр килеп, нинди мәчетләр салып куйганнар, ә! Без үзебез дә, борынгылар сөйләвенә караганда, ничектер шул болгарларга килеп бәйләнәбез икән. Коръән күчереп язучы бабабыз булган, дип әйткән идем бит, шул бабай безнең авыл халкын болгардан китереп әйтә торган булган. Моны мин бәләкәйрәк чакта картәтәй сөйли торган иде. Ләкин үзе, кара крестьян булганлыктан, «Кемнәр соң ул болгарлар?» дигәнгә җавап бирә алмый иде. «Әллә тагы башкорт белән типтәр кебек җирлежирсез халык булды микән?» — дип, үзе дә аптырап утыра иде. Чыннан да кыпчагы булган әнә, нугае булган. Болгары да булган бит инде аның. Бөтен бер халыкны ана карынында ятканда ук кырып бетермәгәннәрдер лә! Ул халык та сездәме, миндәме яши торгандыр бит?.. Малай менә шулар белән кызыксына инде. Казан университетын да бик ошатты, киләсе елны шунда киләм дип дәртләнеп кайтуы әле.

Шунда кылт итеп сенелесе исемә төште:

— Ә теге сеңелегез укый алдымы соң?

— Инде эшли. Үзебезнең Уфа университетын бетерде.

Шул вакыт безнең янга Хәнәфинең кызы килде. Ул инде бая берничә тапкыр урап киткән иде. Ләкин әтисе бая, сөйләү белән мәшгуль булгач, хәзер-хәзер дип, һаман үз яныннан куып җибәрә торды. Әле инде кумады.

— Ресторанда ашыйсылары килә. Анда ямьле бит. Авыл баласы өчен башка ни кирәк? Малайлар да хәйләкәр: моны җибәрәләр. Әйдә инде, кызым, алай булгач. Әйдә...

Хәнәфи, кызының кулыннан тотып, урыныннан торды.

*Февраль — март, 1969*

---

[3] Уфа янындагы исеме атаклы район үзәге.

## ХАЛКЫНА БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

Бай тарихы, данлы һәм гыйбрәтле үткәне, өметле һәм якты киләчәге булган төрки-татарларның һәрбер адымы бәйсез дәүләт төзү теләгендә булу табигый. Дөньядагы һәр милләт үзенең дәүләте булуын тели. Бу закон бозу да яисә башкалар өчен куркыныч күренеш тә түгел. Борынгы чорлардан алып, бигрәк тә мәшһүр бабаларыбыз Аттила, Чыңгыз хан заманнарыннан бирле төрки-татарларның үз дәүләтен булдырып һәм башка дәүләтләргә дә көчле йогынты ясап яшәүләре билгеле. Шуңа да югалган дәүләтчелегебезне кайтару теләге 1917-1918 елларда да, XX гасырның 90 елларында да һәм бүген дә халыкның игътибар үзәгендә тора һәм киләчәктә дә шулай булып калачак.

Халык рухында тирән сакланып калган әлеге теләкне тормышка ашыру өчен көрәшне үз чорында дәвам итүче, әнә яна рух өстәүчеләрнең берсе Галимҗан Шәрәф була. Петроград тимер юл инженерлары әзерләү институты студенты буларак ул 1915 елда ук «Татар учагы» дип аталган студентлар оешмасы төзи. Ильяс һәм Җиһангир Алкиннар, бертуган Гани һәм Габдулла Абызовлар, Сәгыйть Кәримнәр белән татарның киләчәге турында уйланалар, үз Ватаннарын булдыру турында хыялланалар. Әлеге түгәрәк утырышларында Явыз Иванның колониаль сәясәте нәтиҗәсендә дәүләтчелеген югалткан Русия мөселманнарының милли-мәдәни үсеше мәсьәләләрен тикшерәләр, кайбер татар зыялыларының пантюркизм һәм панисламизм белән мавыгуларын тәнкыйтьлиләр, мөселман халыклары мәдәниятенә кагылышлы башка мәсьәләләр буенча фикер алышалар. «Татар учагы» әгъзалары Казан, Саратов, Киев, Ростов һәм башка шәһәрләрдәге фикердәшләре белән элемтә булдыралар. Аерым алганда, 1917 елның августында Дон өлкәсендә үткәрелгән мөселман эшчеләре съездында «Татар учагы» әгъзасы Гани Абызов та катнаша, анда Екатеринослав, Лозовая, Павловка кебек шәһәрләрдән килгән татар шахтерлары һәм аларның җитәкчесе Зәйнулла Булушов һәм Казанда үткән мөселманнар съезды делегаты Нурулла Бикашов белән аралаша. Гани Абызов Петроград студентлары исеменнән Киевтагы мөселман студентлары янында була. «Татар учагы»ның икенче әгъзасы Солтанбәк Мамлиев Уфа белән тыгыз элемтәдә тора.

Февраль һәм Октябрь инкыйлаблары Г.Шәрәфнең язмышын кискен үзгәртеп җибәрә. Ул укуын ташларга мәҗбүр була һәм аны яңа вакыйгалар дулкыны үз эченә бөтереп ала.

Мәгълүм булганча, 1917 елның май аенда Мәскәүдә Бөтенрусия мөселманнарының беренче корылтае җыела. Анда 900гә якын делегат катнаша. Съездда Э.Цаликов, Г.Ибраһимов, Г.Терегулов, Ф.Туктаров, Ә.Мөхетдинова, Галимҗан, Борхан һәм Гыйльметдин Шәрәфләр, М.Бигиев, Г.Исхакый, А.Рәсулзадә, З.Валиди һ.б. катнаша. Корылтайда эшче-крестьяннар, хатын-кызлар тормышы, милли мәдәният мәсьәләләре карала һәм тиешле карарлар кабул ителә. Әлеге мәсьәләләрне тикшергәндә Галимҗан Шәрәф тә ялкынлы чыгышлар ясый. Корылтайда игътибар үзәгендә торган һәм күп бәхәсләр тудырган проблема — Русиядәге дәүләт төзелешенең нинди булырга тиешлеге хакындагы мәсьәлә. Делегатлар төбәкләрдәге милли яшәешнең әлеге мәсьәләнең Русиядә ничек хәл ителүенә бәйле булуын яхшы аңлыйлар. Корылтай күпчелек тавыш белән Русиянең демократиягә нигезләнгән федератив республика булырга тиешлеге турында карар кабул итә. Бу исә мөселман сәясәтчеләренең милли мәсьәләнең нәзари һәм гамәли нигезләрен үзәктәге шовинистларча фикер йөртүчеләргә караганда тирәнрәк аңлауларын күрсәтә.

Июль аенда Казанда сәяси тормыш кайный: бер үк вакытта диярлек Русия мөселман хәрбиләре, татар укытучылары һәм мөселман руханилары корылтайлары үткәрелә. Һәркайсының игътибар үзәгендә мөселман халыкларының дәүләтчелеген булдыру мәсьәләсе тора. Галимҗан Шәрәф корылтайдагы докладында татарлар өчен «туфраклы мохтарият» (территориальная автономия) кулай булачагына басым ясый. Аның бу фикерен И.Алкин, Ф.Кәримов белән Ф.Туктаровлар да хуплый. Корылтай мөселман халыкларының иҗтимагый-сәяси эшчәнлекләре белән идарә итү һәм Вакытлы хөкүмәт белән элемтәдә тору өчен Башкарма орган сайлый. Ул Бөтенрусия мөселман комитеты дип атала.

Галимҗан Шәрәф, Татарстанның мөстәкыйль дәүләтчелеге тарафдары булса да, милли-мәдәни мохтарият ихтималыннан да баш тартмый. Шуна күрә дә аны милли-мәдәни мохтариятне гамәлгә ашырырга тиешле комитет составына сайлыйлар. Бу комитетның әгъзалары итеп И.Әхтәмов, Ә.Мөхетдинова, Ф.Кәримов, К.Кәрим һәм Н.Хәлфин дә сайлана.

Мәскәү һәм Казан съездларыннан соң, ниһаять, 1917 елның 22 ноябрендә Уфада Милли мәҗлес сессиясе ачыла. Анда килгән 96 депутат арасында Г.Шәрәф тә була. Сессия президиумының рәисе итеп Дәүләт думасы әгъзасы Садри Максуди, сәркатибе итеп Габдрахман Фәхретдин раслана. Милли мәҗлес 1918 елның 11 гыйнварына кадәр эшли. Аның эшчәнлегенең бөекмәмләкәтчеләр теләмәгән юлга кереп китү ихтималын абайлаган Русия Халык Комиссарлары Советы (Совнарком) шул көннәрдә «Бөтен Шәрекъ һәм Русиянең мөселман хезмәт ияләренә мөрәҗәгать»ен кабул итә. «Мөрәҗәгать»тә «Мөселман хезмәт ияләре үз тормышларын берниндн ирексезләүләрсез, үзләре теләгәнчә төзи ала, үз диннәрен тотарга хокуклы, аларның бу хокуклары инкыйлабның, Советларның бөтен көче белән сакланачак», диелә. Әлбәттә, документның Милли мәҗлес депутатларына тәэсире зур була. Һәр милләткә үз тормышын үзе теләгәнчә корырга ирек бирү вәгъдә ителгәч, Мәҗлес депутатлары арасында милли-дәүләтчел төзелеш мәсьәләсенең беренче урынга чыгуы һич тә гаҗәпләнерлек хәл түгел. Бу юнәлештә тәүге адым буларак «Идел-Урал штаты»н төзү игълан ителә. Моңа ирешү өчен «туфракчылар» фракциясе әгъзасы Г.Шәрәф тә шактый көч куя. Ул фракция исеменнән «туфраклы мохтарият» хакында махсус доклад белән чыгыш ясый, булачак җөмһүриятнең атамасын «Идел-Урал штаты» дип расларга тәкъдим итә, җөмһүрият мәйданының картасын төзи. Әлбәттә, бу мәсьәлә шома гына узмый, ике фракция — «төркичеләр» һәм «туфракчылар» арасында кискен көрәш бара. Шунысын да әйтү кирәктер, большевиклар, сул эсерлар, гомумән, суллар фракциясе «туфракчылар» ягыннан чыгыш ясый. Ниһаять, алар тәкъдиме өстенлек ала. «Идел-Урал штаты»н гамәлгә ашыру буенча Галимҗан Шәрәф рәислегендә махсус комитет төзелә, аның составына Галимҗан Ибраһимов, Ильяс Алкин, Сәлах Атнагулов, Фатыйх Сәйфи, Сәет Енгалычев, Нәҗип Хәлфин һәм Фатих Мөхәммәдъяров керә. Аларның барысы да җәмгыяви бертигезлек буенча сайланучы Советлар нигезендә мөстәкыйль җөмһүрият төзү тарафдарлары була.

«Идел-Урал штаты»н төзү комитеты Казанга күчкәч, аның — Президиумы рәисе итеп И.Алкин, ә урынбасары итеп Г.Шәрәф раслана. Г.Шәрәфнең милли дәүләтчелек төзелеше турындагы фикерләре беркадәр үзгәрә. Беренчедән, ул «Идел-Урал штаты»н федерация составындагы мохтариятле җөмһүрият итеп төзергә тәкъдим итә. Икенчедән, хакимият органнары советлар системасы буенча сайланырга тиешләр, ди. Өченчедән, һәр совет халыкның милли нисбәтен искә алып сайланырга тиешлеген яклый.

Кызу бәхәсләрдән соң, күпчелек тавыш белән Г.Шәрәфнең тәкъдиме кабул ителә. Әмма аның элекке тарафдарлары Г.Шәрәфнең фикерләре үзгәрүне кабул итмиләр һәм Казан белән Уфа матбугатында аңа «гомумхалык сайлаган җыелыш карарларын бозганы өчен» шелтә белдерелү турында хәбәрләр басыла. Шулай да бу вакыйганы Г.Шәрәфнең «Идел-Урал штаты»ннан ваз кичүе дип бәяләү дөрес булмас иде. Ул, зирәк сәясәтче буларак, мәҗлестә кабул ителгән карарга вәзгыятьнең үзгәрүенә бәйле кайбер үзгәрешләр кертү зарурилыгын аңлап эш иткән булса кирәк.

Галимҗан Шәрәфнең бөтен теләге Милли мәҗлестә кабул ителгән «Идел-Урал штатын»тормышка ашыру, ә моның өчен Казанда бөтен мөмкинлекләр дә була:

милли оешмалар, хәрби көчләр, матбугат һ.б. Алар 1918 елның 8 гыйнварында башланып киткән Икенче мөселман хәрбиләре съездында актив катнаша. Съездда «Идел-Урал штаты»н 1918 елның 1 мартында игълан итү хуплана. Съезд унышлы башланып китә. Большевиклар партиясе әгъзалары, мөселман комитеты вәкиле Шиһаб Әхмәров, Балтыйк буеннан, Польшадан килгән, шулай ук чуваш, мари, мордва, башкорт делегатлары бердәм булып съездны һәм «Идел-Урал штаты»төзелүне сәламли. Әмма тиздән большевикларның каршы астыртын эш алып барганлыгы ачыклана һәм Президиум рәисе буларак И.Алкин, документлар файдаланып, моны фаш итә. Большевиклар исә, яшертен очрашулар оештырып, съезд делегатларына «капкын» әзерли. «Идел-Урал штаты»н игълан итәргә бер көн калганда, 28 февральгә каршы төндә, съезд җитәкчеләре кулга алына. Шулай итеп, «Идел–Урал штаты»н игълан итү өзелә һәм Казанда хәлләр кискенләшә. Мона Гайнанетдин әл-Болгариның — вәисовчеләр җитәкчесенең үтерелүе дә кушылып китә. Шәһәрдә кан коелу куркынычы туа. Галимҗан Шәрәф кан коюны булдырмау өчен зур тырышлык куя: Совет органнары һәм 2 нче мөселман съезды җитәкчеләре, Хәрби шура вәкилләре арасында сөйләшүләр алып бара. Озак еллар дәверендә кан коюны большевиклар булдырмады дигән уйдырма яшәп килде. Бу дөрес түгел, киресенчә, алар халыкны кискенләштереп, провокацияләр ясап торалар. Шуның бер мисалы булып Гайнанетдин Вәиси әл-Болгариның фаҗигале рәвештә һәлак булуы тора. Хәрбиләрдән полковник Әкрам Бигловның да тынычлык ягында булганлыгы мәгълүм. Сөйләшүләрнең берсендә ул: «Без канлы бәрелешне булдырмас өчен бөтен көчне куярбыз, әмма совет хакимияте «Идел-Урал штаты»н төзүгә ирек бирмәс, аларга ышанычым юк»[1], — ди. Милләт мәҗлесендә төзелгән Хаят белән Икенче бөтенрусия мөселман хәрбиләре съезды оештырган Хәрби коллегия арасындагы мөнәсәбәтләр Казанда канлы бәрелешне булдырмауда төп рольне уйный.

Бу хәл татар халкына хас түземлелек, гаделлек, башкаларга юл кую кебек сыйфатларның көчле булуын күрсәтә. 1918 елда татар зыялылары артык тыйнаклык күрсәткәннәр, диючеләр дә бар, әмма татар миссиясе тыныч юл белән генә тормышка ашырылырга дучар ителгән. Ул шулай булачак та.

1918 елның 22 мартында Татар-башкорт Совет Республикасы хакында декрет чыга. »Йолдыз» газетасы язуына караганда, күпчелек морадыбызга ирештек, Мәскәү белән килешү булды, динебезне саклап калдык, телебезгә дә ирек булыр, дип тынычлана. Әмма әлеге тынычлану озын гомерле булмый. Шул көннәрдә үзәк икенче ударны әзерли.1918 елның 28 мартында пулеметлар белән коралланган 300 матрос броневикларда Казан урамнарында һәм базарларда хулиганлык кылып, халыкны өркетеп йөри. Кулга алулар башлана. Мөселманнарның икенче съезды карары белән Болак артында 1552 елдан соң беренче мәртәбә татар халкының демократик юл белән сайланган хакимият органы — «Мөселман халык комиссариаты» оеша. Аның составына Исмәгыйль Атнагулов, Исхак Алмаев, Габдулла Габдрәшитов, Фәхрелразый Басыйров, Әкрам Биглов, Әфтәхетдин Габдуллин, Сөләйман Ловчицкий, Гали Моракаев, Фатих Мөхәммәдьяров, Сөләйман Полторжицкий, Кәшшәф Терегулов, Адәм Якубовский, Әхмәтсолтан Таһиров керә. Комиссариатның рәисе итеп Исмәгыйль Атнагулов, рәискә иптәшлеккә И.Кәрим, И.Алмаев, сәркатиплеккә Г.Габдрәшитов, К.Терегулов сайлана. Чынлыкта әлеге оешмага «Идел-Урал штаты» проектын тормышка ашыру эше йөкләнә. Комиссариат «Мөхтәрәм мөселман кардәшләр!» дигән мөрәҗәгать кабул итә. Әлеге мөрәҗәгатьтә төп максатлар күрсәтелә»[2].

«Идел-Урал өлкәсе» гәзитенең әлеге мөрәҗәгать басылган 24 нче март санында Ф.Басыйровның «Төрки-татар демократиясенең таләпләре» исемле мәкаләсе дә урнаштырылган. Анда «Идел-Урал»ны тормышка ашыру, бу өлкәләргә караган советларның составларын үзгәртү фикере яклана. Тиздән үтә актуаль таләп туа: Татар-башкорт җөмһүриятенә кергән советларның съездына, җир һәм милли составны искә алып, яңадан сайлаулар уздыру. Әмма болар яхшы теләк кенә булып кала, чөнки барысы да искечә эшләнә, төрки-татар демократиясенең таләпләрен

[1] Вәлиев Р. Болак арты республикасы. — Казан: Татар.кит.нәшр.,1999. — 49 б.
[2] Шунда ук.–57-58 б.

исәпкә алмыйча гына советлар тарафыннан «ленинчыл һәм сталинчыл милли сәясәт» тормышка ашырыла.

Мәгълүм булганча, Үзәк тарафыннан уйланылган Татар-башкорт Совет Республикасын төзү эшен И.Сталин үз кулында тота һәм бу гамәлләргә Галимҗан Шәрәфне дә тарта. Г.Шәрәф язуына караганда, башта аны телеграфка чакырып, «Идел-Урал» чикләре турында мәгълүмат алганнан соң, берничә көн үткәч, И.Сталин тарафыннан кул куелган Татар-башкорт Совет Республикасы турында күрсәтмә игълан ителә.

28 февральдән соң аска тәгәри башлаган милли хәрәкәт, Татар-башкорт Совет Республикасы турындагы күрсәтмә дөнья күргәч, бөтенләй диярлек тынып кала. Беренчеләрдән булып «Идел-Урал штаты» коллегиясе эше туктала. «Татар-башкорт Совет Республикасы турындагы күрсәтмә чыккач һәм аны төзү өчен махсус коллегия барлыкка килгәннән соң, безнең коллегия үз эшен туктатты», — дип яза Г.Шәрәф. II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съезды тарафыннан төзелгән Мөселман халык комиссариаты да эшен туктатырга мәҗбүр була. Казан шәһәр Советы каршындагы Мөселман комиссариаты һәм өлкә комитеты түбәндәге карарны игълан итә: «Үзенең асылы белән контрреволюцион булган «Идел-Урал» өлкә комиссариаты вәкилләреннән һәм Совет комиссариатының кайбер әгъзаларыннан оешкан шәһәрнең татар өлешенең Революцион штабын юкка чыгарырга һәм яңа вакытлы Пролетар революцион штаб төзергә. Шәһәрнең Болак арты өлешендә контрреволюцион хәрәкәтне ахырынача бетерүне Мөселман эшләре буенча комиссариат шул Революцион штабка йөкли».

Милли оешмаларны, «Идел-Урал штаты»н, Болак артында дәвам иткән 2 нче мөселман хәрбиләренең съездын куып таратуга, тар-мар итүгә кызганыч ки, татар большевиклары М.Вахитов, М.Солтангалиев, С.Сәетгалиев, Я.Чанышев, Г.Касыймов, Х.Урманов, И.Галиев, С.Әхтәмов, К.Якубов һәм башкалар зур өлеш кертә. Нәтиҗәдә Хәрби Шура һәм Мөселман халык комиссариаты әгъзалары кулга алына. Берничә кеше кача. Тиздән корал җыю нияте белән Казан Советы өч кешедән торган штаб төзи. Ана Ефремов, Солтангалиев һәм Севров керә.

Гасыр башында башланып, 1917–1918 елларда яңа үрләргә менә алган милли-мөселман хәрәкәтенә үз заманында ук шактый югары бәя бирелә. М.Солтангалиев бер хатының «Болак арты республикасы»на кагылышлы юлларында болай дип яза: «Соңгы вакыйгаларның агымы безнең өчен куркыныч түгел иде. Бу вакыйгалардан соң оештырылган «Болак арты республикасы» да безнең өчен ул кадәр үк куркыныч булмады. Безгә оешкан рәвештә милли хәрәкәтнең калган өлешен бетерү мөмкинлеге туды. Үзәк тарафыннан Татар-башкорт Республикасын игълан итү безгә «шурачылар» белән көрәшергә һәм Кызыл Армияне, мөселман полкын оештыруда мораль куәт бирде. Мәскәүдән зур булмаган матрослар отряды китерттек һәм шәһәрнең бездән бер айга якын аерылып торган татарлар өлеше — «Болак арты республикасы» — хәрби частьларны анда керткәч, үзенең «тимер батальоннары» белән безгә сугышсыз бирелде».[3]

Икенче бер мәкаләсендә, шул вакыйгаларга бәя биреп, ул болай ди: «Шул замандагы эчке һәм тышкы хәлләрне искә алганда, без тәгаен әйтә алабыз: «шурачы»ларның чыгышы, соңрак булган чехословаклар чыгышы тарафыннан тудырылган «Самарская учредилка»га һәм Колчакка караганда, Совет хакимиятенә күбрәк бәлаләр китергән булыр иде. Менә ни өчен без татар хезмәт ияләре тарихындагы бу моментны иң җаваплы чор дип карыйбыз. Чөнки аның нәтиҗәсе Совет властена каршы Идел өстендә барлыкка килгән күк күкрәүләрне тарату яисә мәсхәрәле һәм данлыксыз рәвештә артка чигенү булуы ихтимал иде. Татар социалистлары җитәкчелегендә без аларның барлык махинацияләрен бер сугуда җимердек».

Инде сүзне большевикларның оппонентларына бирик. Әле 1918 елда ук «Йолдыз», «Корылтай», «Безнең тавыш» газитләре, меньшевикларның «Рабочее дело» һәм башка басмалары чыгып килә. Аларда Совет хакимиятенең, Милли Мәҗлеснең, II Бөтенрусия мөселман хәрбиләре съездының материаллары басыла,

[3] Мирсаид Султан Галиев. Статьи, выступления, документы.–Казань, 1992.- С.425.

«Болак арты республикасы»на карата булган мөнәсәбәтләр дә кин яктыртыла. Әлбәттә, соңрак күп кенә гәзитләр ябылып, бары тик большевистик басмалар гына дөнья күргәндә, әлеге вакыйгалар турында бары тик «милләтчеләр», «Забулачка» дип, мәсхәрә итеп кенә яза башлыйлар. 2нче мөселман съезды хакында бөтенләй язылмый, ә языла калса, бары тик «контрреволюцион җыелыш»,»милләтчеләр оясы» кебек уйдырмалар гына язылып килде.

Татар-башкорт Совет Республикасы төшенчәсе беренче карашка «Идел-Урал штаты»ннан әллә ни аерылмый кебек. Шул ук халыклар, шул ук территория. Әмма ТБСРның эчтәлегендә ике халыкны капма-каршы кую сизелә. Монда төрле фикерләрнең бер-берсенә каршы киләчәге көн кебек ачык. Мәгълүм булганча, В.Ленин, И.Сталин һәм җитәкчеләрнең башкалары да четерекле мәсьәләләрне чит куллар белән хәл итүне хуп күргән. Бу очракта да, әйтелгәнчә, И.Сталин, М.Вахитов, М.Солтангалиев, хәтта партиясез, чынлыкта В.Ленинның милли сәясәтен кабул итмәгән Галимҗан Шәрәфне һәм башка татар зыялыларын махсус комиссиягә (ул аны техник комиссия дип атый) җыеп, аларның эшчәнлегеннән оста файдалана, төрле вәгъдә-тәкъдимнәр белән үз ягына аудара. Шундый тәкъдимнәрнең беренчесе — Татар-башкорт Совет Республикасын төзү.

Большевиклар хакимияте, И.Сталин киң фронтта һөҗүмгә күчәләр. Төп удар милли хәрәкәтнең социалист-федералистларына гына түгел, хәтта большевиклар арбасын төптән җигелеп тартып барган «суллар»га да кагыла. М.Солтангалиев белән М.Вахитов моны беренче булып тотый.

«Болак арты республикасы» беркем өчен дә куркыныч тудырмыйча, аның асылы үз-үзен саклаудан гыйбарәт иде. «Большевикларның бетмәс-төкәнмәс җинаятьләренә тагын берсе өстәлде. Бу эш халык исеменнән эшләнде. Килер бер заман, халык исемен файдаланып кан коюны һәм халыкларны бер-берсенә бәрелештерүләрнең эчке серен аңлап, аларны җирәнеп искә алырлар», — дип белдерә ул чордагы оппозицион матбугат[4].

Инде 94 елдан соң әлеге мәкалә авторына, газета хезмәткәрләренә татар халкы исеменнән зур рәхмәтләребезне әйтәбез. Барыбыз да бер фикердә һәм бердәм булсак, «Идел-Урал штаты» бөтен Идел буе һәм Урал якларында яшәүче халыкларның яклаучысы булыр иде. Кызганыч ки, «Идел Урал штаты»н игълан итүне өзеп, 2 нче мөселман хәрбиләренең съездын куып таратып, бөтен милли оешмаларны ябып, Үзәк тиз арада И.Сталинның «автономизациясен»ә, ягъни хокуклары чикләнгән дәүләтчелек төзүгә юл ача. Бухарин белән Ленин арасындагы дисскуссия дә моңа тәэсир ясый. Бухарин унитар дәүләт яклы булып, бернинди автономияләр кирәкми фикерен алга сөрә. В.Ленин бу фикерне тәнкыйть итеп, бөтен Шәрекъ халыкларына автономия бирәчәкбез, ди. Ленин Сталинның «автономизация» концепциясен дә тәнкыйть итә, әмма вакытсыз вафат булуы аркасында планнары тормышка ашырылмый.

В.Ленин һәм И.Сталин Татарстан республикасын төзүне бик ашыгыч рәвештә уздыралар. Совнарком рәисе В.И.Ленин һәм Наркомнац рәисе И.Сталин Көньяк Урал һәм Идел буендагы 7 губернага җибәргән телеграммаларында 1918 елның 5 маенда булачак киңәшмәгә төрле халыклардан вәкилләр җибәрүне таләп итәләр. Монда ТБСР мәсьәләсе каралырга тиеш була. Күрсәтелгән срокка башкорт вәкилләреннән башка барысы да килеп җитә. Киңәшмә бары тик 10 майда гына эшли башлый. 7 көн дәвамында киңәшмә ТБСР мәсьәләсе буенча фикер алыша. Бу киңәшмәдә төп ике фикер була: беренчесе — ТБСРга каршылар, икенчесе — ТБСР төзүне тормышка ашыру кирәклеген алга сөрүчеләр. Өченче фикер буларак, мари һәм чуваш вәкилләре ТБСРга каршы булмауларын, бәлки чикләрен тагы да арттыруны сорыйлар. Әмма тиздән хәлләр үзгәрә. 1918 елның 13 июнендә булып узган Идел буе һәм Урал алды халыкларының ТБСРга багышланган киңәшмәсендә чуваш һәм мари вәкилләре ТБСР проектына каршы чыга.

Анда Г.Шәрәф «Идел-Урал штатлары» турында зур доклад белән чыгыш ясый. Ул үз фикерләрен дәлилләү өчен бик күп фактлар, статистик мәгълүматлар китерә. Киңәшмәдә аның төп фикерләрен хуплагандай булалар, әмма озакламый, үзәктәге

4 Рабочее дело. 1918. -17(30) марта

бөекмәмләкәтчел шовинистларның басымы астында, башкорт, чуваш, мари, мордва вәкилләре үзләренең фикерләрен капма-каршы якка үзгәртәләр: «Идел-Урал штаты»на гына түгел, «Татар-Башкорт Совет Республикасы»на да каршы чыгалар. Имеш, бу милләтләрнең тигезлегенә хилафлык китерәчәк.

Г.Шәрәф үз фикерләрен никадәр якларга тырышса да, унышка ирешә алмый. Әлбәттә, бу «үзгәреш»тә Милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты житәкчеләре (беренче чиратта И.Сталин) һәм В.Ленин да турыдан-туры катнашканнар дип фаразлауга нигез бар. В. Ленин үзенең бер чыгышында, без башкортларга автономия бирдек, башкаларга да шул ук сәясәтне алып барачакбыз, ди. Бу инде турыдан туры «Идел-Урал штаты» булмасын дигән сүз икәне һәркемгә аңлашыла.

Татарстан җөмһүрияте әнә шулай озакка сузылган тартышулардан, сәяси алдашулардан соң гына оеша алды. Татарларның төрле губерналарда чәчелеп яшәве дә эшне кыенлаштырды, чөнки аларның берсендә дә диярлек татарлар күпчелекне тәшкил итмиләр һәм шунлыктан мохтарият төзүгә нигез була алмый. Бу мәсьәләне гадел хәл итү өчен губерналар чикләрен генә түгел, бәлки өяз һәм волость чикләрен дә аларда яшәүче халыкның милли составына нисбәтле рәвештә үзгәртү таләп ителде. Әлеге очракта җирле идарә теләгән исәпкә алып һәм Мәскәүдәге архив документларын өйрәнеп эш итү кирәк иде. Бөекмәмләкәтчел Үзәк исә бу мәшәкатьләргә баруны артык һәм кирәкмәс эш итеп санады. Екатерина II тарафыннан бүлгәләнеп, төрле губерналарга кертелеп калдырылган татар-башкортларны һәм башка халыкларны барлау, исәпләү кебек эшләр дә Галимҗан Шәрәф тарафыннан башкарыла. Бу татар милләте өчен бик җаваплы эш булганлыктан, ул аны үз өстенә ала.

Булачак Татарстан җөмһүриятенең мәйданын һәм чикләрен билгеләү мәсьәләсендә Г.Шәрәфкә Милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты житәкчесе И.Сталин белән еш очрашырга туры килә. Ул үзе бу хакта болай искә ала: «В.Ленин һәм М.Калинин имзасы белән декрет (ТАССРны төзү турында — Р.В.) игълан ителгәнгә кадәр, Сталин комиссия эшендә башыннан алып ахырына кадәр бик актив катнашты. Безнең тарафтан якынча сузылган чикләр, аерым җентекләп эшләнгән кисәкләр, сәнәгатьне, авыл хуҗалыгын өйрәнү материаллары, теге яисә бу төбәкнең халык составы, административ төзелеш һәм шуларга охшаш башка әзерлек материаллары — барысы да Сталинга житкерелә, ә ул аларны үзендә калдыра да икенче утырышта үз төзәтмәләре белән кире кайтара. Г.Шәрәф барысын да ачык итеп яза алмаган булса кирәк: менә шушы «төзәтмәләр» аркасында «Кече Татарстан» барлыкка килә дә инде. Татарлар урнашкан күп районнар кертелми. Бигрәк тә Уфа һәм Бәләбәй өязләре әлегә беркая да кертелми. 1922 елда исә, референдум уздырырбыз дигән булып, Сталинның указы белән Кече Башкортстанга көчләп кушыла. Моны әлеге дә баягы Екатерина II, Романовлар алып барган, гомумән, Мәскәүнең шовинистик сәясәтен яңа шартларда уздыруның бер нәтиҗәсе дип карарга кирәк. Бу да тарихи факт. Монда бигрәк тә «бүлгәлә һәм хакимлек ит» сәясәте ярылып ята: татар-башкортны талаштырырга, ә инде чуваш һәм мордваны Мәскәү ягына тартырга... Халыклар теләгән искә алу юк. Шулай итеп, озак еллар дәверендә татар-башкорт милли демократиясенең һәм мордва, чуваш, мари вәкилләренең тырышлыгы белән оеша башлаган «бердәм административ берәмлек төзү» проекты юкка чыгарыла һәм шовинистик идеяләргә нигезләнгән тоталитар режимга юл салына.

Нәтиҗәдә, «Идел-Урал штаты» төзеләсе төбәктә 1920 ел урталарына өч административ берәмлек — Кече Башкортстан һәм Татарстан җөмһүриятләре, шулай ук Уфа губернасы барлыкка килә. Беренче төзелгән план буенча Уфа, Бирск шәһәрләре һәм Бәләбәй өязе Татарстанга кертелергә тиеш була. Ул вакытта моңа Зәки Вәлиди дә каршы килмәгән, чөнки анда татарлар күпчелек тәшкил итә. Әмма Татарстанның болай «зураюы» шовинистик үзәккә, аларның бүлгәләп хакимлек итү максатларына һич тә туры килми. Аларның нияте — Уфа белән Казанны Татарстан җөмһүриятенә кертмәскә. «Саллы» дәлилләре дә бар: Казанны Татарстанга кертсәң, аның фән үзәге буларак әһәмияте калмаячак. Мондый каршылыкны университетка оялаган шовинистлар аеруча хуплый. Бөтенрусия Үзәк Башкарма Комитеты аларны «тынычландырыр» өчен Казан университетының үзәккә буйсынулы булуы хакында махсус карар чыгара.

Казан губерна башкарма комитетының бер төркем бөекмәмләкәтчел шовинист тарафдарлары, Татарстан җөмһүриятен төзүнең урынсызлыгын дәгъвалап, хәтта Сталин белән Ленинга кадәр барып житәләр. Бу ачыктан-ачык шовинистик гамәл хәтта ВКП(б) Үзәк Комитетында һәм Халык Комиссарлары Советында да яклау тапмый: Татарстан җөмһүрияте төзелә һәм Казан аның башкаласы итеп тәгаенләнә. Уфа губернасының язмышы референдум юлы белән хәл ителергә тиеш булса да, гадәттәгечә, алдау белән тәмамлана.

Галимҗан Шәрәф монда да үзен чын милләтпәрвәр итеп күрсәтә. Әгәр дә ул эшләмәгән, көрәшмәгән булса, бүген без нинди хәлдә булыр идек соң? Инде моны аңларга вакыт җитте. Аның тарафыннан Татарстанның географик картасы төзелү, гарәп графикасын саклау өлкәсендә керткән хезмәтләре әле бүген дә актуаль икәнлеге барыбызга да билгеле. Шушы вакыйгалар дәверендә һәм соңрак Г.Шәрәф яңа режимның эчке серләрен аңлап, үзен халыкны агарту-укыту эшенә багышлап, көрәшен дәвам итә. Ул конференцияләрдә кызып-кызып докладлар сөйли, милләтенә хезмәт итүнең төрле юлларын эзли һәм таба. Менә шуларның бер дәлиле. Тоталитар режимның дәүләтчелек мәсьәләсен үз кулына алуын аңлагач, Г.Шәрәф халыкка белем бирү өлкәсендә хезмәт итәргә мәҗбүр була һәм тиз арада мәшһүр тел белгече булып китә. 1926 елда ул СССР Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты, ә 1929 елда эксперименталь фонетика буенча Халыкара ассоциациягә хакыйкый әгъза булып кабул ителә. Г.Шәрәфне XX гасыр башында татарлардан беренче академик дип карау дөрес булыр. Ул педагогика институтында эшли һәм татар телен укытуның яңадан-яңа ысул-алымнарын эзли һәм өйрәнә.

1920 елларда гарәп алфавитын юк итү кампаниясе башлангач, аны саклау буенча күп эш башкара. 1926 елда Бакуда булып узган конференциядә гарәп шрифтын саклау һәм үстерүнең кирәклеге хакында 8 тапкыр чыгыш ясый һәм нәтиҗәдә гарәп алфавитын саклап калуга өлеш кертә. Әмма Үзәкнең таләбе буенча гарәп алфавитын кулланугa киртәләр тудырыла. Моның белән килешә алмыйча, Г.Шәрәф 1927 елның 7 маенда И.Сталинга хат юллый: «Хөрмәтле иптәш Сталин! Сезгә үземнең «Төрки халыклар өчен латин хәрефләрен кабул итүгә карата» дигән хезмәтемне юллап, Сезнең игътибарыгызны түбәндәге моментларга юнәлтергә теләр идем.

1. Хәрефләрне алыштыру мәсьәләсе төрки халыклар арасында гомуми саннары берничә миллион исәпләнгән грамоталы һәм ярым грамоталы булган һәркемгә бик якыннан кагыла. Хәреф алыштыру мәсьәләсе — уку һәм язу процессында яңа күнекмәләр тудыру дигән сүз, ә бу, бик күп энергия һәм матди чыгымнар тотып, өр-яңадан укырга-язарга өйрәтү була. Миллионнарча укый-яза белүче кешеләр халыкның бөтен катлауларында таралган булу сәбәпле, бу эш массовый мәсьәлә булып тора һәм, һичшиксез, үзенә зур игътибар белән килүне таләп итә, уйламыйча гына әзерлексез эшләп булмаганлыкны күрсәтә, чөнки бөтен җәмгыяви катламнарның актив өлеше гадәттә халыкның укый-яза белгән өлешен тәшкил итә. Мондый адымның халыкның укый-яза белмәгән өлеше өчен нинди психологик тәэсир ясаячагы турында әйтеп тә торасы юк.

2. Абстракт рәвештә фикер йөрткәндә, хәрефләр алыштыру язма культура мәсьәләсендә чынлыкта бер халыкны элек яки бүген дә әлифбасы булмаган өммәткә төшереп калдыру дигән сүз, чөнки яңа графикага күчү элеккеге язмадан һәм язу күнекмәләреннән бөтенләй баш тартуга бәрабәр. Ике төрле язуны вакытлыча саклау һәм яңа графикага әкренләп күчү дә бары тик бу фактны яшерү, күчү кыенлыкларын өлешчә җиңеләйтү генә була.

3. Хәрефләр алыштыруга җитди карасак, бу гамәл дәүләттән зур чыгымнар таләп итәчәк, наданлыкны бетерүне яңадан башлауга, китапларны яңадан басуга, мәктәпләрдә ике төрле әлифба өйрәтүгә h.б. бәйле өстәмә матди чыгымнарга һәм күп төрле административ чаралар куллануны тәэмин итүгә китерәчәк.

4. Югарыда күрсәтелгән күпләп сарыф ителәчәк көч-дәрман һәм матди чыгымнар ахыр чиктә хәреф сызымнарының алышынуына гына китереп, яңа хәрефләрне өйрәнүчеләргә ни мәдәни, ни икътисади яктан бернинди уңай нәтиҗәләр бирмәячәк, чынлыкта кирәклеге әллә ни мөһим булмаган формаль адым гына булып калачак.

5. Уку-язуның тизлеге полиграфик яктан да, уку-язу ягыннан да латин хәрефләренең бүген төрки халыкларда гамәлдә булган һәм камилләштерелгән гарәп графикасыннан тулаем алганда бернинди өстенлеге дә юк. (Бу беркадәр парадоксаль булып яңгыраса да, чынбарлыкта, һичшиксез, нәкъ шулай.) Бу мәсьәләләр мин Сезгә җибәрә торган хезмәтемдә фәнни-оештыру ысуллары ягыннан бик җентекле тикшерелгән.

6. Хәрефләрнең халыкара кулланылышлары ягыннан караганда да, һәр тел аерым-аерым булганлыктан, латин әлифбасының бәйнәлмиләллеге тышкы яктан гына.

7. Төрки халыкларның мәнфәгатьләре күзлегеннән караганда, бернинди уңай алшартлар булмаган көе әлифба алыштыру мәсьәләсен куюү һәрьяктан зарарлы, ул гавамның ачуын кабартуга һәм ризасызлыгы артуга, Совет хакимиятенең мәдәни чараларыннан гомумән канәгатьсезлек белдерүенә китерәчәк. Гамәлдәге хәрефләрне латинчага алыштыру төрки халыклар арасында көчләп урыс транскрипциясе кертү турындагы 1907 елгы патша фәрманының («31 март кагыйдәләре») эчен тышка әйләндерү буларак кабул ителәчәк. Миссионерларның һәм ярыммиссионерларның латин хәрефләрен кертүдә ачыктан-ачык яки астыртын рәвештә катнашуы халыкның ризасызлыгын көчәйтәчәк кенә. Бәлки әлифба алыштыру бүген яхшы ният белән эшләнәдер, әмма соңгы нәтиҗәләре мәдәни үсештә торгынлыкка китергәнлектән, файдасыннан зарары күбрәк булачак.

8. Югарыда әйтелгәннәргә дә карамастан, бу мәсьәлә буенча Шәрекь Совет җөмһүриятләрендә яраклы һәм яраксыз алымнар белән чикләнмәгән коткылар таратыла, чынбарлыкта, бигрәк тә быел, латин графикасына күчүгә каршы ни телдән, ни язма рәвештә бер генә чыгышка да мөмкинлек калдырылмады.

9. Милли коммунистлар арасында күпмедер «латинчылар» булуы чын вәзгыятьне билгеләми, чөнки аларның барысы да диярлек якыннанрак танышканда йә төзәлмәс карьерачылар, йә үз карашларына җавап бирә алмый торган сай акыллы халык булып чыга.

Бу мәсьәләнең искиткеч зур сәяси әһәмияткә ия булуын истә тотып, Сезнең секретарьлардан берәрсенең минем бу язмам белән һәм узган ел Бакуда уздырылган тюркологларның беренче корылтаендагы докладларда һәм чыгышларда бәян ителгән фикерләр тупланган стенографик хисап белән Сезне дә таныштырып, Сезнең шәхсән үзегезнең бу мәсьәләгә беркадәр игътибар бирүегезне үтенергә җөрьәт итәм...

Стенографик хисапны Сезгә җибәрмәгән булсалар, аны Мәскәүдәге Бөтенрусия Шәрекьне өйрәнү ассоциациясеннән сорап ала аласыз. Инде тюркологлар корылтаеның бу мәсьәләләр буенча кабул иткән карарларына килгәндә, кызганычка каршы, алар ярым-йорты хәлдә һәм бу Шәрекь җөмһүриятләрендәге партия тәшкиләтләренең бик аз ярдәм итүләре белән аңлатыла. Бу мәсьәләнең зур игътибарга лаек булуын тагын бер мәртәбә ассызыклап әйтүне кирәк табам. Г.Шәрәф»[5].

Латин графикасын кертүне, гарәп шрифтын юк итүне Г.Шәрәф патша сәясәтенең дәвамы гына түгел, ә шовинизмның дәвамы итеп карый. Хәзерге демократия чорында да шовинизмның дума түрендә ничек «биегәнен» күрдек. Имеш, латин графикасы Россияне һәлакәткә китерәчәк... Менә бусы инде шовинизмның дәвамы икәнлеге һәммәбезгә дә билгеле. Совет хакимияте, башта латинны, ә аннан кириллицаны кертеп, халыкны үз тарихыннан аерды, янадан-яңа авырлыкларга дучар итте. Йөз процентка якын белемле халыкны наданнар рәтенә бастырырга тырыштылар. Шрифтны бетерү, ул төрки халыкларны алфавиты да булмаган халыклар рәтенә бастыру, дип яза Г.Шәрәф. И.Сталинга үзенең фәнни хезмәтен тәкъдим итә. Халыклар «атасы» белән шундый мөгамәләдә булган тагын кемне күрсәтә алабыз соң? Бу бит коры кыюлык түгел, ә фәнни нигездә язылган нәтиҗәләр. Гарәп шрифтын бүген дә укый алмый азапланабыз, ә бит безнең мең елдан артык тарихыбыз гарәп шрифты белән язылган. Шулай итеп, Г.Шәрәф 1927 елда ук безнең үз тарихыбыздан ераклашуыбызны күрсәтә. 1937 елда кулга алынганчы Г.Шәрәф Казанда партиясезләрнең җитәкчесе дип санала ала. И.Сталинга,ҮКна Казан зыялылары тарафыннан язылган хатлар, гаризалар һ.б. — барысы да аның аркылы уза.

[5] Вәлиев Р. Фаҗига.- Казан: Татар.кит.нәшр., 1996.-32-34б.

Бүген инде шуны ассызыклап әйтә алабыз: милләтләргә үз тормышларын үзләре күреп яшәргә ирек биргәндә генә Русия яна үрләргә менә ала, ә киресен эшләгәндә гомум милли кризиска, таркалуга юл ачылачагы көн кебек ачык. Дөньяда барган үзгәрешләр дә шуны таләп итәчәк. Милли проблемаларга керосин сибеп торган шовинистларга инде акылга килергә вакыт.

Бу тарихи процессларнын шулай булачагын Галимжан, Борхан, Гыйльметдин Шәрәфләр, Гаяз Исхакый, Садрый Максуди, Фуад Туктаров, Газиз Монасыпов, Әкрам Бигловлар кебек шәхесләр алдан сизеп, марксизм-ленинизм идеяләрен кабул итмиләр, партиягә кермиләр, кайберләре чит илгә үк китеп бара.

Ни кызганыч, 1937 елны репрессияләнеп, Галимжан Шәрәф сигез елга каторгага озатыла, бик озак «халык дошманы» булып йөри. Шундый шартларда да соңгы сулышына кадәр татар милләте өчен көрәшә. Сөрелүдән каты авырып кайтуына, торырга урыны булмауга карамастан, ул «Зодчий» исемендәге поэмасын язып калдыра. Анда явызларның явызы булган Иван Грозныйны һәм Иосиф Сталинны тәнкыйть утына тота. 1950 елның 13 гыйнварында вафат булып, татар зиратына күмелгән Г.Шәрәф бары тик 1991 елның 30 сентябрендә генә реабилитацияләнә. Мирсәет Солтангалиевтән дә куркынычрак милли зат булган, күрәсең. Чыннан да, ул бит М.Солтангалиев кебек коммунист та түгел, ә бары тик «Идел-Урал штаты»н тормышка ашыру, бәйсез дәүләт төзү өчен көрәшә. Партиягә кереп унайлыклар да эзләми, барына түзеп халкына хезмәт итә. Гаяз Исхакый исемен кайтару өчен көрәшә, үз сүзен ачык итеп халыкка, хакимияткә житкерә. Ул чор өчен бу чын батырлык була. Халкыбыз моны аңлап, Г.Шәрәфкә дөрес бәя бирергә тиеш. Әмма аның исемен мәңгеләштерү буенча бүгенгәчә нәтижәле эш күрсәтмибез әле. Югыйсә, 1990 еллар башында жәмәгатьчелек, Казанның Париж коммунасы урамын Бертуган Шәрәфләр урамы дип алыштыруны сорап, Башкарма комитетка хат та юллады. Әмма Казанда бүгенгәчә андый урам юк. Татарстан башкаласының нәкъ уртасында Галимжан Шәрәфкә һәйкәл куелырга тиеш, чөнки ул Татарстан жөмһүриятен төзүнен төп идеологы, аны булдыру өчен жаны-тәне белән көрәшкән олы зат. Татар халкы, хакимият органнары моны аңларга тиеш!

Тарих кабатлана, диләр. Царизмны бәреп төшергәч, инкыйлаб сөреме белән исергән халыкның зур өлеше, большевикларның вәгъдәләренә ышанып, «социализм» сукмагыннан китте, кызыл байрак астына жыелды. Аның кая китереп чыгарганлыгын инде тарих күрсәтте, әмма узган заманны сагынучылар бүген дә күп әле. Бу хәл исә милли мәсьәләләрне чишү юлында хәзерге вакытта да зур комачаулык тудыра. Татарларга, көндәлек сәяси активлыктан яңа этапка күчеп, мөстәкыйльлекне тормышка ашыру юлын узарга туры килә.

Табигый сорау туа: 1918 елның февраль һәм март айларында татар дөньясында сәяси киеренкелекне булдырмаска мөмкин идеме? Әлбәттә, бөтен мөмкинлекләр булган. Эш шунда ки, «милләтчеләр» белән большевиклар арасында ике төрле идарә шәкеле буенча кискен көрәш барган. Беренчеләре демократия юлын таләп итсәләр, икенчеләре диктатура урнаштыруны даулаган. Ә мәсьәләнең гадел хәл ителүе, ул чорның сәяси вазгыятен истә тотып, демократия белән диктатура элементларының бергә үрелеп кулланылуы нигезендә генә мөмкин иде. Әмма беренчеләрнең жиңелүе мәсьәләне диктатура тарафдарлары файдасына хәл ителүгә китерде, ул үсте, ныгыды. Моның фажигале нәтижәләрен бүген дә һәркайсыбыз татый әле. Шулай ук диктатура хакимиятенең мәңгелек була алмавы да ачыкланды. Моны тарих үзе исбат итте. Инде, дөреслек өскә чыкты, дисәк тә ярый...

Ул чакларда кем ничек уйлаган соң? Г.Ибраһимов 1920 елның февралендә түбәндәгечә фикер йөрткән: «Әллә нинди милли идарәләр, милли шуралар, хәрби шуралар тирәсендә әйләнеп, чех, Колчак вакытында татар революционерларын тоттырып йөргән күп ихлас күнелләр башларындагы иске буржуадан кергән чүп-чарларыннан сафландылар... Тик бернинә гажиз бәндә генә әле һаман да Финляндия, Гөлжә, Харбин татар буржуаларының нәжес кулларыннан тамган хәбис бер тиеннәргә чукынып, Париж банкирларының бусагалары төбендә, рус монархларына койрык булып, адәм көлдереп йөриләр. (...) Башкалар: 1) иске тормышта ике төрле коллык кичергән эшче-крестьян хатыннары(...); 2) хезмәт халкының азатлыгы кайда

икәнен аңларлык булган мөгаллим-мөгаллимәләр, мөрәббия (тәрбияче) иптәшләр; 3) тарихның хәзерге дәверендә, хезмәт белән капиталның канлы, рәхимсез сугышы вакытында, кайсы якта булу мәсьәләсен эшче-крестьян гаммәсе ноктасыннан карап чишкән татар әдипләре, шагыйрьләре; 4) һәркайда, һәр заманда иң бөек әмәлләр белән янучы яшьләр (...), шул авыр, фаҗигале, канлы көрәш, рәхимсез диктатура аша тарих күгендә янып, саф азатлык өстәүче, күңелләрне үзенә тартып торган якты коммунизм кәгъбәсенә таба юл тоттылар».

Уйлап карасаң, барысы да киресенчә бит. Болак артындагы милләтчеләр — азатлык өчен көрәшчеләр. Алардан күлеп, тарих күгендә азатлык эзләп, коммунизм кәгъбәсенә юл тотучылар инкыйлабка, аның житәкчеләренә ышанып ялгыштылар. Алар барысы да ГУЛАГта һәлак булдылар. Тагы бер сорау туа. Моның барысына кем гаепле:инкыйлабмы, әллә кешеләрме?

Монда инкыйлабның гаебе юк, чөнки ул череп беткән патша хөкүмәтен, халыкка гражданнар сугышы ачкан «вакытлы хөкүмәтләрне» юк итте.Инкыйлабтан соңгы диктатура, барын да көч куллану ягына күчереп, демократиягә юл калдырмады. Башка сәбәпләрне дә, бигрәк тә тарихтагы аерым шәхесләрнең ролен дә онытырга ярамаганлыгы барыбызга да мәгълүм. Юлбашчы киләчәкне барыннан да төгәлрәк күзаллап, халыкларның теләкләрен искә алып эш иткәндә генә инкыйлаб үз жимешләрен бирергә мөмкин. СССРның жимерелүе менә шуларның үтәлмәве белән аңлатыла. Халыклар фикере белән санашмаган, киләчәкне бары тик диктаторлык күзлегеннән генә күзәткән И.Сталин әле 1918-20 елларда ук СССРның жимерелү нигезләрен салып калдыра.

Без гаделлек, дөреслек өчен бабаларыбыз башлаган көрәшне дәвам итәргә тиешбез. Тоталитар режимның корбаннарын, милли каһарманнарыбызны онытырга хакыбыз юк. Бәйсез дәүләтебезне булдырып, аның нигез ташларына бәйсезлек, ирек, гомумкилешү, тынычлык кебек милләтебезнең изге теләкләре язылсын иде. Аларны аңлау, тормышка ашыру өчен, узган тарихыбыздан күренгәнчә, үзаң, акыл, уяулык кына житми, ә кыюлык та кирәк. Бары тик боларның барысы да бергә булганда гына, аларга ия булган зыялылар, киң катлам халык, яше-карты «Ватан, милләт» дигән сүзләрнең төп серен, мәгънәсен аңлый һәм үзен-үзе жиңәргә, кирәк булса, үлемгә дә барырга сәләтле була. Туган халкының бәйсезлеге, теле, мәдәнияте, гомумән, бөтен төрки-татарның якты киләчәге өчен гомерен биргән курку белмәс Галимжан Шәрәф — әнә шундый каһарманнарның берсе. Аның исеме һәр татар кешесе өчен якын һәм кадерле.

**Рәмзи ВӘЛИ,**
*тарих фәннәре докторы, профессор*

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кулъязма жибәргәндә түбәндәге документлар булу мәжбүри:

1. Паспорт күчерелмәсе (титул, прописка бите).
2. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы күчерелмәсе.
3. ИНН күчерелмәсе.
4. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
5. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп).

# ТАНСЫК ҺӘМ БАЙ БУ КӘРВАН...

«Ошбуны язарга» ничә айлар инде күңелдә бер көч, хис тынгысызлап, әйдәп торды: әйе, нәкъ Тукаебыз әйткәнчә, «вөжданымның көчләве»дер. Бу — шагыйрә һәм әдибә буларак киң жәмәгатьчелеккә яхшы таныш булган Фирүзә Жамалетдинованың «Еллар кәрваны» исемле шигырьләр китабын, төрле елларда язганнарыннан сайланмасын укыгач туган халәтем иде. Хатын-кыз ижатчыларга хәерхаһ жаным тагын бер кат куаныч кичерде, әдәбиятта үзенчәлекле, һичкемне кабатламаган, һичшиксез, аерым игътибарга, мәкаләләргә, фәнни тикшерү-күзәтүләргә лаек (мин моңа бөтен барлыгым белән ышанам!) булган шагыйрәбез өчен «бер горурлык хисе», Сибгат ага Хәким әйтмешли, «эчтән бәреп яна битләрдә».




Дәрдемәнднең мәгълүм шигырендәге «Сезне милләт кызлары, аһ... и өмит йолдызларым.../ Бер күреп каналмадым...» дигән юлларын нәкъ менә шагыйрәләребезгә адреслап, көйләп йөрдем. «Милләт аналары» исеме белән «Шәхесләребез» сериясендә («Жыен» нәшрияты) чыккан китап тәэсиреннән дә айнымаган жаным белән шагыйрәләребезнең ижатын да әнә шул милләтнең рухын, жанын тәрбияләүче газиз әнкәләрнекенә охшаш табам мин — һәм моны ышанып әйтәм. Әйе, бүгенге вазгыять шагыйрәләребезгә дә, һәммәбезгә дә шундый миссия йөкли, моны да беләбез. Талантлыларга бигрәк тә...

Мин Фирүзә ханымны утыз елдан артык беләм — студент чагыннан ук өмет уяткан житди, акыллы Чүпрәле кызын күздән югалтмыйча, гел күзәтеп, кызыксынып, укып киләм. Хәзер аңлыйм: университетта да (әй кадерле, газиз татар теле-әдәбияты факультеты! Синең шанлы тарихың сагынып сөйләргә генә калдымы? Тиңсез рухи мәктәп идең син күп әдип-шагыйрьләр өчен! Бул бәхил, гел риза без синнән — бу әлвидагны көтмәгән гамьсез балаларың... Ит гафу, әй изге йорт!), Язучылар берлеге уздырган семинарларда да, аннан соң күп еллар Чаллы әдәби мохитендә кайнап үскән, чарланган икән аның үзенчәлекле каләме, сүз көче кодрәте...

Язучылар берлеге дигәннән, анда кергәндә биргән тәкъдимнамәмдә шундый сүзләр язганмын: «Фирүзә — белемле, шигъри традицияләрне үзләштергән, үзенә кадәр язганнарның ижатын (мин барыннан да бигрәк үзебезнең С.Сөләйманова, Х.Әюп кебек шагыйрьләрнең рухи йогынтысын тоям... Һәм, әлбәттә, А.Ахматова, М.Цветаева кебек шагыйрәләр, башка халыклар әдәбияты тәэсире) өйрәнгән, үзенең шигъри стилен, сурәтле үз дөньясын тапкан шагыйрә... Жир кызы ул, кырыс тормыш, дөнья, яшәү

Жамалетдинова Ф. Еллар кәрваны. Шигырьләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2011.–287 б.

тәҗрибәләрен бөтен тулылыгында сендергән нәфис җан иясе. Әмма бу чынбарлык аның назикъ күңеленә килеп бәреләдә җинелеп чигенә кебек... һәм бу мизгелләр югары кичерешле шигырьгә әверелә. Сыктау, елау, зарлану юк. Дөньяны фәлсәфи тоя ул, милли күз-күңел белән кичерә һәм шәхси тойгыларын гомум итеп күтәрә белә, әнә шулай шигырьгә әвереләдерә. Формасы да ялкытмый, чөнки күп төрле фикер, тел-сурәт чаралары бай, кызыклы... Кыскасы, үзенә бер тылсымлы дөнья!»

«Еллар кәрваны» *(Татарстан китап нәшрияты, 2011 ел)* китабын укыгач, бу фикерләрем ныгый гына төште, шагыйрә күңел дөньясынын укучысы, аңлаучысы, хәтта бер гашыйгы итеп тоям хәзер үземне һәм бу табигыйдер дип беләм. Чын шигърият тылсымы шунсыз булмыйдыр, мөгаен!

Башта ук шуны әйтим: китап — бер матур, бөтен өлешләре килешле, төгәл, тәңгәл булып тоелган, димәк, яхшы төзелгән бер бинаны (әллә бакчанымы?) хәтерләтә. Бу, әлбәттә рухи төзеклек, бөтенлек, хәтер биографиясеме ул, туган як, үз кауме, халкы, заманы һәм заман күренешләренә карата хисләреме — алар барысы да бергә, тыгыз, аерылгысыз бәйләнгән.

Дүрт өлешкә бүленүе дә шартлы гына булып тоела, еллар буенча да хронология сизелми... Ә бәлки, рухи үсеш, шигъри омтылыш, тәҗрибә һәм акыл, яшәү, нәтиҗәләр... Этаплар! Аларның барысына да бер исем — ул эзләнүче, туган җире, нәселе, зур тарихлы халкы һәм аның язмышы белән шәхси хисләрен куша алган шагыйрә — Татар Кызы... Һәм бу китап — берб\u00f6тен, ихлас җан эндәшләре, дөнья белән сөйләшүләр, табышлар, югалтулар белән тулы мәхәббәт юлы һәм мәңгелектә көрәш, эзләнү дөньясы, чынбарлык һәм шигъри дөнья бергә кушылган Хыял иле...

Укучылар (һәм мөхтәрәм мөхәррирләр дә!) ялыкмасын, әмма мин алда китаптан сүзләремә, фикерләремә дәлил итеп, шигъри мисалларны мулдан китерергә исәплим һәм укучылар да минем зәвыкымны җәлеп иткән юлларга битараф калмаслар дип ышанам. Бигайбә!

*Ил-көнгә игелек — бүләгем,*
*Гомерем нурыннан терелгән...*

Ә туган авылы басуларын шагыйрә менә ничек күрә:

*Уҗымнарның җылы бишегеннән*
*Салкын көздә яшел моң чәчелә.*
*Ята алар читтән кызыгышып*
*Сәлам эскертенең чал чәченә.*
*Үзләреннән яшел моң чәчелә...*

Ә таулар турындагы фәлсәфә нинди!

*Таулар өчен шундый ныклык кирәк,*
*Һәр ташының үз урыны булсын!*
*Тәгәрәүдән куркып ятса алар,*
*Ишеләчәк беркөн Бөек Тылсым!*

Ә «Мәрьям ана күз яше» гөленнән ясалган тәсбих нинди уйлар кузгата шагыйрәдә:

*Үтә кеше... Тик, кем булып? –*
*Кеше булып туса да...*
*Гөлләрдән дә кала икән*
*Күз яшьләре булса да.*

Узган заманнарда патшалар шигырь укыган дәверләр дә булган. Ә бүгенге базар?

*«Үзегезгә бәя куегыз!» дип*
*Заман дәшсә, сүзсез калачак без.*
*«Әүвәле — Сүз булган...» Сүз — амәнәт!*
*Ә без телсез кая барачакбыз?*

Әмма ул халкының үлемсезлегенә ышанычын, тарихи хәтерне бер мизгелгә дә җуймаячагын тәкърарлый, Җирдә могҗиза кебек яши әле татарым, ди: «Сигезенче могҗизасы / Шушы Җирнең — бездер! Без!» Ә татарга кайчан да җиңел булмаган. Бүген дә...

*— Ничек яшисең? — диләр дә,*
*Елмаеп куям:*
*— Ярый...*
*Җирләрдә урын юк сыман,*
*Күкләрдә җаным арый...*

*Җавап бирә алмый торам*
*Танышлар сорaганда.*
*Ничек яшимдер — кешеләр*
*Бүречә улаганда...*

Шулай, бу Ашина ыруынын изге тотем бүресе яки безнен Ак бүребез түгел шул. Болганчык заман! Шагыйрә хәтта үзенә мактау сүзләренә дә шикләнеп куя: башка берәүне кимсетү йә кыйнау исәбенә түгелме бу? Менә нинди бүгенге чор гримасалары! Уйланырсың...

Мәхәббәт турында да гаҗәеп матур, яна янгырашлы сүзләр белән яза Фирүзәбез:

*Син еракта калдың. Шуңа җанның*
*Түгеләсе килә, түгелсен.*
*Диңгез әнә аягыма яткан,*
*Ә син, бәләм, диңгез түгелсең.*

Шигъри сүз көченең ташларны да эретерлек икәнен менә бу юллары сөйләмимени?

*Үпкәләүләр нигә? Тормыш гүзәл!*
*Төн үтәр дә янә таңнар атыр.*
*...Бер-берсенә бәрелгәнгә микән*
*Ярда ташлар шома һәм дә матур.*

Мондый табигыйлек, халәтләр көчендәге пластика классик әдәбиятлардан килгән дәвамлылык үрнәге, мөгаен. Һәм менә бу юллар кемне битараф калдырыр икән:

*Җәйге көнем утка төшкән мизгел,*
*Һәр көйгән тап — чәчкәләрнең миңе...*

*Җаннар көя — сулар юкка түгел,*
*Күзләр көя — гүзәлләкләр юкка.*
*Әллә нинди бүген кеше заты,*
*Тешләр үткен, ә иреннәр — юка...*

*Ә җиһан бай! ( Байлык — бер айлыктыр),*
*Сөю җитми безгә! Сөю генә...*

Бу сүзләр алдында мин дә тынып калам һәм вакыйга саналырлык китап турындагы сүзләремне ( башкалар да мина кушылыр дигән өмет белән!) шушы урында туктатам. И «өмит йолдызларыбыз», яныгыз, яшәгез, язагыз, милләт кызларыбыз! — дим.

**Рәдиф ГАТАШ,**
*Татарстанның халык шагыйре*

---

## «Казан утлары» елъязмасы



*Журналыбыз 1922-1930 елларда «Безнен юл», 1930-1932 елларда «Атака» һәм «Яналиф», 1933-1965 елларда «Совет әдәбияты», 1965 елдан «Казан утлары» исеме белән дөнья күрә.*

**февраль**

**90 ел элек** (1923) «Безнең юл»да Һади Такташның «Мәңгелек әкият» һәм «Күктән сөрелгәннәр» шигырьләре;

**80 ел элек** (1933) «Совет әдәбияты»нда Шамил Усмановның «Легион юлы» романы;

**60 ел элек** (1953) «Совет әдәбияты»нда Нәкый Исәнбәтнең «Рәйхан» драмасы;

**55 ел элек** (1958) «Совет әдәбияты»нда Фатих Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» романы;

**50 ел элек** (1963) «Совет әдәбияты»нда Әмирхан Еникинең «Рәшә» повесте, Әнвәр Давыдовның «Себер трактында квартал» исемле шигырьләр циклы;

**45 ел элек** (1968) «Казан утлары»нда Фатих Хөснинең «Кечкенә дога» хикәясе;

**40 ел элек** (1973) «Казан утлары»нда Эдуард Касыймовның «Һаваларда тургай» романы;

**30 ел элек** (1983) «Казан утлары»нда Әхсән Баяновның «Таш китап» романы;

**25 ел элек** (1988) «Казан утлары»нда Якуб Зәнкиевнең «Иртеш таңнары» романы, Фәнис Яруллинның «Бәхет турында уйлану» исемле шигырьләр циклы дөнья күргән.

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Имәнкискә

Имәнкискә авылы Лаеш районында, район үзәге Лаеш эшчелар бистәсеннән 16 чакрымда, жирле үзидарә советы үзәге Чырпы авылыннан — 2, Казаннан 56 чакрым ераклыкта урнашкан,

Авыл атамасы борынгы тарихи чыганакларда һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә еш искә алына.

Имәнкискә авылы Казан ханлыгы чорында да булган, аның янында борынгы һәм соңгы болгар чорларына мөнәсәбәтле авыл хәрабәсе, борынгы болгар заманына караган бизәнү әйберләре һәм соңгы болгар чоры белән бәйләнешле каберлек табылган.

С.М.Шпилевский Имәнкискә авылы янында элек шәһәр, курган һәм курган янында борынгы каберлек булуын билгели. Имәнкискә авылы халкы хәтерендә сакланып калган риваятьләргә караганда, курганда хәзинә күмелгән дип уйлаучылар да булган. Аны казып эзләүчеләр дә табылган, ләкин аларның барысы да эчәк һәм башка авырулар белән авырый башлаганга, исән чакта бу урыннан китү ягын караганнар.

Д.А.Корсаков жыентыгында Имәнкискә авылы теркәлгән. Анда ясак түли торган 48 татар яшәве күрсәтелә.

Авыл зиратында XVII гасырның 80 елларында яшәгән шагыйрь һәм дин эшлеклесе Хажи Хафиз күмелгән.

1901 елда В.П.Семенов мөхәррирлегендә басылып чыккан географик хезмәттә Имәнкискә тарихи, тирә-юнендә өекләр (валлар) һәм курганнар булган авыл буларак искә алына.

Элек Имәнкискә авылы урнашкан урында калын урман үскән. Бирегә килеп утырган халык урманны төпләп чәчү жирләре ясаган. Авыл халкы телендә әлегә кадәр сакланып калган Арьяк ышна басуы — шул вакытларның истәлеге.

Имәнкискә авылы Кама ярына, табигатьнең бик матур урынына утырган. Авыл тирәсендә күлләр күп. Олы күл, Урта күл һәм Кече күлләр үзара тоташканнар. Ул ермак кебек озынрак су хасил итә һәм бу су Иделгә коя. Моннан тыш Камыш күле, Мунчала, Брыс, Киндер, Хужагол биле, Карамалы, Балыклы, Шуран, Озын, Әби, Завадный күлләре һ.б. бар.

Авыл тирәсендә Шурана һәм Сыерчык таулары калкып тора. Басу-кыр тирәләрендә Иске йорт урыны, Янган атау арасы, Билчәнлек астыры, Сурачи кырачы, Грән буе түбә. Ташбилге урыны кебек берәмлекләр бар.

---

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

## Имәнлебаш

Татарстандагы меңләгән авыллар арасында һәрберсе үз матурлыгы, үз яме, үз традицияләре белән аерылып тора. Шундыйларның берсе — Имәнлебаш. Ул халык телендә Имәнле яки Инеш дип атала торган кечкенә генә су буена утырган. Авыл Зәй районында, район үзәге Зәйдән – 15, җирле үзидарә советы Югары Шепкә авылыннан 3 чакрым ераклыкта урнашкан. Анда татарлар яши.

Имәнлебаш авылы 1870 ел чыганагында болай искә алына: Имәнле суы ярына утырган Имәнлебаш авылының 75 хуҗалыгында 232 ир-ат һәм 225 хатын-кыз көн иткән. Анда мәчет, су тегермәне булган, халык балта эше, умартачылык белән шөгыльләнгән.

Авылда татар мәгърифәтчесе, язучы, шагыйрь һәм табиб Таҗетдин Ялчыгол (1768 – 1838) кабере бар. Таҗетдин Ялчыголның туган җире мәгълүм түгел. Төркиядә һәм Дагыстанда укыганлыгы билгеле. 1785 елдан Таҗетдин Ялчыгол Зирекле, Кызыл Чапчак һәм Мәлем авылларындагы мәдрәсәләрдә мөгаллимлек иткән. Ул 1838 елда Имәнлебаш авылында вафат булган. Т.Ялчыголның педагогика һәм халык медицинасы буенча язган хезмәтләре, шулай ук танылган төрки шагыйре Суфи Аллаһиярның «Сәбәтелгаҗизин» әсәренә анлатмалары мәгълүм.

Имәнле суының башланган җиренә нигезләнгәнгә күрә, авыл Имәнлебаш дип исемләнгән. Имәнлебашның тирә-юне элек калын урман белән капланган булып, урман, нигездә, мәһабәт имән агачларыннан торган. Шуның өчен елга һәм авыл да имән агачларына мөнәсәбәтле атама йөртә.

Заманасында Имәнлебаш авылы хәзерге урынында булмаган. Элегрәк ул Чапчак ягында оешкан, соңыннанрак хәзерге урынга утырган.

Бу тирәләргә шомырт җыярга килгән хатын-кызлар әлеге урынның урман-суларга, чишмәләргә бай, урманнарда җиләк-җимешләрнең күп булуы турында кайтып сөйлиләр һәм, озаклап кинәшкәннән соң, сигез гаилә шушы урындагы зур урманның ямьле аланына килеп утыра. Тора-бара авыл зурая башлый һәм бу урын Имәнлебаш халкының төп нигезенә әверелә.

Вакытлар үтә-үтә Имәнлебаш кешеләре күрше авыллар белән аралаша башлый, үзара йөрешеп бәйрәмнәрне дә бергә үткәрәләр. Айгыр исемле җыен бәйрәме оештыралар. Бу җыен тирә-юньдә чиратлап үткәрелә торган башка җыеннарга караганда иң алдан бәйрәм ителгән. Тырышып эшләгән авыл халкының бәйрәм үткәрү өчен матур урыннары күп булган.

Табигать ярлылануга карамастан, авыл мохите әле дә искиткеч матур. Мина тирә-юньне күрсәтеп йөргән Зөһрә кечкенә сәяхәтебезне Салкын чишмәдән башлады. Элегрәк кызлар белән егетләр шушы чишмә янында кичке уеннар үткәргәннәр. Чишмәнең көченә торган гадәте, ягъни бу урынны вакытлыча калдырып тору үзенчәлеге бар икән. Бу авылда мин экспедициядә булганда аның чыкмаган вакыты иде. Ләкин ул киләчәктә барыбер килеп чыгачак, дип көтә иде авыл халкы.

## Ирмәш

Ирмәш авылы Актаныш районында, район үзәге Актаныш эшчеләр бистәсеннән 2 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Актанышбаш авылыннан — 2, Нефтекамск шәһәреннән — 37, Әҗәкүл пристаненнән 3 чакрым ераклыкта урнашкан.

1870 ел мәгълүматлары тупланган Уфа губернасы авыл атамалары исемлегендә Ирмәш авылы болай сурәтләнә: Ирмәш авылының 35 хуҗалыгында ислам динендәге 95 ир-ат һәм 97 хатын-кыз яшәгән.

Олы буын кешеләре сөйләвенә караганда, авылның оешуы болай булган. Агалы-энеле Ирмәш һәм Шәриф исемле ике туган килеп төпләнер өчен урын эзләп йөргәннәр, һәм көннәрдән бер көнне бик матур бер җиргә килеп чыкканнар. Якында гына Агыйдел елгасы аккан. Бер ягында тау, икенче ягында күл җәелеп яткан. Ирмәш дигәненә бу урын бик ошаган һәм ул шушында төпләнеп калган. Шуннан бирле авыл аның исемен йөртә. Ә Шәриф исемлесе Шәриф авылын нигезләгән.

Авылга якын гына урында Иске Идел бар. Башта бу елга Агыйделгә тоташкан була. Дамба төзелгәннән соң Иске Идел Агыйделдән аерылган. Элек Иске Иделдә

пароходлар йөргән, ул тирән һәм киң булган. Дамба төзелгәч су киткән һәм Идел дә тарайган, саеккан. Су киткән урында урман үскән. Янында болын бар, аны Әргәнеш дип йөртәләр. Авыл халкы бу болынга Идел аша көймәләргә утырып чыгып, печән хәзерләргә бара. Авылдан ерак түгел генә ике күл бар. Берсен Озын күл, икенчесен Үлек күле дип йөртәләр. Элегрәк бу күлдә үлгән кешеләрнең киемнәрен чайкаганнар. Яз көне ел саен кар сулары эрегәч, зур гына бер күл барлыкка килә. Аны авыл халкы Бака күле дип йөртә. Бер-ике айдан ул кибеп бетә.

Авыл кечкенә булу сәбәпле, хәтта башлангыч мәктәп тә юк. Ирмәш авылы Актанышка бик якын булганга, бала-чага шунда барып укый.

## Исәк

Исәк авылы Буа районында, район үзәге Буа шәһәреннән 30 чакрымда, Тәтеш пристаненнән 72 чакрым ераклыкта урнашкан.

Исәк атамасы күп кенә тарихи белешмәләрдә теркәлгән.

Д.А.Корсаков җыеп бастырып чыгарган белешмәдә (XVIII гасыр) күрсәтелгәнчә, Олы Бола ярына утырган Исәк авылында 151 йомышлы, ясак түли торган 5 татар кешесе һәм 1 керәшен татары яшәгән. 1859 елдагы мәгълүматларны эченә алган А.Артемьев белешмәсеннән билгеле булганча, Олы Бола суы ярына урнашкан Исәк авылындагы 121 хуҗалыкта 399 ир-ат һәм 391 хатын-кыз гомер кичергән, мәчет эшләгән. 1898 елда басылып чыккан тарихи белешмәдә Исәк авылында татарлар көн күргәнлеге искәртелә. К.П.Берстель мәгълүматларына караганда, Исәк авылында 1090 татар кешесе яшәгән.

Олылар хәтерендә сакланып калган риваять буенча, Исәк һәм Багыш исемле ике бертуганның Багыш исемлесе Багыш авылын, Исәк атлысы Исәк авылын нигезләгән.

Исәктә өч төрле нәсел яшәгән. Беренчесе — Болгардан күчеп килгән халык, икенчесе — Монталай нәселе, өченчесе — чуашлар булган.

Болгар нәселе күбрәк сәүдә белән шөгыльләнгән, үзләрен эре тотканнар, чая, житез, унган, акыллы булганнар. Авылны иң матур, уңдырышлы туфраклы җиргә салганнар.

Исәкнең иң зур байлыгы — Бола елгасы. Ул авыл яныннан боргалана-боргалана ага. Елга авылга гасырлар буе яшәү чыганагы булып торган, туендырган, чистарткан, мал-туарны сугарган.

Авыл хуҗалыгында төп урынны игенчелек алып торган. Халыкның хезмәт кораллары булып урак, сабан һәм чалгы исәпләнгән.

Исәк акрынлап үсә һәм зурая барган. Авылга читтән башка кешеләр дә күчеп килгән һәм алар төпләнеп калганнар. Эшкәртелгән җирләр күбәйгән.

Авыл халкы югары һәм түбән катлауга аерыла барган. Авыл байларының зур йортлары, тегермәннәре һәм җир биләмәләре булган. Мал-туарлары күп булганга күрә алар хезмәтчеләр дә тоталар. Авылда үз һөнәрләре белән танылган кешеләр дә яшәгән. Читекче Сәйфетдин, сарык тиресеннан тун тегүче Изахетдиннәр тирә-юньдә дан тоткан.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# Н

**НӘҖМИЕВ** Тәлгат Самат улы (1.3.1950, Кукмара р-ны Байлангар а.), публицист. Казан ун-тын тәмамлый (1979). 1981 елдан Саба р-н «Җину байрагы» (хәзерге «Саба таңнары») газетасы баш мөхәррире. «Яшә, Саба-йорт!» (1999), «Туган туфрак кадерле» (2001), «Сабаларда эчәр суым булгач» (2005) очерклар, «Саба мәзәкләре» (1999), «Тагын... Саба мәзәкләре» (2001), «Тагын... тагын... Саба мәзәкләре» (2004), «Саба: елмаюлы тарих» (2012) мәзәкләр җыентыклары авторы.

Әдәб.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

**НИГЪМӘТИ** (Нигъматуллин) Галимҗан Әмирҗан улы (26.7.1897, Башкортстан Респ-сы Чишмә р-ны Үдрәкбаш а. – 1941, Коми АССР), әдәбият галиме, әдәби тәнкыйтьче. Уфада «Галия» мәдрәсәсендә, 1922 дә – Шәрык хезмәт ияләренең коммунистик ун-тында (Мәскәү), 1924 тә Дәүләт журналистика ин-тында укый. 1926 га кадәр Бөтенроссия Үзәк башкарма ком-тында милли матбугат буенча инструктор. 1926дан Казанда. «Кызыл Татарстан» г-тасының (1926-27), Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире (1928-30), «Яналиф» ж-лының җаваплы мөхәррире (1930-32), бер үк вакытта 1929-37 елларда Шәрык пед. ин-тында (1934-37 елларда татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, 1935 тән проф.). 1920-30 елларда татар әдәбият белеме өлкәсендә культура-тарих мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Н. татар әдәбият белеменең фәлсәфи-эстетик нигезләрен, сәнгать иҗатын әдәбият белеме, фәлсәфә, эстетика, тарих, психология, социология фәннәренә таянып комплекслы рәвештә өйрәнү принципларын нигезли. Шәрык һәм Гарәб әдәбиятларын чагыштырып өйрәнә. Татар әдәбиятына А.С.Пушкин, Л.Н.Толстой, А.П.Чехов, М.Горький, Н.Г.Чернышевскийларның тәэсире турындагы мәкаләләр (гуманистик пафос, демократизм, шәхеснең иҗади хезмәтен һәм ирекен поэтикалаштыру, сәнгати-эстетик осталык, иҗади шәхеснең батырлыгы һәм какшамаслыгы); татар әдәбияты буенча дәреслекләр һәм укыту программалары авторы. Нахакка репрессияләнә, вафатыннан соң аклана.

Әсәр.: Әдәбият мәйданында. М., 1925; Революция елларындагы әдәбиятыбыз. М., 1929; Әдәбият һәм тормыш (Әдәбият фәне мәсьәләләре, тәнкыйть). К., 1931; Сайланма әсәрләр. К., 1958.

Әд.: Гилазов Т. Выдающийся татарский литературовед (к столетию Галимджана Нигмати) // Научный Татарстан. 1997. №2; Нигматуллин Э.Г. Жизнь. Творчество. Память: Очерк жизни и деятельности Галимджана Нигмати // Казань. 2002. №9; Галиева Э.Г. Татар әдәбияты белемендә культура-тарих мәктәбе. К., 2002.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**НИГЪМӘТУЛЛИН** Әхәт Зәйнетдин улы (30.11.1921, хәзерге Оренбург өлкәсе Кызыл гвардия р-ны Үтәй а.), әдәбият галиме, филология фәннәре докторы (1992), проф. (1993), Башкортстан АССРның атказанган фән эшлеклесе (1982). Казан ун-тын тәмамлый (1949). 1952 елдан Тобольск укытучылар ин-тында татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире. 1954 елдан Башкортстан ун-тында, 1993 елдан Башкортстан пед. ин-тында (башлангыч сыйныфлар методикасы кафедрасы мөдире), 1997 елдан Башкортстан мәгарифен үстерү ин-тында (туган тел һәм әдәбият кафедрасы мөдире, 1998-2000 туган тел һәм чит телләр кафедрасы мөдире). Хезмәтләре Г.Тукай, М.Гафури, Ш.Камал, Һ.Такташ, Ф.Кәрим, М.Җәлил, Г.Кутуй, Х.Туфан иҗатларына, агымдагы әдәби процесска карый, татар әдәбиятын урта мәктәптә укытуга багышланган. «И гомернең үзәннәре, үрләре» (Уфа, 2002), «Өзерен бер карадың да» (Уфа, 2006), «Күзгә кыек күрсәтә» (Уфа, 2007) исемле шигъри җыентыклар авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗәдәге Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Сәнгатьле уку (теориясе һәм гамәли методикасы). К., 1968; Урта мәктәптә татар әдәбиятын өйрәнүнең фәнни-методик нигезләре. К., 1982; Проблемно-развивающие уроки литературы. Уфа, 2000.

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

Әдәб.: Асанбаев Н.А. Судьба // Агидель. 2006. № 12; Гареева Г.Ф. Основатель методики татарской литературы как науки // Учитель Башкортостана. 2006. №12.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**НИГЪМӘТУЛЛИН** Энгель Галимҗан улы (6.11.1930, Казан – 16.7.2001, шунда ук), әдәбият галиме, әдәби тәнкыйтьче, тәрҗемәче, филол. фән. канд. (1972). Казан ун-тын (1952), 1 нче Мәскәү чит илләр телләре буенча пед. ин-тын (1967) тәмамлый. 1967-72 урта мәктәптә эшли, 1972 дән Казан ун-тында. Фәнни эшчәнлегенең төп юнәлешләре – татар әдәбиятын системалы-комплекслы рәвештә дөнья әдәбияты контекстында өйрәнү (социологик-тарихи, фәлсәфи-эстетик, культурология һәм әдәбият белеменә кагылышлы аспектларда); татар әдәбиятының рус һәм Көнбатыш Европа әдәбиятлары б-н бәйләнештә өйрәнү; татар әдәбиятының үсешен күзаллау; бүгенге татар прозасының поэтикасы. Иске татар, нем., ингл., франц. телләреннән татарчага һәм русчага татар халкының тарихы, мәдәнияте, мәгърифәтенә багышланган фәнни мәкаләләр тәрҗемә итә. Европалыларның татарларга, татар мәдәниятенә карата мөнәсәбәтләрен белдергән мәгълүматларын җыеп бастыра.

Әс.: Раздвигая века и границы: К вопросу о связях татарской литературы первой трети XX века с литературой Западной Европы. К., 1977; Диалог литератур: Указ. переводов произведений русской литературы на татарский язык. К., 2002; Европа һәм татарлар: Тарихи парчалар // Мирас. 1999. № 8-9.

Әд.: Балашов Ю. В сговоре с совестью // Казань. 2002. №9; Нигматуллина Ю.Г. Системно-комплексное исследование художественного творчества: История научного направления в Казанском университете. К., 2004.

**НИГЪМӘТУЛЛИНА** Йолдыз Галимҗан кызы (29.4.1929, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1971), проф. (1973), ТАССР, РСФСР атказ. фән эшлеклесе (1979, 1981), атказ. проф. (2004). Казан ун-тын тәмамлый (1951), ш.у. 1957-2010 елларда эшли. Казан ун-ты каршында вузлар арасында сәнгати иҗатны системалы-комплекслы рәвештә өйрәнү буенча фәнни юнәлешнең оештыручысы һәм житәкчесе, аның методологик һәм теоретик нигезләрен булдыручысы. Фәнни эшчәнлегенең төп юнәлешләре – әдәбият теориясе һәм әдәбият белеменең методологиясе, цивилизация һәм культурология аспектларыннан чыгып дин һәм мәдәният диалогы; сәнгати иҗат үсешен күзаллау; әдәби багланышлар (татар әдәбиятының рус, ш.у. төрек, әзәрб., әрм. әдәбиятлары б-н); татар әдәбиятында модернизм. Аерым хезмәтләре чит илләрдә басылды (Австрия, Германия, Кытай, Төркия). ТР ның Дәүләт премиясе лауреаты (1999).

Әс.: Комплексное исследование художественного творчества: Проблемы прогнозирования. К., 1990; Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. К., 1997; «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. К., 2002; Системно-комплексное исследование художественного творчества: История научного направления в Казанском университете. К., 2004.

Әд.: Саяпова А.М. На высоте мировой научной мысли // Научный Татарстан. 1999. №1; Фасхутдинова Э. Верность призванию // 2004. №10.

**НИЗАМИ ГАНҖӘВИ** (Әбү Мөхәммәд Ильяс Йосыф оглы) (1141 тирәсе, Гәнҗә ш., Атабәкләр дәүләте, хәзер Әзербайҗан дәүләте – 1209 тирәсе, шунда ук), әзәрбайҗан шагыйре, гуманист, фикер иясе. Фарсы телендә язган. Туган гаиләсе шәһәр халкының урта хәлле катламына карый. Тәпле белем ала: математика, астрономия, химия, медицина, география, тарих, логика фәннәрен, чит телләрне өйрәнә. Иң мәшһүр әсәре – 5 поэмадан торган «Хәмсә». Беренче поэма «Мәхзәнел-әсрар» («Серләр хәзинәсе», 1180) төзелеше б-н «тартмалы композиция»не тәшкил итә; 2 бүлеккә бүленгән: яшәешнең төрле мәсьәләләренә багышланган тезмә фикерләүләрдән һәм хикәяләрдән гыйбарәт булган 20 мөстәкыйль бүлек-мәкаләләрдән тора. 1414 елда «Мәхзәнел-әсрар» Хәйдәр Харәзми тарафыннан төрки-татар теленә тәрҗемә ителә. Әсәрнең аерым өзекләре И.Березинның Казанда басылган «Төрек хрестоматиясе»нә («Турецкая хрестоматия», т.1, 1857) керә. «Хөсрәү вә Ширин» исемле икенче поэмасы мәхәббәтнең бөеклегенә һәм гуманистик идеяләргә дан җырлый. Ана нигезләнеп төрки-татар шагыйре Котб 1342 елда шул ук исемдә шигъри роман яза. «Ләйлә вә Мәҗнүн» исемле өченче поэма фаҗигале мәхәббәтне тасвирлауга багышланган. 1950 елда ул М.Максуд тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителә һәм аерым китап булып бастырыла. Дүртенче «Җиде гүзәл» (1196) исемле поэма сюжетын шах Бәхрам Гүрнең җиде игелекле патша кызлары тәэсирендә галел, акыллы хөкемдарга әверелүе тәшкил итә. Циклның «Искәндәрнамә» исемле

соңгы поэмасы 2 кисәктән тора: «Шәрәфнамә» («Дан поэмасы») һәм «Икъбалнамә» («Бәхет поэмасы»). Аларда Искәндәр яулап алучы патша, фәлсәфәче, акыл иясе һәм пәйгамбәр итеп тасвирлана. «Искәндәрнамә» (оригиналда да, төрле версия һәм тәрҗемәләрдә дә) Идел һәм Урал буйларында киң таралыш ала. Төрек шагыйре Әхмәди (1334-1413) тарафыннан тәрҗемә ителгән вариант аеруча популярлык казана, татар мәктәп-мәдрәсәләрендә дәреслек булып хезмәт итә, С.Кукляшевның «Татар хрестоматиясе»нә («Татарская хрестоматия», 1859) кертелә. Җәмгыятьнең иң мөһим социаль-сәяси һәм фәлсәфи мәсьәләләрен, кеше яшәешенең асылын поэтик фикерләү яссылыгында караганда «Хәмсә» поэмалары үзара әчке бәйләнешкә ия. Әзәрбайҗан галиме А.А.Гаджиев фикеренчә, «Хәмсә» — иң элек гомернең асылы, яшәешнең мәгънәсе, кешенең бурычы турындагы ренессанс (янарыш) характердагы эпик-фәлсәфи трактат. Н.Г. кеше психологиясен сәнгати яктан ачуны тирәнәйтә, кеше характерын динамикада бирә; утопиягә нигезләнгән социаль гармониягә ия булган дөнья тудыра. «Хәмсә» көнчыгыш һәм бөтен дөнья әдәбияты үсешенә зур йогынты ясый. Лирик диванның бер өлеше сакланып кала: 6 касыйдә, 116 газәл, 2 кыйтга һәм 30 робагый. Диванның лирик әсәрләре һәм поэмалардан өзекләр татар теленә Г.Рәшиди, Н.Исәнбәт, Ә.Исхак, Л.Шагыйрьҗан тарафыннан тәрҗемә ителәләр. Н.Г. иҗаты татар халкының рухи тормышында, татар әдәбиятының үсешендә зур роль уйный. Н.Г.нең геройлары, образлары, сюжетлары, мотивлары Котб, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, Г.Кандалый, Дәрдемәнд, Г.Тукай һ.б. татар шагыйрьләре әсәрләрендә очрый. Тәхәллүсләренең берсе «Мәҗнүн» булган. Тукай «Мәхәббәт» исемле шигырендә Н.Г. геройлары исемнәрен бөек мәхәббәтне гәүдәләндерүче чара итеп файдалана.

«Искәндәрнамә» поэмасының күчермәләре ТРның Дәүләт музее фондларында, Казан. ун-тының Фәнни китапханәсендә саклана.

Әд.: Бертельс Е.Э. Низами: Творческий путь поэта. М., 1656; Алиев Г.Ю. Темы и сюжеты Низами в литературах народов Востока. М., 1985; Миннегулов Х. Татарская литература и восточная классика. К., 1993; Әхмәтова Э. Низами һәм Котб иҗатына бер караш // Татарстан. 1996. №6.

*Х.Й.Миннегулов.*

**НИЗАМИЕВ** Рашат Мияссәр улы (1.3.1950, Саба р-ны Олы Мишә ав. туа), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1992). Казан ун-тын тәмамлагач, (1972) Биектау р-ны Олы Битаман урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. 1974-81 елларда «Татарстан яшьләре» г-тасында башта корректор, соңрак җаваплы сәркатип булып эшли. 1981-83 тә «Ялкын» ж-лында җаваплы сәркатип. 1983-97 дә «Казан утлары» ж-лында проза бүлеге мөхәррире, аннары баш мөхәррир урынбасары. 1997-2005 тә «Идел» ж-лы баш мөхәррире. 2007 дән кабат «Казан утлары» ж-лында. «Йолдыз янгыры» исемле беренче шигъри җыентыгы 1980 елда дөнья күрә. Шигырьләре тупланган «Кызыл җәй» (1983), «Тормыш трамвае» (2005), повестьләр һәм хикәяләрдән торган «Бөек сер» (1986) һәм «Кызыл кар яугач» (1993), «Яшьлеккә хат» (2003), балаларга атап язылган «Яралы керпе» (1987), публицистик язмалары тупланган «Алдым каләм кулыма» (2007) исемле җыентыклар авторы. Н.нең иҗатында яшь буынны тәрбияләү, әдәп-әхлак кагыйдәләре, милли традицияләрне янарту кебек проблемалар игътибар үзәгендә. Ул шулай ук күренекле татар композиторының тормыш һәм иҗатына багышлап «Фәрит Яруллин» (1990, икенче исеме «Ут һәм җыр» , 2000) дигән документаль роман язып бастыра. Н.ның бүгенге көн иҗатына күбрәк публицистик үткенлек, драматик киеренкелек, фәлсәфилек һәм лирик җылылык хас.

Әд.: Шабаев М. Үз йолдызы бар // Казан утлары. 2000. №2; Хәлим А. Милли тәсбих турында хикәят // Мәдәни җомга. 2002. 15 февр.

*Г.М.Габделхакова.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# АРТИСТ ЯЗМАЛАРЫ

## Мин ничек Казанга укырга бардым

Унынчы сыйныфны тәмамлагач, кулга аттестат алгач, ничек кенә булса да авылдан чыгып китәргә, кайда булса да укырга кирәк икәне каныбызга сеңгән иде. Тик институтка керә алмасаң, оятыннан нишләрсең? Әти-әни генә түгел, туганнарың да. «Яхшы укый, тырыш бала, аннан кеше чыгачак», дип өметләнеп яшәгәндә өметләрен акламасаң, күзләренә ничек карарсың, алай гына да түгел, бөтен авыл. Чалпы урта мәктәбе укытучылары алдында оятка калуың бар. Шуңа күрә бөтен теләк Казанга барып, нинди дә булса институтка керү. Минем өчен кайсы булса да барыбер, мин әле институтның, шәһәрнең нәрсә икәнен белми идем. Әни кич белән юлга дип тәмле ризыклар әзерләде, малае Казанга укырга бара бит! Габдулла абыйдан калган ботинка, Нурулла абыйдан калган чалбар, күлмәк кенә үземнеке. Кияргә юньле кием дә юк, хәер, ул турыда уйламадым да инде. Уналты яшьлек чандыр гына бер малай, сөенә-сөенә укырга керергә бара. Авылдан чыгып Карамалыга житкәндә бик көчле яңгыр ява башлады. Өс киемнәребез манма су, аяк киемнәребезгә капкара балчык чабатадай ябыша, куптарып алмалы түгел. Атлап булмый башлагач, Нәжибәгә әйтәм: «Без болай баралмыйбыз, әйдә, аяк киемнәребезне салып, берәр жиргә яшереп куябыз». Рангазар күперенә житкәч, күпер астына төштек тә, аяк киемнәребезне беркем дә күрмәслек итеп яшереп калдырдык, кайтканда кире алырбыз янәсе. Хәзер атлавы шулкадәр жиңел, рәхәт булып китте, яланаяк йөрергә шулкадәр өйрәнелгән, пычрак сизелми дә.

– Нәжибә, әйдә, басу аркылы Сарманга барабыз, Рангазарга кереп тормыйбыз, югыйсә Чаллыга бүген барып өлгермәбез.

Шулай итеп, ашлык басуы арасыннан бик озак җәфаланып баргач, көч-хәл белән Сарман тавына килеп чыктык. Сарманнан самосвал машинасына утырып, кичкә Чаллыга барып життек. Әйткәнемчә, аяклар тездән кара балчыкка ябышып каткан. Чаллы пристаненда аякларны, битләрне юып, яланаяк пароходка утырабыз. Мин инде билет алып тормаска булдым, халык белән буталып, әйткәнемчә, буем кечкенә, үзем чандыр, ык-мык килдем дә, тиз генә пароходка кереп тә киттем. Бераз баргач билет тикшерә башладылар. Мин тиз генә пароходның бер почмагына, кеше керә алмый торган мичкәләр арасына сеңдем. Мине моннан бер кеше дә эзләмәс, таба алмас кебек тоелды. Чыннан да, монда кеше бардыр дип, беркем дә уйламаячак. Караңгы төшкәч, Нәжибәнең хәлен белергә бардым. Ул бит минем билетсыз икәнемне белми, күз алдына да китерми. Ничек инде, курыкмыйча, пароходка билетсыз керергә мөмкин. Мин үзем дә Нәжибәне күргәч айнып киткәндәй булдым, нәрсә эшләгәнемне аңлап, куркуымнан калтырана башладым. Нәжибә: «Син нәрсә, авырыйсыңмы әллә?» – дип сорады. – «Юк, мин әйтәм, аз гына калтырата, яңгырда салкын тигән ахры», – дим. Төнлә керфек тә какмыйча, үземне сүгеп чыктым: «Дурак та дурак, син дә дурак!»

Менә Казанга да килеп життек. Сөенечемнән үземне кая куярга белмим. «Ну, малай, Чаллыдан Казанга бушка килдең бит!» Траптан төшкәндә зур гына гәүдәле, сары чәчле бер урыс егете билетлар тикшерә башлады. «Готовьте билеты!» Мин

нишләргә дә белмичә катып калдым, чиратымда аптырап торам, менә килеп каптым. Мине халык төрткәли-төрткәли алга таба этә башлады. «Ну что ты стоишь? Глухой что ли?» – диешәләр. Бер заман билетларны тикшеручe урыс янына китереп бастырдылар. Ул миннән билет сорый: «Где ваш билет?» Мин авызымны ачып бер сүз дә әйтә алмыйм, аякларым да атламый. Гомеремдә беренче мәртәбә урамга чыккан сарык бәрәне кебек аптырап карап торам. Шуннан сон бу кеше мине күтәреп алды да, арт ягыма шундый итеп китереп типте, очып киткәндәй булдым. Карасам, җирдә аунап ятам, фанер чемоданым ачылып киткән, әйберләрем таралганнар, әни биргән йомыркалар төрлесе төрле якта тәгәрәшеп ята. Ярый әле китап битенә төргәнгә, барысы да ватылмаган, исәннәре дә бар иде. Шул вакыт Нәҗибә: «Нәрсә булды, бик озак тордын?» – ди. Мин әйтәм: «Билетымны югалтканмын, шуны эзләп азапландым», – дим.

Әле ин кызыгын сөйләргә онытканмын икән. Нәҗибә: «Әйдә инде, тиз бул! Нәрсә мыштырдыйсын? Әнә, трамвай кузгала!» – ди. Кая, без утырганчы трамвай кузгалып та китте. Артыннан чабабыз да чабабыз. Үзебез: «Туктагыз, туктагыз инде», – дип кычкырабыз. Тамаклар бетте. Кая туктау, трамвай бара да бара. Белмим, әллә тукталышка килеп життек, әллә кешеләр зур сандыклар күтәргән яланаяк авыл балаларын жәлләп микән, трамвайны туктаттылар. Монда да билет саталар икән, русча: «Берите билет», – дип бер апа ике мәртәбә янымнан узып китте. Мин кая барсам шунда килә, ул яныма килгән саен, мин икенче урынга күчәм. Шуннан, кыяфәтемә карап торды да: «Что спросишь, чаплашка», – диде дә, кулын селтәп, жирәнгән кыяфәттә урынына барып утырды. Менә хәзер минем хәлне күз алдына китереп карагыз инде. Шушы баланы язмыш театр дөньясына алып кереп китә.

## Боз өстендә

Минем белән кызык хәлләр еш була дип язган идем инде. Шундый бер вакыйганы искә төшерәсем килә. 1972 елнын февраль башында этидән хат килеп төште. «Улым, вакытын булса, бер әйләнеп кил әле, бәләкәй баланы да алып кайт, бик күрәсем килә, хәлем әйбәт түгел!» Казаннан безнен авылга кайту жинел түгел, бигрәк тә кыш көне, житмәсә бала белән. Бервакыт театрда авылдашым Әсләхне очраттым, ул Азнакайда балалар больницасында баш врач булып эшли иде. Отчет белән Казанга килгәннәр: район больницасынын баш врачы, райисполком кешесе – өчесенә ике машина. Берсе ГАЗ-69, икенчесе «Волга».

– Әйдә, Азнакайга кайтабыз», – дип шаярта. – Үзем алып кайтам, – ди.

– Сез кайчан кайтасыз?

– Иртәгә, төштән сон.

– Ярар, уйлармын.

Спектакль беткәч, барысын да хәл иттек.

– Мин иртәгә улым Рөстәм белән, ана әле биш кенә яшь, сине үзебезнен урамда, йорт каршында көтеп торам, – дип, сүз куештык Әсләх белән.

Сажидәгә кирәк әйберләрне әзерләргә куштым:

– Иртәгә авылга китәм, – дидем.

– Син нәрсә, кыш көне, сезнен авылга кереп булмый, анда юл юк.

– Мин кайткач булыр. Әти кайтырга кушкан, үзем генә түгел, Рөстәмне дә алып кайтам.

– Ты что, одурел что ли? Зимой 400 км с ребенком, я не разрешаю!

– Мине тынламасан этине тынла, баланы бик күрәсем килә, дигән. – Төне буе талашып чыктык. Нишләсен, риза булды.

– Бер-бер хәл булса, үзен жавап бирәсен, мин сине кисәттем, – диде Сажидә.

Финляндиядән алып кайткан зур сары сумканы шул кадәр тутырган, күтәреп булмый.

– Син нәрсә тутырдын анда?

– Әтигә жылы спортивный трико, әбигә күлмәклек (минем үги әнине без әби дип йөртә идек). Рөстәмнен жылы алмаш киемнәре, сина костюм, күлмәк, поло-

тенце. Подарки – чай индийский, сухофрукты, шоколадные конфеты, разное печенье.

Минем хатын яртылаш русча, яртылаш татарча сөйләшә, татарчага үзем өйрәттем. Ачуы килгәндә гел русча сөйләшә. Менә хәзер дә:

– Две бутылки коньяка, лимон, икра. Смотри, сам не пей!

Ул Казан ресторан трестында бухгалтер булып эшли иде. Шуңа күрә нәрсә кирәк, шуны ала, ул заманда бар нәрсә дә дефицит иде. Хәзер генә ул ни телисең, шул бар, акчаң гына булсын. Костюм кесәсенә паспорт белән, бераз җыйган «заначка» бар иде, шуны салдым. Тагы нәрсәләрдер сөйләгән иде Саҗидә, оныттым инде. Шундый зур бүләкләр, күчтәнәчләр белән эти янына кайтырга чыктык. Зур сумканы «Волга» машинасының багажнигына көчкә сыйдырдык. Шунда Саҗидә әйтә: «Рөстәм улым, әллә бармыйсыңмы, әнә кара, буран чыгарга тора, авыл бит ерак». Кая, Рөстәм машинадан чыгарга уйламый да. Миңе тагын бер-ике мәртәбә кисәтте: «Зинһар, юлда кешеләр белән эчә күрмә, үзең генә түгел, бала бар. Помни, что я тебя предупредила! Повторять не буду!»

Казаннан ике машина белән чыгып киттек. «Волга» машинасында улым белән икәү барабыз. Тегеләр «вездеход»та өчәү күңел ачып, баян белән җырлап, рәхәтләнеп кайталар. Әсләх баянда искиткеч уйный, җырлый да. Саескан тавына җиткәч, миңа әйтәләр: «Без Кама уртасында туктап, боз өстендә утырып, бер яртыны эчәбез, ул безнең гадәткә кергән – «обычай», – диләр. Мин аңладым, болар миннән бер ярты өмет итәләр. Шунда шофер белән теге сумканы чыгарып боз өстенә куйдык. Мин бер ярты коньяк, бер лимонны кисеп алларына куйдым. «Сезгә бик зур рәхмәт инде, миңе зурлап туган ягыма алып кайтасыз. Сез беләсезме кемне алып кайтканыгызны? Әйдәгез, шуның өчен берне күтәреп куйыйк». Коньяк белән лимон капкач, күңел тагы да күтәрелеп китте. «Без кем белән кайтканыбызны бик яхшы беләбез», – дип, тегеләр шешәнең төбенә төштеләр. Мин тагы нәрсәдер әйтмәкче идем, райисполком кешесе, ярар, әйдә кузгалыйк, дип, миңе үзләре янына вездеходка утыртты. «Минем анда бала борчыла, сезнең белән озак бара алмыйм», – дип, әйтеп карадым. Әсләх баянын сузып җибәргәч, күңел әллә нишләде. Ярый, сезнең хөрмәткә ике җыр башкарам да, бала янына барам. Кая ул ике җыр, бер башлагач шактый җырладык. Чистайга җитәбез дигәч, тегеләр, әйдә, Чистайга кереп ашап чыгабыз, диләр. Мин бала янына төшеп утырдым, ул рәхәтләнеп йоклый иде. Да, болар минем калган коньякка да өмет итәләр ахрысы дип уйлавым булды. Чистайга да килеп җиттек. Машина ашханә янына килеп туктады. Рөстәмне алып ашханәгә кердем. Минем дуслар көтеп утыралар.

– Ярый инде, булгач булсын, тагы бер коньягым бар. Әйдәгез, шуны бераз эчәбез, монда юкка кердек, кайтырга иде тизрәк, караңгы төшә, бала белән уңайсыз. Әйтегез шоферыгызга, минем сумканы алып керсен.

Бер заман шофер килеп кергән:

– Анда бит сумка юк!

– Ничек юк? Шундый зур сумка кая китсен!

Тиз генә машина янына чыгып киттем, багажникны ачып карыйм, сумка юк! Хуҗалар янына кердем дә:

– Минем әйберләр юк бит, нишлибез?

Миннән сорыйлар:

– Ә син сумкаңны багажникка куйдыңмы соң?

– Нишләп аны мин куярга тиеш, аның өчен шофер бар бит! Син нишләп минем әйберләрне багажникка куймадың, шундый зур сумканы күрмәдеңмени?

– Мин сумка ташып йөри торган малай түгел, игътибар да итмәдем, утырдык та киттек, – ди шофер.

Райисполком кешесе машинаны кире Камага җибәрде.

– Бар, алып кайт артист Шакировның сумкасын!

Хәзер нишләргә? Бер ярты аракы чыгардылар, ашарга алдылар. Кая миндә ашау-эчү кайгысы, әйберләремне тапса иде дип, бер Ходайдан ялварам. Ходай шундый чакта гына искә төшә бит ул. Хуҗаларым ашадылар, эчтеләр, машина да

кире кайтты. Юл уртасында, боз өстендә калган сумканы ничек табасың? Кешеләр дурак түгел, алганнар да киткәннәр. Инде хәзер нишләргә? Кире Казанга кайтыргамы? Бернинди кучтәнәчсез эти янына кайтып булмый бит инде. Сажидә алдында оят. Аек килеш әйберләрен боз өстендә калдырып киткән. Сөйләсән, кеше ышанмас. Тот та, әйберләреңне Кама елгасы уртасында боз өстендә калдыр инде. Бу бит акылга сыймаслык эш. Исерек булсаң бер хәер, аек килеш! Иптәшләремә аптырап карап торам.

Берсе әйтә:

– Әйдә, Азнакайга кайтыйк, кучтәнәчләрне анда алырсың, паспорт югалганын да әйтербез.

– Минем хәзер кучтәнәч алырлык акчам да юк. Булган акчам паспорт эчендә иде.

Барысы да айнып киткәндәй булды.

– Син нинди шофер, хуҗаларыңны йөрткәч, аларның әйберен кем күтәрсен, кем урнаштырсын, аны син эшләргә тиеш! Син! Мин сезне чын күңелдән хөрмәт итәм, ә сез!?

Барысына да бик нык үпкәләдем. Ачуымнан нәрсә әйткәнмендер, хәзер инде хәтерләмим. Казанга кайтасы килми, авылга да барасы килми, үз-үземне кая куярга белмим. Әй, дурак, сезнең белән нигә чыгып киттем! Көчкә тынычландырып, Азнакайга кайтарып җиткерделәр. Төнге сәгать унберДә бала белән кайтып төшкәч, апа белән җизни бик нык аптырадылар.

– Нишләп кайттың, кем китерде, әйберләрең кайда? – бер-бер артлы сорау артыннан сорау бирә башладылар. – Сажидә баланы ничек җибәрде?

Әллә мине, Сажидәне ташлап, баланы аларга карарга алып кайткан, дип уйладылар ахыры. Чөнки аларның балалары юк иде, алар өчен мин бала булдым, бигрәк тә эни үлгәч. Нәрсә булган, барысын да сөйләдем.

Икенче көнне иртүк апа белән кибеткә кереп, этиләргә кучтәнәчләр, Рөстәмгә киемнәр, үземә күлмәк, свитер алдык. Минем бәхеткә, апа гомер буе кибеттә сатучы булып эшләде. Шуңа күрә кирәк әйберләрне ала алдык. Хуҗалар да җыелып кучтәнәчләр алганнар, райисполком машина бирде. Буралы авылында безне Беларусь тракторы көтә иде. Алдан Беларусь бара, артыннан без, шулай авылга килеп кердек. Әти белән әби сөенеп каршы алдылар, бигрәк тә эти. Рөстәмне күргәч күңеле тулды. «Әй, бәләкәй малай, сине күрми үләм икән, дип уйладым». Әтинең хәле чыннан да әйбәт түгел иде. Ике көн күнгач кире Казанга кайтып киттек. Әгәр бу бәладән исән-сау котылсам, эчмәм дип сүз биргән идем. Бер айдан барысы да онытылды. Сажидәгә, әйберләребез «Волга» машинасының багажнигы ачылып, сикерткәндә төшеп калган, дип аңлаттык. «Чыгып киткәндә үк миңа сезнең багажник ябылмады кебек тоелды. Ярый инде, әйберләр табылыр, баланы исән-сау алып кайттың – миңа монысы очень важно, – диде ул.

Үзем язам, үзем аптырыйм, нишләп мондый хәлләр гел минем белән генә булды икән?

## Мин ничек беренче мәртәбә опера тыңладым

Миңа, яшьлек елларымда татар театрын, аның артистларын күрергә насыйп булмады. Авылыбызда тыңлыйм дисәң хәтта радио да юк иде. Үз гомеремдә беренче мәртәбә театрны Мәскәүдә Щепкин исемендәге театр училищесында укыганда күрдем, анысы да рус театры иде.

Беркөнне безнең укытучыбыз *Лидия Ивановна Дейкун*: «Мин сезгә Большой театрга билетлар алырга куштым. Анда Глинканың «Иван Сусанин» операсын карарга барырсыз, акчаларыгызны әзерләгез», – диде. Мин әйтәм: «Мин Большой театрга бармыйм, минем анда җырлыйсым юк. Мин драма артисты булам». – «Шакиров, нәкъ миңа синә анда барырга кирәк тә, чөнки синең әле операны тыңлаганың юк. Большой театр белән танышып кайтырсың». Укытучы кушкач нишлисең, тыңламый хәлең юк. Әлбәттә, минем өчен акча кызганыч иде. Без бүтән театрларга бушка,

студент билеты белән керәбез, монда түләргә кирәк. Билет бәясе 70 тиен, нәкъ безнең бер көнлек ризык. Безнең стипендия аена 21 сум. Шуңа күрә хәтерләмим, күпме кеше барганбыздыр, артык күп булмас.

Зур театрның эченә кергәч, мондагы матурлыкны күреп, шаккаттым, булса да булыр икән мондый искиткеч матурлык, барсы да алтыннан. Безнең утыра торган урыннарыбыз бик биектә булып чыкты, 4 нче яруста. Менә «Иван Сусанин» операсы башланып китте, музыка уйныйлар, җырлый башладылар. Мин аптырап як-ягыма карыйм. Минем янымда утырган өлкән яшьтәге апалар бик бирелеп музыка тыңлыйлар, сәхнәне карыйлар. Бераз утыргач түзмәдем: «Нигә алар гади генә сөйләшмиләр, гел җырлыйлар, мин аларның нәрсә җырлаганнарын аңламыйм, зинһар аңлатыгыз, нәрсә турында җырлыйлар соң алар?» – дип бер өлкән яшьтәге ападан сорадым. – «Молодой человек, не мешайте слушать оперу, сидите тихо, внимательно слушайте, потом поймете».

Утырам, утырам, бер дә кызык түгел, урыслар бик каты көчәнеп, акырып кычкыралар, җырлыйлар, сүзләрен аңлый алмыйм, никадәр кычкырмасыннар, күңелемә, җаныма тәэсир итми, бу миңа ят нәрсә. Эчтән генә уйлап куйдым, болар бит дөрес уйнамыйлар, ягъни сәхнәдә дөрес яшәмиләр. (Мин бит әле опера сәнгатенең үз законнары барын белми, аңламый идем, аны аңлар өчен үзе бер гомер кирәк.) Декорацияләре әйбәт, киемнәре искиткеч, сәхнә тулы йөзләгән халык. Көчле утлар, карлар ява. Әмма күңел тартмый, икенче пәрдәдә чыгып китәм дип утырганда, сәхнәгә ике ат килеп чыккач, бөтенләй аптырап телсез калдым, куанычымнан күземә яшьләр килде, авылны күргәндәй булдым. «Карагыз, кара! Нинди матур атлар!» дип сикереп тордым. Янымдагы тамашачыларга төртә-төртә күрсәтәм: «Сез нәрсә, күрмисезме әллә, шундый матур атларны! Мондый атлар дөньяда юк!» Тамашачылар миннән көлә башладылар. Кайберләре тынычландырырга кереште, күршедәге теге апа: «Молодой человек, ради бога, успокойтесь, прошу Вас, дайте мне послушать оперу!» – дип, миңа кисәтү ясады. Мин әйтәм: «Сез бит белмисез, их, безнең авылда булса иде мондый атлар! Юк шул, мондый атлар авылда буламыни?» Күңел әллә нишләде. Полякларның Иван Сусанинны җәзалап үтерүләре дә ул кадәр тәэсир итмәде, чөнки мин ышанмадым. Ә менә ике атның сәхнәгә чыгуы гомерлек истәлек булып калды. «Әйе, мин әйтәм, менә сиңа опера», – дим. Бер студенттан сорыйлар икән: опера белән опереттаның аермасы нәрсәдә? Студент: «Опера – мужчина, оперетта – женщина», – дип җавап биргән. Миңа операны шул студент хәтле аңлау өчен генә дә, бик күп мәртәбә опералар тыңларга кирәк иде.

## Мин ничек Совет паспорты алдым

1956 елда ун классны тәмамлагач, кайда булса да укырга кирәк ич инде дип, үзебезне Казанга институтка керергә әзерлибез. Өч ел буе 20 чакрымга көз диме, кыш диме, кар диме, буран диме, бер кисәк икмәк күтәреп, Чаллы урта мәктәбенә җәяү йөреп укып кара әле! Нәҗибә белән икебезнең уку яхшы иде. Югыйсә, ул заманда кем сине көчләп укытсын, үзебез чын күңелдән теләп укыдык.

Институтка керер өчен колхоздан справка алырга кирәк, колхоз укырга җибәрергә рөхсәт бирә, дип. Әгәр колхоздан справка ала алмасаң, институтка керә алмыйсың, паспорт та бирмиләр. Бер сүз белән әйткәндә, син авыл кешесе, мәңге авылда калырга тиеш. Синең киләчәгең мангаеңа язылган, кол булып тугансың, кол булып үләсең! Шуңа күрә, Канәгать абый Газизуллин артыннан басуда, сөргән кара җирдә: «Канәгать абый! Канәгать абый! Зинһар, справка бир инде!» – дип елыйелый, Нәҗибә белән артыннан чапканым әле дә хәтеремдә. Ул, ат өстеннән генә: «Әгәр сезне колхоздан җибәрсәк, монда кем эшләр, сез нәрсә, колхозны җимерергә уйлыйсызмы?» дип котыбызны алган иде. Шунда безнең күз яшьләрен күргәч, бик ялынгач, түзмәде, справка алырга рөхсәт бирде. Рәхмәт инде, андый кешене ничек онытасың.

Паспорт алуым да хәтеремә бик уелып калган. Безнең авылдан район үзәге Тымытыкка кадәр 40 чакрымнар булыр. Иртән иртүк Нәҗибә белән чыгып киттек, бер

чабабыз, бер йөгерәбез, ниһаять көндезгә әбәткә барып життек. Район үзәге бит, мина бик матур күренде. Милиция, паспорт бүлеге дигән язуны күргәч, әллә нишләп куркып киттем. Керергәме, кермәскәме, дип икеләнеп торганда, Нәжибә алып кереп китте. Эчтә караңгы, ниндидер тимер рәшәткәләр бар. Нәжибәне фотога бик тиз төшерделәр. Шуннан мине чакырдылар. Паспорт бирә торган апа мина гажәпләнеп карап торды да: «Юк, энем, сиңа паспорт биреп булмас, кыяфәтең паспортка төшәрлек түгел. Кара инде бу күлмәгеңне, кара инде бу чалбарыңны, аягыңда бер нәрсә дә юк. Яланаяк паспорт алырга килмиләр. Совет паспортын синең кебек хәерчеләргә бирмиләр. Ул – Совет гражданинының горурлыгы! Син нәрсә, безне мыскыл итеп юри шулай киенеп килдеңме? Бар, авылыңа кайтып кәчтүн, ак күлмәк, аягыңда ботинкаң булсын, киенеп кил», – диде. Мин нишләргә белмичә, ап-ак булып каттым да калдым, күзләргә дә, жыларга да белмим, куркуымнан, оятымнан жир тишегенә кереп китәр идем. Түземедем: «Апа, безнең авыл моннан 40 чакрымнар бит, мин ничек кайтып килим. Аннан соң, минем авылда паспортлы кешене күргәнем дә булмады. Мина ничек киенергә кирәк икәнен әйтүче дә булмады. Минем бит кияргә кәчтүм-чалбарым да юк. Ничек инде мин авылга оялмыйча кайтыйм?» – дип елап жибәрә яздым. «Бар, бар, авылыңа кайт, киенеп кил, күземә күренмә!» Шунда фотога төшерүче абый мине жәлләп: «Ярый, бик борчылма, аягың белән чалбарың күренми анда. Күлмәгең бераз искерәк икән анысы. Ярый, анысын табармын, менә шушы костюмны киярсең», – дип стенада эленеп торган кәчтүмне бирде. Фотога ничек төшкәнемне хәтерләмим. Ярый әле Нәжибә бу хәлләрне күрмәде, мине көтеп тышта утыра иде, күрсә, белмим, оятымнан нишләр идем. Шул көнне үк 40 чакрымны тагын жәяүләп кайтырга чыктык. Юл буе: «И, Ходаем, бу турыда беркем дә белмәсен иде», – дип, теләк теләп кайттым. Ничек инде, сиңа Совет паспортын бирмәсеннәр, дөньяда моннан зур кайгы, хәсрәтнең булуы мөмкин түгел, оятыннан асылынып үләрсең, хурлыгы ни тора. Сиңа Совет паспортын бирмиләр! Кияргә киемең юк! 16 яшьлек егетнең хәлен күз алдына китерәсезме? Минем өчен моннан да зур гаделсезлек юк. Әгәр фотограф абый булмаса? Мин бит аңа рәхмәт тә әйтә алмадым. Гарьлегемнән ауный-ауный елыйсым килде. Хәзер инде ул паспортны кайчан алганымны хәтерләмим. Әллә шул көнне алдык, әллә яңадан килеп. Паспортны карагач, үземне танымадым, ниндидер бер бәхетсез бала рәсемнән карап тора иде. Ә менә Чуар-Абдул авылының яшелчә бакчасыннан кишер урлап, туйганчы ашадык, югыйсә, авылга кайтып житеп булмас иде.

**Әзһәр ШАКИР,**

*Татарстанның һәм Россиянең халык артисты,*
*Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт*
*премиясе лауреаты*

## КАР БАШЫНА КАР ҖИТӘ...

Быел ирем Аяз Гыйләҗевнең тууына 85 ел тулды. Андый даталар үткәннәрне хәтердә янарта... Моңа тагын Татарстанның беренче Президенты, милләтебезнен иң күркәм шәхесләреннән берсе М.Шәймиевнең әтисе Шәрип Шаһимөхәммәт улына багышлап чыгарылган «Сагыну» китабын (төзүчесе һәм мөхәррире Н.Гыйматдинова) уку да сәбәпче булгандыр. Милләтне милләт итеп башка халыкларга таныту юлында әйтеп бетергесез изге эшләр башкарган Президентыбыз әтисенең, гомумән, бу нәселнең эшлекле гамәлләренә ышандыра торган дәлилләр җыелмасы итеп кабул иттем мин ул китапны. Татарстан җиренә бәрәкәт иңүгә илткән юл башында торган, ихтирамга, хөрмәткә лаеклы Шәрип ага турында тасвирлап язып халыкка җиткерү бик кирәкле эш иде. Мин бу китапны мәгълүмат чыганагы буларак та яратып укыдым. Шаһимөхәммәт улы Шәрипнең авыр туфрагы җинел булсын, урыны җәннәттә булсын! Амин! Ул илебезгә, җиребезгә ихлас хезмәт итәргә сәләтле нәсел башы атасы була алган!

Хәзерге Президентыбыз Остазы сабакларын камилләштерә барып, ахыргы нәтиҗәсе әйбәт була баруы белән куандыра тора! Россия җирендә генә түгел, бөтен дөнья халыклары янәшәсенә куелып макталырлык дәрәҗәгә күтәрелә барабыз, дип куанып яшим мин. Президентларыбыз үтемле фикерләрен кистереп әйтеп, халкыбызны дөньяга танытталар икән, бу бит аларның оештыра белү осталыгы нәтиҗәсе! Акыллы ата – Шәрип ага никадәр ихлас, эшчән, акыллы башлар тәрбияләп калдырган булса, инде килеп Нургали ага да кимен куймаган ич! Илебез, Татарстаныбыз аларга таянып горур күтәрелештә булып, Республикабыз халкына куанычлар китереп яши, уңышларга ирешә. Бусы һәммәбезнең күз алдында. Күркәм эшләребез дәвамлы булсын! Аталар – илебезгә, җиребезгә, милләтебезгә бәрәкәтле хезмәткә балаларын әзерләүче шәхесләр булып ишәйсеннәр. Әниләр үрнәк гаиләләрнең тоткасы булсыннар. Амин! Сүз башымның җебе, эшнең башы һәм нәтиҗәлелеге, беренче чиратта, шәп оештыручыдан тора, дип әйтәсем килүгә кайтып кала.

Минем ирем – Аяз Гыйләҗев тумышы белән Язучы иде. Кемнәрдер, әдәбиятны кечкенәдән яратып укып, тырышлыгы белән язучы булып күтәрелә. Ә Аяз туганда ук язучы гына булып туган икәнлеген үзенең язмаларында да гел ачыклап килгән. Кайберәүләр комплимент итеп: »Син булмасаң, Аязың Язучы булып күтәрелә алыр идеме икән?» – диләр. Җавабымда «Мин Аяздан Язучы ясаучы түгел», дим. Дөрестән дә шулай. Аллаһы Тәгалә аны Язучы итеп яраткан. Аның күзәтүләре, дөньяны анлавы, аннан үзенчәлекле мәгънә чыгара алуы, алдан күрүчәнлеге белән тирә-яктагы кешеләрдән аерылып торды. Без бер гаилә булып кырык биш ел бергә яшәдек. Гаилә булганчы дус мөнәсәбәтләрдә дүрт ел дәвамында йөрүләребез мине шундый нәтиҗә ясый алырлык иткәндер.

Аяз бервакытта да житәкче эшләрдә эшләүне күз алдында тотып яшәмәде. Хәтта эш урынына барып утырып эшләүне дә кабул итә алмады. Ул бөтен дөнья әдәбиятыннан хәбәрдар булды, сәясәткә кагылышлы мәгълүматларны нык күзәтеп торды, милләт мәсьәләләренә аек күз белән карарга тырышты, милләтара ызгыш-талашларның кабынуыннан нык курыкты. Балаларының эш яратып үсүен теләде. «Алар нинди һөнәр сайласалар да мин каршы булмаячакмын, тик алар гадел, эшлекле, белемле булсыннар», диде. Мин аның таләпләренә яраклашырга тырышып яшәвемне генә белдем. Ярашмый кара, ай-яй-яй! Безнең гаиләнең законнары коры иде!..

Аяз гомер-гомергә иҗатка яшь буынны тартырга тырышып, аларны төрле юллар белән үстерергә тырышты. Ул бер генә яшь язучыны да читкә тибәрмәде, булдыра алган кадәр дәртләндерергә, өметләндерергә тырышып, милләткә, хезмәткә рухландыру җаен эзләде. Ул үзе күп еллар дәвамында Язучылар берлегенә кабул итү комиссиясендә рәис вазыйфасын башкарды. Баштагы елларда Сибгат абый Хәким рәис булып, ә Аяз аның урынбасары булды. Ул аны үзе башкарырга тиешле «мәҗбүри гамәл» итеп кабул иткәндер. Сибгат абыйга бер заман партия өлкә комитетыннан шелтә белдереп, Аязны ул вазыйфасыннан «алып ату»ны таләп итәләр. Сибгат абый: «Аны алсагыз, мин үзем дә китәм», — дигән төгәл җавабын бирә.

Аяз Язучылар берлегендә бердәмлек, дуслык, татулык, талантлы әсәрләр тудыра алырлык мохит булуына ирешергә омтылды. Аяз Гыйләҗев, Нурихан Фәттах, Хисам Камалов, Гариф Ахунов, Әмирхан ага Еники, Мөхәммәт Мәһдиев яшәгән еллар Язучылар берлегендәге мохит белән хәзерге көн Язучылар берлеге мохите арасында җир белән күк аермасы кебек аерымлык хасил булды кебек. Әллә мина гына шулай тоеламы?! Шулай булсачы! Мин татар телендә чыга торган дәүләт матбугатына язылып барам. «Мин дә язылмагач, кем матбугат чыганакларының бөтенлеген саклауга өлеш кертсен соң?» дип тә язылам. Кайберләрен укып та бетерә алмыйм. Бу гадәт Аяздан безнең гаиләгә сеңдерелеп калдырылган. Язучылар белән сирәк кенә аралашканда да аларның татар матбугатыннан хәбәрдар түгел икәнлекләрен тоям да, үзен язучы санаучы бу кешенең әдиплек һөнәренә тугры хезмәтче булуына шигем арта. «Нишләп укымыйсың син ул газетаны?» дип сорап та куйганым бар. «Аларда рәтле материаллар күргәнем юк минем, алар минем темага кагылышлы кызыксынырлык әйберләр бирмиләр» кебек җаваплар ишетәм. «Син яз кызыклысын, шул вакытта тагын да кызыклы булып китәр ул газета яисә журнал», дип тә әрепләшкәнем бар. Ни гаҗәп, мин шулай дип уйлап, әрләшеп йөрүдән генә үзгәреш булмый икән. Шунысына ышандым: язучыларга да оештыра белү осталары кирәк икән. Аяз гомере буе татар әдәбиятында лидер булмавына ачынып яшәде. Шул эзләнүләре чорында Мостай Кәримгә татар әдәбиятындагы лидерлыкны тапшырырга теләп тәкъдим ясап йөргәннәре дә хәтердә. «Мостай ага, син бит татар, ник безгә лидер түгел син?» дигән иде ул ачынып. Мостай ага башкортларга насыйп булган икән шул. Әле Әмирхан ага Еники чорында татар язучылары аның әкрен генә сайланып чыккан фикерләренә колак салалар иде. Юк, Әмирхан ага бервакытта да Язучыларның югары тәхетенә менәргә омтылмады, ул турыда әйтергә теләмим, аның кистереп бер-ике абруйлы сүз әйтүе җитә иде. Кайсын Кулиев, Расул Гамзатовларның милли йөзле язучылар булуына көнләшеп яшәде Аяз. Яшьләрдән берәүне тартып күтәрәсе килде аның, шул юлда күзе мәңгелеккә йомылганчы эзләнде. Табигать бушлыкны яратмый, булмый калмый әле ул, булачак, дип, өметләнеп яшәде.

Кулыма соңгы елларда чыккан Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары җыентыгын алдым. Анда барлыгы 321 кеше исәпкә алынган икән. Никадәрле талант ияләре бар анда, никадәрле ихлас татар милләтенә хезмәт итүчеләребез тупланган. Саный, исәпли китсәң, бихисап икән безнең талант ияләребез, тик лидерлыкка дәгъва кылучыларыбыз юк дәрәҗәсендә икән. Аязлар чоры язучылары бер йодрык булып яшәделәр кебек, ләкин алар арасында да лидер булып ярылып торган Язучы булмады кебек. Аяз лидер түгел дә түгел иде инде, аның холкы лидерлыкны тартмый иде. Ә Язучылар арасында Аязның сүзе «үтемле сүз» булып исәпләнгәнен беләм. Аның кисәтүләре, тирән мәгънәле чыгышлары һәрвакыт игътибар үзәгендә булды. Баштагы елларда аны билгеле оешмалар тарафыннан күзәтү астында тоттылар, тора-бара ул олыгая төште, гомер кыска бит ул...

«Өч аршын җир» әсәре чыккач купкан гауга күз алдыма килә дә имәнеп китәм. Татарлык-тарлыкның чын үрнәген күрсәтте шул чор җәмәгатьчелеге. Менә милләт характеры, нишләтәсең аны?! Бернишләтеп булмый! Татар дөньясында Аязны унсигез ел буе шул әсәре өчен «ботарладылар». Ә Мәскәү тәнкыйтьчеләре аны чын әдәби әсәр язганы өчен ихластан мактады! Казанда да

әсәрне мактаучылар булды, ләкин аларның Аяз белән янәшә тагарак боткасын ашыйсылары килмәде. Аяз ялгыз иде! Аяз беркемгә дә үпкәләмәде. Нәшриятта китапны чыгарыргамы-чыгармаскамы дигән фикер тугач, рецензиягә Нурихан Фәттахка һәм Хәсән Хәйригә биреләр. Алар икесе дә, совет чынбарлыгына яла ягып язылган әсәр икәнлеген нык дәлилләр белән раслап, әчке рецензияләр язалар. Аяз шул көннәрдә берникадәр Нуриханны әрләп алганын томанлы гына хәтерлим, ләкин ул бу каршылыкны бик тиз «йотты», ник бер вакыт Нурихан хакында тискәре фикер әйтсен. Ул Нуриханны әсәрне үзенчә аңлаган кеше дип кенә кабул итте һәм үпкәсен онытты. Архивтагы чыганакларда Аяз Нуриханны бары тик зур галим, үзенчәлекле милли Язучыбыз итеп кенә телгә ала. Хәзер уйлап куям: «Әгәр шул елларда ук Аязны күккә күтәреп мактый башлаган булсалар, Аяз күтәрелә алмыйча «горурлык боткасында» батып яткан булыр иде. Әле ярый андый каршылыклар килеп чыккан, ул бит ачуланганнарына үч итеп көне-төне язды. Алдагы җыелышның нинди формада үтәсен чамалап, Переделкинога юллама алып чыгып кача иде. Шунда язып ята иде. Һөҗүмнәргә шулай итеп каршы тора алды. Ходай аңа шундый холык биргән, ярый әле мактап бозмаганнар, дип нәтиҗә чыгарам. Соңгы көннәрдә архивын барлап, компьютер хәтеренә кертеп утырам, нәтиҗәне шул чыганакларны барлаганда ясап куйдым. Аязга 1983 елда Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирделәр. Тәкъдим ителүен ишетү белән чыгып качты. Минем аша гына Казан хәбәрләрен ишетеп яшәде. Кемнәр сугәр, кемнәр мактар бит әле?! Аларның матбугатта басылуларына игътибарын юнәлтеп вакытын әрәм итәсе килмәгән. Бирелмәве дә бар бит әле?! Премия бирелү билгеле булган көннәрдә Казанга кайтты. Тантанага мин бара алмадым, кунаклар кабул итәргә, өйдә калдырылган идем. Безнең гаилә өчен иң зур тантана булды ул! Татар дөньясында гел сүгелгән Аяз Гыйләҗев Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булсын инде! Хикмәтле хәл! Гариф Ахунов иде ул вакытта Язучылар берлеге рәисе, ул жаны-тәне белән Аязга премия бирелүне теләде. Рәхмәт яусын, урыны җәннәттә булсын!

Тантанада Аяз мөнбәрдән Г.Тукайның «Бер татар шагыйренең сүзләре» дигән шигырен яттан сөйләгән. Әхсән Баян хатыны Дания Баһаветдинова икенче көнне исе-акылы китеп Аязның нинди шәп оратор икәнлегенә таң калганлыгын белдергән иде: «Кара инде син аны, Г.Тукайның нинди шигырен эзләп табып, үзенә туры китереп, халыкка тәкъдим итте бит...

*...Курыкмаслыкта күңелем мисле «әс-әр» минем,*
*Күңелем дузәк, аузымнан ут чәчрәр минем.*
*Дошман бозмый фикрем, уем җәмгыятен,*
*Аңар каршы керпекләрем гаскәр кеби минем.*
*Уңга, сулга аумыйм, һануз алга барам,*
*Юлда манигъ күрсәм, тибәм дә аударам;*
*Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә,*
*Мәгълүмдер ки, курку берлән өрку харам....*

Шигырьне Аяз тулысынча сөйләде. Даниягә аның «тибәм дә аударам»ы нык тәэсир иткән иде...

Аяз Мәскәү нәшриятларына рәхмәтле булды. Ана 1987 елның декабрендә Россия дәүләтенең әдәбият өлкәсендәге иң зур бүләген – М.Горький исемендәге премияне бирделәр. Ул тантанага Мәскәүгә мин дә барган идем. Аязны анда нык зурладылар, гаҗәп тә олпатлы мактау сүзләре аның адресына яңгырады. Шушы мактаулар аны ничектер «горурландырганнар» кебек. «Горурлану тәэсире» – авыр чир бит ул. Аны тирәнгә җибәрмичә үткәрә дә белергә кирәк. Архивындагы материалларга карыйм да, алда әйтеп үткән шикләнүләремнең дөреслегенә ышанып куям. 1989 елларга ул үзен аңлап, эшкә янәдән яшьләрчә керешкән. Аллага шөкер! Әле аннан сон да никадәрле күркәм әсәрләрен иҗат итә алды.

Аяз әдәбиятка чын рәссамнарча язылган әсәр килеп керсә, һушы китеп мактарга

ябыша торган иде. Кемнен кем булуына карамыйча, ул бары тик әсәрнен әсәр булуына гына таянып, мактау сүзләренен иң купшыларын табып халыкка житкерергә тырыша торган иде. Менә нинди киң күңелле иде ул әдәбиятка килүчеләргә карата! Әдәбияты булмаган милләт — милләт булмый, ул шуны нык аңлады. Милләт өчен жанып-көеп яшәгән шәхес буларак, әдәбиятыбызның офыгын киңәйтергә тырышып, булдыра алган кадәр көч сарыф итте. И-и татар әдәбиятын дөнья күләм аренага чыгарасы килде дә инде! Таралган татарның яшәү рәвешен күрсәтерлек әсәрләрне теркәп калдырырга тырышты. Шул юнәлештә Ибраһим Сәләховның Казакъстанда яшәп гомер итүче татарларга багышланган «Имәннәр тамыр жәйгәндә» дип аталган әсәрен камилләштерергә бик нык ярдәм итте. Якуб ага Зәнкиевнын «Иртеш таңнары» романы Себер татарларына кагылышлы тарихи әсәр итеп кабул ителерлек булуына кулыннан килгән тырышлыгын куйды. Болар һәммәсе дә төп нөсхәләрендә Аяз архивында саклана.

2012 елның октябрь аенда Рөстәм Мингалимнен 75 еллык юбилеен билгеләп үттеләр. Танылган шагыйрьнең чордашлары бер-берсен кабатламыйча, һәркемнен үз стилендә ижат итүе, дус-тату булулары, үзара ярдәмләшеп яшәүләре турында сөйләделәр. Менә ничек тә була икән бит татарлык! Аларның шундый бердәм булганнары өчен мин дә чын күңелемнән сөендем.

Дәүләтебез житәкчеләре еш кына: «Бергә булыйк, бердәм булыйк!» дип кабатлый. Аларның шундый чакыруларыннан соң, «Амин! Амин! Амин! Бәрәкалла! Бәрәкалла! Бәрәкалла!» дип, Ходайга табынам. Бу сүзләрне бертуктаусыз язучылар әйтергә тиеш, минемчә. Алар тәртип, әдәп, шәфкатьлелек чыганакларына таянып эш итүчеләр үрнәге булырга тиеш ич. Һәркем үзенчә ижат итсен, тик ул, чын, ихлас ижат булып, милләт рухын яктыртуга хезмәт итсен иде...

Сәясәт өлкәсендә горурланырлык лидерларыбыз булуы сөендерә. Әдипләребез арасында әйдәп барырлык лидерны таба алмавыбызга өзгәләнеп борчылам! Әллә бу очраклы гына күренешме? Мин генә аңламыйммы? Әллә бу очракка карата «Кар башына кар житә!» дигән шомлы фараз ятышлы буласымы?!

Аяз әдәби әсәр язарга алынган кешеләргә хәерле күтәрелеш теләп, киңәшләрен бирер бертуктаусыз хатлар юллаган. Кайберләренә сак кына: «Әсәрләрегездән аңлавымча, сез тормыш тәжрибәсе туплаган, өлкәнәйгән кеше күренәсез, бәлки бу өлкәдә янадан эшләмәвегез кулайрактыр», — дип тә куйгалаган. Яшьләргә килгәндә, күп укуны таләп иткән. Нәрсәләр укырга кирәген дә аңлаткан. Болар һәммәсе дә аның гомер юлында бертуктаусыз, шул ук вакытта акча алмыйча башкарылган эшләр булган. Аязга бит гаиләсен дә асрарга кирәк иде. Ул гаилә башы вазыйфасын да тиешле дәрәжәдә үти алды, рәхмәт аңа! «Кадерле картым, урының жәннәттә булсын, милләт тә сине онытмас әле, Алла боерса!» дип өметләнәм мин. Амин! Шулай булсын.

*Журнал укучыларга Аяз Гыйләжевнен 1993 елны язылган бер мәкаләсен тәкъдим итәм.*

**Нәкыя ГЫЙЛӘЖЕВА**

---

# «БЕЗ БИТ БӘХЕТСЕЗ ЗАМАН ҖИМЕШЕ»

Менә мин «Йәгез, бер дога!» дигән әсәремне тәгалләдем. Анда сүз кырык ел элек булган вакыйгалар турында бара. Әсәрдә телгә алынган һәр кеше — чын, һәр вакыйга үз башымнан үткән! Үткәнемә һәм тарихка хилафлык кылмыйча, үзем кабул иткән дөреслекне сурәтләргә омтылдым. Чөнки кеше зурмыкечкенәме, аның тарихка үз мөнәсәбәте, үз аршыны бар. Мина бу хатирәләрдән котылырга кирәк иде, чөнки хәтеремнең иң якты еллары (22 яшьтән 28гә

кадәр) Сталин зоналарында, төрмәләрдә үтте. Ул темага бик күп авторлар, үзләренең караш-фикерләреннән чыгып, бәя бирделәр, төрле жанрларда язып чыктылар. Мин инде язмам дигән идем. Ләкин уйлый-уйлый, яши-яши, укый-укый шундый нәтиҗәгә килдем: мин булган лагерьлар турында әле беркем дә язмаган. Чөнки андый типтагылар 1948 елда гына төзелде. Без соңгы дулкынга эләктек. Шушы лагерьларда үткән көннәремне, кеше булырга ярдәм иткән, күземне ачкан бик күп олпат ирләрне әгәр мин язып ачыкламасам, бу дөнья турындагы фикерләремне укучыга чыгармасам, әсәрләремнең төбенә төшү кыен булыр иде. Бу роман минем киләчәгемне түгел, ә үткәннәремне билгели. Сент-Экзюпери әйтә: «Мине язганнарымнан эзләгез». Гади, һәркем башына килә торган фикер. Ләкин менә тарихи шәхес әйткәч, ул ышанычлырак... Без бит үз фикерләребезне дә кемнәндер оялыбрак әйтәбез. Чөнки безнең беребезне дә татар халкының да, дөнья халкының да әле укытучы-остаз итеп, акыл иясе итеп таныганы юк. Безнең татар әдипләренең гомер юлларын әсәрләренә карап фикер йөртү кыен. Затлы кешеләребез хакында истәлекләр басылып чыга, ләкин алар искиткеч ярлы, фәкыйрь. Чорыбызның иң зур, фаҗигале язмышын кичергән Салих Сәйдәшев турындагы истәлекләрне генә карыйк. Ул китап әллә кайчаннан бирле кибет киштәләрендә тузан җыеп ята. Әгәр без шушы бөек шәхесне ача торган нәни генә дәлилләр белән беркетеп, кеше җанына, аңына үтеп керерлек искәрмәләр белән чыгарган булсак, бу китап тормыш дәреслеге булып хезмәт итәргә тиеш иде бит. Чөнки XX гасырда Сәйдәш кебек талантлы, аның кебек бай рухлы һәм татар җанын аркылыга-буйга, түбәннән югарыга аңлаган шәхес тагын бармы? Ул — безнең милли каһарманыбыз! Бу бөек сүзне без Тукайга карата гына әйткән идек. Халыкка маяк, күңел серләренә юлдаш булырлык, телне-моңны, бөтенлекне аңлаган ике милли каһарман бер гасырга җитә дип аңларга кирәк.

Тукай каршылыклы шәхес булмаган дип кем әйтә ала?! Әлегә без аны гел уңайга гына сыпырып тордык. Туры Тукай, дибез. Аның хаталары булмаганмени?! Үз замандашларына карата мөнәсәбәтләрдә «балаларча суллык авыруы» белән авырмаганмени? Тукай, миңа калса, үзенең каршылыклы булуы белән дә бөек. Аның ясаган хаталары, кылган гамәлләре — уңаймы алар, тискәреме — безнең өчен гыйбрәт, сабак. Ә Сәйдәш... Аны изеп таптаган, иҗатын буып торган кара ташлар аз булганмени?!

Радиодан чыгышларының берсендә Мөхәммәт Мәһдиев «революциядән соң татар әдәбиятында бер генә күренекле әсәр дә юк», дипраслап чыкты. Бу нилектән туа? Талантлы язучылар булган кебек, халыкның талантлы укучылары да булырга тиеш... Телисеңме-теләмисеңме, әдәбиятның югарылыгын, аның базар бәясен, әгәр шулай әйтергә яраса, укучы билгели. Дөрес, татар әдәбиятының туксан биш проценты бүген авылга хезмәт итә. Татарның зыялы, әзерлекле укучысы аз. Әдәби телнең нечкәлекләрен белеп язган Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Гариф Ахунов кебек язучыларның тел байлыгыннан күпме процент татар файдалана? Безнең әдәбиятның зур ялгышы — ул халыкка ярарга тырыша, аның алдында тез чүгә, үрмәли, вагая. Ә бит язучылар төрле зурлыкта булган кебек, укучының кабул итү дәрәҗәсе дә бердәй түгел. Миргазиян Юныс татар әдәбияты турында хөкем чыгарганда моннан мең ел элек башланган Европа әдәбиятлары белән чагыштырып карый. Ә бер уйлап карасаң, безнең проза бик яшь әле, аңа йөз ел гына тулып килә. Әдәбиятны караңгыга кысрыклап кертү җинел ул. Дөнья әдәбияты классиклары, без хаклы рәвештә ярата торган шәхесләр белән чагыштырганда, әдәбиятыбыз түбәндә түгел... Бары тик яшь булып кала. Бер генә әдип тә, бер генә әдәбият та үз халкының дәрәҗәсеннән югары сикерә алмый...

Әгәр якын елларда татар бетмәсә... Чын татарлар туу өчен тагын ике-өч буын үтү кирәк. Бүген безнең исламиятнең бөеклеген аңлатып бирер галимнәребез юк. Диннең өстә яткан кануннарын аңлатудан башка тирәнгә керә алган

шәхесләр күренми. Дин әһелләре чыгыш ясаганда үз сүзләренең кемгә, нинди катлау кешеләренә юнәлдерелгәнен ачыклап бетермиләр. Әлбәттә, динсез булмый. Дин — милләтнең, халыкның бөтенлеге сагында зур көч. Милләт өчен уртак дин алган халыклар гына дәүләтчелеккә ирешкәннәр. Динле, дәүләтле булу — тарихның бөтен юлларында бәхет саналган... Безнең милләтебезнең эчке ресурслары хәзер юкарган чак...

Без жиде миллионлы халык, дибез. Кайберәүләр аны егерме миллионга да житкерә. Бу бит — миф. Катнаш гаиләләр күбәя барган чорда нинди миллионнар булырга мөмкин! Алдырма син сан белән! Бер генә мисал: безнең Вил Мирзаянов дигән егетебез дөнья каршында үзенең көрәше, максатының ачыклыгы белән дан казанды. Бүгенге көнгә кадәр бу шәхеснең иманын, ул иманның ныклы нигезләрен ачып бирә алганыбыз бармы? Гомумән, без милләткә хезмәт итә торган шәхесләргә бәя биреп үтмибез, ныгытмыйбыз. Уртак каһарманнарыбызны күтәрә белмибез. Башкортларны гына алыйк, Салават Юлаев белән алар күпме еллар яшиләр. Шундый зур, якты шәхесләр милләтне жылытып торалар. Алар милли тамырларга һәрвакыт көч бирә торган дым... Югыйсә, бездә ул чорның Бәхтияр Канкаевлары, Батыршалары юкмы? Тарих алга барсын өчен шәхесләрдән калыккан баганаларга гына күпер салып була. Безнең уртак милли батырларыбыз бармы бүген?

Муса Жәлил? Ул ачылып беткән шәхес түгел... Мин Жәлил һәм аның иптәшләре хакында шик-шөбһә уятырга теләмим. Яшьләрне тәрбияләүдә үз вакытында аларның роле югары булды. Ләкин... Милли геройлармы алар? Татарның киләчәге өчен һәлак булдылармы? Уртак ватан өчен һәлак булулары белән тарихта калырлар, әлбәттә, әгәр килер заман яңа дәлилләр табып, аларның батырлыгын батырлык дип таныса...

Авылларның рәвеше үзгәрә. Мәчетләр салына. Ләкин бу изге эшкә күп жирдә ашыгып, алдан уйлап бетермичә тотыну сизелә. Мәчетләрнең чын архитектура үрнәге булып, гасырларга калачак, дип төзелергә тиешлеген онытмасак иде.

Тәкъдир язган һәр мизгелдә минем язмышым агышы: үтәлергә тырышып караган эшләрем үтәлгән, эшләнәсе эшләнгән. Һәрчак хак юлдан гына барганмындыр дип әйтмим. Без бит бәхетсез заман жимешләре. Шулай булдык, тегеләй булдык дип никадәр генә күкрәк какмыйк, гасырга хас хаталар бөтенебездә дә бар. Берәүләр бүген ашыгып-ашыгып үзгәрергә маташа, икенчеләр кабат ялган юлга баса... Без яшәгән ил шундый булды ул, ак киемнән корымлы казан янында йөреп, тапсыз калу мөмкин түгел иде.

Кичергән мизгелләргә бәя дә үзгәрә икән шул. Менә ни өчен үткәннәргә кайтып кабатланасы килми.

Хәзерге мәгълүматларга таянганда, Сталин чорында һәр өч кешенең икесе теге яки бу күләмдә жәзалау органнары белән бәйләнештә торган. Катлаулы, авыр чор! Мине төрмә сукмакларына этәргән кешеләрне моннан ике ел элек кенә беллем. Бар — исәннәре, бар — күздән югалганнары. Барчасы белән күрешеп сөйләшеп йөрим. Аерым шәхесләргә караганда, чорны ныграк гаеплим. Беләм, ул гаепләләр шушы елларда тәүбәгә килде. Тәүбәгә килеп, күңеленне сафландыру — үзе дә бер батырлык ич. Тәүбәгә килү (покаяние) һәртөрле дини өйрәтүләрдә күңел байлыгына ия булу түгелмени? «Казан утлары»ның 10 нчы санында басыла башлаган «Йөгез, бер дога!»дигән роман-хатирәмдә мин хәзерге заманның катгый сорауларына үткәндәге гыйбрәтләр белән җавап бирергә тырышам.

Кешеләргә гаеп ташлау, шик-шөбһә белдерү көнчелек галәмәте. Әгәр мин әдәбиятта кайсыбер уңышларга ирешә алмаган булсам, минем өскә кара хәбәрләр ябырылыр идеме икән? Юк, билгеле. Миңа таш атып, калкынырга тырышкан кемсәләрне ээрлекләргә дә, үч алырга да тырышырга жыенмыйм. Югарыда телгә алынган романым әнә шул кемсәләргә җавабым да булыр. Язмышым турындагы хөкемемне, йомгаклау сүзләрен мин замандашларыма шунда тапшырам.

«Балта кем кулында?» романын моннан ун-унбиш еллар элек язарга уйлаган идем. Әлбәттә, сюжеты гадирәк иде, тынычрак агышлы иде. Ләкин әсәр үзе өлгерде һәм мине дә өлгертте. «Балта кем кулында?» романы минем иң җитди әсәрләремнен берсе, дип уйлыйм. Монда минем чорга, халкыма мөнәсәбәтем чагыла. Балта кем кулында? Балта ленинизм, совет режимы кулында! Бу режим ике катлауны да имгәтте. Югары катлауны чамасыз-чиксез байлыгы белән, бернинди җаваплылык тотмый торган иркенлеге белән, бөтен бозыклыкка юл ачып, талауга, халыкны мыскыллауга йөз тотып имгәтте. Ярлы-ябагайны исә ач тотып, салымнар белән сытып, кешелек хокукларын тартып алып имгәтте. Совет режимы аста да, өстә дә гарипләрне генә тудырды. Мин соңгы әсәрләремнең бөтенесендә дә шушы режимның татар халкын ничек изүе, талавы хакында фикер йөртәм. Милләтнең һәлакәте алда әле... Без гел инкыйраздан куркабыз. Ә бит инкыйраз инде булып узды. Тагын нинди инкыйраз көтәргә мөмкин! Татар кызларының кырык проценты чит милләт егетләренә кияүгә чыга. Татар егетләренең кырык процenttан артыгы чит милләт кызларын алып үз йөзләрен югалта. Бер Нажар Нәҗми авылыннан гына да 26 татар кызы Үзбәкстанга кияүгә чыгып, соңгы берничә ел эчендә үзбәк халкын күпмегә баетты! Без алга карый белгән милләт түгел. Бер кыйсса: Ленинградның Товстоногов театры берничә ел элек Япониягә гастрольгә бара. Шуннан кайткач, күренекле актер Олег Басилашвили шундый бер хикмәтне сөйләде. Токиодан 75 чакрымда бер югары мәктәп бар икән. Анда Япониянең булачак галимнәре, эшмәкәрләре, министрлары, икътисад хуҗалары, кыскасы, сайлап алынган балалар укый икән. Шушы мәктәпнең ректоры Ленинград театрын расходланып чакырта, ике спектакль куйдырта. Шәкертләр бик матур каршы алалар. Басилашвили ректордан сорый: «Менә без сезгә ят булган рус тормышыннан «Ат тарихы» һәм «Ваня агай» спектакльләрен күрсәттек. Сезнең укучыларга моның ни файдасы бар?» Ректор: «Әгәр шушында укыган мең җиде йөз укучының, дистә еллар үткәч тә, бу спектакль исенә төшеп, күнелендә мәрхәмәт очкыны кабынса, димәк, безнең бүгенге эшебезнең нәтиҗәсе булган», – ди. Менә япон ничек алга карый! Авылда калып, дуңгыз, ат койрыгы борып кына алга китеп булмый. Шәһәр әлегә татар шәхесләрен бирми. Канында, җанында милли рух юк икән, андыйларны мин «ямаулы татарлар» дип атыйм. Ана карынынннан ук Сәйдәш моннарын, «Ак бүре» әкиятләрен тыңлап үсмәгән татар беркайчан да чын татар була алмый. Халкына мәхәббәт тәрбияләнмәгән кешедән ничек инде милли каһарман чыксын! Ләкин... Татарның коесы корыган, чишмәсе агышын туктаткан дип әйтергә җыенмыйм. Хәзерге көндә милләтне ныгытырга мөмкинлекләр бар.

**Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ,**
*сентябрь, 1993 ел*

# КОРЫМАС ГӨЛ



Яшәлгән гомеремдә язмыш төрле кешеләр белән очраштырды. Аяк чалырга маташучы көнчел, пычрак күнелләләр белән дә юллар кисешкәләде. Шөкер, андыйлар сирәгрәк, мина күбрәк сокланырлык яхшылары очрады. Шундыйлары арасында Сафиуллина Флера Садрый кызы ин якыны, иң ярдәмчеле, ин игелеклесе иде. Аны югалту бик авыр булды. Соңгы юлга озатырга килгәндә күнелемдә туган шигъри юлларны да хушлашу мәрасимендә укый алмадым, күзләремнән бертуктаусыз яшь акты. Остазым рухына багышлап, бер елдан соң сезгә укып үтәм:

*Соңгы юлга озатабыз,*
*Бер- беребезне юатабыз.*
*Соңгы юллар соңгы юлмы?*
*Әллә соң ул юл башымы?!*
*Мәңгелеккә күчүләрнең*
*Дәвамымы, иң башымы?*
*Җанның, җиргә тәнне ташлап,*

*Киң Галәмгә барышымы?*
*Фани дөнья баешымы?*
*Бакыйлыкка агышымы?*
*Безгә җавап бирүче юк,*
*Аннан монда йөрүче юк.*
*Аллаһыга тапшырабыз,*
*Бары аңа ышанабыз.*

Милләт өчен, телебезнең үсеше хакына тау- тау хезмәтләр язган кешегә Аллаһы Тәгалә әҗер-савапларын бирер дип, дога кылам, чөнки Флера Садрый кызы бик күп саваплы эшләр башкарды, аларны гыйбадәт итеп кабул итәргә мөмкиндер. Намаз уку, ураза тоту кебек мөселманнар өчен фарыз гыйбадәтләрне үтәмәсә дә, анын кешеләргә, милләтебезгә кылган яхшылыкларының исәбе-саны юк. Ул дин тотучыларга да ихтирамлы, игътибарлы булды. Остазымнан күп нәрсәгә өйрәндем, аның күркәм сыйфатларын үземдә дә булдырырга тырыштым.

Ул күркәм сыйфатларнын иң беренчесе — кешелеклелек, кемнен кем булуына карамастан ихтирам итү. Кафедрага килеп кергән бер генә кешене дә, эше бихисап күп булса да, тынламыйча, ярдәм күрсәтмичә чыгарып җибәрмәде. Ә ул елларда ярдәм сорап килүчеләр байтак иде. Шулай ук килеп кергән кешеләргә кунакчыл рәвештә чәй тәкъдим итәлде. Менә шул елларда остазымның студентлар, аспирантлар белән мөгамәләсен сокланып күзәттем. Искиткеч җылы мөнәсәбәт, һәр сүзендә ярату, ихтирам сизелде. Вакытында зачет, имтихан тапшырмаган студентны да тиргәп чыгармый, аналарча шелтәләп, үгет- нәсыйхәтен бирә иде.

Шәхсән үземә дә искиткеч ихтирамлы, игътибарлы булды. Аны диссертациям генә түгел, бөтен тормышым, уй-фикерләрем дә кызыксындырды. Телефон аша сөйләшәсе булганда, тавышымны ярты сүздән танып, »Рәзинә хәлләрең ничек?» дип, үз баласыдай якын итеп сөйләшә иде. Казаннан киткәндә еш кына »кайтырга акчаң бармы, акча биримме?» дип тә әйткәч, күзләремә яшьләр тыгыла иде, чөнки мин тугыз балалы гаиләдә үсеп, кечкенәдән үземне-үзем кайгыртып яшәргә күнеккән, студент вакытта да «китәргә акчаң бармы?» дип сораучы булмады.

Флера Садрый кызы мине байтак Казан галимнәре, язучылары белән дә таныштырды. Бөтенесенә мактап, дәрәҗәмне арттырырга тырышты. Ул мине шагыйрә буларак та бик хөрмәтләде. Остазым кебек үзенең аспиранткасын өенә чакырып, иң кадерле кешесен сыйлаган кебек кунак итә торган башка фәнни җитәкче бармы икән?! Юктыр, чөнки бу күренеш киресенчә булырга тиеш. Мәктәптә укый торган ике балама Флера Садрый кызы «дәү әни»гә дә әйләнде, минем сумкага «дәү әни»ләреннән дип, күчтәнәч салып җибәрә иде.

Иң яхшы сыйфатларыннан икенчесе — сабырлык. Дөнья булгач, төрле вакытлар, төрле вакыйгалар була, төрле холыклы кешеләр белән аралашырга туры килде остазыма. Ни генә булса да, йөрәге янып, кайнап торса да, ул олпат ир-атлар кебек тыныч кала белә, кайчагында киеренкелекне уен-көлке сүз белән дә йомшарта ала иде. Бу аның оста психолог булуыннан килгәндер.

Өченче яхшы сыйфаты – намуслылык. Үзгәртеп кору һәм аннан соңгы елларда укытучыларга матди яктан яшәү авыр булды. Авырлыкларга карамастан, нинди генә ымсындыргыч тәкъдимнәр ясалса да, Флера Садрый кызы намусына хилафлык китермәде. Аның фатирында торгынлык елларында ире исән чагында алынган өй җиһазлары. Бар байлыгы – күнел байлыгы һәм исәпсез-хисапсыз китаплары иде.

Дүртенче күркәм сыйфаты (бәлки, аны иң беренче дип тә атарга мөмкиндер) – эш яратуы, тырышлыгы. Ул беркайчан да үзенә ташлама ясамады, ял да итмичә эшләде дә эшләде. Бер мисал китерәм. Үзем кафедра мөдире булып эшләгән елларда Чаллы дәүләт педагогика институты студентларына остазымны күрсәтәсе, анын лекцияләрен тынлатасым килеп, бик ялынып, бер генә уку елына китертә алдык. Берничә диплом эшенә җитәкче дә булганлыктан, шул хезмәтләрне йокламыйча төн буе тикшереп утыра иде.

Бишенче сыйфаты – ярдәмчеллеге. 1992 елны күбесенчә яшьләрдән торган өр-яна «Телләргә өйрәтү» кафедрасы оештырылганда, кафедра мөдире Флера Садрый кызыннан башка бер генә укытучының да гыйльми дәрәҗәсе юк иде. Җитәкчеләрнең ярдәме белән барлык кафедра әгъзасы да кандидатлык диссертациясен, ә беренче аспиранты Әлфия Шәүкәт кызы Йосыпова докторлык диссертациясен яклады. Кафедрада шулхәтле җылылык һәм шул ук вакытта эш атмосферасы хакимлек итә иде. Ул чорда бергәләп күпме программа, дәреслек, уку кулланмалары әзерләп бастырдылар! Аспирантура елларын (1994-1998) мин бик сагынып искә алам. Кафедрада берсеннән-берсе матур гөлләр үсә иде. Шуларның берсен – чәчәк кебек кызыл яфраклысын мин әле дә кафедра, Флера Садрый кызы, Мөхәммәт Мәһдиев истәлеге итеп үстерәм, ул гөлнең исемен дә белмим, «корымас гөл» дип атадым. Гөлнең тарихы шундыйрак: бакыйлыкка күчәр алдыннан Мөхәммәт абыйның өенә Флера Садрый кызы һәм кафедра укытучылары хәл белергә баргач, Мәһдиев истәлеккә шушы гөлне биргән була. Бу гөлгә әле тарихын белгәнче үк игътибар иткән идем, җайлап кына бер кечкенә үсентесен алдым. Чаллыга кайтып җиткәнче гөлем бөтенләй шиңде, шулай да суга салып куйдым. Берничә сәгать эчендә ул калкынды, матурланды, ә берничә көннән тамыр да җибәрде. Аннан кечкенә гөлемне туфракка утырттым. Ул бик тиз үсә, суны нык яратканлыктан, су җитмәсә, шиңә башлый, су сибү белән кабат терелә. Озак вакыт өйдә тормаганлыктан, ничәмә-ничә гөл корыды, ә бу сулса да, ныклап корымый, янадан тернәкләнә, шуңа күрә мин аны «корымас гөл» дип атадым.

Флера Садрый кызы хезмәтләрен дә шушы корымас гөл белән чагыштырам. Милләтебез яшәгәндә, кешеләр татар телендә сөйләшкәндә, ул халкыбыз күнелендә шинмәс гөлдәй яшәр!

*Кеше китә – җыры кала диләр,*
*Калды җыры, калды күңелдә.*
*Искә төшкән саен, сагыш булып,*
*Җаннан моңы, җыры түгелә.*
*Аның җырын беркем кабатламас,*
*Ул үзенчә Җирдә җырлады!*

*Туган телне күпме хезмәтендә*
*Күккә чөйде, сөйде, зурлады.*
*Телебезнең күркәмлеген кат- кат*
*Исбатлады һәрбер юлында.*
*Мәгъруp таудай язган китаплары*
*Балкый хәзер кояш нурында.*

**Рәзинә МӨХИЯРОВА**

# КОЯШКА ҮРЕЛГӘН ЕГЕТ

Бер елдан артык инде Фәниссез яшибез. Үзенең көчле булуына ул безне шулкадәр дә инандырды ки, дөньяда юклыгына һаман ышанып җитеп булмый әле.

Армиядә турниктан егылгач, егерме яшендә урын өстенә кала ул. Егылуы – булдыксызлык галәмәте түгел. Чамасыз тәвәккәллек, кыюлык нәтиҗәсе. Турникта «кояш» ясамакчы була ул. Ягъни бик нык атынып, кул, аяк, гәүдә бөгелмәгән килеш турник тимере аша әйләнеп, аягың белән һавада зур түгәрәк сызып чыгу бу. Армиядә өч ел хезмәт итеп тә, «кояш» ясаган кешене безнең частьта күргәнем булмады минем. Кыюлыктан һәм башың әйләнмәүдән тыш кулның бик тә көчле булуы да кирәк әле монда. Атналар буе ныгып-әзерләнеп, анда да аска йомшак маталар түшәп, каеш белән ике кулны турникка бәйләтеп дивизиядә дә бик сирәкләр генә эшли алган моны.

Күп булса өч ел яшәрсең, диләр врачлар Фәнискә. Ул исә тагын 54 ел яшәп дөнья куйды. Шыр сөяккә калган, хәрәкәт күрмәгән сызланулы гарип тән моны ничек булдыра алган соң? Медицина үзе генә моны аңлата алмыйдыр шикелле. Җавапны тәннән түгел, рухтан, күңелдән эзләргә кирәктер. Шөкер, бу хакта мин Фәниснең үз фикерен дә ишетеп өлгердем.

*- Синең турыда, Фәнис, «Язмышны җиңгән кеше» дип әйтүләргә ничек карыйсың? Язмышны җиңеп буламы?*

- Язмыш турында күп уйланам мин. Шундый фикергә килдем: безнең язмышлар Алла тарафыннан тулаем ук язып куелмагандыр ул. Кеше үз язмышына азмы-күпме йогынты ясый аладыр. Алла безгә, әйтик, нинди дер холык-фигыль, сәләт бирергә мөмкин. Менә шул холык безне язмышыбызга этәрәдер. Мин менә бөтен җирдә гел беренче булырга ашкынып торган бер кеше булганга, армиядә чакта турникта башка берәү дә эшли алмаганны эшләмәкче идем, бу мине фаҗигагә китерде. Ләкин ул ашкыну беркая да китмәде, миндә үк калды. Шуна күрә эзләнәсең, бәргәләнәсең, һәм эчеңдә булган мөмкинчелекләрне ача башлыйсың... Шулай итеп минем холкым миңа азмы-күпме бирелгән сәләт - шагыйрьлек булып бәреп чыккан, салына башлаган юлдан - шигырьләрне армиягә киткәнче дә язгалый идем бит.

*- Ягъни холкың сине еккан да, егылгач, тартып та торгызган.*

- Әйе, нәкъ шулай.

Әңгәмәбез ун ел элек 12нче хастаханәдә барды.

Ә теге беркем дә эшләмәгәнне эшләргә омтылуда котылпларны ачкан сәяхәтчеләрне җилкеткән романтик ашкыну да булган, әлбәттә.

*Ә ул биектән егылган —*

*Кояшка үрелгәндә.* — Бу хакта әнә шулай дип язган идем мин.

*- Телевизордан бертуктаусыз корыч бәдәнле әзмәверләрне, Сталлоне-фәләннәрне күрсәтеп торалар. Бусы да чынбарлыкка бик туры килми әле аның, ә рухи көч дигәне хәзер аеруча дефицит бит. Рухи дистрофиклар заманы бу... Әнә монда да, үз-үзенә пычак салган берәү, инде врачлар бугазын ямаганнан соң, тәрәзәдән сикергән... Тән эчендә янган хикмәтле утның көче, рух нықлыгы ни ул, Фәнис?*

- Мин аны шулайрак аңлый башладым. Әгәр дә күңелеңдә нәрсәгә дә булса омтылыш юк икән, син, нинди генә таза кеше булсаң да, барыбер әкренләп-әкренләп, юеш җирдә яткан агач кебек, череп бетәсең.

*- Ихтыяр мускулларын ныгытып буламы ул?*

- Ныгытып була, ныгытырга кирәк. Үзең беләсең бит инде, язарга шул

хәтле дә утырасы килмәгән көннәр була. «Их, берәрсе килеп чыксын да, булсен иде бу эштән», - дип уйлыйсын кайчагында. Ләкин барыбер тотынасын. Чөнки сүзеннен кемгә дә булса кирәклеген беләсен. Язучы көн саен үз-үзен раслап яшәргә тиеш. Менә бүген язма, иртәгә язма, берсекөнгә язма - син инде язучы буларак онтылачаксын.

*- Язучы буларак үзеңне җуячаксың да.*

- Әйе. Шуннан әле кеше буларак үзенне җую да башланырга мөмкин. Һәм менә үз-үзенне раслар өчен ихтыяр көче табарга кирәк. Һәр көнне утырырга. Яхшы язылмы, начармы - аны бит кайта-кайта эшләп тә була. Кайчак бөтен язганынны ертып та ташлыйсын. Аннан сон бөтән формада туа ул. Барыбер синен эш процессын бара. Агачны шомарткан кебек шомарту бара эчтә.



*Очучылар мәктәбе курсанты Ф.Яруллин. 1958 елның июне. Фаҗигале егылуга (17 июль) санаулы көннәр генә калган инде.*

*- Без күбрәк тәнгә дикъкать итеп өйрәнгән. Син тән эчендәге көчне, аның резервлары булганны тоеп торасың инде, әйеме?*

- Әйе. Кайчагында менә бер әйбер язмаслык хәлдә буласын. Ләкин кулга каләм алганнан сон ниндидер бер илһам килеп, менә шушы эчке бер рух үзе дә көч бирә кешегә. Физик көч тә бирә. Арыйсын, әлбәттә, сыгылып каласын. Прозада бигрәк нык алҗыта. Шигырь әле ул азмы-күпме күнелгә ниндидер җинеллек тә бирә, унышлырак сүз әйтә алсан, очынып йөрисен.

*- Ә прозада шахтага төшкән кебек, әйеме?*

- Әйе! Прозада көн саен утыру өчен чыннан да рухны чыныктырырга кирәк. Рух ул - алмаз кебек, ныграк кайраган-игәүләгән саен шәбрәк ялтырый. Тик кенә ятып торсан, әллә алмаз ул, әллә күмер - белмәскә дә мөмкинсен.

*- Фәнис, 1964 елны чыккан, «Мин тормышка гашыйк» дигән беренче шигырь җыентыгыңны, аннары үз язмышыңны чагылдырган «Җилкәннәр җилдә сынала»ны сөенеп күтәреп алган беренче укучыларың да 30-40 яшькә картайды бит инде.*

- Рәхмәт аларга! Шул хуплаулары, яратулары белән алар мина ышаныч, ныклык өстәп тордылар. Элекке укучылар кебек актив укучылар юк инде ул хәзер. Сынар шигырен чыкса да, хат язалар иде. Шул бер шигыренә әллә кайлардан -- Мәскәүләр, Украиналардан да килә торган иде хатлар. Хәзер дә укымыйлардыр дип әйтмим, ләкин язу нык кимеде. Хат дигән нәрсә үзе дә искереп барамы инде әллә... Менә без язучылар да элек гел хат белән аралаша торган идек. Чөнки телефоннарыбыз юк иде. «Декабристлар»да яшәгән Туфан Миннуллинга мин «Волгоград» урамыннан хат язып җибәрә торган идем. Ул заманда хаты да иртән салсан кичкә барып житәдер иде бит анын Казанда.

*- Язучыга, җигелеп эшләр өчен, мөмкинлекләреңне ачар өчен ышаныч бик кирәк. Үз көчеңә, талантыңа ышану. Менә шул ышаныч дигән нәрсә арту-кимүләр синдә ни рәвешле барды?*

- Баштарак житеп бетми иде ул. Бер әсәр яза идем дә, шул басылып чыкмыйча торып бүтән әйбергә тотына алмый идем. Хәзер инде бер әсәрне язып та бетермәгән килеш икенчесенә омтыла башлыйм. Язганың хуплап каршы алынмаганда да аны начарга чыгарырга ашыкмыйм. Кайчакны бүтәннәр, ана башка караш белән күз салганнан сон, гел бүтәнчә бәялиләр... «Җилкәннәр җилдә сынала» 1972 елны «Казан утлары»нда басылды, 1973 елны китап булып чыкты. Ул зур танылу китерде мина. Ышаныч та арта төште инде. 1974 елда Камал театры «Әнә килә автомобиль»не куйды. Ул гел зал шыгрым тулы килеш һәм бик озак — дүрт ел буе барды. Аннары Кучмә театр да куйды, анда да гел аншлаг белән барды ул. Бусы икенче бер жанрда күтәрелеп алу булды.

*«Менә шушы спектальнең уңышы күпләрнең күңеленә тиде. Элек исәнләшеп йөргәннәр күрмәмешкә салышып уза башладылар. Шунда мин язучылар арасында бер-берсенең уңышыннан көнләшү барлыгын аңладым.* (Көндәлектән. 2009. 4 ноябрь.)

Ышаныч янә арттыы инде. Үзгәртеп корулар башлангач, СССР таркалгач, иҗатым аеруча нык ачылып китте. Шул 90нчы елларда 5-6 поэмамны яздым, үзем әйбәт кенә поэмалар дип саныйм инде, ун повестемнын алтысын яздым.

«Тегене яздым, моны яздым...» Күпләр моны шулай гади итеп кенә аңлыйлар да. Сөякләр, буыннар сызлауны әйтмим дә инде, баш авырткан хәлдә дә әдипләрнен ничәсе генә повестьлар, поэмалар иҗат итә алыр иде икән? «Техник» ягы да бар бит әле. Башта Фәнис таякчыклар ярдәмендә машинкада баса башлый. Әмма бик авыр, алҗыта торган эш була бу. Гел чалкан яткач, аркасы да тишелә башлый. Мендәр өстенә папка куеп, әле бер янда, әле икенчесендә шул хәрәкәтсез бармаклар белән язарга өйрәнергә туры килә инде. Ручка да кулдан төшеп киткәли. Шундый хәлдә теге «илһам» дигән иркә, чәүчәләк «кош»ны да янында тотарга кирәк бит әле. Соңгы ике елда дип беләм, нәкъ менә шул каләм тота алмау, күнелендәге кәгазьгә төшерә алмау сәбәпле, иҗаты шигырь белән генә чикләнде. Әҗәлен әнә шул, үткәндәге «кин диапазонлы» Фәнистән ераклаша бару да якынайтмады микән аның? Көндәлегеннән янә бер өзек китерим әле (мәкаләмдә өзекләрнен матбугатта чыкмаганнарын гына бирермен).

*«Йоклап булмый. Иртәнге сәгать өчтә уянам да, һич йоклап булмый башлый. Аннары 5нче яртыларда Нурсөяне уятып, иртәнге чәйне эчәбез. Шунсыз рәт керми. Һәркөн иртән торганда шундый арып, эт булып уянам. Берни эшләп булмас сыман. Миндә женнәр көче бардыр, ахры. Чирлим дип иркәләнеп ятасы инде. Юк, төнлә үләм-үләм дип ятам да, Нурсөя юындырып, яраларны бәйләгәч, бер чынаяк кофе эчәм дә, эчтәге женнәр уяна башлый. Каләмгә тотынам һәм, ни хикмәт: каләмнен дәвалау көче бар. Язу дигән галәмәт тамырлардагы каннын агышын тизләтә, борын тишекләрен киереп үпкәләргә һава тула. Төнге йокысызлыктан аңгырайган баш миенең бормалары аша акыллы уйлар йөгерә башлый. Бер ярты көн шулай эшләгәч, бора-бора сыккан кер кебек бушанып каласын.»* (2000 ел, 13 июль.)

Әлбәттә, Фәниснең хәтта жиңеллек дигәне дә үзенең гадәти хәле, авыр халәте белән чагыштыргандагы жиңеллек инде ул.

*«Быел күп эшләргә туры килде. Арыдым. Ни язасы, ни укыйсы килми. Башка вакытта проза язып арыгач шигырьләр агыла башлый һәм шулар күнелне күтәреп, арыганлыкны бетерә иде. Бу юлы бер шигырь юлы да башка килми. Димәк, тән генә түгел, жан да арыган.» (2003, 10 октябрь.) «Ә көч кимегәннән кими. Түбән төшә башлаганымны сизәм, шигырьләргә ялкын житми, проза язарлык көч юк.»* ((2004, 23 июнь).

Ә менә башкарган эш күләмен, юллар, табаклар санын исәпкә алсаң, тап-таза ир-ат язучылар өчен дә баһадирлар йөге бит бу! Һәм ул, күп кенә китаплар кебек, кибетләрдә тузан жыеп ятмады, Фәнис язганны халык тансыклап көтеп ала иде.

Элекке электромонтерның, гарипләнгән солдатның әдәбиятка шулай тиз кереп китүе, иҗат колачының кинәйгәннән киңәя баруы шаккатыра. Шигырь белән прозага драматургия, әдәби тәнкыйть һәм публицистика да ялганды.

1964 елны «Мин тормышка гашыйк» дигән — шигырь, 1966 елны «Май төне» дигән хикәя жыентыклары (48 һәм 65 битле китапчыклар) дөнья күрсә, иң зур популярлыкны аңа 1972 елны «Казан утлары»нда — 87 мен, 1973,1986 елларда китап булып 15 һәм 12 мең тираж белән басылган, «Жилкәннәр жилдә сынала» дигән бәяны (повесть) китерде. (Бер хезмәттәшебез мәктәп баласы чакта бу китапны төнлә юрган астында фонарь яндырып елый-елый укыган.) 1978 елны исә ул, русчага тәржемә ителеп, 100 меңле тираж белән чыкты. Фәниснең «Әнә килә автомобиль» дигән пьесасы исә 1974 елны Марсель Сәлимжанов тарафыннан куелды. Камал театры тарихына бер елда иң күп уйналган спектакль булып кереп калды. Дүрт ел рәттән жәмгысе өч йөз тапкырдан артык уйналган ул! Шуннан соң Кучмә театрда да аншлаг белән озак кына барды. Төрле театрларда һәм телевидениедә тагын унөч пьесасы куелды аның. Шуңа өстәп жырлары күпме әле!

Әйе, халык шундук үз итте, яратты Фәнисне. Ул — чын халык язучысы. Аның хәтта Нурсөяләре дә бераү генә түгел, өчәү бит!.. «Мин аның көчле ихтыярына сокланам, хатынының шәфкатьлелегенә баш иям... Рәсемнәре («Сөембикә» журналыннан кисеп алынган) каршымда тора. Аларга багышлап бала табар өчен генә кияүгә чыктым. Нурсөя туды инде. Фәнисне бүген-иртәгә көтәбез. Ирем, ничектер, малай туса, Фәнис кушам дигәч, икенче исемнәр әйтеп маташа. «Фәнис кушмагач, мин аны тапмыйм да», — дим...» Күп еллар элек Башкортстанның Бишбүләк районында яшәгән Әлфия Булатның Уфада чыга торган «Өмет» газетасы журналисты Равил Хәкимовка язган хатыннан бу. Балтач районыннан Салисә ханым да Нурсөя таба әнә.

Тиешле максатчан ярдәм булса, Союз күләмендә һәм күпмедер дәрәҗәдә дөнья күләмендә дә исемен таныта алыр иде әле ул. Инде 1964 елны, ягъни яза башлавының дүртенче елында ук, ул яшь шагыйрьләрнең Бөтенсоюз конкурсында икенче урынны ала. Англиядә чыга торган атналык газетада аның автобиографиясе, фоторәсеме һәм берничә шигыре басыла. Монда Фәнис бүтән җәһәттән әйткән сүз бик урынлы: «Бер-беребезне күтәрүдән куркабыз. Шуңа безнең әдәбият үз куеныннан чыга алмый.»



*Фәнис белән Нурсөя (1974). Бергә яшәү башлауларына ун ел үткән...*

Хәзер янә теге әңгәмәбезгә әйләнеп кайтыйк әле.

*- Фәнис, мин синең журналистлык сәләтеңә таң калдым. «Туган авылым Кызылъяр» дигән проблемалы мәкалә кебек мәкаләне татар журналистларыннан кем генә яза алыр иде икән? XX гасыр азагында, нефть төбәгендә яшәп яткан татар авылының аянычлы хәле бөтен катлаулыгында гаҗәеп бер осталык белән тасвирланган анда.*

- Мин аны «Казан утлары»на җибәргән идем, ул чактагы баш редактор басмады бит. Очерклар бүлегендә Кояш Тимбикова иде, ул ошатты да, кертеп бирде. Теге ятькырды-яткырды да, шалтыраттым инде, басасызмы, дип. Юк, басмыйбыз, ди. Нигә басмыйсыз, дигән идем, бу әйбер нефтьчеләрне түбәнәйткән, ди. Безгә икмәк кирәкми, икмәкне без теләсә кайсы илдән сатып ала алабыз, иң беренче чиратта безгә нефть кирәк, газ кирәк, ди. Шуннан соң мин аны «Аргамак» журналында бастырдым. Шунысы кызык, нефтьчеләр үзләре бик әйбәт карады бу мәкаләгә. «Татнефть»нең генераль директоры Ринат Галиев, нефтьчеләр турында бердәнбер дөрес язган кеше син, Фәнис, диде. Нефтьне күбрәк чыгарыр өчен чыннан да экологиягә зыян салдык шул, диде...

Биш бүлектән торган бу мәкаләнең бер урыны аеруча гыйбрәтле тоелды миңа. «Авыл яныннан гына газ торбалары узып та чиләнеп утын ягу, утын әзерләү халыкны бик рәнҗетә иде, әлбәттә. Хәтеремдә, ул вакыттагы авыл советы рәисе Закуан Шәйхетдинов газ кертү өчен нык тырышып карады. Хәтта Министрлар Советы рәисе Гомәр Усмановка кадәр барып житте. Ләкин Усманов: «Сезнең газны бөтен Европа яга, сез шуның белән горурланыгыз. Тагын кайсы район үз продукциясен шулай дистәләрчә илгә чыгара ала?» — дип, жиребездән чыккан газның исен иснәп, шуның белән горурланырга кушып җибәргән... Дөрес, бик каты йөри торгач, дуңгызчылык комплексы дип аталган афәткә газ кертүгә ирешә ул.» Бу хәлләр миңа Разил Вәлиев сөйләгәнне искә төшерде: «Милли китапханә директоры чагында, авылга кайткач, бер класссташ очрады. «Нихәл, Разил, китапханә төзеденме әле?» — дип сорады. «Юк, төзеп булмады шул әлегә», — минәйтәм. «Син аны төзи дә

алмаячаксың, — ди сабакташ. «Нигә алай дип әйтәсең, менә бит монда сыерларга шәп кенә абзар төзеп куйгансыз». Җавапны һич онытасым юк. «Сыерларга була ул, сыерлар алар сөт бирә, ит бирә... Ә менә сыерлар китап укый белсә, аларга китапханә төзерләр иде.»

Фәнис башкаларга, бигрәк тә түрә-фәләннәргә җайлаша-яраклаша, матур булып күренергә тырыша торган тәти зат түгел иде. Хәтта аермачык нәрсәләргә дә үз фикер лупасы аша баккалаган ул. Мине аның менә бу сүзләре шаккатырды: «Китапларның кешеләр укымаганын укырга ярата идем. Ни өчен бу китапларны укымыйлар?»

*«Татарстан хәзер үз байлыгына үзе хуҗа түгел. Шәймиев тешсезләнде. Парламентта оппозиция юк. Татар конгрессы кунаклар җыеп, шуларны ашатып-эчертеп йөрүдән башка эш эшләми... Милләтнең сулышы кысылганнан-кысыла бара. Халыкка аракы белән пиво җитәрлек булса, башкасын таләп итми.»* (2004, 8 июль.)

Әдәби ел йомгакларында Фәнис Яруллинның бер докладчы тарафыннан бракка чыгарылган «Кыйгак-кыйгак каз кычкыра» дигән бәянына, тыелып кала алмыйча, беренче һәм бердәнбер рецензиямне («Кыйгак-кыйгак... җан кычкыра») язган идем мин. Әсәрдә монарчы бер генә язучы да күрмәгән нәрсә — мактаулы социализмда хатын-кызның хатын-кызлык сыйфатларын, эчке матурлыгын, нәфислеген җуя баруы тасвирланган. Фәнис үзе исә — дисталәгән рецензия авторы. Һәр сүзне интегеп язган, колагында врачларның «күп булса өч ел яшәрсең» дигән сүзе яңгырап торган кеше күпме кадерле вакытын әнә шулай башкаларны үстерешү-күтәрешүгә сарыф иткән! Ничәмә-ничә үзе өметле санаган авторга әсәрләрен (повесть-романнарга кадәр!) төзәтешкән һәм хәтта язышкан да бит әле ул!

Фәниснең татар теленең үзенчәлекләрен күп кенә тел белгечләрен дә уздырып ачкан («Моңлы тел»), җыр сәнгатен нечкәләп тоеп язган («Җырны урлап буламы?») мәкаләләре, «Җан» дигән фәлсәфи уйлanулары, шәхес турында, зыялылык турындагы көндәлеккә теркәлгән фикерләре аның гакыл һәм күңел офыкларының шактый киң булуын күрсәтә.

*«Әгәр дә нинди дер әсәрләремне укуга яки исемне атауга минем үземне күз алдына китермиләр икән, димәк, мин шәхес буларак өлгермәгәнмен. Яисә Фәнис Яруллин дигәч минем әсәрләрне, андагы геройларны күз алдына китерә алмасалар да шулай дияргә кала. Ә исем астындагы Халык шагыйре, Тукай премиясе лауреаты дигән әйберләр алар — безнең күңел өчен генә. Халыкка алар берни бирми. Фәнис Яруллин икәнсең, димәк, син яхшы язарга тиешсең. Бары шул таләп.»* (2001, 12 декабрь.)

*- Синең янга, Фәнис, ярдәм эзләп килүчеләр дә күп бит әле. Мораль ярдәм!*

- Әйе, нинди дер экстрасенс кебек хис итә башладым инде үземне. Менә синең янга килгәч нәрсә эшләргә кирәген аңладым, рәхмәт, дип соныннан хат язучылар күп. Кешегә әлләни кирәкми бит, аны тыңлый белергә генә кирәк. Тыңлаучы юк хәзер. Ә мин бүлдермичә ярты сәгать тә, бер сәгать тә тыңлый беләм. Сөйли торгач, үз сорауларына үзе үк җавап табып, тынычланып кайтып китә кеше.

*- Миңа «Ул яшьләр тормышын белми» дип әйтүчеләр белән бәхәскә керергә туры килгәне бар. Синең янга яшьләр дә күп килә бит.*

- Исәпләп утырдым әле, елына мең ярымлап кеше килә икән, кара исәп белән инде бу, шуларның 70-80 проценты чамасы яшьләр - студентлар, укучылар. Сезнең «Идел»дә басылган повестьларның берсе дә уйлап чыгарылган әйбер түгел, шулар сөйләгән хәлләр. Мәхәббәттә уралып-буталып бетәләр дә, шуннан чыгарга юл эзлиләр.

*- Синең янга килеп! Ачылалармы, яшермичә сөйлиләрме?*

- Тулысынча ачылалар! Кызлар ничә егет белән йоклаганнарына кадәр әйтәләр.

*Нурсөя:* Нишләп бабайга килеп сөйлиләр икән болар оялмыйча дип аптырыйм инде.

- Бер бик шәп сюжет бар әле менә. Бер кыз килеп сөйләп йөри.

- *Дәвамлы сөйләүмени?*
- Бер ел бара бугай инде бу.
- *Килеп сөйләү генә түгел, синең алда вакыйга бара, алайса. Сериал!*
- Вакыйга бара! Нәрсә белән бетәр, белгән юк әле. Бик җилле бер мәхәббәт өчпочмагы хасил булды анда.
- *Синдә, Фәнис, чыннан да ниндидер бер көч, хикмәт бар инде, алайса. Тикмәгә йөрмәсләр иде.*

*Нурсөя:* Ана бит кияүгә кайсысына чыгыйм икән дип тә килаләр. Егетләрен алып киләләр анын янына. «Фәнис абый, кара әле, ниндирәк кеше икән», диләр.
- Кайсыберләре карточкасын алып килә.

*Нурсөя:* Берсенә карточкасы буенча әйтте, алкаш була бу настоящий, дип.
- Әйе, эчә торган кеше булырга охшаган, дигән идем. Шулай булып чыкты тәки.



Казан Педагогия институтының 109нчы группасы студентлары белән. 1978 ел.

Фәнис Яруллин кешеләрдәге яхшылык, битарафлык, көнчелек кебек сыйфатларны ачып салган лакмус кәгазе сыман да булды ул. Яшь инвалидтан без белгән Фәнис Яруллинны ясашучыларның беренчесе «Яшь ленинчы»га килгән, әле бик әйбәт тә булмаган шигырьләре аша авторның хәлен тоеп ерак Баулы районының Кызылъяр авылына юл чыккан, Фәнис турында «Татарстан яшьләре» һәм «Яшь ленинчы» газеталарында язган Марс Шабаев, әлбәттә. Күпмедер вакыттан бирегә Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Рәшит Гәрәй һәм Абдулла Гумеровлар да килә. «Совет әдәбияты»нын (1965 елдан «Казан утлары») баш мөхәррире Абдулла агайны Фәнис аерып әйтә. «Авылга килеп киткәннән соң Абдулла Гумеров мине күзеннән ычкындырмады», — ди. Фәнис Казанда хастаханәгә яткач, Сибгат абый белән хәл белергә килеп, аның шигырь дәфтәрен актарып, әйбәт дип тапканнарын журнал өчен үз куллары белән күчереп алып китәләр! (Хәзер бераү дә диярлек хәтерләмәгән Абдулла агайның миңа да игелеге тиде.) Үзе шәп кенә тәнкыйтьләгән «Татнефть»нең ул чактагы генераль директоры Ринат Галиев турында сөйләгәндә исә Фәниснең тавышлары ук үзгәреп китә иде. Үзенә һәм татар мәдәниятенә ихтирамлы, ярдәмчел булганы өчен генә дә түгел. Зыялы олут зат булганга да. Киләм дип әйтеп тә килмәгәне өчен (инфарктган соң бит бу!) телефоннан шалтыратып тагын кайсы олы түрә гафу үтенеп торыр иде икән?

Фәнискә игелекне укытучылар да эшли. Бу хакта үзе болай дип язды ул: «Янымa бик күп яшьләр килеп йөри. Житен һәм мех комбинатларыннан, төзелешләрдән һәм югары уку йортларыннан. Шуларның берсе Рушания Арсланова үзе дә шигырьләр яза... Рушания Казанның 18нче эшче-яшьләр мәктәбендә укып йөри. Көннәрдән бер көнне ул миңа мондый сорау бирде: «Фәнис, син укуыңны дәвам итәргә теләмисеңме?» Әлбәттә, минем теләк зур: надан килеш шигырь язып булмаячак... Мин Рушанияга: «Эш минем теләктән генә торса иде!» — дидем.

— Мин бу хакта үзебезнен мәктәп директоры белән сөйләшеп карыйм әле, — диде Рушания.

Директор исә хәзер «Тулгак», «Газзәбану» кебек үтә популяр әсәрләре белән меннәрчә укучыны әсир иткән Гөлчәчәк Галиева була. Ул бу үтә мәшәкатьле эшне хуплый, һәм педагоглар хастаханәгә килеп Фәнисне укыта башлыйлар. «Бу хөрмәтле

укытучылар үзләренең төп эшләреннән соң авырулар ыңгырашып яткан палатада дәрес бирәләр иде. Моның өчен аларга беркем бер тиен дә түләмәде», — дип язып калдырган. Фәнис үзенең «Алар һаман минем укытучыларым» дигән мәкаләсендә. Аның «Сез ин гүзәл кеше икәнсез» дигән җыры да асылда шуларга багышланган... Соңыннан ул нәкъ шул рәвешле университетның татар теле бүлеген дә тәмамлый әле.

«Фәнис белән мавыгып алу булды, аның турында нинди генә сокланулы мәкаләләр иҗат ителмәде. Соныннан үзебез, шул мәкаләләрне язучылар ук, аның көчлелегенә шулкадәр дәияләштек-күнектек ки, нинди генә исемнәр алуга да карамастан Фәниснең һаман да әле шул ук хәлдә икәнен, һәр яңа көнне иҗатта үткәрү аның өчен үзенә күрә бер җиңү, олы казаныш булуын онытып та җибәргәлибез бугай. Аратирә Фәнискә карата гамьсезлек, мәнсезлек, ә кайчакта хәтта ки таш бәгырьлелек күрсәтүебезне аңлап та житкермибез бугай», — ун ел элек шулай дип язганмын. Ә менә монысы Фәниснең үз сүзләре: «Мәрхәмәт ул кешегә ярдәмгә ашкыну, үзеңнең вакытыңны яки бик кирәк нәрсәңне корбан итү бәрабәренә башкаларга яхшылык эшләү... Ә мәрхәмәт, талант кебек, сирәк кешеләргә бирелә, күрәсең». Тикмәгә генә язмаган инде ул моны. Көндәлектә исемнәр теркәлгән урыннар да бар. Язучылар берлегенең кайбер житәкчеләренә үпкәсе аеруча зур аның.

*«Шагыйрь Гакыйль Сәгыйревнең 15 февральдә туган көне. Ул Димитровградта яши. Әнисе дә инсульт белән ята икән. Үзе хәзер элеккечә авызга ручка кабып та яза алмыйм ди. Гакыйль белән телефоннан бер ярты сәгатьләп сөйләштек. Союздан аңа шалтыратмаганнар, котламаганнар. Ә бит котлагыз дигән идем. Нинди дә булса матди ярдәм күрсәтү турында әйткән дә юк инде.»* (2004, 17 февраль.)

Чыннан да, язучыларга бөтенләй катышы булмаган кешеләр дә аларга игелек кылганда Язучылар берлегеннән шундый хәлдәге кешене телефоннан котлау кадәресе генә дә авыр микәнни соң инде?

*«Менә Гакыйль Сәгыйрев тә үлеп киткән. Ул нәкъ минем белән бер яшьтә иде... Ул да гомер буе урын өстендә ятып язды. Авызына карандаш кабып, үз китапларына үзе рәсем ясады. Шуңа Казаннан квартир да бирмәделәр» (2009, 8 август).*

Фәнис, көндәлеккә язуынча (2000, 25 ноябрь), Берлек рәисенә «Гакыйльне Казанга китерергә иде бит» дип мөрәҗәгать иткән булган һәм «Язучылар союзы инвалидлар йорты түгел, үзеннең монда килүенә сөен әле» дигән җавап алган.

*«Өченче көн Әдип Маликов үлгән. Минем беренче шигырьләрем республика матбугатында күренә башлагач ук ул минем иҗатымны хуплап, күңелемне дәртләндереп хат та язган иде. Элеккерәк буын язучылары татар әдәбиятына яңа кеше килүенә шатланганнар. Аларны үстерү өчен иҗатларын хуплаганнар. Хәзер кешеләрнең күңеле тарайды, көнчелек артты. Яхшырак әсәрең басылып чыкса, дус дигәнең дошманга әйләнә, мескен булсан гына, «башыңны тагын да түбәнрәк и», — дигән кебек, башыңнан сыйпап китәргә мөмкиннәр. Чөнки мескеннәр күбәйгән саен урта кул шигырь язучылар ца үзләрен бөекләр рәтенә кертә башлый.»* ( 2009, 26 апрель.)

*- Син хәзер көчле язучы, Фәнис. Кемнәрдер, бәлки, артыгын көчле дип тә карыйлардыр. Туры сүзле дә әле үзең. Кайберәүләргә, бәлки, әйбәт әсәрләр язмыйча, тешләк булмыйча, зәгыйфь булып урында ятуың әйбәтрәктер дә.*

*Нурсөя:* Фәнис син әйткәнчә ятса, күпләр шатланырые.

*- Кемнәрдер, әйе, Фәнискә көндәш итеп карый. Ә син үзең моңа ничек карыйсың, Фәнис?*

- Мин шушылай көнләшеп карауларына, хәтта үчләшеп карауларына да артык борчылмыйм. Кайчакта хәтта сөенеп тә куям. Бер мескен кеше генә булып ятсаң, дошманың да, дустың да булмаска мөмкин.

*- Кызганучылар гына булырга мөмкин.*

- Кызганып башыңнан сыйпап китүчеләр бар инде ул. Ә менә әз генә алар дәрәҗәсенә күтәрелсәң, моны бик гафу итәргә теләмиләр шул.

*- Ә менә үзеңнең язучыларга мөнәсәбәтең үзгәрдеме? Үзең өчен берәр төрле яңалык ачтыңмы?*

- Мин иҗат кешеләрен идеаллаштырыбрак караганмын. Язучылар арасында

кимчелекле кешеләр булырга тиеш түгел дип. Күбрәк аралаша торгач, кимчелексез адәм баласы юк икәнне аңлый башладым. Үзем дә бит менә һәркемгә тигез итеп, дөрес итеп кенә карый алмыйм, кемгәдер симпатиям бар, андыйларга ярдәм итәсен килеп тора. Ә кемдер килеп керү белән нигәдер ошамый. Ул сиңа укырга алып килгән әйбәт әсәрне дә «җүнле түгел!» дигән фикер белән укый башларга мөмкинсең. Шуңа күрә кемнәрнеңдер миңа карата әйбәт булмауларына исем дә китми... Исем дә китми дию дөрес ук түгелдер, һәрхәлдә, моңа аңлап карыйм дип әйтә алам. Мине нигә бөтен кеше дә яратырга тиеш ди әле, яратмаганнары да булсын. Кешеләрдәге кимчелекле эшне күрсәм, әйтик, кемдер вәгъдә иткәнен эшләмәсә, бу күпмедер вакыт минем күңелне тырнап йөри инде йөргән. Ләкин уйлыйм-уйлыйм да, әй, нигә миңа яхшылык эшләргә тиеш ди әле ул, дим. Миңа яхшылык эшләсә, шуның бәрабәренә аңа кемгәдер начарлык эшләргә кирәк булуы бар бит. Менә шулай үз-үзенне тынычландыра алу, кемнедер гафу итә, кичерә алу сөенеч тә бирә, үз күз алдында үзенне үстереп тә җибәрә инде ул.

*- Нурсөя, син менә Фәнискә нинди өметләр белән килдең инде? Кырык еллап гомер үтәр дә, Фәнис белән шулай бергә чөкердәшеп яшәрбез дип алга карап уйлаганың булдымы?*

- Юк инде, киләчәкне гел уйлый белмәгәнмен. Просто җәл иде ул. Минем егетем дә бар иде, между прочим. Фәнис белә. Фәнис янына да алып килгән идем әле мин аны. *(Көлә.)*

*- Әле сез сөйләгән кызлар кебек, шушы егеткә чыксам ничек була дип күрсәтергә түгелдер ич?*

- Юк, аңа Фәнисне күрсәтер өчен. Авыл хуҗалыгы институтын бетерә иде ул Фәнис янына килгәндә.

- Баянчы егет тә әле ул.

- Бик матур җырлыйдадыр ие.

*- Ай, Фәнис, шундый егеттән тартып алдыңмени әле син Нурсөяне?!*

*Нурсөя:* Шундый шәп итеп мораль укый иде әле ул егет миңа, ялгыш адым ясавымны, үкенәчәгемне шундый акыллы итеп исбатлап бирә иде. «Ул да кеше бит, ул да синең кебек яшь бит - һәм шушы хәлдә!» минем җавабым гел шул булды. Аннары үзе белеп тә житкермәгән кызга өйләнеп китте ул, Караганда ягынамы... Килгәч, Фәнисне ташлыйм дигән уй беркайчан да башыма кереп карамады. Ничек инде, аннан икенә дә хурлык була бит... Ну инде яшь вакытта, конечно, теңкәгә тиюче ир-атлар аз булмады. Хатын-кызга бәйләнәләр бит инде ул - кая барсаң да. Фәнискә: мин шундый юлдан китсәм, кырык яшьтә Тукай премиясен ала идең, дип тә әйткәнем булды.

*- Нурсөя, алар... язучы халкы идемени?!*

- Ул чакта минем бөтен аралашканым шул язучылар бит инде. Гади кешеләр арасында, элек үзем эшләгән җирдә, андый мөнәсәбәт булмады...

*- Бу бит... сиңа гына түгел, Фәнискә дә мөнәсәбәт...*

- Мин шуның белән бик нык интектем инде. Нык нервыга тияләр, рәнҗетәләр иде. Ну беркем дә әйтә алмас инде Фәнискә: мин шулай булдым синең хатының белән, дип - шул гына сөендерә. Гомер узган бит инде... Ул юлга кермәдем, шөкер. Без бит нинди тәрбия алган? «Береги платье снову, а честь смолоду» - абыйның ин яратып әйтә торган сүзе бу - балачактан ук. Ә хәзер ничек китте? Тегесе дә җәл түгел, бусы да.

*- Күпләргә күлмәк җәлрәк тә булырга мөмкин әле... Фәниснең холкы үзгәрдеме, Нурсөя?*

- Юк, үзгәрмәгәндер, Рәфикъ, шул ук тешләгән җиреннән өзә торган гадәте *(көлә.)* Фәнис усал ул! Әле бүген дә элэкте үземә!

*- Өйдә хуҗа булып яши инде, име?*

- Хуҗа! Еще менә болай итеп тота! *(Көлә, ике йодрыгын берьюлы төенләп күрсәтә).* Болай гына да түгел! *(Бер йодрыгын төенли)...* Үз гомеребездә беркайчан да бер-беребездән рәнҗеш сүзләре ишетмәдек. Бәлки, ул артыгын

сабыр булгангадыр инде. Аннан, мин, чыркылдык булсам да, тегендә-монда йөрмәдем бит, Рәфикъ, өйдә генә чыркылдап ятадыр ием.

- *Фәнис, ә менә син киләчәкне планлаштырган идеңме? Гаиләңнең киләчәген?*

- Үзем бик озак яшәмәм әле дип уйладым инде. Врачлар да бик тиз үләрсен дип вәгъдә итеп торгач *(икәүләшеп көләләр)*. Мәйтәм, өч ел булса да бәхетле яшәргә кирәк. Нурсөя миннән соң бүтән кешегә чыгар дидем. Чибәр кыз, мәйтәм, табар әле. Шулай дип кенә өйләнеп киткән идем. Аннан бер-береннән гадәтләрен, холкын белә башлыйсың бит инде, ияләшәсен. Әлбәттә, безнен дә гел ал да гөл генә булып тормады, ачуланышкан чаклар да булды.

- Ачуланышканны да кеше белмәде. Кешегә сөйләп кеше шатландырмыйк дидем.

- Нурсөянен бер бик әйбәт ягы шул: үзе бик тиз кызып китә торган булса да, мина карата сабыр ул... Мин йокыдан бик иртә торам. Менә бүген икедә тордым. Йоклый алмыйм чөнки. Язарга утырдым инде.

- Икедә түгел, икенче унбиш минутта! Өченче көнне дә шулай торды.

- *Ә син, Нурсөя?*

- Ул йокламагач, йоклап булмый инде. Аны бит борырга кирәк. Бер ягында кырык-кырык биш минуттан артык яммый ул. Юкса тәне тишелә башлый...

- Анын чисталыгы тагын! Нурсөя чиста тотмаса, мин инде күптән череп беткән була идем, бөтен җирем тишелеп-агып беткән була иде инде...

*«Бүген Нурсөянен туган көне. Иртәдән бирле пешеренә, ләкин пешергән ризыкларын үзебез атна буе ашарга туры килер. Безнен туган көннәрне кеше белми дә. Гомумән, Нурсөя үзен күрсәтергә, мактатырга яратмый. Телевидение килсә дә, берәр эш табып, күләгәдәрәк калырга тырыша.»* (2003, 20 октябрь.)

*«Нурсөя 18 августтан бирле больницада ята. Эчем бик авырта дип йөри иде. Практолог тикшергән. Авыр күтәрмәскә кушкан. Бөтен врачлар да аңа авыр күтәрмәскә куша. Ничек күтәрмәсен? Минем белән бергә бөтен дөньябызны ул күтәреп бара бит. Йөрәге, бөере, ашказаны, туры эчәге, веналары, кыскасы бөтен органы эштән чыккан инде анын.»* (2009, 25 август.)

Фәнисне 1932-34 елларда «Корыч ничек чыныкты» дигән автобиографик роман язган Николай Островскийнын тонык бер күләгәсе итеп кенә күрүчеләр дә бар. Ләкин «Татар Островские!» дип горурланып әйтү дә Фәнис Яруллинны түбәнәйтә төшү була әле ул. Чөнки күнел хөрлегенә ия Фәнисебез бернинди ялган идеологиягә дә хезмәт итмәде. Аннан, анын «батырлык вахтасы» да күп озаккарак сузылды бит (Островский 1936 елда, 32 яшендә дөнья куя).

Фәнис үзе исә бу хакта болай дип яза: *«Мине күп вакыт Николай Островский белән чагыштыралар. Ә бит безнен татар әдәбиятында Николай Островскийга каләрле үк Фатих Әмирхан булган. Анын таланты, минемчә, Н.Островскийныкыннан күпкә өстен һәм күпкырлы: 1. Нечкә юмор. 2. Әсәрләрендәге тормышчанлык. 3. Анын «Фәтхулла хәзрәт»е, «Гарәфә кич төшендә»ге алдан күрүчәнлеге безнен бүгенге көннәрдә расланмыймы?.. Нигәдер шунын белән чагыштырырга бер генә әдәбият белгеченен дә башына килми.»* (2001, 12 декабрь.)

Фәнисне шул ук Островский белән икенче яклатып чагыштырып карыйк әле. Фәнис Язучылар берлегенә хатыны Нурсөяне шәхси секретаре итеп рәсмиләштерик дип үтенеч яза. «Ул минем барлык язганнарымны машинкада баса, газета-журналлар, китаплар өчен әзерли», — ди. Болай дип тә өсти: «Мин акча да, башка нәрсә дә таләп итмим, бары тик анын эш стажы гына барсын иде». Үтенеч канәгатьләндерелми генә түгел, аңа хәтта җавап та бирелми. Нәтиҗәдә Нурсөянен пенсиясе Фәнис үлгәндә нибары 4090 сум була. Островскийга исә Сочида йорт салалар, персональ машина һәм шофер билгелиләр, махсус секретарь беркетәләр. Фәниснен бик тә, бик тә Татарстан язучылары съездларында катнашасы килә. Ләкин бу бер-ике тапкыр гына тәти аңа – мәшәкате артык зур тоела Берлек җитәкчеләренә. СССР язучыларынын беренче съезды алдыннан Островскийнын өендә рация урнаштыралар. Ул шуннан бөтен чыгышларны да тынлап ята һәм үзе дә чыгыш ясый әле.

Безнең замангарак күчсәк, ике кулсыз калган Украина шахтеры Владислав Титов каләмне авызына кабып хикәяләр яза башлый. Чит илгә җибәреп, аңа протезлар ясаталар, протез кул белән басарлык язу машинкасы, махсус телефон аппараты эшләтәләр, хатынын, акча түләп, үзенә секретарь итеп беркетәләр, язарына җим булсын өчен чит илләргә командировкаларга йөртәләр. Фәнискә исә гап-гади теләктәшлек кенә дә җитеп бетми. Бер язучы аңа хәтта мондый киңәш тә бирә әле: «Авыр булгач, нигә язасың, сиңа кем куша? Ят өеңдә тик кенә!»

Ләкин аның хәлендәгеләрнең сирәгенә тәтегән бик тә олы бүләк ала Фәнис. Бу — аның хатыны. Моны язмыш бүләге дип кенә әйтеп була микән? Фәнис мәктәптә укыганда ук кыю, үткен телле, кызларны иләсләндерерлек егет була инде.

*«Кичәдә бер кызык хәл булып алды: сәхнәгә залдан бер ханым күтәрелде дә, минем турыда сөйли башлады. Мин 9нчы класста, Фәнис 8нче класста укыган чакта без Кызылъярга кунакка барган идек, ди. Шунда Фәнис клубның ишегенә кулларын җәеп аркылы басты да, безне чыгармый, кайсыбызныдыр тотып каласы килә иде бугай, ди... Бик аккуратно киенеп йөри иде, ди.»* (2001, 29 сентябрь.)

Казанда хәлен белергә килгән кызлар өчен ул ярдәмгә мохтаҗ яшь шагыйрь генә түгел, чын ир-егет тә булган, күрәсең. Берничәсе әнә аның янында бөтенләйгә калырга теләүләрен дә әйтәләр әле.

*«Яшь, матур кызларны минем яратуым гадәти хәл инде ул, ләкин яшь кызларның мине яратулары гаҗәбрәк. Бу минем фантазиям тудырган фикер түгел. Алар яратуларын исбатлыйлар бит.»* (2000, 15 гыйнвар.)

Ләкин Фәнис аларны түгел, Нурсөяне сайлый. Ул үзе бу хакта болай дип яза: «Нурсөягә мин әкренләп гашыйк булдым. Күрәсең, аның тышкы матурлыгына караганда эчке сыйфатлары: күңеленең байлыгы, әйткән сүзенә, биргән вәгъдәсенә тугры булуы, тормышка, мәхәббәткә җиңел бер уен итеп кенә карамавы минем җанны әкренләп били баргандыр». Ләкин Фәнис сайлап кына эш бетми шул. Шуннан соң ниләр булганын мин әле бүген генә (ягъни 2013 елның 9 гыйнварында) Нурсөянең үзеннән сөйләттем.

— Фәнис янына килгәләп йөри идем инде. Бер-ике кич кунгалап та киткәли идем. Эшләре күп чакта эшләшеп. Университетта укый иде бит. Контроль эшләрен кәгазьгә яза алмыйдырие. Бөтенләйгә килергә куркыткандыр инде. Шуннан соң бик озак килми йөрдем мин. Общежитиегә әнисен җибәрде. Ияреп бардым инде. Аннан тагын килми тордым. Алар авылында пионервожатый булган Фәтхия исемле кыз бар иде, син беләсендер дә әле аны. Казанга килеп, укырга кергән иде ул — менә шул Фәтхияне җибәрә башлады мине чакырырга. Бер барам да, тагын килмим инде.

*— Туктале, Нурсөя, нигә килми башладың да, аннары нигә килдең? Сөйлә әле шәпләбрәк.*

— Нәрсәсен сөйлим ди инде аның. Шул кил дә кил, кал да кал, дигәч, калдым инде *(көлә)*. Гомер буе «талаштык» аннары, Рәфикъ, шуның өчен. Нигә киләм дип батыраеп торган кешене чакырмыйча, килмәгәнне мәҗбүрләп китерден, дим инде *(көлә)*. Киләм дигән белән әйбәтрәк яшәгән булыриең, дим. Ә ул, киләм дигән, бәлки, бер ел да тормыйча китеп барыр иде, ди.

*— Каты талашкансыз икән!*

— Авырлыклар күп булса да, матур яшәленелде үзе.

*«Акчаң булса бөтен нәрсәне хәл итеп була», — диләр кайбер танышлар. Ә туалет эшләрен, юындыру, перевязка ясауларны әйтә башласаң, акчаң да, үзең дә кирәкми дип кача башлыйлар. Нурсөянең больницада икәнен белсәләр, телефоннан хәлне дә сорашмыйлар. ...Язарга уйланган әйберләр дә язылмый. Нурсөянең кырыйда бөтерелеп йөрүе кирәк. Юкса мин язганда аны икенче якка чыгарып җибәрәм инде. Аның рухы кирәк икән барыбер...»* (2000, 29 август.)

*«Нурсөя больницада, ансыз өйдә яктылык, җылылык ким. Күңелдә бушлык. Югыйсә Сәүия* (Нурсөянең сеңлесе Минзәләнең кызы) *дә әйбәт карый. Яши-яши мәхәббәт, бәлки, бетәдер, ләкин кешеләрне бергә бәйләп торучы башка бик күп нәрсәләр бар. Без аларга әле атамалар да уйламаганбыз.»* (2009, 28 октябрь.)

*— Сәүиягә дә тиз ияләште бугай Фәнис. Сәүия бик яратып карашты бит сиңа Фәнисне.* (Сәүия хәзер Ветеринария академиясендә физика һәм математика укыта.)

— Әйе, алар бер-берсенә бик тиз ияләштеләр. Ярата иде Фәнис Сәүияне. Мин Сәүияне бераз гына ачулана башласам да, Фәнис шундук аны яклый иде: «Ярар инде сина! Житте инде сина!» Мәктәп тәмамлагач, 94нче ел бу, Сәүияне операциягә дип алып килгән идек бит без Казанга. Аягына операция ясатырга дип. Алты ай ятачак, ике операция ясарбыз, дигәннәр иде. Өч елга сузылды бу. 7 операция ясадылар. Фәнис белән Сәүиягә бер-берсен анларга, бәлки, шул да ярдәм иткәндер әле.

*— Сез икегез дә больницада яткандадыр инде бу, Фәнисне элек хәлен белергә килеп йөргән «кызлары» да караган бугай бит. Берәр, икешәр көн торып.*

— Булды инде. Кызылъярдан беренче мәхәббәте Надия дә ике тапкыр килде әле. «Жилкәннәр жилдә сынала»да Фәнис аны Фәүрия дип биргән.

...Ул үләр алдыннан мин больниста идем. Мин чыккачтын нәкъ ун көн торды. Белмәдек без анын үләсен. Берни әйтмәде, берни үзгәрмәде. Сәүия белән Айзиләне чакырткан иде, өч төн рәттән бездә кундылар. Айзиләбезгә ике яшь тә дүрт ай иде ул чакны. Фәнис Айзиләне бәби чактан ук диярлек өстенә утыртып, ана нидер сөйли торган иде. Аннан бергәләп китап та укый башладылар. Бу юлы да кичтән әкият китабын кулына тоттырып, «бабай, укы!» диде Айзилә. Фәнис көчәнеп бер-ике юл укый да, Айзилә икенче битне ача: «Бабай, укы!» Укый торгач, Фәниснен хәле начарланып китте.



*Иҗат бара!*

«Скорый» чакырдык. Мин тиле бит инде, ялганлый белмим, температурасы ничә, дигәч, 38,5 дидем. Килсен өчен кырык диярга кирәк икән. Тын ала алмый, йөрәге кыса иде бит, шуны кат-кат әйтергә кирәк булган инде. Ә болай безнен участокка гына тапшырганнар мин әйткәнне. 2 сәгать 40 минуттан килде врач. Аптырап карап-карап торды да, бик мескен тоелгандыр бу авыру, антибиотик язсам, йота алырсызмы, диде. «Я еще и вас проглочу!» диде Фәнис. Маржа көлде инде, «В таком состоянии еще можете шутить!» – диде. Врач киткәч, 11гә кадәр утырдык әле. «Ятыгыз, нигә мине саклап утырасыз», — диде шунда Фәнис. «Барыбер йокы килми бит», — дибез инде... «Мин йоклыйм, мина комачаулыйсыз», — ди бу. Сәүияләр чыгып яттылар инде. Мин еш-еш авыр сулаганын ишетеп янына килеп басам да, «Берни кирәкми!» — ди. Борып яткырдым инде төнлә. Иртәнге 6да тагын «Скорый» чакырдык, хәле бик начар иде. Фәнис гел үзенчә инде ул, тешен чистартмыйча дару эчми. Чистарттым инде. Даруны эчеп, су йотты да, шуннан сон әйткәнне дә анламый башлады. Алай да, «бор!» дигән Сәүиягә – врач карар өчен чалкан яткырган иде бит. Бик әкрен әйткән, мин ишетмәдем дә. Врачлар, шок, алып китәргә, больниска салырга кирәк, дигәч, Нурислам Нуримановичка шалтыраттым. Баулының элекке главасы бу. Хәзер «Россельхознадзор»да эшли. (Хәбипов турында Фәнис, 5 ел хакимият башлыгы булуга карамастан, кешелеклелеген җуймаган, дип язган, көндәлектә башка әйбәт сүзләре дә бар. – Р.Ю.) Ул 18нчегә шалтыраткан, без анда яткан идек, әйбәт больнис, Рөстәм Сәйфуллович, баш врач инде, врачлар җибәрер, диде. Ләкин тиз арада гомере өзелде шул Фәниснен. Ярый әле «Скорый»да тилмертеп йөртмәгәнбез. Анарчы Миннегөл апаны чакырган идек, ул, пульсын тоткан килеш, ясин чыкты.

*— Бу – Фәниснен бер документаль әсәренен герое бит инде, ятим баланы Америкага җибәреп, соныннан анын ничек яшәвен тикшереп кайткан кеше.*

— Әйе, шул. «Нурсөя, менә укып та бетердем, йөрәге дә типми башлады», — диде Миннегөл апа... Шулай итеп, китте дә барды инде менә. Тыныч кына . Йөзе дә үзгәрмәде, ничек яткан булса, шул көйгә эреде генә.

*«Тегендә» киткәндә дә үз өендә, караучыларын янда булганда әкрен генә китеп барсан иде ул...»* (2003, 20 гыйнвар. Әнгәмәдән.)

Бергә яшәүләренә 47 ел тулган була ул чакны...

— Ул һаман мин алданрак үләр дип курыкты. «Синнән калсам, мине өч көннән черетәләр. Кем генә караса да, мин өч көннән үләм», ди торган иде.

*— Йә, Фәнистән соң син ничек яшисең инде?*

— Яшәмим дә сыман. Җир белән күк арасында мин, Рәфикъ. Һаман әле аңыма кайтып җитә алмыйм, үзем дә шаккатам шуңа. Кырыгына чаклы бөтенләй ангыраеп йөрдем. Өйгә ашыгып кайтам да, күргәннәремне Фәнискә сөйләргә дип йөгереп керәм *(елый)*...

Айзилә дә бик сагына Фәнисне. Элек килеп керүгә «Бабай, привет!» ди торган иде (урысча белмәгәндә дә «привет» сүзен белә иде). Хәзер дә менә килеп керә дә, портреты янына басып, «Бабай, привет, мин килдем!» — ди. Йокламый бездә (елдан артык берьялгызы яшәсә дә, Нурсөя һаман шулай «без», «бездә» дип сөйли әле). Мин ныграк чирләгәндә әнисе бездә кунарга тели инде — юк! Бер тапкыр төнге 11дә такси чакырып кайтып киттеләр. Йокламый, үкерә инде, «Мин өйгә кайтам, монда бабай юк!» — ди...

*— Берәр үкенечле нәрсә калмадымы? Әйтелмәгән сүз, бергәләп эшлисе эш?*

— Калды шул. Фәнис бик матур җырлыйдырие. Борынгы җырларны. Моны Гөлчәчәк апа (Галиева) да белә иде. Бер туган көндә, тыңлап-тыңлап торды да, «Нигә яздырмыйсыз?» — диде. Булмады шул инде. Эшләп өлгермәдек... Үпкәләшсәк, мин ваннага кереп кер уарга тотына идем, кер беркайчан бетми инде ул бездә. Дөбер-шатыр су коям инде. Ә Фәнис җырлый. «Гөлҗамал»ларны, «Уел»ларны... 69 яшенә хәтле җырлый алды әле. Аннан күкрәге авыртып, тыны кысыла башлады инде...

Нурсөягә хәзер тынычлап яшисе, ял итәсе, көч-саулык җыясы кана. Фәнис алдында йөзе ак, тузан бөртеге кадәр генә дә гаебе юк бит аның. Күпме мәшәкать төште өстеннән. Йокыдан да икедә-өчтә торасы түгел. Юк инде, һаман шул газап эчендә яши. «Ул чын шәхес, гади кеше генә түгел. Берничек тә оныта да, тынычлана да алмыйм», — ди. Сәламәтлеге дә юк инде. Фәнис хакына ясатмый калдырган операциясе дә булган бит аның. Хәзер, үләр вакыт җиткәч, ясатып тормыйм инде, ди. Врачларга да күренә, больницада да ята, әмма файдасы тия микән соң — 220-230лы басым белән дә «Ничего страшного!» дип чыгара торган булгач (басымы болай 170-180 тирәсе, 160ка бик сирәк төшә икән)... Шунда янә Фәниснең бер сүзе искә килде инде. Авыруы көчәеп, Нурсөя аны «Больниска кер» дип бик кыстый башлагач, ул баш тарткан һәм: «Анда кешегә утын түмәренә караган кебек кенә карыйлар», — дигән.

Фәнис Яруллин 2011 елның 9 декабрендә дөнья куйды. Урыны җәннәттә булсын!..

Авылдагы сыйныфташларының берсе генә дә исән булмаган инде ул чакны.

Соңгы көненә кадәр егет булып, егетләрчә яшәде Фәнис!

Кемне җуйганыбызны аңлап җиткерәбез микән?

**Рәфикъ ЮНЫС**

**P.S.** Мәкалә инде язылып бетте дигәндә, ана соңгы нокта булып, Урал ягыннан менә шушы шигъри хат килеп төште.

## Нурсөя

**Иң шәфкатьле хатын–кызлар өчен**
**Билгеләсә орден Русия,**
**Әйтер идем: аңа лаек бүген**
**Татарстан кызы Нурсөя.**

**Һәйкәлне дә аңа куегыз, дип,**
**Исән чакта һәм чын алтыннан.**
**Языгыз, дип, зур хәрефләр белән:**
**— Сөембикәләрнең затыннан!**

**Нурислам АЙБУЛАТОВ.**
*Чиләбе өлкәсе, Чибәркүл шәһәре.*

*Әминә Бикчәнтәева (1913-1986) – узган гасырның икенче яртысында иҗат иткән күренекле балалар язучысы, чәчмә әсәрләрдән берничә повесте, мәзәк хикәяләре басылып чыкса да, ул нигездә балалар шагыйрәсе. Иҗатын билгеләгән төп китаплары – «Сайланма әсәрләр» (1963), «Минем танышларым» (1983).*

*Быел Әминә Бикчәнтәеваның тууына 100 ел тулды. Шул уңайдан аның балалар өчен язылган берничә шигырен тәкъдим итәбез.*

## Дәү әнием

**Әниемнең әнисе
Әбием була минем.
Әби генә түгел әле,
Ул минем дәү әнием,**

**Ак ефәктәй чәчләрен
Ул тарап куя үреп,
Чисталыкка өйрәнәм
Мин дә аңардан күреп.**

**Күзлексез күрмәсә дә,
Таяксыз йөрмәсә дә,
Җитмеш яше тулса да,
Бик картайган булса да,**

**Тәмле ашлар пешерә,
Матур гөлләр үстерә;
Өебезнең нуры ул,
Барыбыздан олы ул.**

**Мин бакчага киткәндә,
Озатып кала мине,
Кайтканда каршы ала,
Бигрәк тә әйбәт инде!**

**Кызыклы әкиятләр
Сөйли кичләрен безгә,
— Бәбкәм, — диеп иркәләп,
Эндәшә үзебезгә.**

**Җылы оек, бияләй
Бәйли безгә көз җиткәч;
Мин дә аңар бүләкләр
Алырмын үсеп җиткәч.**

**Өйдә аны һәммәбез
Яратабыз, сөябез:
— Син бик кадерле безгә,
Озак яшә, — диябез.**

## «Әйтмим» диеп әйтмәс идем

**Капка төбендә утыра
Кечкенә кыз Кәбирә,
— Кич булган ич, Кәбирә,— дим,—
Нигә кермисең өйгә?
Ә ул әйтә: «Әйтмим», ди.**

**Ни исемле соң курчагың,
Әйтче миңа, нәнием?
Исемең ничек, матур кызый,
Кем соң синең әниең?
Ә ул әйтә: «Әйтмим», ди.**

Курчагыңның исеме ничек?
Аны яратасыңмы?
Әлли-бәлли итеп аны,
Җырлап йоклатасыңмы?
Ә ул әйтә: «Әйтмим», ди.

Иртәгесен мин бу кызның
Янына да килмәдем.
Башыннан да сыйпамадым,
«Әйт әле» дә димәдем.

Әй, күңелсез Кәбирәгә,
Беркем килми янына,
— «Әйтмим» диеп әйтмәс идем,
Сорагыз,—дип ялына.

«Әйт әле» дип әйтегез,— ди,—
Хәзер барысын әйтәм,— ди,—
Кире булмам инде бер дә
«Әйтмим» диеп әйтмәм,— ди.

— Кичә кире булганыма
Бүген бик үкенәм,— ди,—
Белгәнемне әйтмәгәнгә,
Мин гафу үтенәм,— ди.

## Һаман яз була

Салкын саф һава,
Йомшак кар ява.
Урамга чыксаң,
Битләр кызара.

Кар бөртекләре
Өстеңә куна,
Үзләре матур
Һәм салкын була.

Кояш нурларын
Бик аз сипсә дә,
Кошлар еракка
Очып китсә дә;

Йөрәкләр безнең
Һаман шат була,
Безнең йөрәктә
Һаман яз була.

*Хәкимҗан Халиков (1933-2002) – балалар язучысы, шагыйрь. Озак еллар балалар матбугатында эшләгән журналист. «Йолдызлар ничәү?», «Шук бабай», «Иң гадел дус» һәм башка күпсанлы китаплар авторы. Әлеге шигырьләре туууына 80 ел тулу уңаеннан бирелә.*

## Карамыйм

**Сез ничектер, мин хәзер**
**Телевизор карамыйм.**
**Дәү әни дә: – Сүндер, – ди, –**
**Йөрәгемә ярамый.**

**Анда хәзер бары тик**
**Гел үтереш, гел суеш.**
**Җир йөзендә бервакыт**
**Бетәр микән бу сугыш?**

**Без яраткан кинолар,**
**Белмим, кая киттеләр?**
**Алыштырды аларны**
**Коточарлык мультиләр.**

**Чит илләрнең чүпләрен**
**Күккә чөеп мактыйлар.**
**Күзләрен дә йоммыйча,**
**Кап-караны ак, диләр.**

**Телевизор белән мин**
**Шуңа күрә хушлаштым.**
**Дәү әни дә сөенде:**
**Китап белән дуслаштым.**

## Сәгатьле Сәгыйть

**Сәгате бар Сәгыйтьнең.**
**Әллә яңа булганга,**
**Бер дәрестә йөз тапкыр**
**Карап ала ул аңа.**

**Укытучы: – Биш бишең,**
**Яле, ничә була? – ди.**
**Сәгыйть торып басуга:**
**– Тиздән унбер тула, – ди...**

**Нинди шау-шу?! Сәгате**
**Йөри ласа келт-келт-келт,**
**Тик класска кушылып**
**Көлгән кебек кет-кет-кет...**

Сәгать куеп каршына
Ашый Сәгыйть ашын да.
Хәзер аның сәгате
Кулда түгел — башында.

## Әбүгалисина

Галигә мин бик еш кына
Карап торам шаккатып.
Укытучы сорау бирсә,
Җавап бирә чатнатып.

Нинди авыр теманы да
Шундый җиңел аңлата.
Сөйләгәндә барыбызны
Авызына карата.

Мәсьәләләр чишешә ул
Хәтта абыйсына да.
Шуңа аны охшатам мин
Әбүгалисинага.

## Белем иле

Белем иле кайчак миңа
Никтер серле урман кебек.
Ә юллары кызыктырып,
Гел чакырып торган кебек.

Уңдагысы: «Укытучы
Булыйм дисәң әткәң кебек,
Энем, менә шушы юлдан
Кит син», — диеп әйткән кебек.

Сулдагысы: «Иген ик син,
Игенче бул», — дигән кебек.
Өченчесе ни өчендер
Бүтән киңәш биргән кебек.

Сукмакларын әйткән дә юк:
Мең тармаклы имән кебек.
Тик нигәдер бу илдә мин
Һич адашып йөрмәм кебек.

Укытучы дәрес бирә,
Тормышка юл салган кебек.
Әллә шуңа дөнья миңа
Гел яктыра барган кебек.

## Риза Шәфинең тууына 90 ел

Риза Шәфи (Риза Закир улы Шәфиев) 1923 елның 20 февралендә Башкортстанның Кыйгы районы Үрге Кыйгы авылында дөньяга килә. Урта мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты факультетына укырга керә. Әмма өмет-хыялларын дәһшәтле сугыш өзә. 1941 елның 22 июненнән үк ул — Ульяновскидагы хәрби училище курсанты. Соңыннан хәрби академия тәмамлый. Хәрби инженер буларак хезмәтен дә ижади эштә: фәнни-тикшеренү институтында башлап җибәрә. Алга таба да аны хәрби техниканың ин яна төрләрен булдыру, куплап җитештерү белән шөгыльләнгән фәнни оешмалар, заводларга тәгаенлиләр. Куәтле ракеталарны булдыру хезмәтенә дә ул беренчеләрдән булып билгеләнә. Хәрби хезмәткә утыз ел гомерен бирә. Аның бертуган абыйсы Исмәгыйль Шәфиев әле сугышка кадәр үк танылып килүче шагыйрь була, әмма ул яу кырында ятып кала.

Хәрби хезмәттән киткәч кенә, ана балачак хыялларын тормышка ашырырга мөмкинлек ачыла. Казан, Уфа, Ижау шәһәрләрендә бер-бер артлы шигъри әсәрләре, мәкаләләре, китаплары басылып чыга. Ул елдан-елга шигъри иҗат камиллеген үстерә.

Укучыларына лирик шигырьләрен, юмор-сатира үрнәкләрен, әйтем-мәкальләргә тартым икеюллыкларын һәм хикмәтле сүзләрен, милләтебезнең узганнары белән горурланып, бүгенгебез, киләчәгебез өчен хафаланып язган әсәрләрен бүләк итә.

*Чал тарихның текә түрендә*
*Безнең эз – безнең дан күренә.*
*Гасырлар дәлилләр без барын –*
*Илаһи кавем син – Татарым!*

— дип яза шагыйрь.

«Шагыйрьнең гаять зур иҗатының әле бер өлеше генә киң катлам җәмәгатьчелеккә мәгълүм. Безнең бурыч — аларны туплап тирәнтен өйрәнү, халык игътибарына ирештерү. Риза абыйның бай иҗаты, гомер юлы еллар кысасына гына сыя алмый. Ә бит чын каләм әһелләренең гомере халык хәтере белән исәпләнә.

«Янарыш» газетасы каршында әдәби түгәрәк оештыру өчен дә күп көч куйды шагыйрь, кинәшләрен бирде, хаталар китсә, кычытканын кыстырып килеп тә җитә иде. Какмас-чакмас, юмор-көлке белән үз фикерен җиткерми дә калмас.

Без хәзер әдәби түгәрәгебезне «Риза Шәфи исемендәге әдәби-иҗат берләшмәсе» дип атыйбыз. Бу исә остазыбызның исемен мәңгеләштерүгә юнәлтелгән бер адымыбыз. Тагын шуны да әйтергә кирәк: туры сүзле, милләтпәрвәр шагыйребезнең исеме безгә Казан, Чаллы, Әлмәт ишекләрен узарга ярдәм итүче ачкыч та. Чөнки Риза абыйны һәр җирдә беләләр. Аны олылап искә алалар.

Берләшмә утырышында Риза Шәфи исемендәге премия булдыру турында да килештек. Бу чара Удмуртия мәдәният министрлыгы һәм Удмуртия Язучылар берлегендә яклау тапты. Ул премия шигърият, проза һәм публицистик язмалар авторларына, ин лаеклыларга тапшырыла», — ди бүгенге көндә Удмуртия Язучылар берлегенең татар телле язучылар бүлеге җитәкчесе булып эшләүче шагыйрь Ринат Батталов.

Риза Шәфи 2001 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы иде. 2004 елның 3 декабрендә Воткински шәһәрендә вафат булды.




Язучылар җыелышыннан бер күренеш. Беренче рәттә (сулдан уңга) — Рафаэль Мостафин, Фатих Хөсни, Әхмәт Исхак; икенче рәттә — Нил Юзиев, Аяз Гыйләҗев, Шәүкәт Галиев. Үткән гасырның 80 нче еллары.



Язучы Фәйзуллин Заһит Батыр улы (Заһит Фәйзи).



Замандашлар, яшьтәшләр. Драматург Туфан Миңнуллин һәм партия-дәүләт эшлеклесе Рәис Беляев. 1985 ел.



*Шәүкәт Галиев һәм Ринат Мәннан. 2009 ел.*



*Галим, язучы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Хуҗиәхмәт Шакиәхмәт улы Мәхмүтов. 2003 ел.*



*Чаллы дәүләт театрының баш режиссеры Фаил Ибраһимов.*

## КЫЗЛАРЫБЫЗНЫҢ ТАРИХИ ҖИҢҮЕ

Күп миллионлаган тамашачы караган «Беренче канал»ның «Голос» телепроектында татар кызлары Динә Гарипова белән Эльмира Кәлимуллина Россиянең иң яхшы җырчылары булып танылды.

Динә — Яшел Үзән, Эльмира — Түбән Кама районы кызы. Динә журналист булырга хыяллана, Эльмира Казан дәүләт консерваториясендә музыкаль белем ала.

«Эльмира Кәлимуллинаның Бөтенроссия «Голос» телевизион бәйгесенең финалына чыгуы, ә Динә Гарипованың анда җиңү яулавы Татарстандагы иҗади потенциалның гаҗәеп чагылышы булды».

Казан Кремлендә әлеге конкурс җиңүчеләре белән очрашуда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов шулай дип белдерде. Президент Динә белән Эльмираның әти-әниләренә, укытучыларына, шулай ук кызларның проекттагы остазлары Пелагея белән Александр Градский адресына рәхмәт ирештерде.

Динә Гарипова, үз чиратында, Президентка әлеге очрашу һәм җиңүдән соң юллаган котлаулар өчен рәхмәт белдерде. «Атказанган артист исемен алу — зур мәртәбә. Алга таба да без бу дәрәҗәне саклап, әлеге исемгә лаеклы булырга тырышачакбыз», — дип вәгъдә бирде җырчы. Эльмира Кәлимуллина Бөтенроссия телевизион проектындагы уңышның үзен һәм Динәне Росссиянең иҗат мәйданында Татарстан илчеләре итүен, моның зур җаваплылык булуын әйтте.

Очрашуда кызлар алдагы планнары турында да сөйләде. Алар икесе дә музыка өлкәсендә белемнәрен камилләштерергә уйлыйлар. Рөстәм Миңнеханов кызларга алга таба карьераларын дәвам итү өчен кирәкле ярдәм күрсәтеләчәгенә ышандырды. Очрашу соңында Президент Динә белән Эльмирага фатир сертификатлары тапшырды.

## ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ МОХИТНЕ САКЛАУ ЕЛЫ

2013 ел — Татарстан Республикасында Экологик культура һәм әйләнә-тирә мохитне саклау елы.

Бу хакта ТР Президенты Рөстәм Миңнехановның Указы бар. Агымдагы ел тулаем Россия Федерациясендә Экологик культура һәм әйләнә-тирә мохитне саклау елы буларак уздырылачак — бу турыда РФ Президенты Владимир Путин 10 августта махсус Указ имзалаган иде. Ел чарасының төп максаты — һәрбер кешенең әйләнә-тирә мохиткә хокукын тәэмин итү, җәмгыятьнең игътибарын әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләренә юнәлтү, халыкның экологик культуралылыгын формалаштыру һәм арттыру, диелә әлеге документларда. Искәртеп үтәбез: былтыр 6 апрельдә Астанада, гомумән, 2013 елны барлык БДБ илләрендә Экологик культура һәм әйләнә-тирә мохитне саклау елы итү турында килешенгән иде. Ул елны нинди чаралар уздыру планы һәрбер илнең үзенеке — анысы һәр ил-субъектның Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе белән расланып тормышка ашырылачак, шул исәптән Татарстанда да.

## МӘҢГЕЛЕК ХӘЗИНӘЛӘР

Татарстан Милли музеенда «Сокровища Республики Татарстан» альбомын тәкъдир итү булды. Анда республикабызның Дәүләт Киңәшчесе М. Шәймиев һәм ТАИФ компанияләр төркеме генераль директоры А. Шиһабетдинов катнашты. Альбом Татарстан Президенты Р. Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе М. Шәймиев һәм ТАИФ химаясендә чыгарылган.

Бүгенге көндә 1 миллионга якын экспонаты булган Татарстан Милли музее Россиядә иң зурлардан санала. Музей тупламасы нигезендә нәшер ителгән әлеге альбом исә чын мәгънәсендә республикабызның горурлыгы булырлык.

Альбомны 2003 елда Милли музейның хәзерге генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипова җитәкчелегендә эшли башлыйлар. Ул татар, рус һәм инглиз телләрендә язылган. Тиражы - 2,5 мең данә. Альбомда 2,5 мең рәсем бар. Аларда татар, удмурт, башкорт, мари, мордва, чуаш һ.б. халыкларның сәнгате чагылыш тапкан. Анда Борынгы Болгарда табылган археологик ядкәрләр дә, Мисыр цивилизациясе табылдыклары да, 1509 елда беренчеләрдән булып дөнья күргән Коръән дә, XVIII ахыры — XIX гасыр башына караган кульязма Коръән дә, беренче татар китаплары да, каһарман-шагыйрь Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» дә, Идел Болгарстаны чорыннан ук билгеле милли музыка уен кораллары һ.б. экспонатларның да рәсемнәре бар.

## ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ ЖЫР ҺӘМ БИЮ АНСАМБЛЕ ОЕШУГА 75 ЕЛ

17-18 декабрь көннәрендә М.Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрында Халыклар дуслыгы ордены иясе Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле оешуга 75 ел тулу уңаеннан юбилей концертлары булды. Концертның беренче бүлегендә яшь композитор Радик Сәлимов иҗат иткән «Җиде энҗе» этномюзиклы, ә икенче өлештә ансамбльнең алтын фондына кергән җыр һәм биюләр тәкъдим ителде. Тамашачылар Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең халкыбызның бай мирасын саклап калу һәм аны киләчәк буынга җиткерүдә бәһалап бетергесез хезмәт башкаруына янә бер кат инанды.

## ЯҢА ТАТАР ПЬЕСАСЫ – 2012

22 декабрь көнне Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында тугызынчы мәртәбә «Яңа татар пьесасы» конкурсы җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы булды. Тәкъдим ителгән 53 пьесаның 16сы икенче турга үткән, шуларның сигезе призлы урынга чыккан. Беренче урын «Әрем исе» пьесасы авторы Илгиз Зәйнигә, икенче урын «Җеңле күл» пьесасы өчен Зөлфәт Хәкимгә бирелде. Ә өченче урынга «Авыр туфрагын җиңел булсын» дигән пьесасы өчен шулай ук Илгиз Зәйни лаек булды. Мәдәният министрлыгы әзерләгән махсус бүләк «Приют» әсәре өчен Ркаил Зәйдуллага тапшырылды. «Җәмгыять һәм яшьләр» номинациясендә Айгөл Әхмәтгалиеваның «Бәхет агачы» пьесасы иң яхшы әсәре буларак танылды. «Балалар һәм яшүсмерләр өчен» номинациясендә И.Зәйнинең «Кәҗә, Сарык һәм башкалар» әсәре югары бәяләнде. Ә кызыксындыру бүләкләре «Ширзәт белән Гөлшәд» пьесасын иҗат иткән Гүзәлия Тархановага, «Күзләр» әсәренең авторы Марат Кәбировка бирелде.

## БӘЙРӘМГӘ ӘВЕРЕЛГӘН МИЗГЕЛ

Аерым китапка багышланган тантаналар сирәк хәзер. Шул сирәк бәйрәмнәрнең берсе «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы саналган «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы»ның басу цехында уздырылды. Бу көнне биредә Татарстанның халык шагыйре, күренекле җәмәгать эшлеклесе Равил Фәйзуллинның «Мәңгелек мизгел. Вечность мгновения» дип исемләнгән өр-яңа җыентыгы дөнья күрде. Полиграфик яктан затлы итеп эшләнгән әлеге саллы китапта авторның дүртьюллыклары, сигезьюллыклары һәм төрле күләмдәге шигырьләре урын алган. Аларны русчага танылган шагыйрьләр тәрҗемә иткән. Ике телдә нәшер ителгән бу мәҗмугада кереш сүз, автор турында белешмә һәм шагыйрьнең басылып чыккан китаплары исемлеге дә бирелгән.

Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Ирек Миңнәхмәтовның әле генә конвейердан төшкән, типография буяулары исе аңкып торган яңа китапны аның авторы Равил Фәйзуллинга тапшырды. Ирек Җәүдәт улы үзенең котлау сүзендә инде берничә буынның Равил Фәйзуллин әсәрләре белән тәрбияләнеп үсүен, мондый дәрәҗәдәге әдипләрнең һәрбер кылган зур гамәле вакыйгага әверелүен билгеләп үтте, авторның моңарчы дөнья күргән 50дән артык китабына яңалары өстәлеп торуына ышаныч белдерде, шагыйрьгә олуг юбилее елында бәрәкәтле иҗат уңышлары теләде.

Яңа китап басылып чыгу тантанасында «ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры киңәшчесе, ТР Дәүләт Советы депутаты Ислам Әхмәтҗанов, Татарстан китап нәшрияте директоры Дамир Шакиров, «ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» директоры Ришат Хәсәнов, кайбер газет-журналларның баш мөхәррирләре, язучылар, журналистлар катнашты.

## АЛЬБИНА ЯУЛАГАН ҮРЛӘР

Яңа ел бәйрәменә Казаныбызга Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, опера җырчысы Альбина Шаһиморатова кайтып китте. «Үткән ел минем өчен» «Алтын битлек» фестивале кысаларында Россиянең Зур театрында үзебезнең театрның «Лючия ди Ламмермур» операсында төп партияне җырлавым, шуның өчен «Иң шәп хатын-кыз роле» төрендә бүләкләнүем, Сан-Франциско опера театрында «Волшебная флейта» һәм «Риголетто» опералрында дебютым, Россия тәнкыйтьчеләренең иң шәп җырчыга тәгаенләнгән призы – Costa Diva статуэткасы белән бүләкләнүем һәм, әлбәттә инде, Зур театрда «Травиата» операсында Виолетта партиясен башкарып, 2012-2013 елгы иҗат сезонын ачуым белән истәлекле булды», – диде җырчы. 2012 елга нәтиҗә ясап.

2013 елда исә А.Шаһиморатова АКШның Чикаго Лирик Операсында һәм Лондонның Ковент Гарденында беренче тапкыр җырларга ниятләп тора

## КАМАЛЛЫЛАР МӘСКӘҮДӘ

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының Мәскәүдәге гастрольләре зур уңыш белән үтте. Алар быел башкаланың Кече театрында «Мулла» (Т.Миңнуллин), «Кичтүкле уен» (И.Зәйниев), «Йөзек кашы» (Ф.Хөсни), «Хан кызы Турандык» (К.Гоцци), «Ут күршеләр» (С.Юзеев) спектакльләрен күрсәтте. Һәр спектакль зур аншлаг белән узды.

Камал театрының тамашачылар даирәсе елдан-ел киңәя бара. Берничә ел элек театр Бөекбританиягә гастрольгә барган иде, үткән ел алар Кытайда булып кайттылар. Быелгы елда да чит төбәкләргә гастрольгә чыгу күздә тотыла.

### МАМАДЫШТА ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Шәйхи Маннурның туган көне унаеннан үткәрелгән Кышкы шигырь бәйрәме Мамадышта һәм Тулбай авылында үткәрелде.

Традиция буенча быел да әдипнең туган көнендә күпсанлы кунаклар җыелды. Алар — Казаннан — Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан, Ш.Маннурның мирас комиссиясе рәисе Шаһинур Мостафин, КФУ профессоры, җырчы Мингол Галиев, Чаллы язучылар оешмасы җитәкчесе Вахит Имамов, «Мәйдан» журналының җаваплы сәркәтибе Фидаил Мәҗитов, Ижевскидан — Удмуртия Язучылар берлегенең татар телле язучылар бүлеге җитәкчесе Ринат Батталов, шагыйрь Ибраһим Биектаулы һ.б. Мамадышта аларга җирле шагыйрьләр һәм язучылар, башка кунаклар кушылды.

Шигырь бәйрәме әдипнең Мамадыш үзәгендәге һәйкәле янында башланып китте. Митингка шәһәр мәктәпләре укучылары, хезмәт коллективлары вәкилләре байтак җыелган иде...

Аннан соң тантана Мамадыштан Тулбайга күчте. Анда әдипнең каберe зыярәт кылынды, чәчәкләр салынды. Авыл Мәдәният йортындагы кичәгә якташлары шагыйрьнең «Каз көтүче малай» әкиятен махсус сәхнәләштергән иде. Шунда ук Ш.Маннур исемендәге премиянең яңа лауреатлары игълан ителде. Быел ул «Җырлы чишмә» китабы өчен Җәлил бистәсендә яшәүче Рухия Ахунҗановага, «Гомер учагы» китабы өчен Ринат Батталовка, «Бүләк» китабы өчен Түбән Кама шәһәрендә гомер кичерүче Нурзия Мирхазовага, «Тормыш дәрьясын кичкәндә...» китабы өчен Равил Мостафинга бирелде.

### ЯШЬЛӘР ТЕАТРЫНДА ЯҢА ҖИТӘКЧЕ

Г.Кариев исемендәге Казан дәүләт яшь тамашачы театрына яңа директор билгеләнде. Ул — Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Ярмиев Мансур Зиннур улы. М.Ярмиев 1964 елда Саба районының Явлаштау авылында туган, Казан дәүләт педагогика институтының музыка факультетында белем алган. Икътисад фәннәре кандидаты. Моңа кадәр ул «Татарстан» телерадиокомпаниясендә эшләгән.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Россия Президенты Владимир Путин Указы белән, Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль хезмәтнең ТР буенча идарәсе җитәкчесе **Айрат Ринат улы Зарипов** Дуслык ордены белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык иҗади эшчәнлеге, татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен Түбән Кама шәһәре һәм районының «Кама таңнары» җирле иҗтимагый әдәби оешмасы җитәкчесе **Абдуллин Фәтхулла Абдулла улына** «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, Татарстан Республикасында геральдиканы булдыруга һәм үстерүгә шәхси өлеш керткәне өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең «Гасырлар авазы - Эхо веков» фәнни-документаль журналы баш мөхәррире **Шәрәфетдинов Дамир Рәүф улына** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелде.

27 декабрьдә танылган язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Державин исемендәге премия лауреаты, минералогия фәннәре кандидаты **Владимир Владимирович КОРЧАГИН** 89нчы яшендә вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Фәнис белән Нурсөя». Зөфәр Гыймаев рәсеме.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрә **Гөлзадә Бәйрәмова**.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



16 гыйнварда Адлер Тимергалин дөнья куйды. Бу — милли яшәешебездә җуелмас эз калдырган язучы-прозаик, тел һәм мәдәният тарихы белгече.

Адлер Камил улы 1931 елны Сарман районының Иске Минзәләбаш авылында туа. Күнел күзе күккә төбәлгән үсмер, мәктәп тәмамлагач, Казан университетының астрономия бүлегенә укырга керә. Ләкин гаделлек, дөреслек сөючәнлеге аны җирдәге хәтәр хәлләргә, сәяси көрәшкә тартып кертә. 2нче курс студенты совет хакимиятенең халыкка каршы сәясәтен фаш иткән листовкалар язганы һәм аларны таратканы өчен кулга алына. Листовкаларда «халыклар атасы» Сталин да аяусыз гаепләнә, аларның күбесе «Смерть Сталину!» дигән оран белән тәмамланган. Мондый тәвәккәл диссидентлар бөтен совет мәмләкәтендә дә бик-бик аз булган.

Адлер ага төрмә камераларында да үзен фидакарьләрчә тота. Ул кичергән хәлләр аның белән үткәрелгән һәм журналыбызда басылган әңгәмәдә («Шомалыкны, шомаларны сөймим». 2011, №2) бәян ителде... Әдип 1997 елны гына реабилитацияләнгән.

Иреккә чыккач, Казан университетына кире алмыйлар инде, укуын Ташкент Укытучылар институтында дәвам итәргә мәҗбүр була ул. Аннан, 1953-55 елларда Минзәләбаш мәктәбендә физика һәм математика укыта, Казан Пионерлар йортында фән-техника түгәрәге җитәкчесе булып та эшләп ала.

А.Тимергалин фәнни-фантастик жанрда иң күп эшләгән, дистәдән артык китап һәм җыентык чыгарган әдип (бу — «Пәһлеван каберe», «Ерак планетада», «Адашкан йолдыз», «Кайтыр юллар» һ.б.).

Адлер Камил улы озак еллар буена (1957-70 һәм 1979-90 еллар) Татарстан китап нәшриятында мөхәррирлек итеп, татар терминологиясен үстерүгә, сүзлекләр нәшер итүгә гаять зур көч салды.

Адлер аганың күп кенә хезмәтләре «Казан утлары»нда басылды. «Миллият сүзлеге» исә 2004-2007 елларда һәр сан саен бирел барылды. 2007 елда ул китап булып та басылып чыкты. Бер өлеше генә дөнья күргән бу уникаль әсәр тиешле бәһасен алып җиткермәде әле.

1 гыйнварда туган әдип 2 гыйнварда кулга алына, үлеме дә шул айда булды...

Туры сүзле, горур бу әдипнең, гыйлем иясенең тормышы бүген дә киләчәк буыннарга да үрнәк булырлык.

**«Казан утлары» журналының редакция коллективы.**



Гөлзадә Бәйрәмова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)